# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*


## Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Зиннур МАНСУРОВ. Каршылыклы хисләр карулаша... *Шигырьләр.* ........3
Рафис КОРБАН. Артык кешеләр. *Роман-эссе.* ........9
Дания НӘГЫЙМ. Меңәр җанның өермәсе миндә... *Шигырьләр.* ........75
Зиннур ТИМЕРГАЛИЕВ. Мәңгелек хәрәкәт. *Повесть.* ........80
Рәсимә ГАРИФУЛЛИНА. Шул исемне аклап, атлап киләм... *Шигырьләр.* ........108
Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Төерле пылау. *Хикәя.* ........113

ЯҢА ИСЕМНӘР

Зөһрә РАМАЗАНОВА. Көн саен дежавю... *Шигырьләр.*
*(Ф.Гыйләҗевнең кереш сүзе белән).* ........125

«СЕЗ ИҢ ГҮЗӘЛ КЕШЕ ИКӘНСЕЗ!» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Сания ӘХМӘТҖАНОВА. Сабыр сөю сагышы. *Повесть.* ........128

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Әминә ГАЗАЕВА. Йөрәгем яктыра күңелле уйлардан. *Шигырьләр.*
*(Балкарчадан Р.Корбан тәрҗемәләре.)* ........147

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Фоат ГАЛИМУЛЛИН. Әдәбият фәне аксакалы *(Тәлгат Галиуллинга 85 яшь).* ........149

ПУБЛИЦИСТИКА

Рухия АХУНҖАНОВА. Сөббух Рәфыйков ядкяре. *Документаль бәян.* ........155

ФӘН

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Татар тамырларыннан үскән җете гөлләр. ........173
*Фотоархив:* Марс Шабаевның тууына – 90 ел. ........178

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ләйлә ДӘҮЛӘТШИНА. Татар халкының рухи мирасын барлау. ........180

ХӘТЕР

Әнвәр СӨЛӘЙМАНОВ. «Сагышлы моңнар» иясе Рәшит ага, яки ул гаиләдә һәммәсе шагыйрь *(Журналист, шагыйрь Рәшит Гатауллинның тууына – 85 ел).* ........185

ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР

Каләмендә аның – атом көче *(Зәки Зәйнуллинның тууына – 90 ел).* ........188
Тормышта да, сәхнәдә дә затлы булды *(Эмиль Җәләлетдиновның тууына – 90 ел).*
*Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара.* ........189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ........190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 7 (1209) 2023*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмахананең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---


Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.06.2023, график буенча 29.06.2023, басылып чыгу вакыты 05.07.2023
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^1/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-1633. Тираж 5459.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.

12+

© «Казан утлары», 2023 ел



Зиннур
Мансуров

# КАРШЫЛЫКЛЫ ХИСЛӘР КАРУЛАША...

## Гарьле елмаю

Кайчак акыл шактый сәер хәлнең
мәгънәсенә бик тиз төшенә.
...Искәрмәстән Амур юлбарысы
керде бүген таңгы төшемә.

Тарлаудагы ерткыч тирәсендә
дәүләт түрәләре гәпләшә.
Бәгырьдәге зур-зур борчуларны
ачык күрәм ошбу гамь аша.

Соңы мәгълүм инде, ирек бирсәң
мылтыктагы утлы чакмага.
Нинди асыл токым корый, диеп
рәсми даирәләр чаң кага.

Хәтта хаким тынгы таба алмый,
шундый җанвар кимеп барганда.
Әлмисактан бирле кадерләүгә
даим исәп тота бар җан да.

Иркәлектә, әнә, иркенәеп
яши хәзер безнең дәү мәче.
Кайгыртучан илнең хөкүмәте
көтә аннан ишле дәвамчы...

Каршылыклы хисләр карулашты,
йөгреп узды тәннән ят кан да.
Назда йөзә, бакчы, кыргый мәхлук
газиз телләр үлеп ятканда.

Зиннур МАНСУРОВ (1949) – *Татарстанның халык шагыйре, публицист, җәмәгать эшлеклесе; «Йөз суы», «Җәрәхәтле йөрәк җылырак», «Дөреслек икегә төрләнмәс», «Тукай белән әңгәмәләр» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Мәмләкәтнең бәгъзе милләтләрен
кемдер таркатканда өлешләп,
олылыклы заттай юлбарысны
үстерәбез яшьтән өф-өфләп.

Оҗмах кошы кебек рәхәт чигә,
тәмле сүзләр ява як-яктан...
Күпсенүдән түгел күрсенүем –
барчабызны Аллаһ яралткан.

Язык тулы җирдә булып тора
монафикъча гамәл кылу да;
иблис ымы өскә калкып чыга
һәрбер каһкаһәле көлүдә.

Өмет белән карыйм алгы көнгә,
уйландырсын төшнең ахыры.
...Читтән генә күзләп, гарьле килеш
елмаерга базды Ак бүре.

## Ике яклы чынлык

Җирдә һаман артып тора кыек юллар,
ишәядер ялгыштырган адым да.
Адәм заты гаеп гамәл кыла икән,
җавап бирер кырыс хөкем алдында.

Байтак илләр бергә-бергә золым иткәч,
әһле дөнья ничек кенә яшь йотмый.
Әмма алар гадел җәза алыр өчен
халыкара трибуналга ашыкмый...

## Уйга батырган бәхет

Телдәр затлар шундый оста итеп
яңа бәхет тели халыкка.
Күпме купшы сүзнең бары берсе
туры килсә икән хаклыкка.

Кәләвәдәй татлы кәлимәдән
аңкып тора җәннәт ис-косы!
Әмма минем өчен күпкә газиз
насыйп сәгадәтнең искесе.

Кемгә хаҗәт андый яңа котлык[1],
элеккесен сызып ташласа?!
Монпасилар сипкән монафикъның
куенында чып-чын таш ята.

Химаяле Коръән хәрефенә
ясин чыга, имеш, яңалиф...
Оҗмах мисле тормыш вәгъдә кылып,
озак ымсындырды ялган миф.

Бәхет булып иңгән олуг телнең
кирәк түгел миңа яңасы.
Кадерлерәк безгә кадимгечә
көч-дәрт биргән моңлы җан ашы.

Маңкорт кавем язган яңа тарих –
үткәннәрне бозу лабаса!
Менә шулай, кешем, менә шулай
тирән хәтереңне ләм баса.

Инде бүген, әнә, җиде ятлар
төрле «необәхет» өләшә.
«Алданмагыз!» – диеп, элгәрләрем
дәшә кебек кара ел аша.

Тәмам әгъва сыман тәэсир ясый
рәсми сөйләмдәге кай алым...
Берәр түрә илгә яңа бәхет
теләгәндә өнсез калгалыйм.

[1] Котлык – бәхет мәгънәсендә.

## Хәрәмләшү

Артында яманлык тормыйдыр –
киекләр исәбен алучы
арттырып күрсәтсә тартарны.
Мәкерле көндәшлек сәбәптер –
хакимдәй кыланган хисапчы
киметеп күрсәтсә татарны.

## Хәтәр афәт

Төрле чирләр кырып йөргән җирдә бик күп кешене,
соңра илгә ярдәм иткән күккә баглы көч име.

Газиз затлар башын ашый канлы сугыш афәте,
әмма яшәү дәртен бирер элгәрләрнең ак аты.

Тоташ хәвеф алып килә шаулы дөнья казасы,
тар-мар булмас япан кырда әбкәң куйган каз башы[2].

Безгә чиксез зыян сала хаҗәт чакта мән юклык,
тәмләп кенә барча милләт җанын кыяр мәнкортлык.

## Идарә итү билгесе

Хакимлекне тоту хикмәтләре
бөтерелде бүген башымда.
Җитәк өчен, имеш, гаять зарур
прәннек белән камчы ашы да.

Чыбыркыны өстен чыгармакчы
идарәче затның күбесе.
Ә гавамга тиеш күмәчләрне
ашый һаман казна күсесе.

## Милләт теләгән шартлау

Яулык япкан камикадзе шәһит китсә,
ихтыярсыз майтармыйдыр ни генә!
Оят белмәс ирләр бүген шомлы йөкне
күбрәк өя гүзәл затлар иңенә.

Фәрештәсе качкан илләр ишәйгәндә,
күздә, Раббым, ничек татлы яшь калсын?!
Бозмагызчы хатын-кызның вазифасын –
«демографик шартлау» гына ясалсын!..

## Аерымлык хасияте

Безнең токым, баштук тәдбир кылып,
гасыр үрләренә юл алган.
Дөнья буйлап шундый сөйләк йөри:
«Татар тугач, яһүд елаган...»

Безнең өммәт фикер иткән чакта
төзек формулалар ишелә, –
искәртмәле акыл исәбенчә,
ике тапкыр ике биш була.

[2] Каз башы – элек урып-җыю вакытында 25-50 көлтәдән куела торган чүмәлә.

Безнең кавем, ахры, ифрат садә,
иш-куш арасында тиз үскән.
Соңра ханлык тажын жуя барып,
көндәшенә дәүләт төзешкән.

Безнең милләт бигрәк сәйяр жанлы,
охшап куя бик еш дәрвишкә.
Уртак уйга килә белмәс галәм
өч кешедән туплар дүрт фирка.

Безнең гавам артык тырыш бугай,
тамырында кайнар кан ага.
Кайчак татар тупны тибеп кертә
үзе саклый торган капкага.

Безнең халык гыйлем чәчү өчен
көйли жаһил мәннең көен дә;
китап басу эшен фарыз санар
хәтта шаулы мәхшәр көнендә...

## Әгәр булса...

*(Экспромт)*

*Ачыгыз тәрәзәләрне,*
*Булса тәрәзәгез!..*
М. Әгъләмов

Һава хәлен даим сүкмик,
жәе – жәйдер, көзе – көз...
Хәйран калып багыйк жиргә,
әгәр булса күзебез.

Даулы уклар атмыйк күккә,
мотлак Аллаһ колы без.
Жәннәт багы ясыйк илдә,
әгәр булса кулыбыз.

Шикле капчык саны артыр,
эчтә ятар төрле без.
Туры сүзне ярып салыйк,
әгәр булса телебез.

Юлдан, кардәш, «Тукай маршы»
тизлегендә басып уз!
Юкка чыкмас шанлы токым,
әгәр булса башыбыз.

## Мөэминчә фикерләү

Мондый этлек һич тә истән чыкмас,
бәгыремдә калыр бу ачы.
Эчтә калкып куйган үчне басып,
яхшылыклар телим дошманыма:
сау-сәләмәт кенә булсачы!

Минем өскә тагы үтен сытты,
авызыннан исә ... бал ага.
Урынсызга санап орышуны,
яхшылыклар телим дошманыма:
очрый күрмә хәтәр бәлагә!

Алгы көндә йә аш белән сыйлар,
маңгаема орыр йә ташын.
Мөэмин затлар ачу тотмый диеп,
яхшылыклар телим дошманыма:
жирдә әле озак яшәсен!..

Мөдһиш мәнгә озын гомер сорап,
нигә инде шулай язам мин?!
Мөмкин кадәр күбрәк гөнаһ кылып,
мәхкәмәи хисап мәйданында
катырагын алыр жәзаның.

## Тояк эзендәге әфсен

Бала чакта ничек шулай килеп чыккан?!
Искә алып, кылынгандыр йөз гөман.
Болын буйлап узган мәлдә, жиргә ятып,
мин су эчтем ат тоягы эзеннән.

Сусап арган сабый жанны аулак юлда
көтеп торган эчемлекнең тансыгы;
Хозыр-Ильяс касәсеме хозурымда –
мөлдерәмә тулып ашкан таң чыгы!

Көмеш суга әле иртүк йолдыз чумып,
бызлый-бызлый төклетура коенган.
Җитмеш төрле үлән тәме ошбу сыйда,
аңа тагы... курадагы көй иңгән.

Ямьлелектән ямьле җәйнең җәймәсенә
төнгә каршы сибәләгән бал җавы.
Аһ, ни күрәм: нәни күлгә төшеп калган
былбыл кошның келәймәле балдагы!

Түм-түгәрәк язмыш ханым көзгесенә
тиеп киткән фәрештәнең канаты...
Ярар, туктыйм – ерак җәйдә йөргән малай
бүгенгемә йомарламлы кар атты.

Әфсен аша җанны-тәнне бәйли җирем,
аермаска теләгәндәй үзеннән.
...Бала чакның юлы буйлап барган чакта
мин су эчтем ат тоягы эзеннән.

## Пыяла туй уйлары

Бераз моңсу рухта узып киткән
пыяла туй бик күп уйлатты.
Алга табан бер кат карап куйса,
үткәннәргә гамем ун кайтты.

Кайбер хәлне белми калдык бугай,
күпме еллар бергә яшәп тә, –
куышыбыз үтә күренмәле
булган ласа, җаный, яшь чакта!

Туар таңны шунда каршы алдык,
сөю хисе чыкты иркенгә...
Безгә бәйле һәммә төрле серләр
хәзер инде мәгълүм ил-көнгә.

Язмыш ханым бүләк иткән йортны
әллә пыяладан койганнар?!
Чынга туры килмәс гамәл өчен
кабат-кабат аһлап көйгән бар.

Кайчак даулы бәхәс юктан куба
мәшәкатьле тормыш башында.
Бәллүр түбәң һич тә кирәк түгел –
күкләр күреп тора барсын да.

Яхшылыкка юрыйм яшәлгәнне,
йөрәк әле һаман шашына.
Куышыбыз үтә күренмәле,
атмасыннар аңа таш кына.

Бераз моңсу рухта үтеп киткән
пыяла туй бик күп уйлатты...

## Күз яшьләрен яшерү җае

*(Кәнизәк белән сөйләшү)*

– Сине үксеп торган хәлдә
күрмим әле, бал авыз...
– Төрле сәбәп таба тәкъдир –
мин дә сыгам балавыз.

– Текәп багам: йөзең моңсу,
тик шәйләмим күз яшен.
– Ләйсән яңгыр яуган чакта
аны ничек күрәсең?!

– Сабыр җанны вата алмас
берәү түгел, йөз гамь дә.
– Күлгә баргач, сыктап куям
су астыннан йөзгәндә.

– Була икән шундый күзләр –
чаткы чәчкән тере шәм!
– Күңел тулып киткән мәлне
белгертмәскә тырышам.

– Моның кебек яшерүне
кылануга юрамам.
– Минем еглау кемгә кирәк –
сизсен бары Җир-анам.

– Еллар аша караш ташлыйм...

## Гыйбрәтле аңлату

Кешенең гомере кыскамы?
Күпсенә күрмәсен күк-фәләк.
Дөньяга килүен тәкъдирләп,
очына бер көнлек күбәләк.

«Иртәгә» сүзенә бәйләмик
ашыгыч кыласы гамәлне.
Бер көнлек күбәләк каршында
уңайсыз, билләһи, кай мәлне.

Инсаным, яшьлектә эзләнеп,
һай, озак керәсең мәнгә син!
Бер көнлек күбәләк тизләтеп
аңлатыр яшәүнең мәгънәсен.



Рафис Корбан

# АРТЫК КЕШЕЛӘР

РОМАН-ЭССЕ

**Беренче бүлек**

**1**

Салихны эшеннән чыгарып аттылар.

Тагын ике елдан илле тула. Таҗи Гыйззәт белән егерме ел элек куелган «Наёмщик»ны яңадан карап, яңартып чыгарырга дип, җиң сызганып эшләп йөргән көннәре иде.

Бу көнне эшкә килгәч, барысы да аның белән гаепле кеше кебек, ничектер уңайсызланып сөйләшәләр төсле тоелды. Үзе белән бер бүлмәдә утырып эшләүче Баян да, рәссам Ибәтуллин да, аның белән күрешкәндә, кулларын кыенсынып кына суздылар.

– Салих абый, ишек төбендәге белдерүләр тактасына күз төшермәдегезме? – диде Баян.

– Юк болай. Ә нәрсә? Премия язганнар мәллә, бәгырь? Өченче көнге спектакль турындагы докладым өчен.

– Язганнар, ди. Язарлар, бар. Өстән боерык төшкән: штат кыскарту турында.

– Кемне кыскартканнар? Контюковны мәллә? Бер дигән артист, артист булып кына эшләсен, йөрмәсен директор булып, дигәннәрме? Югыйсә берзаман кергән бу минем янга. «Синең барабанчың гел шулай бер-ике мәртәбә генә кагып утырамы анда барабанына?» – дип сорый. Шулай гына, дигән идем, алайса, иртәгә барабанда утырырга мине генә чакырырсың. Йөрмәсен анда ыштан туздырып. Штатын кыскартырга кирәк», – ди.

– Кыскартканнар анда. Барабанчыны да кыскартканнар. Дирижёрын да...

– Ничек? Музыкасыз спектакль була микәнни?

– Була икән шул менә... Исең китмәсен, кыскартылучылар арасында Таҗи дустың да бар.

---

Рафис КОРБАН (1957) – *шагыйрь, язучы, тәрҗемәче; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. А.Алиш, Ф.Хөсни исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Алмалы төн», «Яра», «Ватан» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

– И бәгырь. Әле генә сөенә-сөенә «Чын мәхәббәт»не чыгарган идек ләбаса. Моннан соң куелмас микәнни инде «Чын мәхәббәт»? Ничә җыр гына бар иде бит анда.

– Кайгырма, Салих абый, җырларлар. Сездән башка да.

Салих «һе» дип кенә куйды да коридорга чыгып китте. Баян баярак кына профком кабинетында булган сөйләшү турында искә төшерде. Партия өлкә комитетының беренче секретаре Зиннәт Ибәтович Муратовның үз имзасы белән Татар театрында музыка секторын бетерү турында әмер төшкән иде. Баян Гыйззәтуллин – театрның партия оешмасы секретаре. Бөек Ватан сугышында катнашып, аннан соң тагын бер ел армиядә хезмәт итеп, Казанга кайтып төшкәннән соң, Камал театрының әдәби бүлек мөдире булып эшкә урнашкан яшь коммунистны театрның партия оешмасын җитәкләргә билгеләп куйганнар иде. Партия өлкә комитеты фәрманын профкомнан, директор белән режиссёрлардан башка гына хәл итеп булмый, әлбәттә. Ул башта бу хакта баш режиссёр Ширияздан Сарымсаков белән сөйләште.

– Эшнең шуңа таба баруын чамаларга була иде инде, – диде Ширияздан Мөхәммәтҗанович. – Салих абыйны гына түгел, Таҗи Гыйззәтовны да кыскартырга дигән фәрман бар. Анысын, рольләре аз дигән сылтау белән кыскартырга, диелгән. Быел бигрәк тә каныктылар аларның икесенә дә: Салихка – Композиторлар союзында, Таҗига – Язучылар союзында. Театрны музыкадан башка ничек күз алдына китерә торганнардыр ул обкомда?.. Мин белмим.

– Нишлибез соң, Ширияздан абый? Үзләренә әйтергә кирәк булачак бит бу хакта.

– Аларга гына түгел. Бөтен коллективка игълан итәргә кирәк булачак. Әйдә, керик Кәнтүк янына. (Алар директор Гомәр Контюковны үзара шулай атап йөртәләр иде.) Габдулла белән Хөсәенне дә чакырыйк. Режиссёрлар бит, всүтеки.

Бу яңалык алар өчен дә шок иде. Барысы да аптырашта калдылар. Ләкин обком карарына каршы килеп булмый. Анда яхшы беләләр, обком бит ул! Театр музыка бүлегеннән башка да эшли ала. Һичшиксез җырлы булырга тиеш түгелдер спектакльләр, дигәннәрдер. Чынлап та, музыкаль драма театры аерым булырга тиештер, бәлки.

Сүз күп булды профкомда. Сүзне түгәрәкләп, Ширияздан Сарымсаков:

– Дөнья күрсәтер. Иптәш Контюков, син – директор. Администрация карарын сиңа чыгарырга туры киләчәк. Таралышыйк, – диде.

– Ә, юк, егетләр. Мин өстемә ала алмыйм бу мәсьәләне. Профком белән парткомга үзләрен чакырып сөйләшик. Бергәләп җиткерик бу яңалыкны аларга, – диде ул шунда, аптыраган кыяфәт чыгарып.

– Салих абый партия әгъзасы түгел бит. Монда администрация карары турында сүз бара, – дип каршы төште Баян, шулай ук авырлыкны үз өстенә алырга теләмичә.

– Алайса, болай итик, егетләр: «Партия өлкә комитетының Татарстанның Совет композиторлары һәм язучылары Союзлары карары нигезендә театрның музыка секторы мөдире Салих Җамалетдин улы Сәйдәшевне һәм артист Таҗетдин Кәлимулла улы Гыйззәтовны эштән кыскартырга»,

дигән боерык чыгарырга һәм белдерүләр тактасына элеп куярга, – диде Сарымсаков.

– Без аларны урамга куып чыгара алмыйбыз, иптәшләр. Штатлары кыскартылган очракта да, аларга яңа эш тәкъдим ителергә тиеш, – диде Контюков.

– Кем кыскарту идеясе белән чыккан, шулар эшен дә табар.

– Анысын инде үзләре карарлар. Без аларның хезмәт кенәгәләренә «Сәнгать эшләре буенча комитет карамагына театрдан эштән кыскартыла», дип язып куйсак, шул булган.

– Ә кем кул куя?

– Кем булсын, син инде. Син бит директор.

Сарымсаковның шушы сүзе сөйләшүгә нокта куйды. Театр халкы эшкә килгәләгәнче, боерыкны машинкада бастырып, белдерүләр тактасына элеп тә куйдылар.

Салих боерыкны укыды да, ни дияргә дә белмичә, беркавым баскан урынында каккан казык кебек катып калды.

«Нинди миһербансыз бу дөнья! Бер аның белән генә рәхимсез кылана. Гомере буе шулай булды. Ни өчен аның белән генә шулай килеп чыга? Кем каргады икән аны? Нинди каргышлар төшә икән соң аның башына? Сөеп, яратып өйләнгән хатыны Валентинасы үлде. Икенче хатыны хыянәт итте. Уллары Рәләф, Эмиль вафат булдылар. Әтисе урынына калган җизнәсе Шиһап, «халык дошманы» дип, төрмәгә утыртылды. Шамил Усманов, Кәрим абыйсы Тинчурин, Фәтхи Бурнаш дусты «халык дошманы» дип атып үтерелделәр. Инде менә Таҗи дусты белән икесен эшләреннән кыскарталар, урамга куып чыгаралар. Шулкадәр үк кирәксез, артык кешеләрмени соң алар бу тормышта?»

Башын авыр уйлар өермәсе биләп алган Салих бүлмәгә кире кереп, берсенә дә бер сүз дә әйтмичә генә, тумбочка өстендә яткан бүреген алып, башына киде. Аннары дивар буенда моңаеп торган кебек күренгән пианиносының капкачын ачты һәм баскан килеш кенә бармаклары белән клавишалар өстеннән йөгереп узды. Урындыкка утырды да күңеленә килгән көйләреннән импровизация уйный башлады. Боларның берсе дә, әле Баянга да, Ибәтуллинга да таныш түгелләр иде. Салих сүзсез генә берничә минут уйнагач, урыныннан торып, өстәле читендә торган ноталар саклаган сандыгын ачып карады. Анда инде берничә елдан бирле театр репертуарында барган спектакльләргә язылган музыка ноталары ята иде. Барысы да аның үз көйләре. «Моннан соң беркемгә дә кирәге юк инде боларның, дип уйлады ул. Алып кайтып китәргә микән? Үзенә дә кирәк түгелләр бит инде хәзер. Калсыннар шунда. Кирәк дип тапмасалар, җыештыручы чүплеккә чыгарып ташлар әле».

– Йә, егетләр. Төрле чакларым булгандыр, гаеп итеп калмагыз. Сау булыгыз, – диде дә, чөйдән пәлтәсен алып, Салих ишеккә таба атлады.

– Кергәләп йөр, Салих абый, – диде Баян.

Салих дәшмәде. Аның күңеле тулган, сүз әйтсәм елап җибәрермен, дип уйлады да чыгып китте.

Чыкса, белдерүләр тактасы янында башын кашып, Таҗи Гыйззәт басып тора иде. Ул Салихны күрде дә ышаныргамы, ышанмаскамы бу игъланга дигән кыяфәт белән:

– Укыдыңмы, Салих, бу боерыкны? – дип сорады.

– Укыдым, бәгырь. Беренче апрель шаяртуы дияр идем, әле мартның уналтысы гына. Әйбәт шаяртканнар анда безнең өстән, – диде Салих.

– Әйдә, керик әле Кәнтүк янына. Дөрес түгелдер бу.

– Кердең ни дә, кермәдең ни, кулын куйган, боерыгын раслаган, тагын ни кирәк? Әйдә, киттек урамга. Синең белән миңа монда бернинди эш тә калмаган.

– Ничек инде? Ничек инде калмаган? «Наёмщик»ны быелгы планга керттеләр бит. Бездән башка гына чыгарырлар микәнни? Әле күпме эшлисе бар. Өр-яңадан сөреп чыгасы...

– Әйдә, киттек. Үзләре беләләрдер.

Шулай диде дә Салих урам ишегенә юнәлде. Аптыраган Таҗи да аның артыннан иярде.

Урамга чыккач та алар беравык ни эшләргә, кая барырга белмичә, аптырап басып тордылар. Өйләренә кайтып китсәләр, анда ни эшләсеннәр? Хатыннарына ни дип әйтерләр? Болай театр ишеге төбендә дә басып торып булмый.

– Киттек Кекинга.

– Миндә акча юк бит.

– Миндә бар дип беләсеңме?

– Алай булгач, нәрсә кибеткә дәшәсең?

– Син кем?

– Таҗи.

– Ә мин – Сәйдәш. Тәк што, без бит үзебез байлык!

– Булырсың байлык. Урамга себереп түккәннәр әнә, потың бер тиен. Болай да зарплатаң йөз сумга тулмый дип зарланып йөри идең.

– Шулай буласы билгеле иде инде. Әле узган атнада гына Союзыгызда тетмәңне теттеләр дигән идең бит. Менә шуның нәтиҗәсе инде бу.

– Булды инде, бөтен җонымны җолкып бетерделәр.

– Әйдә киттек, сөйләрсең, – диде дә Салих Кекин йортына таба атлады. – Безгә әллә ни күп кирәкми, берәр кружка сыра булса, шул җиткән.

Алар кесә төбендәге тиеннәрен санап, берәр кружка сыра алдылар да тәрәзә буендагы иң читтәге өстәл янына барып утырдылар. Кибеткә кергән-чыккан барысы да аларны яхшы белә, әледән-әле исәнләшеп, баш кагып, кайсылары хәлләрен сорашкалап, яннарында үтеп-сүтеп йөрде. Эштән кыскартылуына Сәйдәштән ныграк гарьләнгән Таҗи, күңеле нечкәреп, Язучылар союзында булган җыелыш турында сөйләргә тотынды.

– «Чын мәхәббәт» авызларын томалар дип уйлаган идем. Ничек кабул итте бит халык! «Изге әманәт»тән соң безнең өчен зур җиңү иде инде бу. Бик исләре китте. Көнчелек харап итә бугай безне. Көнләшәләр. «Изге әманәт»не дә ничек яратканнар иде. Аннан соң ничек бетереп ташладылар шул кабих көнчеләр.

Таҗи Гыйззәтнең 1944 елда Салих Сәйдәшев белән бергәләп чыгарган «Изга әманәт» драмасы башта тәнкыйтьчеләр тарафыннан яхшы кабул ителсә дә, партия Үзәк Комитетының шул елның августында чыгарылган «Татарстанда сәяси пропаганда эшенең куелышы турында»гы карарыннан соң, Мәскәү алдында яхшатланып, таләпчәнлекне

көчәйтәбез дигән булып, язучыларның әсәрләренә, театрларның репертуарында уңышлы гына барган барлык спектакльләргә дә ревизия башлана. Мирсәй Әмирнең «Миңлекамал», Таҗи Гыйззәтнең «Изге әманәт», «Ялкын» спектакльләре, сәяси хаталары булу сәбәпле дип, театр репертуарыннан алып ташлана.

– Шул көнчеләрнең тырышлыгы аркасында илле яшьлегемне дә уздырмадылар. Синең илле яшьлегеңне дә уздырмаячаклар инде болар болай булгач, – дип көрсенде Таҗи, кружкасында яртылаш кына калып барган сырасын чөмереп.

1945 елның 15 сентябрендә Таҗи Гыйззәткә 50 яшь тулган иде. Шәриф Камалның вафатыннан соң, ул узган гасырда туган язучылар арасында иң өлкәне булып калган иде. Нәкый Исәнбәт, Гомәр Бәширов, Афзал Шамов кебек, өлкән дип саналган язучылар да, аннан биш яшькә кече булып, мөрәҗәгать иткәндә абый дип дәшәләр иде.

– Исең китмәсен, Таҗи абый, хикмәт яшьтә түгел, хикмәт үзеңнән соң кала торган эштә, хезмәттә.

– Барысы да шул Шәйхинең «Тартай арбасы»ннан башланды яңадан. Мескен үзенә дә каты эләкте инде. Партиядән чыгарып аттылар. Утыртып та куймасалар ярый тагын, – дип, Таҗи, Шәйхи Маннурның былтыр «Совет әдәбияты» журналының дүртенче санында чыккан шигыре уңаеннан булып алган гауга хакында искә төшерде. – Тәнкыйтьчеләрнең сәяси уяулыгы белән бу шигырь сәяси яктан зарарлы дип табылды.

Монда да редколлегия әгъзалары булып торучылардан партия Өлкә Комитетының идеология буенча шөгыльләнүче вәкиле Камил Фасеев та, Язучылар союзы җитәкчесе Әхмәт Ерикәй дә, Союзның партия оешмасы секретаре Кави Нәҗми дә судан коры чыктылар. Журнал редакторы Газиз Иделле корбан булырга тиеш дип табылды да, тагын бер гаеплене эзләргә керештеләр. Ә ул редколлегиядә драма әсәрләре өчен җаваплы кеше Таҗи Гыйззәт булып чыкты. Берүзен журналның редколлегиясеннән чыгарып ташладылар.

– Редколлегиядә поэзия буенча җаваплы Әхмәт Ерикәй дә, «Язгы җилләр» романын язганчы шагыйрьләр рәтендә йөргән Кави Нәҗми дә гаепле түгелләр икән. Таптылар бер йомшак кешене! – дип үртәлде Таҗи. – «Чын мәхәббәт» тә, «Изге әманәт» шикелле корбан буласы иде, әле ярый Мәскәү Язучылар союзы идарәсе секретаре Сафроновка укыткан идем, бәхетемә! Бик яхшы отзыв язып җибәрде безнең Өлкә Комитетына. Ых та итмәделәр. Котлары очып тора Мәскәү сүзеннән. Бер дигән спектакль килеп чыкты. Синең тырышлык белән, әлбәттә. Музыкасы да шәп булды. Ничек әйбәт бара!

– Менә шуның әйбәт баруы безгә зыян эшли дә инде, төшенәсеңме, Таҗи абый? – диде Сәйдәш. Ул үзенең кружка төбендә генә калган сырасының соңгы тамчыларын йотып куйды да: – Нәрсә, тагын берәрне кабатламыйбызмы? – дип сорады.

– Зыян итмәс. Бүген ярый. Бүген зарплатаның калган өлешен бирергә тиешләр. Кереп алырбыз. Обходной тутырганнан соң кырык өч сумын бирербез дип әйттеләр, – диде Таҗи.

Алар тагын берәр кружка сыра китерттеләр.

– Бүген эштән кыскартылуыңның сәбәбе болар гына түгел бугай. Унынчы мартта нәрсә булды соң анда сезнең Союзда? – дип, Сәйдәш моннан берничә көн элек кенә Таҗи дустына каләмдәшләренең выговор чәпәүләре хакында искә төшерде.

– Тагы да шул партком үчле. Кырык өченче елдан бирле килә инде ул. Мин Язучылар союзының җаваплы секретаре булган чаклардан бирле. Сөйли башласаң, озакка китә. Менә шул парткомның моннан өч ел элек миңа яла ягып язган мәкаләсе буенча Өлкә Комитетына хат юллаган идем, «Изге әманәт» турында язган мәкаләсе уңаеннан тиешле бәя бирүегезне үтенәм», дип. Хатны Язучылар союзына төшергәннәр. Унынчы мартта Союз партия оешмасының бюро утырышына чакырдылар. Көн тәртибендә: «Коммунистлар Юнысов һәм Гыйззәтовларның иҗади һәм шәхси эшләре буенча хисаплары», дигән мәсьәлә. Юнысов дигәне – Әхмәт Юныс, үз эшчәнлеге турында хисап тотты да, шуның белән вәссәлам. Галочка өчен генә куелган мәсьәлә. Икенче көн тәртибендә минем хат.

– Нәрсә булып бетте инде?

– Нәрсә булып бетсен. Күреп торасың – эштән сөреп чыгардылар.

– Өлкә Комитетына шундый чара күрелде дигән җавап юллаячаклармы инде: эштән кыскартылды, дигән?

– Юктыр. Нинди җавап бирәсен табарлар. Хат буенча сөйләшүне миннән сорау алудан башладылар. Имеш, ни өчен мин Союз эшеннән канәгать түгел?

Мине объектив тәнкыйтьләмисез, дигән идем, тотындылар тагын да шул яла ягуга. Алдан хәзерләнгәннәре әллә каян күренеп тора. Үзем дә хата җибәрдем, илле яшьлек юбилеемны да үткәрмәдегез, дидем. Әхмәт Ерикәй торып басты да, бу объектив сәбәп түгел, бу шәхси нәрсә. Моның ише дәгъваләр белдереп Өлкә Комитетына хат язу – бала-чагалык, дип сөйләргә тотынды. Мин алай дип язмадым, сезгә генә әйтәм, дигәнне тыңларга да теләмәделәр. Шулай итеп, партком йомгаклау сүзендә: «Бүген бюро утырышының көн тәртибенә Таҗи Гыйззәт мәсьәләсен куеп ялгышмадык. Ул чынлап та тәнкыйтьне күтәрә алмый, бик авыр кабул итә. Соңгы вакытта ул үзенең иҗатында артта өстерәлә. Аның әсәрләре заман таләпләренә җавап бирми. Болар барысы да партбюро утырышы карарында чагылыш табачак», дигән чыгыш белән бюро утырышын тәмамлап та куйды.

Менә, эштән куылуымның бөтен сәбәбе шул.

– Һәй, бәгырь, Таҗи абый, Таҗи абый. Эштән куылуыбызның сәбәбен әйттем бит инде: ул – көнчелек. Аларның әсәрләре укылмый. Синеке әнә ничек җырлап бара! Менә шул эчтән яндыра аларны. Шул тынгылык бирми. Шуның өчен юк-бар сәбәп табып, юк итәргә телиләр. Төрлечә каһәрлиләр. Менә күрерсең, әле без синең белән эштән куылсак та, аларның эчләрен яндыра торган спектакльләр иҗат итәрбез. «Наёмщик»ны яңадан эшләп чыксак, быел ук халык егылып карый торган шедевр тудырачакбыз, Алла боерса!

– Булыр микән, Салих? Сине дә кыскарттылар бит, урамда калдырдылар. Икебез дә артык бит хәзер без бу җәмгыять өчен. Артык кешеләр.

**2**

Кибеттән чыккач Таҗи яңадан театрга кереп китте. Обходной лист тутырып, хезмәт хакының эшләгән көннәр өчен тиешле өлешен алырга дип. Салих кереп тормады. Әллә кая түгел, күршедә генә, керермен әле бер, дип уйлады.

Эштән кыскартылыр алдыннан гына Салихны да Композиторлар союзында шәпләп кенә тәнкыйть утына тотканнар иде. Ике союзның да аларның шәхси эшләрен тикшерүе тиктомалдан гына түгел иде. Бу утырышлар алдыннан гына Өлкә Комитетының идеология бүлеге мөдире Камил Фасеев ике союз җитәкчеләрен дә үзенә чакырып сөйләшү үткәрде.

Фасеев үгезне мөгезеннән алып сөйләште ул көнне.

– Иптәш Ждановның «Звезда», «Ленинград» журналлары турында чыгышыннан соң музыка өлкәсендәге торгынлыкны бетерү буенча илдә киң фронт белән башланган эш ни өчендер безнең республикада әллә ни сизелми. Ярар, үткәрдегез инде җыелышларыгызны да. Тәнкыйть утына да тоттыгыз инде кайбер коллегаларыгызны. Ә нәтиҗәсе кайда? Мәскәүдә дә укып кайттыгыз. Зурлап опера театрын да ачтык. Кайда опералрыгыз? Нәҗип Гаязович? Һаман сездән генә көтәргә тиешбезмени дөнья классикасы дәрәҗәсендәге әсәрләрне? Әхмәт Фазыйлович, кайда либреттолар? Язучылар нигә язмый? Һаман да шул кәмит белән генә сыйламакчы буласызмы халыкны? Йә шул музыкаль драма белән генә? Ул драматургларыгыз да бер-берсен чәйнәшеп ятудан ары киткәннәре юк.

Шушы сүзләрдән соң Фасеев өстәл тартмасыннан ниндидер конверт алып, Әхмәт Ерикәйнең кулына тоттырды да сүзен дәвам итте:

– Менә бу Таҗи абзыйның партком өстеннән шикаяте. Ул нәрсә? Мәсьәләне Өлкә Комитеты хәл итәргә тиешмени инде? Карагыз, тикшерегез дә җавап бирегез. Аннан соң, ул Таҗи Гыйззәт белән Салих Сәйдәшевнең «Наёмщиг»ын опера итеп үзгәртеп яздыру хакында күпме сүз алып барырга була? Академия театрының быелгы репертуарына тагын шуны кертеп куйганнар. Сөйләшегез авторлар белән, хәл итегез бу мәсьәләне. Опера итеп үзгәртеп язарга нүҗәли хәленнән килми инде ул Салих абыйның?

Фасеевта булган бу сөйләшүгә хәтле үк инде Композиторлар союзында унсигезенче февральдә үткән җыелышта да композиторларның күбесенә карата бик күп тәнкыйть сүзләре әйтелгән иде. Анда Салих кына түгел, Мансур Мозаффаров та, Заһид Хәбибуллин да, Җәүдәт Фәйзи дә тәнкыйть утына тотылды. Ә Салихка аеруча каты бәрелделәр.

– Сәйдәшев унбиш ел элек язган әсәрләре дөньясында яши, – дип бәрелде аңа үзенең докладында Нәҗип Җиһанов. – Дөрес, Сәйдәшевне халык ярата. Әсәрләренең халык иҗатына якын булуы, матурлыгы өчен ярата. Ләкин ул нәрсә язды соң соңгы унбиш елда? Бөек Ватан сугышы елларында нәрсә язды? Хәзер нинди уйлар белән яши? Аның бүгенге заман биеклегеннән торып музыкада халкына әйтер сүзе юк микәнни? Аның торгынлыгы безне борчый. Театрларның аның әсәрләрен бары тик касса, табыш алу өчен генә файдалануы композитор өчен начар хезмәт булып тора. Аю хезмәте. Әгәр дә ул бүген моннан унбиш ел элеккеге кебек халык күтәреп ала торган җырлар язмый икән, димәк, ул иҗат өчен ниндидер ят уйлар белән яши. Без аңа бу торгынлыктан чыгарга ярдәм итәргә тиеш. Сәйдәшев иҗаты

турында сөйләгәндә минем иптәш Ждановның «Звезда» һәм «Ленинград» журналлары турындагы чыгышында әйткән сүзләрен исегезгә төшерәсем килә: «Халкыбызның мәнфәгатьләре һәм зәвыгы бик югары күтәрелде, һәм шул югарылыкка күтәрелергә теләмәгән яисә моңа сәләтсез кеше тормыштан артта калачак».

Салихның да, Таҗиның да эштән кыскартылулары һәр ике союзның да сүздә бер төрле сөйләп, эштә икенче төрле гамәл кылуларының күрсәткече иде. «Без Салихка ярдәм итәргә тиешбез», дигән сүзләр аларның икейөзлелеген генә сөйләвен Салих бик яхшы аңлый. Ничек инде унбиш ел буе берни дә эшләмәсен? Ул унбиш елның өч елы Мәскәүдә опера студиясендә үтте. Ул чакта язмады, әлбәттә. Ә аннан соң Таҗи абыйсы белән «Бишбүләк», «Изге аманәт» драмаларын чыгармадылармыни? Хәбибулла Фәтхуллинның «Күзләр»е, Галиәсгар Камалның «Хафизәләм-иркәм»е, әле генә чыккан «Мулланур Вахитов» – алар аның хезмәте түгелмени? Никадәрле җыр гына язды. «Ватан», «Поход» маршлары...

***

Таҗи абыйсын озаткач, Салих кая барырга да белмичә, озак кына кафе ишеге төбендә басып торды. Бүреген артка чөеп, башын күтәреп, һавага карады. Язгы чалт аяз күк читендә каурый болытлар йөзә иде. «Эһ, шул болытларга утырып китәсе иде очып... еракка-еракка, бернинди кайгы-хәсрәтне белмәгән, булганын да аңламаган ваемсыз бала чакка.

Шунда аның биш-алты яшьлек бәләкәй малай чагында әнисе белән Миңлебай бабайлары йортына барулары, анда әнисенең сеңлесе Маһикамалның кызы Мәрьям алдына утырып, гармунда уйнарга өйрәнүләре хәтеренә килеп төште. Мәрьям, ундүрт-унбиш яшьләрендәге кыз, шундый матур иттереп тальян гармунда уйный. Ул Салихның бармакларын үзенекенә бәйләп куя да, гармун бармакларына баскалап, белгән көйләрен уйный. Шулай итеп Салихны көй чыгарырга өйрәтә. Акрынлап малай да отып кала, Мәрьям апасының алдыннан төшеп, үзе генә уйнап күрсәтә. Салих әнә шулай гармун белән җенләнә башлады. Ул исенә төшкән саен әнисен Дары бистәсендә яшәүче Миңлебай бабайларына алып барырга сорый торган булып китте. Миңлебай бабайның йорты да зур, ике катлы таш өй. Беренче катында читек-кәвеш тегү остаханәсе. Шунда ук кибет. Икенче катта яшиләр. Анда уйнарга балалар да күп. Әнисенең энесе Мостафаның кызлары Гөлсем белән Факия дә чама белән Салих яшендә. Мәрьям апайларының алар белән утырырга вакыты булмаганда, шулар белән бергәләп әвәрә киләләр. Салих мич башына үрмәләп менеп, морҗа калагын ала да, шуңа агач кашык белән суккалап көй чыгара. Йә апасының гармунында, ул өйрәткән көйләрне шыңгырдатып, кызларны рәхәтләндереп биетә. И күңелле була торган иде. Соңга табарак, Салих бераз үскәч, әтисенең абыйсы Бикмөхәммәтнең кызы Рауза да, элек әтисенең кибетендә приказчик булып эшләгән Насретдин исемле егеткә кияүгә чыгып, аларның да бер-бер артлы кызлары Разия, Рабига, Асия, Һава дөньяга килделәр. Салих баштарак Рауза апасына ул кызларын карап үстерергә булышты. Ә унбер яше тулганда, аның үз апасы Әминә дә, Шиһап исемле егеткә кияүгә чыгып, җизнәсе алар белән яши башлады. Насретдин җизниләре икенче

йортка күчтеләр. Бераздан Шиһап җизнәсе, гармунда уйнарга һәвәслеген белеп, Салих өчен рояль сатып алды.

Хәер, аңа хәтле дә әле ел саен җәй башында Насретдин җизнәсе аларны Рауза апасы белән этисенең туган авылына, Өбрәгә, Сабан туена алып кайта торган иде. Анда Бикчәнтәй бабай белән аның янында калган олы улы Бикмөхәммәт гаиләсенә кунак булып, Казаннан башка балалары да җыйнала. И күңелле була. Салихның гармун уйнаганын белеп, каяндыр тальян табып китерәләр. Малай аларны үзе белгән көйләрне уйнап җырлата, биетә.

Миңлебай бабаеның авылы Битаман да ерак түгел Өбрәдән. Тик анда инде аларның беркемнәре дә калмаган. Бабай авылдан яшь чагында ук чыгып киткән. Патша армиясенә – солдат хезмәтенә. Егерме ел хезмәт итеп кайткач, патша әмере белән аңа Казан читеннән җир биргәннәр. Шунда йорт салып кереп, Дары бистәсендә яшәп калган. Шулай да Бикмөхәммәт абзыйсы ат җигеп, җыйналышып бер көнне Битаман Сабан туена да барып киләләр. Сабан туйлары бит әллә ничәшәр көн була торган иде. Әнә шулай, авылдан авылга кунакка йөрешә торганнар иде. Битаманда Миңлебай бабайны белгән кешеләр бар иде. Салих хәтерли әле, Миңлебай бабай үзе дә яшьрәк чакларында уллары Мостафа белән Мозаффарның гаиләләрен алып, Сабан туйлары вакытында Битаманга кайткалый торган иде. Анда үзләренең чыбык очы туганнары бар дип әйтә торган иде. Бабай озын гомерле булды. Утыз дүртенче елда гына дөнья куйды. Бик таза, нык бәдәнле, алыптай дәү гәүдәле, озын сакаллы, кем әйтмешли рус поплары шикелле бер карт иде. Әнисе Мәхүпҗамал үзен: «Мин этигә охшаган», – дип әйтә торган иде. Ул да шул этисе кебек озын зифа буйлы, бик матур, сөйкемле хатын иде.

Ә инде Шиһап җизнәсе рояль дә алып кайткач, музыка белән гел саташты Салих. Җитмәсә, күршедә генә, аның шикелле үк гармун җене кагылган Мансур исемле малай яши икән. Аның белән дуслашып алгач, берсеннән-берсе уздырып, музыка белән шөгыльләнә башладылар.

Ундүрт яше тулгач, Шиһап җизнәсенең кыставы белән сәүдә училищесына укырга кергән иде. Бер үк вакытта музыка училищесында да укыды, өч ел. Унҗиденче елда сәүдәнекен ташлады, ә музыкальныйны тәмамлап чыкты да театрда музыкант булып эшләргә күчте. Шул чакта сәүдә юлыннан китсә, гомере үтәр идеме менә шундый адәм мәсхәрәсендә? Тоттылар да берни әйтми-нитми, сәбәбен дә аңлатып тормыйча эштән куып чыгардылар. Бер тиен акчасыз урамда калды менә хәзер. Болай да 89 сум хезмәт хакы ала иде. Хәзер анысы да булмаячак. Кая барыр, кемгә барып ялыныр? Нинди дәүләт соң бу талантларын хөрмәт итми торган? Халык бит ничек ярата! Ә җитәкчеләр?.. Мәдәният, сәнгать белән идарә итүчеләр?..

Шуларны уйлады да Салих күңеле тулып, урамда ук елап җибәрә күрмим тагын дип, өенә юнәлде. Ярый әле, ерак барасы түгел, театр ишегалдында гына. Өйдә, хатынына берни әйтми-нитми, үзенең эш бүлмәсенә кереп китте, өс-башын да алмаштырып тормыйча, караватка барып ятты да тыйлыга алмыйча үксеп-үксеп, елады.

Бу көнне бөтен гомер юлы, барлык шатлык-кичерешләре, кайгы-сагышлары белән аралашып, аның күз алдыннан узды.

**3**

Апасы Әминәнең Шиһап җизнәсе белән ничек танышып, яратышып йөргәннәрен белми Салих.

Улы Җамалетдин вафат булганнан соң Бикчәнтәй карт, беркемнең дә сүзенә карамыйча, олы улы Бикмөхәммәтнең кызы Раузаны Җамалетдин кибетендә приказчик булып эшләгән Насретдинга кияүгә бирергә дигән карарга килә. Күрәсең, исән чагында Җамалетдин приказчигыннан канәгать булып, аны үз күреп, бөтен мөһим эшләрен курыкмыйча аңа тапшыргандыр һәм бу хакта атасы Бикчәнтәй карт белән дә сөйләшкәне булгандыр. Ул гына да түгел, малай чагыннан ук Җамалетдинга өйрәнчеклеккә тапшырылып, аның өендә үскән Насретдин, Раузага өйләнгәч, хуҗасын югалткан йортта хуҗа булып яшәргә дә торып кала. Шулай итеп, Салих һәм аннан дүрт кенә яшькә олы апасы Әминә уникенче елга хәтле җизнәләре Насретдин белән туганнан туган апасы Рауза тәрбиясендә үсәләр. Дөрес, Насретдин да гаиләдә үз урынын яхшы белә, Җамалетдиннан калган сәүдә эшләре, асылда, тол калган Мәхүпҗамал өстендә булып, кияү исә һаман да шул приказчиклык дәрәҗәсендә эш алып баруын дәвам иттерә.

Көннәрнең берендә Салихларга яучылык итү белән шәһәрдә аты чыккан күрше карчыгы Шәрифә абыстай килеп керде. Кичке як иде. Мәхүпҗамалның ахшам намазын укып, намазлыкларын җыештырып, чәй эчәргә дип әзерләнеп йөргән чагы иде. Шәрифәне күрүгә, әнисенә чәй хәстәрләп йөрүче Әминә ялт итеп кенә күрше бүлмәгә чыгып гаип булды.

– Мөмкинме? Хуҗалар өйдәләрме? Әссәламегаләйкүм, ни хәлләрдә яшәп ятасыз? – дип, ишектән керүгә Шәрифә абыстай түр башына ук барып кунаклады.

– Әйдүк, Шәрифә абыстай, түрдән уз, – дип, Мәхүпҗамал инде түрдәге кәнәфигә үк барып утырган карчык янына килеп, үзе дә аның каршындагы кәнәфидән урын алды. – Нинди йомыш белән йөрисең, Шәрифә абыстай? Сөйләп җибәр.

– Бик зур эш белән килдем, Мәхүпҗамал күрше, – диде кунак һәм утырган җирдән күлмәк итәген ачып, кызыл күннән чәчәкләп-чуклап тегелгән читек кигән уң аягын алга сузды һәм читеген каплап торган ак батист шарабарын өскәрәк күтәрде. – Күрәсеңме нәрсә бу?

Мәхүпҗамал эшнең нидә икәнен шундук чамалады. «Яучы булып килгән», дип уйлап куйды. Аннары:

– Әллә инде... – дип әйтте дә туктап калды.

– Әйе, әйе, Мәхүпҗамал абыстай, дөрес уйлыйсың. Яучы булып килдем, – диде Шәрифә.

– Бездә кияүгә бирерлек кыз, өйләндерерлек егет юк бит әле, Шәрифә абыстай, – диде Мәхүпҗамал.

– Нишләп булмасын? Әминәгез бөтен тирә-күрше күз алдында, бер кашыкка салып йотарлык сылу булып җитешкән. Кияүгә бирергә бик вакыт.

– Яшь бит әле ул. Уналтысы яңа тулды. Балалыктан чыкмаган.

– Сөйләмә юкны. Әминә йөз яшерә белә, итагатьле. Әле хәзер дә, мине күрүгә, каршы якка чыгып гаип булды. Әмма дә үзе кебек үк уңган егетнең күзе төшкән кызыгызга, күршекәйгенәм.

– Булмас, юкны сөйләмә, урамга чыгып, күзгә-башка күренеп йөргән бала түгел.

– Алай дисең дә, ахирәт кызлары белән кичләрен Шәрык клубы кичәләрендә күренгәләгән бугай, ахры.

– Үзбашка түгел, Шәрифә абыстай, сорамыйча бер җиргә барганы юк. Бер-ике мәртәбә, иптәшләрем белән дигәч, барырга үзем рөхсәт биргән идем шул. Аннан ни булган? Тәртип бозып, азып-тузып йөрмәгән. «Сәйяр» труппасы куйган кичәләрне карарга бөтен Казан яшьләре йөри. Бернинди гөнаһысы юк.

– Тәүбә-тәүбә, нинди гөнаһ булсын. Алай дип әйтүем түгел. Йөрсен, ул гына артта калырга тиеш түгел заманнан. Заманасы шундый бит аның. Менә шул клубта бик итагатьле, бик тәртипле бер егетнең күзе төшкән кызыгызга. Шуны гына әйтергә теләвем.

Мәхүпҗамал Әминә кереп югалган якка борылып карады да сүзен дәвам итте:

– Нинди егет инде ул?

– Менә шул клубтагы бөтен кичәләрне оештырып, яшьләр күңелен күреп йөрүче иң затлы егеткә хуш килгән Әминәкәй. Шиһабетдингә. Менә шул Шиһабетдин үтенече буенча килдем дә инде. Каршы да килмәгез, сөенегез генә, бик затлы, бик уңган, булган егет. Күз өстендә каш. Алам дисә, Казанның бөтен кызларын үзенеке итәрлек.

– Әминә үзе ни дияр бит әле? Әйтәм бит, бала гына бит әле ул. Уналты яшьтә генә.

– Кызлар алар унике яшьтән балигъ була. Менә мин үзем ундүрт яшемдә чакта чыктым кияүгә. Бер дә ялгышмаганмын. Аллага шөкер, бик матур яшәп яткан көнебез. Утыз биш ел бергә торабыз. Ун бала таптым. Бишесе үстеләр, Аллага шөкер. Әл-хәмдүлиллаһ, әл-хәмдүлиллаһ!

– Ярар, Шәрифә абыстай, атасы вафат булса да, Әминә ятимә бала түгел, әби-бабалары, әнисе, туганнары бар. Аллага шөкер, җыйналышып сөйләшербез, киңәшербез. Хәл итәрбез.

– Бик яхшы, бик хуп. Озакка сузмыйча хәл итсәгез иде, Мәхүпҗамал абыстай. Җәй кергәнче, шушы апрель аенда ук башлы-күзле булып каласы килә Шиһабетдиннең. Тимерне кызуында сугу мәслихәт, дигәннәр борынгылар.

***

Әминәне Шиһапка кияүгә бирү-бирмәү буенча өйдә кызу гына бәхәсләр булып алды. Бу хәбәрне ишеткәч, җомга көнне аларга каладагы бөтен-туган-тумача җыйналды.

– Беләм мин ул кызыл авызны! Җәдитче! Искелекне себереп түгәргә, рус мәдәнияте кертергә дигән максат белән йөрүче бәндә! – дип, иң әүвәл Сабирҗан абзыйлары каршы төште.

Сабирҗан – этиләре Җамалетдинның энесе. Бикчәнтәй бабай авылда олы улы Бикмөхәммәт белән торып калган. Башка туганнар – Мөхәммәди, Җамалетдин һәм Сабирҗан, бер-бер артлы Казанга чыгып киткәннәр. Башта Мөхәммәди юл алган. Аннары аларның этисе Җамалетдин. Бикчәнтәй карт ярдәме белән калада үз эшен ачкан Мөхәммәди әле Салих туганчы ук

вафат булган. Шактый гына мал-мөлкәте, эше калган. Мөлкәтен һәм эшен Бикчәнтәй карт ризалыгы белән бердәнбер улы, бу вакытта әле балигълык яшенә җитмәгән Мөхәммәтгали белән, кече туганнары Сабирҗан бүлешкәннәр һәм уртак эш алып бара башлаганнар. Әминәне Шиһапка кияүгә яучылап килгәндә, Сабирҗан әле үзе дә өйләнмәгән, әмма дә инде олыгаеп бара торган, шактый гына хәлле тормыш алып баручы буйдак ир уртасы иде.

– Син алай кистереп кенә куйма әле, Сабир туган, Әминә үзе ни дип әйтә бит. Бу эштә алай ашыгырга ярамый, – диде Насретдин. – Әткәй мәрхүм ни дияр иде исән булса.

– Әти дә ашыкмаска киңәш иткән булыр иде, – дип, сүзгә Мөхәммәтгали кушылды. – Искелекне себереп түгәргә өндәп йөрүче ул кызыл авызны гаиләгә кертсәк тагын, йортны клубка гына әйләндерәсе кала инде.

– Клубка әйләнәме, юкмы, анысын тормыш күрсәтер, ә менә үзен йортка кертмичә булмаячак.

– Ник алай? – диде Мөхәммәтгали.

– Белмисеңмени, торыр урыны юк бит аның. Болгар кунакханәсендә номер алып тора. Әминәне үз янына кертмәс бит инде.

– Болай булгач, бигрәк тә икән.

– Сез, туганкайлар, кызмагыз әле. Берегез дә үзегез тапкан мал белән генә тормыш кормадыгыз. Бикчәнтәй бабай ярдәме белән кеше булдык барыбыз да. Әткәй үзе дә алдынгы карашлы кеше иде. Мине дә сыендырдыгыз, бабай ризалыгы белән, рәхмәт төшкере. Беренче вакытта безгә күчеп яшәр Шиһабетдин. Аллага мең шөкер, хәлебез бар, без күченербез Рауза белән. Төп йортта Әминә белән әнкәй, Салих калырлар.

Моңа хәтле дәшмичә тыңлап кына утырган, ләкин инде күңеле белән кызын Шиһапка бирергә риза булып беткән Мәхүпҗамал да, Насретдиннең шушы сүзләреннән соң үз сүзен әйтмичә булдыра алмады. «Югыйсә башта патша егетенә чыгам дип, ул да булмагач, солдатка булса да ярый, дип, өметләнеп яшәргә калганчы, алучысы барында биреп калырга кирәк», дип уйлап утыра башлаган иде.

– Дөрес әйтә кияү. Вакытында башлы-күзле итәргә кирәк кыз баланы. Син, Сабирҗан, кеше өйрәткәнче, үзеңне карасаң иде башта, – диде ул, Сабирҗанның авызын томалап.

– Нәрсә мин? Нәрсә мин? Миңа ни булган?!

– Берни дә булмаган. Шәрифә карчык әнә күршедә генә. Изге эш белән йөри. Җибәрер идең үзен берәр ирдән кайткан хатынга яучы итеп, болай кеше өйрәтеп утырганчы.

Мәхүпҗамал үзенең артык кызып киткәнен аңлап алды да:

– Үпкәләмә миңа, Сабирҗан, кызымны яклап кына әйтүем. Кайсы ананың баласын бәхетле итәсе килмәс. Кызымның гына түгел, бәлки минем дә бәхетем шул Шиһабетдин кияүдән булыр. Рәхмәт Насретдинга, чит итмәде, бер кәлимә авыр сүз әйткәне булмады. Сыендырды өчебезне дә үз канаты астына. Инде үз көнебезне үзебез күрер чак та җиткәндер, – дип, артык сүзгә юл калдырмыйча, бәхәскә чик куйды.

Берсе дә артык сүз куертып торырга батырчылык итмәде. Яучы Шәрифә карчык аша Шиһапка ризалыкларын белдерергә килештеләр.

***

Туй бик тантаналы үтте. Бик күп затлы кунаклар килде. Аларны шәһәрнең төрле почмакларыннан затлы фаэтоннар ташып кына торды. Кунакларның күбесе заманча, матур итеп киенгән, күлмәк изүләренә кара күбәләкләр таккан егетләр, бала итәкле, бөрмәләндереп теккән җиңле аллы-гөлле озын күлмәкләр кигән туташ-ханымнар – барысы да Салихның да, әнисенең дә күңелендә матур тәэсирләр генә калдырдылар. Яшьләр җырладылар, биеделәр, кем әйтмешли, егылганчы күңел ачтылар. Егылып ятучылар булмады, билгеле. Табында шәраб, хәмер дигән нәрсәләрнең эзе дә юк иде. Иң истә калганы шул булды: халык җыела башлагач, бермәлне кызлар чышын-пышын сөйләшергә тотындылар:

– Тукай! Тукай үзе килгән! Карагыз әле, күрегез!

Тәбәнәк кенә буйлы, авыру чырайлы, малайсыман күренгән ябык кына бу егетне Шиһап җизни үзе барып каршы алды.

«Тукай шушы микәнни инде ул?» – дип уйлап куйды Салих.

– Таныш бул, Тукай туган, минем кайниш Салих була бу! – диде Шиһап, аяк астында буталып йөргән малайлар арасыннан Салихны үзләре янына чакырып алып.

– Шулаймыни? – диде Тукай. – Габдулла абыең булам, минем дә нәни Апуш булып йөргән заманнарым кичә генә кебек әле, – дип, ул Салихка кулын сузды. – Нәрсә, җизнәң пәке бирдеме соң әле?

– Юк. Бирергә тиешмени?

– Тиеш. Әллә белмисең? – Шулай диде дә Тукай Шиһапка борылып: – Син нәрсә, йоланы бозасың? Шартын үтәргә кирәк, – диде. – Менә алайса, ал бу тиеннәрне, Печән базарыннан үзең барып алырсың, җизни пәкесе дип мактанырсың малайларга, – дип, кесәсеннән берничә көмеш тәңкә чыгарып, Салихның учына салды.

## 4

Салих Тукай турында күптән ишетеп белсә дә, болай якыннан аны беренче мәртәбә генә күрүе иде. Шиһап җизни аларның өенә күчеп яши башлагач, Тукай да аларда еш булгалый башлады. Тукай гына түгел, аларның өе Шәрык клубының бер филиалына әверелде, дисәң дә, ярыйдыр. Кемнәр генә килми аның җизнәсе янына. Шул заманның бөтен алдынгы яшьләре: матбагачылар, шагыйрьләр, артистлар, җырчылар. Тагын әллә кемнәр дә бардыр әле, Салих аларны белеп кенә бетерми, ә беләм дигәннәрен Шәрык клубында күргәне бар, шуннан чыгып кем икәнлекләрен таный.

Көннәрнең берендә өйдә Салих өчен бик файдалы хәл булып алды. Ул кеше югыннан файдаланып, гармун шыгырдатып утыра иде. Көтмәгәндә, ниндидер дуслары белән җизнәсе кайтып керде. Аларны күреп, Салих уйнаудан туктады да гармунын җыештырып куя башлады.

– Нигә туктадың? Уйна, уйна, әйбәт чыга бит, – диде җизнәсе.

– Бәй, кайнекәшең музыкант икән бит! – дип куйды аның дусларының берсе.

– Үземнең дә беренче күрүем.

– Яле, яле, уйнап күрсәт әле берәр үзең белгән көйне, – диде җизнәсе кебек үк мыеклы, тузгыган озын кара чәчле әлеге абый.

Салих, кайсын уйнарга икән дип, бераз уйланып торды да, әле беркөнне генә Печән базарында отып кайткан өр-яңа көйне уйнарга булды. Ул әле аның исемен дә белми, беренче ишеткәннән генә искә төшереп, әле кичә генә рәтләп уйнарга өйрәнде. Башта гармунын тарткалап, көйне искә төшерде дә сузып та җибәрде. Кичә көне буе шул көйне өйрәнеп утыруы ярады, ул аны бернинди тоткарлыксыз, җиңел генә башкарып чыкты.

– Каян өйрәндең моны? – диде дә көй уйнап күрсәтергә сораган абый, иптәшенә борылып: – Таныдыңмы, Габди, нинди катлаулы көй, – дип куйды.

– «Кәләү» түгелме соң?

– Шул үзе. «Кәләү Гайшә». Каян өйрәндең бу көйне, кем әле исемең? Әйдә, танышыйк әле, – диде дә, ул Салихның иңеннән кагып, аңа уң кулын сузды: – Заһидулла абыең булам мин.

– Мин – Салих.

– Каян өйрәндең инде бу көйне, Салих туганкай?

– Беркөн Печән базарында бер дустым Байтимернең бабасы уйнап күрсәтте үзенең скрипкәсендә.

– Яле, яле, кем инде ул?

– Әйтәм бит, дустым Байтимернең бабасы. Байтимер әйтә, минем бабай бер үлемсез көй белә, ди. «Нинди көй инде ул?» – дип сорагач, бабае янына алып барды. Шунда, базарда ук скрипкәдә уйнап, акча җыеп утыра икән. Миңа да: «Акча бирсәң, уйныйм», дигәч, – тиз генә өйгә кайтып, булган тиеннәремне санап алып килергә туры килде. Менә шул бабайдан ишеткән көй. Уйнаганын тыңлап тордым да өйгә кайткач уйнап карадым. Кичә көне буе шуны өйрәндем.

– Үзең генәме?

– Үзем генә.

– Гел ул бабай кебек уйнамыйсың бит. Бормалар кертеп җибәрәсең.

– Ә-ә, мин аларын үзем өстим. Матуррак булсын өчен.

– Афәрин! Менә булдырасың! Дөрес әйткән бабай, үлемсез көй бу. Әйдә, минем белән дә танышыйк инде, – диде Заһидулла абый Габди дип дәшкәне. – Габдулла абыең булам мин. Кариев.

– Ә-ә, артист абый.

– Күрдеңмени?

– Ие, күргәнем бар. Театр куясыз бит клубта.

– Ошыймы соң?

– Ошамаган кая.

Салих, «Минем дә уйнап карыйсым килә», дип әйтмәкче иде дә, кыенсынып, тотлыгып калды. Кариев абый малайның ни әйтергә теләгәнен сизгән шикелле:

– Малайлар роленә сине дә кертеп җибәрсәк була икән. Карарбыз әле, – дип куйды.

– Салихка рояль алып бирергә кирәк, Шиһап, – диде шулчак Заһидулла.

– Ә син уйнарга өйрәтерсең.

– Өйрәтербез, Алла боерса. Бик сәләтле егет булырга охшаган. Күрәсең бит, нинди катлаулы көйне алган, әле шуның өстенә үзеннән өстәп уйнап ята. Композиторлык чаткылары да юк түгел.

Менә шушы сөйләшү киләчәк язмышын хәл итте дә куйды Салихның.

Рояльле генә булып калмады, киләчәктә аның музыка юлыннан китәсен, гади музыкант кына түгел, композитор да буласын билгеләде. Әле биш-алты еллар элек кенә бармакларына Салихның бармакларын бәйләп куеп, аны гармунда уйнарга өйрәткән чакта Мәрьям апасы салган оеткы аны шушы юлга алып кереп китәргә насыйп иткән икән.

Озакламый Шиһап җизнәсе бәләкәйрәк кенә рояль дә кайтарып куйды өйгә. Заһидулла абый килеп уйнарга да өйрәтә башлады.

Мәрьям апасы шикелле бармакларын үз бармакларына бәйләп өйрәтмәде Заһидулла абыйсы. Салихның күргәне бар иде, музыкантлар рояль йә фортепиано капкачын ачып, алларына кәгазь бите куялар да шунда рәт-рәт итеп ясалган сызыкларга кунган нота дип аталган тамгаларга карап, көй чыгаралар. Менә шул тамгалар һәрберсе бер авазны белдерә икән. Һәр авазның, ягъни нотаның үз урыны бар. Клавишалардан чыккан тавыш әнә шул ноталарның яңгырашы икән. Дөньяда әллә ниткән тавышлар ишетелсә дә, төп музыкаль тавышлар җидәү генә икән. Ә татар җырларында аларның да бишесе генә файдаланыла, ди. Нигезендә биш кенә нота ятканга күрә татар көйләрен пентатоника дип атыйлар икән. Заһидулла абый клавишаларга баса-баса һәр нотаның ничек яңгыравын күрсәтеп чыкты. Тавышлар калын йә нечкә була бит. Калын йә нечкә тавышларның да төрлесе була: кайберләре тагын да калынрак, йә тагын да нечкәрәк. Шуңа карап ноталар да төрле клавишаларга баскалап, башкаручы тавышының калынлыгына, нечкәлегенә туры китерелә икән. Кыскасы, Заһидулла абый Салихка беренче дәресендә үк бик яхшы сабак бирде. Салихның җиде бармаклы гармунында гына ул җиде генә нота, җидесе дә бер калынлыктагы тавышта ишетелә. Ә менә рояльнең мөмкинлекләре чиксез. Салихка җизнәсе алып биргән рояль дә әле өйрәнчекләр өчен генә икән.

– Мөмкинлекләре азрак, беренче вакытка ярап торыр. Остаргач, җизнәңнән фортепиано алдырырбыз, – диде Заһидулла абыйсы.

Салих өчен монысы да зур бәхет иде инде аның. Гомумән, Әминә апасының Шиһап җизнәсенә кияүгә чыгуына сөенеп бетә алмый Салих. Шулхәтле тыйнак, әдәпле, ярдәмчел, беркайчан да, беркемгә дә тавыш күтәргәне юк. Әнисен дә «Әнкәй» дип кенә тора. Әле шулар өстенә дус-ишләре күпме үзенең. Барысы да билгеле кешеләр. Тукай үзе генә ни тора! Гафур Коләхмәтов, Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирхан, Кәрим Тинчурин, Заһидулла Яруллин, Габдулла Кариев, Нури Сакаев... Боларның барысын да Салих Шәрык клубы кичәләрендә күреп кенә түгел, җизнәсенең үз өйләренә килеп йөри торган дуслары буларак та бик яхшы белә. Күбесе белән үзенә дә соңрак аралашып, дуслар булып яшәргә насыйп итте.

Тукай белән төп-төгәл бер ел күрешеп, аралашып яшәү бәхете тиде Салихка. Апрель аенда, апасы белән җизнәсенең туенда якыннан танышканнар иде. Җизни кеше бирергә тиешле пәкене сатып алырга да акчасын Тукай биргән иде хәтта. Шуннан соң нәкъ бер ел үткәч вафат булды шагыйрь. Ә аңа кадәр әллә нихәтле күрештеләр алар. Габдулла Тукайның Шәрык клубында алдынгы карашлы яшьләрне җыеп, «Халык җырлары – халык күңеленең көзгесе» дигән лекциясен укуын да бөтен күңелен биреп тыңлады ул унөченче елда. Ул әле

Тукайның 1911 елда чыккан «Мәктәптә әдәбият дәресләре» дигән китабын да сүзен сүзгә, өтерен өтергә аерып укып чыккан иде.

Шиһап җизнәсе белән Тукай Казанга бер үк вакытта, 1907 елда, берсе – Буадан, икенчесе Җаектан килгәннәр икән. Кирәк бит, рәхмәт төшкере, икесе дә бер үк Болгар кунакханәсенә, кара-каршы номерларга урнашканнар, якын күршеләр булып яшәгәннәр. Икесенең дә шөгыльләре бер-берсе белән бәйле тагын: берсе – шагыйрь, икенчесе – нашир.

Салихның үз язмышы да Тукайныкы белән охшаш бит. Икесе дә бәләкәйдән ятимнәр. Ата назы күрми үскәннәр. Тукайга да, Салихка да тормышларында бәләкәйдән яхшы күңелле кешеләр очрап, игелекле бәндәләр булып үссеннәр өчен аталары кебек үк изгелекләр кылганнар. Төхвәтулла хәзрәт – Тукайны, Шиһап Әхмәров Сәйдәшне милләт өчен фидаиләр итеп тәрбияләп үстерүдә бәһаләп бетермәслек зур эш кылганнар.

Һәм, ниһаять, язмыш аларны тормышларының бер чорында бергә очраштырып, өлкәненең – яшенә, Тукайның Салихка язмыш юлын ачыклауда дөрес киңәшләрен бирүгә форсат ачкан. Нәкъ менә Тукайның киңәше белән Шиһап җизнәсе Салихның тәкъдирендә язылган сәләтен үстерү өчен бөтен тырышлыгын куйган кеше. Аның ярдәме белән ул үзенең алдагы тормышын музыка белән бәйләде, шушы юлда тиңе булмаган зур уңышларга иреште.

Шиһап Әхмәров үзе октябрь инкыйлабы белән рухланып, ул урнаштырган совет власте халыкларга тигезлек, хөрлек алып килә дип канатланып йөргән, башта әле шул инкыйлаб булсын өчен җанын-тәнен фида кылып, халык арасында бик зур аңлату эше, мәгърифәт нуры тарату буенча җиң сызганып хезмәт куйган бер фидакарь зат булды.

1917 елгы инкыйлабтан соң илдә совет власте урнашкач, шул елда мәгариф халык комиссариатының өяз бүлеге чакыруы буенча Буага мәдәният эшен оештыру белән шөгыльләнергә чыгып киткәннән соң шактый еллар читтә йөреп, Кызыл Армия сафларында хезмәт итеп, Оренбургта беренче татар бригадасы оркестрында капельмейстер, аннан соң Шәрык музыка мәктәбе мөдире булып эшләп йөргәннән соң, Сәйдәш 1922 елда Казанга тәмам өлгергән музыкант, беренче әсәрен иҗат иткән композитор булып әйләнеп кайткан чагында Шиһап җизнәсе китап нәшриятында эшли һәм үзара кредит җәмгыятенең идарә әгъзасы булып тора иде. Бер үк вакытта ул – күп кенә иҗтимагый-сәяси вакыйгаларның үзәгендә кайнаган җәмәгать эшлеклесе.

Ләкин 1922 елда тәмамланган гражданнар сугышыннан соң инде иректә матур тормыш корабыз, патша Россиясендә изелеп, бөлгенлектә, авыр тормышта яшәгән татар халкын бәхетле итәбез дигән идеаллар белән канатланган Шиһап Әхмәровның хыяллары 1929 елда чәлпәрәмә килеп җимерелде. Аны «халык дошманы» дип кулга алдылар һәм төрмәгә утыртып куйдылар. Менә хәзер, җәмгыять өчен кирәксез, артык кеше дип эштән куып чыгарылган Салих, үзен шул чакта репрессия корбаны булган җизнәсе белән бердәй хис итте. Ул да бит, асылда, бу җәмгыятькә кирәксез, артык бер кешегә әверелде. Аны да бернинди сәбәпсез-нисез, аңлатып-нитеп тә тормыйча, тоттылар да эштән чыгарып ташладылар. Әле ярый эштән генә чыгардылар...

**5**

Кияүгә чыккач, Әминә апасы да Шәрык клубы кичәләренә еш йөри башлады. Көндезләрен өй эшләре белән мәшгуль булса, кичләрен Шиһап җизнәсе Әминәне дә, Салихны да клубка чакыра. Клуб ерак түгел, Болгар номерлары урнашкан йортка терәлеп үк тора.

Беркөнне шулай «Сәйяр» труппасының спектаклен карарга бардылар. Шиллер дигән чит ил язучысының «Мәкер һәм мәхәббәт» дигән спектакле икән. Салих өчен мәкере ни дә, мәхәббәте ни, кем әйтмешли, икесе бер кәнди. Ә менә спектакль барышында оркестр уйнаганны карап утыру үзе бер рәхәт. Берьюлы ничә инструмент уйный бит. Скрипкә, мандолина, гитара, гармун... Өздерәләр генә. Салих шунда:

– Ну малай, скрипкәсе сыздыра гына! – дип кычкырып җибәргәнен сизми дә калды.

– Тавышланма! – дип кисәтү ясады җизнәсе.

Салих читенсенеп, як-ягына каранып алды. Аның тавышын ишетеп, алдагы рәтләрнең берсендә утыручы бер малай да борылып, аңа карап куйды. Салих ул малайның да музыкантлар уйнаганын исе китеп күзәтүенә игътибар итте.

Спектакль бетеп, тамашачылар таралыша башлагач, бу малай Салих янына килде дә:

– Ошадымы? – дип сорады.

– Музыкантлары бигрәк тә! – диде Салих. – Шәп уйныйлар бит, өздерәләр генә. Чын оркестр.

– Ә син каян беләсең оркестр дигән нәрсәне? – диде малай.

– Заһидулла абый сөйләде. Төрле инструментлар бергә уйнаса, оркестр була икән. Карале, син кем буласың? Әйдә, танышыйк, мин – Салих.

– Мин – Мансур. Менә шушы урамда ук торам. Әнә безнең өй, күренеп үк тора.

Ул клуб урнашкан йортның теге ягындагы, Салихлар яшәгән йортка терәтеп үк диярлек салынган бинага төртеп күрсәтте.

– Бәй, күршеләр икән бит без. Ничек моңа хәтле бер-беребезне белмәгәнбез? Без менә бу йортта яшибез бит. Сезнекенә терәлеп үк тора.

– Безнең өйләр бер-берсенә аркалары белән сөялешкән икән. Ишегалларыбыз икесе ике якка карый. Уйнарга төрле якларга чыгабыз. Шуңа күрешмәгәнбездер. Мин бу клубка күптән түгел генә йөри башладым әле.

– Мин дә апай кияүгә чыккач кына. Шиһап җизни алып йөри башлады. Җизни шушы клубта эшли безнең. Мондагы кичәләрне ул оештыра.

– Карале, минем җизни дә гел йөри бу клубка. Синең җизнәң белән танышлардыр да әле болай булгач. «Ялт-йолт» журналы редакторы ул. Әхмәт исемле, Урманчиев.

– Шулаймыни? Минем җизни дә нашир бит. Китаплар чыгара. «Мәктәп» дигән журнал чыгара. Алайса, безгә дә кергәләгәне булгандыр әле. Җизни көн саен бер көтү дустын ияртеп кайта. Мин аларга гармунда уйныйм. Әле менә беркөнне җизни рояль сатып алды минем өчен.

– Рояль?! – дип куйды Мансур гаҗәпләнгән кыяфәттә. – Рояль үкмени? Уйный да беләсеңме?

– Өйрәнә башладым инде. Заһидулла абый өйрәтә. Беләсеңме ул абыйны?

– Юк. Каян белим, ди?

– Бүген скрипкәдә шул уйнады бит инде. Сыздырды гына, малай.

– Шул идемени ул? Рояльдә дә уйныймы?

– Уйный гынамы, әйтәм бит, мине дә өйрәтә әле. Иртәгә керерсең, уйнап күрсәтермен. Берничә көй беләм инде.

– Мин дә мандолинада уйныйм бит. Миңа да җизни алып бирде. Пианино да алам дип әйтә, бераз уйнарга өйрәнгәч. Гармун да шыгырдатам.

– Әйбәт...

Мансур икенче көнне түземсезләнеп көтеп алды. Иртән торуга Салихларга барырга ашкынды. Ни кызганыч, ул аларның фатир номерларын сорарга оныткан. Кайсы ишектән керергә икәнен дә белми. Салихка да үзенең фатир номерен әйтмәде. Ул да кермәс инде. Кич тагын шул клубта күрешсәләр генә инде.

Шул вакыт аның башына даһи уй килде: түбәгә менеп карап торырга. Бәлки берәр ишектән килеп чыгар ишегалларына.

Чынлап та шулай булды. Мансур чорма баскычыннан менеп, түбәгә чыкты да Салихлар торган йортның өч ишеген дә күзәтергә тотынды. Йортлар бер-берсенә артлары белән торгач, ишегаллары түбәдән уч төбендәге шикелле әйбәт күренә иде. Моннан хәтта аларның ишегалдына сикереп төшәргә дә уңайлы икән, ике арадагы биек таш койма башына сикерәсең дә аннан – Салихлар ишегалдына. Салих озак көттермәде, уртадагы ишектән килеп чыкты да, ниндидер йомыш белән булса кирәк, урамга таба атлады. Ул арада китеп бармасын тагын дип, Мансур ике бармагын авызына тыгып, ачы итеп сызгырып җибәрде. Әйтерсең лә, үзенә сызгыруын сизгән, Салих ялт итеп артына борылып карады.

– Эһей! – дип кычкырды Мансур, Салихка кулын изәп.

Салих аны шунда ук күреп алды да шулай ук кул изәде.

– Нишлисең анда? Төш җиргә! – диде ул.

– Сине көттем!

– Нәрсә бар?

– Кая барасың?

– Әйдә, бергә. Насретдин җизниләр кибетенә барып киләсем бар. Анда эшне бетергәч, безгә кайтырбыз.

Мансур бая уйлаганча, түбәдән ике арадагы таш койма өстенә сикерде, аннан йортның теге башына хәтле барды да Салихлар ишегалдына сикереп төште.

– Аягыңны сындыра күрмә тагын. Булыр аннан, – диде Салих.

– Алла диген.

– Мин бит Насретдин җизнигә йомышчы булып йөрим. Йомышчы бигүк дөрес тә түгел инде. Теккән читек-кәвешләрен сатарга булышам. Минем бит тагын бер җизнәм бар. Әтинең сеңлесе Рауза апайның ире. Читек-кәвеш тегү белән шөгыльләнә. Үзләренең кибетләре бар. Менә шулар заказ буенча теккән читек-кәвешләрне адрес буенча тектерүчеләргә өләшеп йөрим. Көн саен өч-дүрт заказ була. Шуннан соң бушыйм. Әйдә, вакытың булса, бергә өләшеп кайтабыз. Заказчылар ерак тормаса, тиз бетә эш.

Насретдин җизнәләре дә ерак тормый бит. Печән базары чатында гына.

Алар кибеткә кереп, заказ буенча тегелгән читекләрне алдылар да адреслар буенча йөрергә чыгып киттеләр.

– Синең Тукайны күргәнең бармы? – дип сорады Салих Мансурдан.

– Бар. Шушы Шәрык клубында күрдем, әллә ничә мәртәбә. Ә синең?

– Һо, чиксез! – дип куйды Салих, мактанган кыяфәт чыгарып. – Минем Тукайга гармунда да, рояльдә дә уйнап күрсәткәнем дә бар! Әллә ничә мәртәбә ул сораган көйләрне махсус уйнадым хәтта. Ул Шиһап җизни белән безгә еш кергәли иде. Ә бервакытны мине һәм Солтан Рахманкулов дигән кешене номерына махсус чакырды, безнең уйнаганны тыңларга. Мин гармунда, Рахманкулов абый мандолинада уйнадык. Ул мандолинада уйнаганны тыңларга бик ярата иде.

– Чынмы? Эһ, мин булсаммы, минме... Күрсәтер идем мин аңа уйнап!

– Минем уйнаганны тыңлап торгач, аның: «Яхшы уйный бит, шельма! Музыкант чыгар моннан!» – дип әйткәне бар. Шулай бервакытны җизни бер төркем дусларын ияртеп кайткан. Араларында Тукай да бар. Чын менә, ихлас. Миннән рояльдә уйнавымны сорадылар. Тукай абый бер ягыма, җизни белән Гафур Колахмәтов икенче якка утырып, минем уйнаганны тыңладылар. Сәгатьтән артык уйнаганмындыр, валлаһи. Тукай абый шунда ике тапкыр рәттән «Зиләйлүк»не уйнатты. Беренче мәртәбә уйнаганда бик бирелеп, тын гына тыңлап утырды да, бетергәч, «Тагын бер уйна әле шушы көйне», – диде. Уйный башлауга, акрын гына, башта борын эченнән генә көйләп, аннары сүзләр белән үзе дә кушылды.

«Ишеттем мин кичә: берәү җырлый
Чын безнеңчә, матур милли көй;
Башка киләуйлар төрле-төрле, –
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.

Өзелеп-өзелеп кенә әйтеп бирә
Татар күңеле ниләр сизгәнен,
Мескен булып торган өч йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен.»

Шуннан җыр уртасындарак тавышын көчәйтеп җырлый башлады. Инде җыр бетә дигәндә, кисәк кенә көчле ютәлли башлады. Тамагы карлыкты, тамагыннан кан китте. Кан тамчылары клавишаларга кадәр чәчрәде. Бу Тукайның соңгы тапкыр безгә керүе булды. Берничә көннән аны Клячкин хастаханәсенә салдылар. Шунда ул җан тәслим дә кылды.

– Тукайның соңгы җыры, синең иҗатыңның башы булып чыга болай булгач?

– Бер караганда шулай да кебек инде, малай. Мине бик тетрәндерде бу вакыйга. Беләсеңме?

Алар шулай сөйләшә-сөйләшә, заказчыларның өйләренә йөреп чыктылар. Читекләрне таратып бетерделәр дә, Насретдин җизнәсенә акчаларны кайтарып биргәннән соң, Салихларга кайтып, музыка уйнарга утырдылар. Салих бөтен осталыгын күрсәтте Мансурга. Белгән барлык көйләрен диярлек башкарып чыкты. Гармунда да, рояльдә дә уйнады. Заһидулла абый аңа халык көйләрен генә түгел, композиторлар язган әсәрләрне дә

өйрәтә башлаган иде. Вальс, романс кебек нәрсәләрне дә белә ул хәзер. Ә иң кызыктырганы, көйне төрле уен коралларын бергә туплап уйнау иде Салих өчен. Оркестр белән уйнау. Ансамбль, икенче төрле әйткәндә. Салихның бик тә, бик тә шул ансамбльдә уйнап карыйсы килә иде. Бер-ике елдан бу хыялы да чынга ашты. «Свет» дигән кинотеатрда сеанс башланыр алдыннан кыллы оркестр тамашачыларга музыка уйнап, күңелләрен күрә икән. Заһидулла абый оештырган. Ул Салих белән Мансурны да шунда чакырып, гармунда уйнатты. Уенчыларның күбесе – төрле кибетләрдә приказчик булып эшләүче яшьләр. Аннары Проломная урамындагы Зур рус театрында кыллы уен кораллары оркестры оештырдылар. Оркестрда фортепьяно партиясен Салих Сәйдәшев башкара. Мансур – мандолинада. Мондагы уенчылар инде остарак. Күбесе төрле уку йортларында укучы шәкертләр – гимназистлар, студентлар. Хәбибулла Әхмәдуллин, Мөхәммәт Яушев – скрипкәчеләр, Ибни исемле приказчик – гитара чирттерә. Тамаша вакытында барысы да спектакль карый. Антрактта оркестр уйнап, тамашачыларның күңелен күрә. Тынлы уен кораллары оркестрында да уйнарга туры килде аларга. Монысында Салих – трубада, Мансур кларнетта моңланды.

Бер мажарага да юлыктылар Салих белән Мансур. Шулай бервакыт Салихның башына музыка уйнап, пароходта ял итүчеләрнең кәефен күтәрергә дигән уй килде. Беркадәр акча да юнәтеп булмасмы, янәсе. Булган бар вак-төяк сәмәннәрне җыйнап, Усиягә[1] төшеп киттеләр, пароходның дүртенче класс пассажирлары бара торган палубасына билет алдылар.

– Монда ял итүчеләрнең кәефләрен күтәрер өчен махсус музыкаль салон булырга тиеш, – диде Салих.

– Кайда икән соң ул? Бу безнең ише кара халык утырган дүртенче класс палубасында түгелдер инде.

– Музыка тавышы ишетелә түгелме соң?

Концерт-мазар юк иде бугай, бары тик кайсыдыр каютадан гына ниндидер марҗаның вальс көенә кушылып чырылдаганы яңгырый.

Музыкаль салонны эзләп йөри торгач, алар ап-ак япмалар белән капланган урындыклар тезелеп киткән матур бер залга килеп чыктылар.

– Менә шушы булырга тиеш, – диде Салих.

– Кеше юк бит монда, – диде Мансур.

– Хәзер, мин уйный башлауга җыелачак халык, – диде Салих.

Чынлап та, түрдәге почмакта кап-кара, ялтырап торган затлы рояль тора иде. Бер читтә бик яхшы киенгән, байлар икәнлеге әллә каян күренеп торган берничә әфәнде һәм хатын-кыз сөйләшеп басып тора. Салих рояль янына барды да, түгәрәк әйләнмәле урындыкка утырып, рояльнең капкачын ачты һәм клавишаларга баскалый башлады. Музыка тавышын ишетеп, залга бер хезмәткәр килеп керде дә, йөгереп диярлек барып, Салихның якасыннан эләктереп алды.

– Нишләп йөрисез монда, базар шпаналары! – дип кычкырды да, хезмәткәр, ямаулы чалбар, кыскарып беткән җиңле иске күлмәк кигән, чынлап та базарда урлашып йөргән йолкыш малай-шалайларга охшаган

[1] Усия – Казан елга портының элекке исеме.

Салихны өстерәп диярлек беренче категорияле салоннан куып чыгара башлады. Салонда җыелып торган әфәнделәр аларга карап шаркылдап көлергә тотындылар.

– Булмады бу, – диде Салих. – Барып чыкмады. Төшеп калырга туры килер, ахры.

Алар пароходтан беренче тукталышта ук төшеп калдылар. Богородицкий дип язылган пристаньда Казанга кайта торган пароходта да малайларны әфәнделәр ял итә торган салоннарга якын җибәрмәделәр.

**6**

Салих Заһидулла абыйсы Яруллиннан беренче музыкаль күнекмәләр алган, балачак дусты Мансур Мозаффаров белән төрле залларда беренче чыгышлар ясап йөргән чакларын искә төшерде. Шул елларда ул музыкаль белемне профессиональ нигездә үзләштерергә кирәк дигән карарга килде. Насретдин җизнәсенең сүзен тыңлап, сәүдә училищесына кергән булса, музыкага булган мәхәббәте аны музыка училищесына алып килде. Биредә ул Осип Родзевич классында үзенең Заһидулла Яруллиннан алган, махсус дәресләрдә үзләштергән уйнау осталыгын һәм музыкаль белемнәрен тагын да тирәнәйтте, ныгытты. Бер үк вакытта аның композиция, музыка иҗат итүгә омтылышы көчәйде. Бу вакытта ул үзенең тормышын музыкадан башка күз алдына да китерә алмый иде инде. Унҗиденче елда Сембер Өяз халык комиссариаты чакыруы буенча бер төркем музыкантлар, артистлар, мәгариф хезмәткәрләре белән Буада эшләп алганда да, гражданнар сугышы башлангач, үз теләге белән Кызыл Армиягә алынып, Урта Азиядә басмачларга каршы сугышып йөргән чакларында да, аннан соң Оренбургка барып чыккач та, ул гел музыкант сыйфатында хезмәт итте. Оренбургта хәтта композитор буларак үзен сынап карады, «Озын сәфәр» дип аталган беренче әсәрен иҗат итте. Оренбургта Шәрык музыка мәктәбе мөдире булып эшләгәндә, берүк вакытта оркестр классында укытып, балаларга оркестровка буенча белем биргәндә, үзе дә әсәрләрне оркестр өчен эшкәртү күнекмәләрен үзләштерде.

1922 елның көзендә Салих Казанга әйләнеп кайтты. Аның кайтуына шатлык-сөенечләренең чиге-чамасы булмады Казандагы туганнарының. Ул туп-туры Шиһап җизнәсе белән Әминә апасы өенә кайтып төште. Бу вакытта инде алар элекке Варламовская урамындагы өйләреннән Икенче Тау урамына күчкәннәр иде. Ике катлы йортның беренче каты тулысы белән аларныкы. Гаилә шактый ишле. Әминә апасының инде өч баласы үсә: Үзбәк, Гөлнара һәм Җанбәк. Салихларның әнисе Мәхүпҗамал белән җизнәсенең әнисе Зөләйха, җизнәсенең сеңлесе Зәйнәп белән энесе Хәйрулла һәм этисенең Өбрәдәге абыйсы Бикмөхәммәтнең кызлары Сәгадәт белән Зәкия. Кыскасы, өйдә күңелле. Һәркемнең үз шөгыле, үз эше. Ике кодагый Шиһап белән Әминә балаларын карый, Өбрә кызлары өй эшләрендә булышалар, аш-су пешерәләр. Зәйнәп университетта укып йөри, медицина факультетында, булачак табибә. Жизнәсе Шиһап белән аның энесе Хәйрулла өйдә сирәк булалар икән, җизнәсе үзенә яңа эш тапкан, булышырга авылдан энесе Хәйрулланы да чакырып китергән.

– Идел аръягында авыл салабыз, – диде җизнәсе, эш турында сүз чыккач.

– Нинди авыл?

– Кызыл Байрак.

– Нәрсә, булган авыллар җитмимени халыкка яшәргә?

– Җитә. Бер идея туды монда безнең башта. Иван Грозный Казанны алгач, татарларны су, елга буйларында яшәүдән тыйган бит, аларны елгалардан кырык чакрымга читкә куган. Иделнең уң як яр буйларында зур-зур мәйданнар буш ята. Ара-тирә өч-дүрт рус авылы – Шеланга, Тәмте, Антоновка – берсеннән-берсе егерме-утыз чакрымда утыралар. Республиканың төрле районнарыннан бер-берсенә якын урнашкан, чәчүлек җирләре бик аз булган татар авылларыннан крәстияннәрне менә шул буш яткан җирләргә күчереп, татар авыллары салырга дигән фәрман чыгарды хөкүмәт. ТатЦИК председателе урынбасары Али Ганиев белән мин менә шул эш белән шөгыльләнәбез бүгенге көндә. Хәйрулла энекәшне дә чакырып китердем авылдан. Минем өстә Кызыл Байрак авылын төзетү. Бакчасарай, Берек, Нариман, Шура авылларын төзү бара.

– Кызык икән, – диде Салих. – Миңа да эш чыкмасмы шунда? Клуб мөдире итеп куйсагыз, бу тирә авылларда яшәүчеләргә мәдәни хезмәт күрсәтүне оештырып җибәрер идем. Дуслар күп бит минем артистлар арасында.

– Синең кебек белгеч өчен бу эш кенә бәләкәй булыр. Колачлырак, масштаблырак эшләр көтә сине, каениш.

– Нинди эшләр инде ул?

– Казанда Кызыл Октябрь исемендәге Татар дәүләт театры оештырылды бит. Бу эшне Кәрим Тинчуринга йөкләделәр. Шәрык клубында уйнап йөргән син белгән «Сәйяр» труппасының дәвамы инде бу. Тагын да зуррак аудиториядә, җитдирәк итеп эшли башлау өчен мөмкинлекләр ачыла.

– Бинасы бармы соң? Рус Зур театры сыман.

– Бина мәсьәләсе дә хәл ителде. Вознесенский урамындагы «Сәүдәгәрләр җыены» бинасын беләсең бит. Менә шул «Мәдәният йорты» дип үзгәртелде. Татар дәүләт театры шул бинада эшли башлады. Теләгең булса, хет бүген үк барып киләбез. Егетләр бик дәртләнеп эшкә керештеләр. Барысы да шул синең танышлар, дуслар.

Теләмиме соң инде?! Ничек кенә тели әле.

Алар театрга җәяүләп кенә барырга булдылар. Өч-дүрт елда шәһәр нык үзгәргән, Салихның яңа тормыш белән яши башлаган каланы күрәсе килә иде.

Шуңа игътибар итте Салих: һәркайда кызу сәүдә кайный. Икенче Таудан таш түшәлгән юл буйлап Балык базарына хәтле төштеләр. Монда да һәркайда сату-алу бара.

– Нәрсә бу? Патша заманы кире кайттымы әллә? Бар да сату итә, – дип сорады Салих.

– Нигә, белмисеңмени, Ленин яңа икътисади сәясәт игълан итте бит. НЭП. Былтыргы ачлыктан кырылган халыкның тормышын көйгә салмакчылар большевиклар.

– Яңадан үзләре үк юк иткән тәртипләрне кире кайтаралармыни? Сәүдәгәрләр байый башлаячак бит.

– Шунысы куркыта да. Яңа байларны юк итәбез дип, кызыл террорны тагын да көчәйтергә мөмкиннәр. Аннан соң инде хана. Шуңа күрә сәүдә эшеннән читтәрәк торырга кирәк дип уйлыйм. Насретдин баҗайга да әйтеп карадым. Тыңламый, канына сеңгән сәүдәгәрлек.

– Башка һөнәре булмагач, нишләсен инде. Тормыш алып барырга кирәк бит. Син аңа Кызыл Байрак турында әйтеп карамадыңмы соң?

– Ул белә. Теләге юк. Монда эшем көйле бара, ди.

– Җизни, барып килергә иде, минем дә күрәсе килә башлады ул Кызыл Байракны.

– Барырбыз әле. Иделдә боз катсын. Ноябрь ахырларына бәлки суытыр да инде. Үзем дә өйдә ятам. Пароходлар да тукталды.

– Шулайдыр шул.

Сөйләшеп, Вознесенский урамындагы кибетләрне карый-карый бара торгач, алар Варламовская урамы чатында урнашкан элекке «Сәүдәгәрләр җыены» йортына килеп җиткәннәрен сизми дә калдылар.

– Мәдәният йорты шушында буламыни инде? – диде Салих.

Урам ягы еректан ук үзенең затлы бай сәүдәгәрләр белән бәйле икәнен сөйләп торган ике катлы бу йортның ишегалдында, аңа өстәп салынган бинада элекке елларда йорт хуҗасының хезмәтчеләре яшәгәнен, беренче кат тулысы белән ат абзарлары, хуҗалык каралты-куралары урнашкан булуын Салих яхшы белә иде.

– Мәдәният йорты урам ягындагы шушы затлы өлештә. Ишегалдындагы бинада ике катында да артистлар, хезмәткәрләр яши хәзер, – диде Шиһап, арка сыман итеп ясалган капка яныннан узганда. – Кемнәр икәнен соңыннан үзең күрерсең әле.

Театрда репетиция бара иде. Артистлар кызып-кызып, рольләрен кабатлыйлар. Эш сәхнәгә үк менгән.

Шиһап белән Салих тамаша залына керделәр дә, комачауламаска теләп, шыпырт кына карап тора башладылар. Сәхнәдә барысы да Салихка күптән таныш артистлар: Барый Тарханов, Нури Сакаев, Фатыйма Ильская, Нәфига Арапова, Мохтар Мутин һәм Такташ.

«Такташ? Ул нишләп йөри сәхнәдә?» дип уйлап куйды Сәйдәш.

Репетицияне залдан утырган килеш Кәрим Тинчурин алып бара. Шунда ул Такташның үзен тотышына ризасызлык белдереп, сикереп кенә, сәхнәгә күтәрелде һәм залдан уйнаучыларны күзәтеп утыручы, өстенә шинель кигән бер егет белән Шиһапны күреп алды.

– Салих! Син түгелме соң?! – дип кычкырып җибәрде Тинчурин һәм киредән залга йөгереп төште дә алар янына килеп, Салихны кочаклап алды.

– Мин, Кәрим абый! Мин, менә кайттым, – диде Салих.– Шинелемне дә салмыйча сезне күрергә ашыктым.

– Менә шәп булган!

Тинчурин артыннан сәхнәдәгеләр барысы да алар янына төштеләр. Репетиция өзелде.

– Син кирәк идең безгә, әйбәт булган кайтуың. Татар дәүләт театры ачылды бит, – диде Тинчурин.

– Ишеттем. Менә шуңа күрә дә кайтып төшүгә яныгызга ашыктым. Шатлыгыгызны уртаклашам.

– Рәхмәт. Бер спектакль чыгардык инде. Фәтхи дустыңның «Җирсезләр»ен куйдык. Менә икенче спектаклебезне әзерлибез. Такташны куябыз. «Җир уллары трагедиясе». Тиздән премьера.

– Әйе. Исәнме, Салих дускай! – дип, алар янына килеп баскан Һади Сәйдәшне кочаклап алды.

Аның артыннан башкалар да берәм-берәм Салихны кочып күрешеп чыктылар.

Салих Такташ белән беренче тапкыр ике ел элек кенә Ташкентта очрашканнар иде.

Такташның үсмер еллары Бохарада уза. Биредә ул үзләренә кардәш тиешле бер сәүдәгәрнең кибетендә йомышчы малай булып йөри. Шунда чакта үзенең беренче шигырьләрен яза. Аннан соң аны язмыш Оренбург якларына алып чыга. 1920 елда Җаек буйларында корылык башлана, иген уңмый. Егерме яшьлек бунтарь шагыйрь Ташкентка күченеп китә. Бу вакытта Беренче мөселман Кызыл Армиясенең капельмейстеры һәм трубачысы Сәйдәш һәм яшь шагыйрь Такташ очрашалар һәм берничә ай бергә аралашып яшәп, гомерлек дусларга әйләнәләр. Такташ ул чакта Ташкентта яшәп кала, ә Сәйдәш киресенчә, халык мәгарифе бүлеге чакыруы буенча Оренбургка китә.

Әллә ни күп вакыт узмаса да, дуслар сагынышканнар иде.

– Сез танышлармыни? – дип сорады Тинчурин, аларның кочаклашып күрешкәннәрен күреп.

– Танышлар гынамы, бер телем ипине бүлешеп ашаган дуслар, – диде Салих. – Ач үлемнән Ташкент алып калды безне.

– Дустыңның даһи шагыйрь, драматург икәнен беләсеңме соң? Менә сәхнә өчен искиткеч шәп әсәр язган: «Җир уллары трагедиясе». Шуны куярга хәзерләнеп йөрибез.

– Әллә син дә театрда эшлисеңме? – дип сорады Салих дустыннан.

– Суфлёр ул безнең, – диде Тинчурин. – Менә артист та булырга тора. Төп рольләрнең берсен башкарачак.

– Бирсен Ходай. Булганнан бар да була.

Кәрим Тинчурин шунда артистларны яңадан сәхнәгә куа башлады. Премьерага берничә көн генә калган. Ашыгырга кирәк иде.

– Әйдәгез, сәхнәгә, сәхнәгә! – диде ул. – Дустыгыз белән репетициядән соң сөйләшергә дә өлгерерсез. Мин әле киләчәктә бер коллективта эшләрбез дип тә уйлап торам. Шулай бит, Салих дускай? – дип, ул Салихның үзенә мөрәҗәгать итте.

– Начар булмас иде. Һади да рольгә кергән бит әнә.

– Ул инде ничарадан бичара дип кенә. Кабилне уйнаучы артистыбыз чирләп китте. Ә сине башка эш көтә театрда.

Ул шулай диде дә, артистларга үзләренә генә репетиция үткәрергә кушып, Салих белән Шиһапны ияртеп, залдан алып чыгып китте.

– Әйдәгез, Зәки янына керик әле. Баязитский хәзер безнең директор бит. Күптән сөйләшәбез инде синең турыда. Салих булса, шәп булыр иде дип.

– Үзем дә шуны уйлап алып килдем каенишне, – диде Шиһап. – Беренче спектаклегез начар булмады. Ләкин музыка җитми иде. Музыка, җыр кирәк спектакльгә. Җыр күтәрә рольне. Салих ничә ел инде, әле армиядә, әле музыка мәктәпләрендә, әле төрле түгәрәкләрдә, оркестрларда эшләп, чын музыкант булып җитешкән. Профессиональ сәхнә өчен бер дигән музыкант булачак.

– Без дә шул хакта сөйләшәбез монда үзара. «Җир уллары...»на соңладык инде. Алда тагын бер җитди эш тора: Хәбибулла Ибраһимовның

«Башмагым» комедиясен куярга уйлыйбыз. Шуны җырлы-биюле музыкаль комедия иттереп чыгарасы иде.

Директор Зәки Баязитский Тинчурин сүзләренең хаклыгын алар бүлмәгә килеп керүгә үк раслады.

– Менә бит, бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына, диләрме әле?! Синең турыда гына сөйләшеп утырган идек. Кайттыңмыни, Салих? Эшкә урнашмагансыңдыр бит әле?

– Бүген генә кайтып төште. Чәйләр генә эчтек тә сезнең янга йөгердек, – диде, Салих өчен җавап биреп, Шиһап җизнәсе.

– Әйбәт иткәнсез. Вакытның һәр минуты кадерле безнең өчен. Бик дөрес иткәнсез, – диде Баязитов.

– Артистлар белән көреште дә, синең янга ашыктык, Зәки. Салихны бүгеннән үк музыка бүлеге мөдире итеп билгелик тә, эшне башласын. Сөйләшкәнчә, «Башмагым»ны музыкаль комедия итеп чыгарырга кирәк. Пьесаның бер нөсхәсен биреп кайтарыйк, укып чыксын. Кайда нинди музыка, җыр соралганын карасын.

– Ничек, Салих, син ризамы?

– Карап карарга кирәк. Нинди материал бит, – диде Салих.

– Материалы кызыклы. Җыр-бию сорап торган урыннары җитәрлек. Бер дигән халык җырларын кертеп җибәрергә була. Ярар, сиңа өйрәтеп торасы түгел. Үзең укып чык башта, – диде Тинчурин.

Театрны оештырганда, аның структурасы хакында сөйләшкәндә, үз оркестрын булдыру турында да сүз барган иде. Һәм бу эшне нәкъ менә Сәйдәшевкә тапшыру дөрес булыр дигән фикергә киленде ул чакта. Аның башкару осталыгына гына түгел, оештыру осталыгына да игътибар ителде. Әле малай чагыннан ул төрле клубларда, рестораннарда инструменталь ансамбльләр оештырып, чыгышлар ясап йөрүләрен искә алдылар. Армиядә, Ташкентта, Оренбургта шушы эшне бик яхшы алып баруы хакында сөйләделәр.

– Аннан соң, Салих дус, спектакльләрне музыка белән баету турында гына сүз бармый, театрның үз оркестрын булдыру буенча хәл кылынды. Акрынлап оркестрны туплый башлау турында да кайгыртырга кирәк. Син музыкантларны яхшы беләсең. Казанда булмаганнарын читтән эзләргә кирәк, Әстерханнан, Оренбургтан, Ташкенттан чакыртып кайтарырга. Барысы да сиңа таныш булган җирләр, – диде Зәки Баязитский.

– Яхшы, сөйләштек. Салихка эш эзләп баш ватасы калмады болай булгач, – дип, каенише өчен Шиһап Әхмәров ризалык җавабын бирде.

– Шиһап дускай, синең бүген монда килеп чыгуың баягы, бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына, дигән сүзне тагын бер кат раслый бит әле, – дип, Баязитский сүзен Шиһапка күчерде. Аны театр оештыру белән шөгыльләнә башлаганнан бирле бу кеше белән очрашып сөйләшергә кирәк дигән уй борчый иде. Бу сөйләшү өчен шушы очрашудан да уңайлы момент булуы мөмкин дә түгел, дип уйлады ул.

– Нинди сүзең бар, Зәки туган? Тыңлыйм, рәхәтләнеп.

– Бик мөһим бер мәсьәлә турында сөйләшмәкче идем. Бик зур эш башлап җибәргәнсез дип ишеттек. Идел аръягында татар авыллары төзи башлыйсыз икән.

– Әйе шул. Хөкүмәтнең махсус карары нигезендә Идел аръягында буш яткан җирләрдә чәчүлек мәйданнары аз булган авыллардан крәстияннәрне күчереп, татар авыллары төзү эшенә керештек. Бу эш белән ТатЦИК председателенең урынбасары Али Ганиев үзе командалык итә.

– Шулай икән шул. Сине дә шул эш белән йөри дип ишеттек.

– Кызыл Байрак авылын төзү минем өстә.

– Бик матур җирләр инде ул. Беләбез. Шеланга – Теньки авыллары арасында. Менә шул авылда безнең театр хезмәткәрләре өчен дә дача йортлары салырга җир алып булмас микән дигән идек.

– Шәп идея бу. Нишләп булмасын икән. Булыр. Оештырырбыз. Кемнәргә кирәк, исемлекләрен төзегез. Әлегә урман кисү бара. Анда бит йорт салу өчен бер дигән төз наратлар үскән урман. Балта осталары ялладык. Кышын агачын киссәк, кышкы агач бура өчен бик әйбәт диләр осталар, ә җәйләргә йортлар сала башларга исәп. Артистлар өчен дә йортлар салырга планлаштырырбыз.

– Бик әйбәт булыр иде.

– Килештек, алайса. Ярый, без китик.

Шиһап шулай диде дә, урыныннан торып ишеккә таба атлады.

– Тукта, тукта, Салихка пьесаны бирергә кирәк, ашыкмый торыгыз, мин хәзер, – дип, Кәрим Тинчурин алданрак чыгып китте.

**7**

«Җир уллары трагедиясе»нең премьерасы Такташның да, Салихның да якын дусты Әсгать Мәҗитов бенефисы итеп үткәрелде һәм көтелгәннән дә уңышлы булып чыкты. Спектакль Такташның популярлыгын тагын да югарырак күтәрде. Казанга каяндыр Ташкент якларыннан кайтып төшкән һәм Казан шагыйрьләреннән үзенең дуамаллыгы, шул ук вакытта ничектер үзенә генә хас мифологик, символик образлар аша кешенең рухи хөрлеген данлаган, дини хорафатларга, социаль гаделсезлеккә каршы ярсулы көрәш, гыйсъянчылык идеяләрен алга сөргән шигырьләре белән аерылып торган, яшьләр арасында популярлык казана башлаган яшь шагыйрь яңа яктан ачылып китте. Аны халык күтәреп алды. Һәркайда Такташ катнашкан кичәләр аншлаг белән үтә башлады.

«Җир уллары трагедиясе» куелган саен залда тамашачы шыгрым тулы була иде. Татар театрының да даны үскәннән-үсте. Алда яңа премьера – «Башмагым». Театрның бер яуланган абруен төшерергә ярамый иде. Шуңа күрә артистлар яңа тамашага тагын да җитдирәк, тырышыбрак хәзерләнделәр. Салихка да зур өметләр багладылар.

Салих пьесаны кат-кат укып чыкты. Бер карашка гади генә сюжетка корылган комедия кебек. Халыкчан, үзебезнең мещаннар тормышыннан алынган көлкеле бер әсәр. Халык көйләрен файдаланырга була, дип уйлады Салих. Пьеса үзе дә «Башмагым» дигән халык көе нигезендә язылган булса кирәк. Шул көйне файдаланырга кирәк, һичшиксез. Аннары «Җизнәкәй» җырының көе пьесага ятышып тора бугай. Комедиянең авторы белән күрешеп, берничә җыр тексты яздырып алганда да начар булмас иде.

Салих икенче көнне эшкә килгәч тә, Тинчуриннан иң элек автор хакында сорады.

– Авторы юк, – диде Кәрим.

– Ничек инде юк? Авторсыз әсәр буламыни?

– Авторы Уфада. Хәбибулла Ибраһимов җыр язар өчен генә Уфадан тиклем монда килеп йөри алмый бит инде. Спектакльне чыгарыр көн дә килеп җитеп бара. Әллә ни маташтырмыйча гына, музыкаль бизәлеш ясарга да чыгарырга кирәк.

Салих сүзсез генә килеште. Спектакльнең башында уйнар өчен кереш музыкасы кирәк иде. Җиһан карчыкның сәхнәгә килеп чыгу күренешен матурлар өчен махсус бию көе язды да әлеге шул «Башмагым» белән «Җизнәкәй» көйләрен төрле вариацияләрдә эшләп, җыйнак кына бизәлеш ясады.

Музыка белән генә бетми иде әле эш. Иң мөһиме, бу көйләрне башкару өчен оркестр тупларга кирәк иде. Ул «Шәрык» клубы кичәләрендә уйнаган барлык музыкант дусларын барлап чыкты. Аларның күбесе гражданнар сугышы елларында Казаннан төрле яры таралышып, Салих кебек үк, кайсы Кызыл Армиядә, кайсы Урта Азия якларында, Оренбургта эшләп йөрделәр дә, акрынлап, берәм-берәм яңадан Казанга җыйналыша башлаганнар иде.

Исмәгыйль Һилялов, Мөхәммәт Йосыпов, Хәбибулла Әхмәдуллин, Сәгыйт Алиев, Мөхәммәт Яушев, Исмәгыйль Вәлитовлар театр оркестрында уйнарга бик теләп алындылар.

Премьерага Әхмәровлар гаиләсеннән ике кодагый әбиләрдән һәм балалардан кала барысы да бардылар. Барысының да Салихның Казанга кайткач, беренче эшен күрәселәре килә иде. Премьера болай әйбәт кенә, күтәренке рухта үтте. Сәйдәш дирижёрлык итте. Тамашачылар да, артистлар да канәгать калдылар кебек. Ләкин Салих үзеннән канәгать түгел иде. Ничектер музыкантлар кысылып уйнадылар шикелле тоелды. Монда ул үзен гаепләде. Тиешле дәрәҗәдә дирижёрлык итә алмады бугай. Инструментларның ярашып уйнавы да тиешле дәрәҗәдә түгел кебек иде.

– Булдырдың, әйбәт чыкты, – диде җизнәсе, спектакльдән соң аның кулын кысып.

– Нәрсәдер җитмәде шикелле. Армиядә тынлы инструментлар белән уйнап өйрәнелгән. Монда башкачарак кирәк. Көйләрне үземә иҗат итәргәдер бәлки. Күңелем белән сизәм, ләкин билгеле көйләргә импровизация ясап кына биреп бетереп булмый әйтергә теләгән фикерне.

– Беләсеңме, нәрсә җитми? – диде җизнәсе.

– Беләм!

– Нәрсә?

– Белем! Белем җитми, җизни. Укырга кирәк. Консерваториягә керергә. Әле яшь чакта укып калырга кирәк. Аннан соң, Тукай әйтмешли, «картаеп буыннар каткач, эш белү уңайсыз ул», соң булырга мөмкин. Гаилә мәшәкатьләре басып китәргә мөмкин.

– Дөрес әйтәсең. Училище белеме генә җитми. Тирәнәйтергә кирәк белемнәрне. Гомереңне музыкага багышларга уйлагансың икән, җитдирәк шөгыльләнергә кирәк. Төплерәк белем алырга.

Икенче көнне театрда премьера турында сөйләшү, артистларның уенына анализ булды. Музыка хакында да сүз булмый калмады, әлбәттә. Беренче булып, сүзне Салих алды.

– Мин артистларның уйнавыннан канәгать калдым, җәмәгать, – дип башлады ул сүзен.

– Бигрәк тә Нәфиганың башына төенчек куеп, син язган көйгә бии-бии чыгуы уңышлы булды, – дип бүлдерде аның сүзен Хәким Сәлимҗанов.

– Бәлки шулайдыр, тик мин үз эшемнән канәгать калмавым хакында әйтмәкче идем.

– Үзтәнкыйть – әйбәт нәрсә ул, җәмәгать. Шулай да, минемчә дә спектакльдән тамашачы канәгать калды кебек, – дип башлады сүзен Кәрим Тинчурин. – Ләкин уңышлардан баш әйләнергә тиеш түгел. Һәрберебезгә дә үз өстендә эшләргә кирәк әле. – Кәрим премьера турында сөйләүдән бигрәк алдагы планнар турында сүзгә күчте. – Ел тәмамланып килә. Алда Яңа ел, яңа премьералар. «Башмагым» чыкты. Хәзер аны куйган саен шомартып, кире кайтып эшләмәслек итәргә кирәк. Гыйнварга – «Казан сөлгесе». Бүген читка. Салих, сиңа да киң фронт ачыла анда. Халык җырларыннан файдаланып, өлкәннәр белән яшьләр арасындагы каршылыкларны артык купайтмыйча гына, матур итеп күрсәткән музыкаль комедия чыгарасы иде. Текстны алып кара. Анда шактый гына фольклор кертергә дә була. Яшьләр уеннары. Заман проблемаларын яктырткан нәрсә булырга тиеш дип уйланылган пьеса. Авторы – үзем.

Сөйләшү тәмамлангач, Салих пьесаның бер нөсхәсен сорап алып, шинеленең куен кесәсенә тыкты да, Шәрык музыка техникумына китте. Исәбе әле музыка училищесында укыганда фортепиано буенча дәресләр алган укытучы, профессор Ксаверий Александрович Корбут белән очрашу иде.

Инде биш елдан артык, училищены тәмамлаганнан бирле күрешкәннәре булмаса да, Корбут Салихны таныды.

– О, Салих Сәйдәшев үзе! – дип каршы алды ул аны, ишегеннән керә-керешкә.

– Исәнмесез, Ксаверий Александрович!

– Нинди җилләр ташлады инде бу якларга? Күптән тавыш-тыныгыз юк иде. Кайларда йөрдегез? Ниләр күрдегез? Нәрсәләргә ирештегез? – дип, сораулар яудырды профессор.

– Кайда гына булмадым, Ксаверий Александрович, ни генә эшләсәм дә, музыка белән бәйле булды. Менә Казанга әйләнеп кайттым. Татар театрына музыка бүлеге җитәкчесе итеп эшкә алдылар. Эшнең очы-кырые юк. Бик җитди хезмәткә җиктеләр. Үземдә белем җитмәвен аңладым. Сезнең ярдәм кирәк.

– Бик әйбәт. Белемеңне тирәнәйтергә теләвең бик яхшы.

– Чигарина белән Юшковалардан да фортепьяно буенча осталыкны тирәнәйтәсе иде. Спектакльләрнең музыкаль бизәлеше буенча эшләү гармония өлкәсендәге белемнәрнең дә сайлыгын күрсәтте.

– Үзеңә тәнкыйть күзлегеннән карау бик яхшы. Югыйсә күпләр мин беләм дип тотыналар да, берни дә барып чыкмый, чиле-пешле нәрсәләр тудырып, үзләрен даһи итеп күрсәтергә телиләр. Ә синнән кеше чыгар, болай булгач. Сөйләшермен, Литвинов белән дә, Виноградов белән дә. Белергә тырышуның гаебе юк, ярдәм итәрбез.

– Рәхмәт, Ксаверий Александрович. Миңа, болай булгач, график төзеп, дәресләргә йөри башларга иде.

– Мин риза. Бүген үк булмый инде, иртәгәдән тотынырбыз. Менә шушы вакытка көтәм. Башта фортепиано буенча үткәннәрне кабатларбыз. Аннан акрынлап, композиция буенча шөгыльләнергә күчәрбез.

Салих рәхмәтләр укып чыгып китте.

Өйгә кайтса, анда Зәйнәп белән ниндидер сөйкемле генә бер кыз зал ягында китаплар караштырып утыралар иде. Зәйнәп Казан университетының медицина факультетында укый. Татар кызлары арасында бу уку йортына керүче бик сирәкләрнең берсе.

– Сәлам кызларга! – диде Салих, аның кайтып керүен күргәч, аягүрә торып баскан кызлар янына килеп. – Нишлисез, имтиханга әзерләнәсезме? Тиздән сессия бит.

– Шулайрак иде эшләр. Менә анатомия дәреслеген карап утырабыз. Кеше төзелеше фәнен.

– Карагыз, кара. Сез кешенең тән төзелешен өйрәнегез, ә мин рухи төзелешен өйрәнергә дип хыялланып йөрим.

– Сездән була ул, Салих абый. Кичәге комедиягә музыкагыз бик әйбәт килеп чыккан иде. Башмагын югалткан кызның хис-кичерешләрен халык көйләре аша бик матур ачып бирдегез.

– Ярады инде, артык искитәрлек булмаса да, халык канәгать калды дип сөйләделәр бүген летучкада, – диде Салих, сүзне үзен күкләргә чөеп мактауга күчерүдән читкә борырга теләп, аннары сорап куйды: – Зәйнәп, нәнәм, син сөйлисең дә син сөйлисең, нәрсә бу ахирәтеңнең теле юк мәллә? Таныштырыр идең булмаса.

– Теле бар аның. Тик безнең телдә сөйләшми ул. Шуңа күрә дәшмичә, тыңлап кына тора.

– Марҗамыни?

– Алай димә инде, үпкәләтерсең.

– Ник үпкәләсен?! Марҗа Мария дигән сүз бит инде ул. Гайсә пәйгамбәрнең анасы. Марҗаның да бар җаны, ник сөймәскә марҗаны, дигәннәр. Матур гына кыз күренә, гашыйк булып куймагаем тагын. Булыр аннан соң марҗа! Туган апаңа әйләнер.

– Таныш бул, Валя-Валентина! – дип, Зәйнәп дус кызының кулыннан алды. Анысы, дустының үзе белән таныштыруын аңлады, тыйнак кына итеп, икенче кулын Салихка сузды һәм:

– Здрасьте, – дип куйды.

– Здрасьте, коль не шутите, – диде Салих, шаярткан булып, һәм шулай ук кулын Валяга сузып, исемен атады: – Салих.

– Мой дядя! – диде Зәйнәп. – Музыкальный руководитель Татарского государственного театра!

Теле бар икән:

– Охо! Человек искусства! – диде Валя.

– Да, вот о том же и говорю, что вы изучаете тело человека, а я – душу. Так что занимаемся одним и тем же, объектом нашего исследования является человек.

– Громко звучит.

– «Человек – это звучит гордо!» дип әйткән бит әле бер язучы.

– Әйе, Максим Горький әйткән, – дип, Зәйнәп әле күптән түгел генә ниндидер гәзиттән укыган сүзләрне искә төшерде.

– Ярар, укыгыз, комачауламыйм, дияр идем дә, теге бүлмәдә музицировать итеп утырсам, комачауламын инде, әлбәттә.

– Юк, юк, уйнагыз. Без дә залдан үзебезнең бүлмәгә күчәбез, – диде Зәйнәп һәм китапларын алып, дустын икенче бүлмәгә чакырды.

Салих пианиносы янына барып утырды. Капкачын ачып, бармаклары белән клавишалар өстеннән йөгертеп чыкты. Аннары капкачны яңадан ябып куйды да ишек төбендәге элгечтә салып калдырган шинеленең кесәсеннән театрда Кәрим абыйсы биргән кульязманы барып алды.

«Әйбәт булды әле, кызларга да комачауламыйм. Пьеса белән танышырга кирәк», дип уйлады.

Кайсы тирәләренә музыка сорала, кайда җыр булырга тиеш, шуларны билгеләп чыгарга кирәк иде.

**8**

Пьесаны укып бетергәндә, кич җиткән иде инде. Декабрьдә караңгы тиз төшә шул. Сәгать өч кенә, ә урамда инде кап-караңгы.

– Әйдә, озатып куям, – диде ул, китәргә дип җыенган Валяга пәлтәсен кидерергә булышып.

– Рәхмәт, туганым абый, Валя ерак тормый, күршедә генә, – дип, кыз өчен Зәйнәп җавап бирергә ашыкты.

Салих шулай да иңенә шинелен салды да, кызларга ияреп, урамга чыкты. Тәмәкесен кабызды.

– Син тартасыңмыни, абый? – дип гаҗәпләнеп сорады Зәйнәп.

– Армиядә өйрәндем, ташлап булмый менә хәзер, – диде Салих, акланырга теләгәндәй.

Валя чынлап та ерак тормый икән, бер йорт аша гына. Өчәүләп алар торган йорт капкасы янына килеп җиткәч, Салих:

– Бүген кич ни эшлисез, кызлар? – дип сорап куйды.

– Ә нәрсә, свиданиегә чакырасың мәллә күрше кызын? – диде Зәйнәп, көлеп.

– Свиданиегә түгел, театрга. Бүген безнең анда спектакль.

– «Башмагым»мы? Карадык бит инде.

– «Башмагым» түгел, «Жир уллары трагедиясе». Такташ әсәре.

– Аны карадык. Без бүген Шәрык клубына барабыз. Анда да кызыклы кичә, Фатих Әмирхан белән очрашу.

– Эх, мин дә барыр идем дә, хәзер үк репетициягә китәсем бар. Аннан соң спектакль.

– Иртәгә барырбыз.

– Иртәгә буласын да карадыгыз шул инде, кичә үк. Кызганыч, вакыт юк хәзер. Көн саен репетиция дә спектакль. Кызлар белән йөрергә һич җай килми. Иртәгедән көндез музыкальный техникумга барып, фортепианодан, композициядән дәресләр ала башлыйм. Бүген профессор Корбут белән сөйләшеп кайттым.

– Корбут? – дип сорады Валя. – Ксаверий Александровичмы?

– Шул үзе. Каян беләсең син аны?

– Беләм. Ул бит безнең күршедә генә яшәүче Василий Иванович Виноградовларда еш була.

– Василий Иванович сезнең күршемени? Бик яхшы беләм бит мин аны. Моннан биш-алты еллар элек укып та йөрдем әле үзендә. Берәр көнне янына кереп, хәлләрен белешеп чыкканда начар булмас, алайса.

Валя саубуллашып кереп китте. Салих та, өйләренә кире кереп тә тормастан, театрга китәргә булды. Алар капка төбенә җиткәндә, баганага сөялеп бер егет басып тора иде. Салих, «Кем булыр икән бу?» – дип уйларга да өлгермәде, егет алар каршына чыгып басты да: «Исәнмесез?» – дип хәл белеште.

– Исәнмесез, – диде Салих.

– Туганым абый, таныш бул, Бернияз бу, дустым, – дип, Зәйнәп аны егет белән таныштырырга ашыкты.

Өстенә күн тужурка, аягына ялтырап торган хром итек кигән, хәрби икәнлеге әллә каян күренеп торган, Урта Азия якларындагы халыкларныкына охшаган кара кучкыл чырайлы, Салих яшьләрендәге егет Салихка кулын сузды:

– Әйе, Бернияз атлы булам, Казакъстан Республикасы вәкиллегеннән.

– Салих. Зәйнәпнең туганы.

– Кичә генә армиядән кайтып төште Салих абый, шинелен салырга да өлгермәде әле, – дип, Зәйнәп егет белән аны якыннанрак таныштырырга кереште.

– Ярар, сез калыгыз, мин йөгердем, эшкә, – дип, Салих алар белән хушлашырга ашыкты.

– Без дә хәзер китәбез. Әйттем бит, Шәрык клубына барабыз, – диде Зәйнәп.

***

Шулай итеп, Салихның сагынып кайткан Казанында көндәлек мәшәкатьләр, эш белән кайнап торган ыгы-зыгылы яңа тормышы башланды. Ул көн дә башта иртән театрга барып килә. Андагы хәлләр белән таныша. Аннары Корбут янына ашыга. Анда фортепианода уйнау осталыгын камилләштерә, Европа классик композиторларының әсәрләре белән таныша. Бөек композиторларның һәрберсенең үзенә генә хас иҗат алымнарын өйрәнә. Фортепиано өчен язылган пьесалар, вальслар, скетчлар, кече күләмле әсәрләрдән башлап, төрле ансамбльләр өчен иҗат ителгән катлаулы формаларны, әсәрнең һәр инструмент өчен аерым партитураларын өйрәнү Салихка башкару осталыгын яхшыртуда гына түгел, аның гармониясен, ничек язылышын күз алдына китереп бастырырга ярдәм итә иде. Ул акрынлап, театрда куеласы яңа спектакль өчен музыка әзерләгәндә, халык көйләрен эшкәртү белән генә чикләнмичә, аларны нигез итеп алып, өр-яңа көйләр иҗат итүне максат итеп куя башлады.

Корбут янында берничә сәгать шөгыльләнгәннән соң яңадан театрга репетициягә ашыга. Аннары – спектакль. Ул шулай итеп үзен тыгыз режимда, кысалар эчендә тотарга өйрәнде. Бер генә минутны да бушка

үткәрмәскә тырышты. Аның хәтта шәхси тормышы өчен вакыты да калмый иде. Ә шәхси тормыш дигәнең үзенекен итә. Дөресрәге, яшьлеге үзенекен итә иде. Ул көн саен Зәйнәп янына кереп йөри торган күрше кызы Валентинага нык ияләште. Бу гади ияләшү генә дә түгел, бу гашыйк булу иде.

Рус кызы дип тормады, гашыйк булды да куйды Салих Валяга.

Валя Зәйнәпнең якын дусты, аның белән бергә укучы студент буларак кына түгел, Әминә апасы белән җизнәсенең улы Үзбәкне математика белән рус теленә өйрәтүче репетитор да буларак, аларга көн саен диярлек кереп йөри иде. Әле шулар өстенә музыка белән дә мавыга, пианинода, скрипкада уйный белә икән.

Валя әнисе Анна Ивановна, энеләре Юрий һәм Анатолий белән бергә яшиләр. Алар Казанга Кострома шәһәреннән күченеп килгәннәр. Әтиләре дворян, Костроманың мактаулы гражданины булган. Башта Казанга Валя килгән, университетның медицина факультетына укырга кергән. Әтиләре вафат булгач, Анна Ивановна ике улы белән үзләре дә кызы янына күченгәннәр. Валя Зәйнәп белән бергә институтның соңгы курсын тәмамлап, табибә булырга җыенып йөри.

Шулай бер көнне Валя Үзбәк белән рус теле буенча дәресләр өйрәнеп утырдылар. Аларның урамы шәһәр үзәгендә булгангамы, ул тирәләрдә күбесенчә руслар яши иде. Шуңа күрәдер инде, Үзбәкнең аралашкан малайлары арасында да руслар күбрәк. Мәктәптә рус теле аның өчен авыррак бирелде. Дус кызының энесе булгангадыр инде, Валя аны русчага өйрәтергә теләп алынды.

Салих, эшләрен бетереп, өйгә кайтып кергәндә, Валя белән Үзбәк әле һаман шөгыльләнәләр иде. Ул, аларга комачауламаска тырышып, шыпырт кына бүлмәсенә үтте. Ләкин фортепиано янына утырмыйча һич булдыра алмады. Чөнки тагын берничә көннән премьера, ә бүген репетиция вакытында Кәрим абыйсы спектакльнең кереш өлешенә музыканы ошатып бетермәде.

«Буеннан буена «Казан сөлгесе» җырының төрле вариацияләрдә яңгыравы спектакльне бер югарылыкта тота, җырлар, биюләр аңа күтәренке рух, дәрт бирә. Кереш өлешендә шушы күтәренкелек биреп бетерелми шикелле», – диде ул.

Салих алдына ноталарны таратып салды да, һәрберсен искә төшерә-төшерә, пианинода кабатлап чыкты. Шактый озак утырды. Уртада җырларга курай тавышы кертеп җибәреп, кереш өлешенең үзгәрәк яңгырашына иреште кебек. Инде булды бугай дип, ноталарын җыйный башлаганда гына, аның бүлмәсенә Зәйнәп белән Валя килеп керделәр. Зәйнәп абыйсының Валяга битараф түгеллеген, аңа тыныч кына карый алмавын сизенә иде инде. Валя үзе дә ахирәте белән серләрен уртаклаша иде булса кирәк.

– Комачауламыйбызмы? – дип сорады Зәйнәп, бүлмәгә кергәч.

– Киресенчә, сез кергәч, күңелләр күтәрелеп китә, илһам килә. Җыр иҗат итәсе килә башлый, – диде Салих һәм бармаклары белән клавишаларга баскаларга тотынды. Яңадан ул әле генә уйнаудан туктаган «Казан сөлгесе» көенә вариацияләр яңгырады.

– Нинди матур көй, – диде Валя.

– Яле, син дә уйнап күрсәт, – диде аңа Зәйнәп.

Салих басып, Валяга урынын бирде:

– Рәхим итегез.

– Рәхмәт, – диде кыз һәм утырып, тын гына клавишаларда ноталар сайлый башлады. Аның ниндидер башка көйне уйныйсы килә иде, ахры.

Менә аның бармаклары баскан клавишалар кайсыдыр чит ил композиторының бик тә таныш, атаклы әсәрен яңгырата башладылар. Салих беренче ноталардан ук таныды: бу – Шопен! Ул көчле тавыш белән:

– О, Шопен! – дип әйткәнен сизми дә калды.

– Тс-с-с, – диде Зәйнәп, бармагын ирененә тидереп.

Алар Валяның уйнап бетергәнен тын да алмыйча тыңладылар. Соңгы аккордларны биреп, инструмент тынып калуга, Салих чын күңеленнән сөенеп, кулларын чәбәкләде.

– Браво! – диде ул. Шунда аның Валяны кочаклап аласы, назлап сөясе килеп китте. Ләкин яннарында басып торган Зәйнәп аны бу адымнан тоткарлый иде. – Нинди музыкант таланты яшеренеп ята бит синдә! Әллә безнең театрга гына эшкә киләсеңме, хастаханәләрдә җыен авыру-сырхаулар арасында йөргәнче, – диде ул.

– Юк инде, алты ел гомеремне бирдем мин табиб белгечлегенә ия булыр өчен. Үзегез әйтәсез бит, музыкант, кешеләрнең рухын савыктырса, табиб – тәнен. Табиб хезмәте дә – бик кирәкле хезмәт! Арабызда бер музыкант булгач җиткән инде. Шуның өстенә тиң җитмәслек талантлы музыкант. Халык мактап туймый үзегезне. Беркөнне Виноградов та мактап торды әле.

– Кайда, ничек?

– Юрий Васильевич музыка техникумына, Ксаверий Александрович янына кергән икән. Алгы бүлмәдән кемнеңдер профессор кабинетында рояльдә Моцартның сонатасын уйнавын ишеткән. Шундый чиста итеп, аһәңле итеп уйный, ди. Корбутның сәркатибеннән: «Кем ул шулай уйный анда?» – дип сорагач, анысы: «Салих Сәйдәшев атлы егет», – дип җавап биргән. Менә шулай, уйнавыгыз белән хәтта Юрий Васильевич Виноградовны таң калдыргансыз. Кая инде ул миңа сезгә җитәргә?!

– Корбутта озаграк шөгыльләнсәң, әллә нинди бөек музыкант булырга да мөмкин, – диде Салих, уңышының серен остазына кайтарып калдырып. – Ул бит Петербург консерваториясендә Лядов, Римский-Корсаков, Рубинштейн кебек бөек музыкантлардан, композиторлардан белем алган кеше.

– Ә сез – Корбуттан!

– Ярар, кызлар, монда минем турыда түгел, сүз Валяның уйнавы хакында бара иде. Чынлап та, Корбуттан өйрәнү – минем өчен зур бәхет. Аның кул астында шөгыльләнеп, әле татар театрының да данын күтәрербез, Алла боерса!

– Рәхмәт игътибарыгыз өчен. Мин кайтыйм. Сау булып торыгыз, – дип, Валя алгы бүлмәгә чыгып, киемнәре янына килде.

Шунда, Валя белән хушлашып, «Сау бул», – дигәннән соң нишләргә дә белмичә аптырап калган Салихны Зәйнәп артыннан этеп: «Бар инде, озат, нәрсә карап торасың», – дип пышылдады.

Үзенең югалып калуыннан каушап киткән Салих шунда һушына килеп, ашыгып Валя янына чыкты да, чөйдән аның пәлтәсен алып,

өстенә кигертә башлады. Валя да моны көткән иде, ахрысы, ул, әйтерсең, махсус озаклап киенде, кулын җиңенә кертә алмыйча азапланды. Салих та өстенә шинелен салды да, кыз артыннан урамга чыкты. Алар башта сүзсез генә атладылар. Валяларның капка төбенә җиткәч, кызның үзенең дә тиз генә кереп китәсе килмәде. Салих аны иңнәреннән кочып, үзенә таба тартып китерде. Кыз башта этенгән булды, ләкин шул минутта ук егетнең кочагына сеңде.

– Син нишлисең? – диде ул. Үзе аның саен Салихка тартылды.

– Салкын бит, туңасыңдыр. Өстеңдә пәлтәң бик юка, – диде Салих.

Валя әллә югалып калды, әллә әйтергә башка сүз тапмады, пышылдап кына:

– Рәхмәт, – диде. – Ярар, мин керим. Бүген соң инде. Әни дә югалткандыр. Иртәгә...

– Иртәгә хәтле хуш, алайса. Тыныч йокы.

**9**

«Казан сөлгесе»ннән соң бер-бер артлы тагын дүрт-биш спектакль – «Хан кызы», «Сак-Сок», «Талир тәңкә», «Урал суы буенда»ны чыгардылар. Аеруча истә калганы Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар»ы булгандыр. Һәр спектакль саен Салих остарганнан остарды, музыкаль бизәлешне бирелебрәк, кызыклырак итеп ясый башлады. «Сүнгән йолдызлар» спектакленең бизәлешенә ул «Каз канаты» көен нигез итеп алды. Бу көйне төрле вариацияләрдә файдалану спектакльнең бөтен драматизмын, фаҗигасен биреп бетерергә ярдәм итте. Көй әсәрнең башында ук яңгырый башлый һәм тамашачы күңелендә билгеле бер эмоциональ тойгы, хис тудыра һәм шуны әсәрнең ахырына кадәр алып бара. Сәйдәшнең бу вакытта музыка техникумында Корбутта шөгыльләнүе дә көйләрне оркестр өчен эшләүдә зур ярдәм итте. Ул көйне аерым эшләмичә, һәр инструмент өчен турыдан-туры партитуралар әзерли иде.

Валя белән аралары да көннән-көн якынайды, тора-бара алар инде тормышларын бер-берсеннән аерым күз алдына да китерми башладылар бугай. Һәрхәлдә Салих шулай уйлый иде. Ул Валяның энеләре белән дуслашып китте. Мухиннар, Валентинаның фамилиясе шундый иде, барысы да, кечкенәдән итагатьле булып, яхшы тәрбия алып үскән балалар. Аларны әти-әниләре музыка мәктәбендә дә укыткан, рәсем сәнгате буенча да белем биргәннәр. Салих белән бер яшьтәге туганнары Анатолий аеруча оста рәссам булуы өстенә, музыкадан яхшы белгеч, пианино, рояль кебек инструментларны оста көйли. Аның бу осталыгы тормыш алып барырга да зур булышлык итә иде. Апалары Валя репетиторлык белән шөгыльләнеп, өйгә икмәк алып кайтса, Анатолий музыка уен кораллары көйләүдән акча китерә иде. Берзаман алар бу эшкә Салих белән икәүләшеп йөрергә ияләшеп киттеләр. Анатолий өендә пианино, рояль ише уен коралы булган берәр хәллерәк әфәндедән аларны көйләү, төзәтү буенча заказлар таба да, ике күрше бергәләшеп барып, бер көн эчендә бу эшне җиренә җиткереп башкарып та бирәләр. Салихның музыкаль ишетү сәләте гаять көчле, ул кайсы клавишаның бозык булуын шундук ачыклый һәм көйләп бирә торган иде.

Шулай бер көнне Анатолий Салихны заказ буенча бер Казан сәүдәгәренең фортепиано төзәттерер өчен фатирына чакыруы турында әйтте, вакыт табып барып кайтырга иде, дип үтенде.

– Яхшы, – диде Салих, – барырбыз. Атна уртасында булмый, шимбә көнне иртәдән.

Шимбә көнне Анатолий аның янына иртүк кереп җитте.

– Онытмадыңмы бүген бер абзыйларга барасыбызны? – диде.

Җомга көн премьера булган иде. Габдрахман Хәмиди дигән авторның «Һинд кызы» дигән спектаклен чыгардылар. Эштән соңрак кайтырга туры килде. Шуңа күрә Анатолий кергәндә, Салих әле йокылы-уяулы, иртәнге чәен эчәргә дә өлгермәгән иде. Ул тиз-тиз генә капкалады да фортепиано көйләү өчен инструментларын, камертонын чемоданына тутырып, өйдән чыгып киттеләр.

– Кая барабыз соң, нинди адрес буенча? – дип сорады ул Толядан.

– Мещанская урамында, унбишенче йорт бугай. Номеры хәтердән чыккан. Кичә кереп чыккан идем, бара беләм, – диде Анатолий.

– Унбишенче йорт... – дип куйды үзалдына Салих. Бу йорт аңа таныш бит! Таныш шул. Шул үзе, Фатимахизөһрәләр яшәгән йорт. – Әхмәтҗан Солтанов атлы абзый чакырдымы?

– Шул үзе. Ә син каян беләсең?

– Беләм инде, – диде Салих һәм артыгын дәшмәскә булды.

Моннан дүрт-биш еллар элек Фатимахизөһрә исемле бер кызга гашыйк булган иде ул. Бу аның беренче тапкыр чынлап яратуы иде.

Бу кызны ул чакта музыкадан укытыр өчен дип, Салихны өйләренә аның атасы Әхмәтҗан Солтанов исемле кеше чакырып китергән иде. Уналты яшьлек кыз янына унҗиде яшьлек егетне чакырып китер дә, араларында бернинди дә гыйшык-мыйшык хәлләр булмас дип, башка да килмәслек түгел бит инде. Җитмәсә, кызы бик чибәр, бер кашыкка салып йотарлык. Кызның үзенең дә алма кебек өлгергән, борынына егетләр исе керә башлаган чагы. Салих та матурлыгы белән ни җитте, килде-китте генә егет түгел, чибәр, әйбәт киенеп йөри, тәүфикълы, шуның өстенә музыкант та әле. Музыка коралында бер сыздырып җибәрсә, уналты яшьлек кызның һушын ала да ала инде, кем әйтмешли, патша кызлары да егылып гашыйк булырлар иде хәтта. Әхмәтҗан абзый, әлбәттә, моны яхшы аңлый иде. Шуңа күрә Салихны бер шарт белән чакырды: ул дәресләр биргән вакытта эти кеше үзе дә бер читтә аларның дәресен тыңлап, карап утырырга тиеш иде. Салих моңа каршы килмәде.

Атнага ике көнне икешәр сәгать фортепианода музыка белән шөгыльләнеп утыру ике яшь йөрәк өчен гади генә эш түгел иде. Бигрәк тә кыз үзе Салихка карата битараф булмаган очракта. Чөнки ул беренче көнне үк укытучысы буласы бу егеткә күзе төшеп, гашыйк булып калган иде. Бара торгач сишәмбедән – шимбәне, шимбәдән – сишәмбене, алар икесе дә түземсезлек белән көтеп ала торган булып, бер-берсенә гашыйк булдылар.

Фатимахизөһрәнең әнисе Сембер каласында туып үскән, шул заман өчен алдынгы карашлы, мәдәниятькә омтылучы бер хатын иде. Ахун хәзрәт кызы булса да, ул абыстайлар шикелле йөзен-битен ирләрдән яшереп,

чәчәкле чуклы озын күлмәкләр, укалы камзул, үкчәсез читекләр кими, рус хатыннары кебек европачарак киенеп йөрергә ярата. Кызын да шулайрак итеп тәрбияләргә тырыша иде. Фатимахизөһрәне музыкага өйрәтергә теләүләре дә әнисенең йогынтысында иде. Дөрес, Әхмәтҗан абзый үзе дә татар көйләрен, милли җырларыбызны тыңларга ярата торган кеше икән. Алай да, аның кызының дәрес алуын карап утыруы музыка яратудан бигрәк, кызының итагатен саклау, дәрес алудан башка уйларны башына да кертмәве турында кайгырудан иде. Ләкин ата кеше никадәр кырыс булырга тырышмасын, анасының тәэсире көчлерәк, чөнки ул чыгышы белән иреннән өстенрәк, затлырак тәрбия һәм белем алган. Ә Әхмәтҗан гади мужиктан чыккан, үз тырышлыгы һәм зирәклеге белән генә кеше арасына керә алган, байларның ышанычын яулап кына, сәүдә эшендә ниндидер уңышларга ирешкән, тормыш хәлен яхшырта алган. Әнисенең шундый булуы аркасында, Салих атналар, айлар буе өй тирәсеннән еракка чыкмыйча, йорт тавыгы булып яшәгән Фатимахизөһрәне Шәрык клубы кичәләренә барырга, андагы алдынгы карашлы туташлар белән аралаша башлауга күндерә алды. Тора-бара аңа үзенең мәхәббәтен дә белдерүгә ирешкән. Ләкин кыз атасыннан бик нык курка иде. Инде күндердем, атасы йортын ташлап, үзе белән кавышырга ризалыгын алдым дигәндә дә, атасы нык каршы торып, Фатимахизөһрә бикле капкаларын ачып, өйдән чыгып китә алмады. Алар шулай итеп кавыша алмый калдылар. Язмыш Салихны Казаннан читкә, Урта Азия якларына илтеп ташлады. Аларның мәхәббәте Фатимахизөһрәнең яратып укыган «Дим буенда» китабындагы егет белән кызның мәхәббәте шикелле бәхетсез булып калды.

Казанга әйләнеп кайткач белеште Салих, Фатимахизөһрәне эти-энисе кияүгә биргәннәр, алар Ташкент якларына чыгып киткәннәр. Хәзер дә шунда яшәп яталар икән. Бәхетле булганмы ул, юкмы, Салих болардан бихәбәр иде. Ул бары тик үзенең бу кызга булган көчле мәхәббәтен хәтерләде. Фатимахизөһрә дә аны бәхетле итә алган булыр идеме икән, анысы да Салих өчен бер сорау гына булып калды. Һәм менә аның йөрәгендә кабат, инде икенче тапкыр, көчле мәхәббәт уты кабынды.

Салих үзенең Фатимахизөһрәгә әйткән сүзләрен искә төшерде. Ул аңа: «Мин сиңа энҗе-алмазлар бүләк итә алмам, ләкин мин сиңа үземнең йөрәгемне, саф мәхәббәтемне бирәм. Шуннан да зур байлыкның дөньяда булуы мөмкин түгел! Синең кулыңдагы беләзекләрдә, колагыңдагы алкаларда, таккан мәрҗәннәреңдә түгел чын бәхет. Бәхет ул – ике кешенең берсен берсе сөюендә. Син байлык бәхетне алмаштыра ала дип уйлама. Шуңа өметләнмә. Байлык килә дә китә, ә бәхет гел үзеңдә кала. Бәхет ул сөйгәнең белән бергә булу, бәхет – икең бергә эшләү, иҗат итү, гомер буе бергә яшәү», – дигән иде. Менә хәзер ул шушы сүзләрне икенче бер кызга әйтергә тиеш. Ул чакта кызны ышандыра алмады, үзенеке итә алмады. Аның үзендә дә ныклык җитеп бетмәде бугай инде. Яшь иде шул әле, унҗиде-унсигез яшьлек чаклары гына. Инде бу юлы ялгышмаска иде. Үзеңнең хисләреңнең чынлыгына, ныклыгына ышандырырга иде.

Ә менә хәзер, эштән куып чыгарылгач, барып сыенырга, иңенә башын терәп, күңелендәге бөтен хисләрен ачып салырга, эчен бушатырга бер кешесе дә калмаган бу көннәрдә бәхет дигән төшенчәне ничек аңлатырга?

Чынлап та, нәрсә соң ул бәхет? Фатимахизөһрәгә бик матур итеп аңлаткан иде дә ул чакта бәхетле булуның ни икәнен. Валентинасы белән матур гына яшәгән булсалар, нинди бәхетле тормыш кичерәселәре иде дә бит. Тик шулай булыр идеме икән? Уйлар чанасы салулап, аны тагын әллә кайларга алып кереп китте. Артык кеше бит ул бу дөньяда. Бу җәмгыять өчен кирәксез кеше...

Менә алар әйтелгән адрес буенча килеп тә җиттеләр. Мещанская урамы – Казанның үзәк урамнарының берсе. Салих бит шушы урамда туган, йөз дә беренче йортта. Әнисе шулай дип әйтә торган иде. Әтисе үлеп, Насретдин җизнәсе белән яши башлагач кына, Печән базары тирәсенә яшәргә күчкәннәр. Фатимахизөһрәгә фортепиано буенча дәресләр биргәндә, ике елга якын йөрергә туры килде аңа бу адрес буенча. Шуңа күрә үтә дә таныш кына түгел, күңеленә якын ук бер йортка әйләнгән иде ул. Икенче яктан, бу йортның чит-ят кеше керә алмаслык итеп эшләнгән биек таш коймасы һәм капкасы аның ачуын китерә иде. Төнгә ат башы хәтле йозак белән бикләнеп куела торган шул капка аркасында Фатимахизөһрә сөйләшенгән көндә өеннән качып чыга алмыйча, алар бергә кушылмыйча калдылар ул чакта.

Аларның килүен Әхмәтҗан абзый көткән иде. Гадәттә, ял көннәрендә иртән соңлап кына ачыла торган бу биек капка бүген шыр ачык иде. Әхмәтҗан абзый аларны капкадан керүгә, болдырдан чыгып, бусага төпләренә үк төшеп, каршы алды. Ул Салихны шунда ук таныды.

– Салих әфәнде, сез түгелме соң бу? – диде ул исе киткән кыяфәттә.

– Әйе, исәнмесез, Әхмәтҗан абзый, – диде Салих.

– Саумысыз, саумысыз! Әйдәгез, өйгә узыгыз. Көтәбез, көтәбез. Ләкин һич кенә дә уйламаган идек, Салих әфәнде, сез дә килерсез дип. Сез Казандамыни? Исән-саулармысыз?!

– Әйе, Казандамын, Әхмәтҗан абзый. Үзегез ни хәлләрдә? Бибимәликә абыстай исән-саумы? Фатимахизөһрә?

Алар өйгә керделәр. Өске каттан шаулашып-гөрләшеп чит кешеләр кергәнен ишеткән Бибимәликә абыстай төште. Ул да Салихны шундук таныды.

– Салих әфәнде, сезме бу? – диде ул, таныса да, исе киткән кыяфәт чыгарып.

– Әйе, Бибимәликә абыстай, мин бу, сез яхшы белгән Салих.

– И-и, белгән генәме соң! Сагынабыз сезне, Салих әфәнде. Нинди итагатьле, нинди тәрбияле егет идегез.

– Мин әле дә шундый, сез генә күрә белмәдегез, – диде Салих, юри төрттереп. – Кызыгызны урлап качар дип курыктыгыз. Урлап качучы булмадымы соң алай-болай?

– И Салих әфәнде, ялгыштык бугай ла шул. Китте кызыбыз. Бердәнбер балабыз иде. Картлык көнебездә таянычыбыз, terәгебез булыр дип уйлый торган идек. Казанда гына да түгел, Ташкентка хәтле үк биреп җибәрдек Фатимахизөһрәбезне. Ятабыз менә хәзер хәсрәт эчендә ут йотып. Кайтып күренү түгел, хаты-хәбәре дә юк.

– Ярый, эшли-эшли сөйләшербез, Анатолий Фёдорович көтә анда.

– Яхшы, яхшы, – дип, Әхмәтҗан абзый аларны зал ягында торган

фортепиано янына дәште. – Менә монда моңаеп тора кызыбыздан калган истәлекле ядкарь. Соңгы вакытта нидәндер көе китте. Бибимәликә абыстагызны һич кенә дә тыңламый башлады.

– Фатимахизөһрәбезне ул да юксына, күрәсең.

Салихның хуҗалар белән шулай якын күреп сөйләшүен тыңлап торган Анатолий аларга:

– Фортепиано төзәтү остасын бик яхшы белгәнсез икән бит. Нишләп күптән чакырмадыгыз соң үзен? – дип куйды.

– Белә идек тә, Казаннан киткән иде бит ул. Шәһәрдәдер дип һич башка килмәде шул, – диде Бибимәликә абыстай.

– Әйдә, карагыз әле үзен, егетләр. Рәтләп бирегез әле.

– Яхшы, – диде дә, Салих фортепианоның капкачын ачып, алдында торган түгәрәк әйләнмәле урындыкка утырды, бармаклары белән клавишаларга баскалый башлады. Аннары: – Көйлисе бар. Күптән кагылган кеше булмаган, күрәсең, – дип куйды.

– Юк шул, – диде Әхмәтҗан абзый. – Фатимахизөһрәне көтә. Ә менә Бибимәликә абыстасын тыңларга теләми.

– Хәзер карарбыз, тыңлар, – диде Салих.

– Ярый, егетләр, комачауламыйбыз. Эшләгез. Әйдә, абыстай, киттек. Егетләр эшләрен бетерер алар. Сабирага куш, аш пешерсен.

Шулай дигәч, ул хатынын асрау кыз Сабира бүлмәсенә озатты да үзе Салих Фатимахизөһрәгә дәрес биргәндә карап утырган кәнәфиенә барып кунаклады.

– Мин шушында гына утырып торыйм, сезгә комачауламам, – дип куйды.

– Комачауламыйсыз, Әхмәтҗан абзый. Без бит үз эшебезне сөйләшә-сөйләшә дә башкара алабыз.

– Бик яхшы.

Күптән кул тимәгән клавишалар шактый кипкәннәр. Кыллары да бушап беткән. Аяк белән баскалый торган педальләрне дә ныгытырга кирәк.

– Инструментны сүтеп ташларга кирәк булачак, – диде Салих Анатолийга. – Син сүт әйдә, аннары мин көйләп, бергәләп җыярбыз.

Анатолий инструмент көйләү эшендә үзе дә бик яхшы оста иде. Салих белән танышканга кадәр ул бу эш белән күптәннән шөгыльләнгән булган.

– Ул сүтсен, без сөйләшеп утырыйк әлегә, – диде Салих Әхмәтҗан абзыйга һәм аның янындагы икенче кәнәфигә барып утырды. – Фортепиано артында һәрвакыт бер савыт белән су тотарга кирәк. Югыйсә агач бит, агачның кибә торган гадәте бар. Аны карап торышка сизмисең, ә ул үзенекен итә.

– Шулайдыр инде. Сатып алганда әйткәннәр иде бугай. Онытылган инде. уйнаучы кеше дә булмагач, торды инде шунда моңаеп. Менә Бибимәликә абыстаң үзем уйныйм әле дип башлаган иде, уйный алмый шул. Элеккерәк елларда шактый уйнаштыра торган иде.

– Ярар, рәтләрбез, уйнар. Ничек соң, Әхмәтҗан абзый, Фатимахизөһрәнең хат-хәбәре бармы? Киявегез нинди кеше? Балалары бармы?

– Бер кызы бар. Лалә дип исем кушканнар. Кияү үзебезнең кеше булмады шул. Ни үзбәк, ни әфган. Әй, Салих, Салих. Йөрәгенә ут төртеп калдырдың шул кызыбызның. Син әрмиягә киткәч, янды, көйде. Синең

Ташкент якларында хезмәт иткәнеңне ишеткән булган. Озак та тормады, артыңнан шунда китеп барды. Кая инде табасың ул әрмиядәге кешене. Ташкенттагы дуслары шул егеткә димләгәннәр дә, чыккан кияүгә. Әллә инде кияү дигән кеше үзе яратып алганмы кызыбызны. Яшиләр хәзер менә шул Ташкент якларында.

– Алай икән, – дип куйды Салих. – Сез бит аны ниндидер Сембер егетенә кияүгә бирергә йөргән идегез.

– Йөргән идек тә. Ул егеткә Фатимахизөһрәнең сөйгәне бар, әти-әнисе шул егеткә бирергә теләмәгәннән генә сиңа бирергә булганнар дигән сүз чыгарганнар. Шуннан соң яучы җибәртмәде ул. Газиз атлы егет иде. Бибимәликә абыстагызның Сембердәге туганнарының белешләренең улы. Монда Казанда коммерческий техникум бетереп, банкта эшләп йөрүче бер егет.

– Яраткан идем шул Фатимахизөһрәне.

– Яраткан булгач, яучы җибәртергә идең. Без көттек.

– Ялгыштым шул. Нишлисең инде, хәзер соң, – дип куйды Салих.

– Безнең дә ялгышлык булды.

Шунда Анатолий фортепианоны сүтеп бетереп, Салихка дәште:

– Булды бу. Хәзер җыясы бар инде. Утыр, әйдә, көйли башла струналарын, – диде.

– Ярый, Әхмәтҗан абзый, кылларын көйли башларга куша. Мин барыйм янына, – дип, Салих камертонын алып, скелеты гына торып калган фортепиано алдына барып утырды. Ул һәр клавишага баскалый, Анатолий аларга туры килгән кылларны ныгыта барды. Шулай итеп акрынлап, клавишаларны тавыш яңгырашы буенча көйләп чыктылар. Пианиноның такталарын җыйдылар.

– Булды бу! Эш бетте, Әхмәтҗан абзый. Кабул итеп алыгыз, – диде дә Салих урындыкка җайлап утырды һәм Казанга кайткач беренче тапкыр ишеткән «Җәмилә» дигән җырның көен уйный башлады.

– Матур көй, – диде музыка тавышын ишетеп, алар янына килгән Бибимәликә абыстай.

– Мине музыкага өйрәткән композитор Заһидулла абый Яруллин чыгарган көй, – диде Салих. Ул уйнап бетерде һәм Мәликә абыстайга карап: – Булды, кабул итеп алыгыз, – дип кабатлады.

– Бик зур рәхмәт. Аяк-кулларыгыз сызлаусыз булсын, – диде хатын һәм иренә борылып: – Кая, Әхмәтҗан, әзерләдеңме акчаңны? – диде.

Әхмәтҗан абзый кабаланып, кесәсен актарырга тотынды.

– Юк, Бибимәликә абыстай, берни дә кирәкми. Киявегез булмый калган егеттән бер изгелек булсын, – диде Салих.

– Юк, Салих туганкай, алай булмый ул. Акчагыз котырып тормыйдыр, алыгыз, ал. Менә бу иптәшең дә бушка эшләп йөрмидер, – диде дә, Әхмәтҗан Салихның барыбер алмаячагын аңлап, акчаны Анатолийның кулына тоттырды. – Алыгыз, ал. Бик зур рәхмәт.

– Аш хәзерләгән идек, әйдәгез әле аш бүлмәсенә, – диде Бибимәликә абыстай.

Анатолий ялындырып тормады, абыстай күрсәткән якка таба атлады. Салих та, иптәшенә каршы килеп булмый инде дип, аның артыннан китте.

## 10

1924-25 елларда театрда премьералар әллә ни күп булмады. Салих башта Ксаверий Александровичта, аннары профессор Бормусовта, укытучылар Чигарина белән Юшковада гармония, композиция, фортепиано буенча дәресләр үтте. Куела торган спектакльләрне музыкаль яктан бизәү буенча төрле тәҗрибәләр ясады. Бик еш кына үзләре белән бер урамда яшәүче Василий Иванович Виноградов белән аралашты. Аның белән бергә «Сания» һәм «Эшче» опералары язу белән шөгыльләнүче Газиз Әлмөхәммәтов һәм Солтан Габәши янында булды. Бер үк вакытта көн саен диярлек театрда репетицияләр үткәреп, спектакль барган көннәрдә оркестрга дирижёрлык итте. Бу музыкантлар, композиторлар белән аралашу аңа профессиональ яктан үсәргә, белемнәрен тирәнәйтергә нык ярдәм итте. Бу елларда инде ул татар көйләрен генә түгел, дөнья югарылыгындагы күренекле композиторларның катлаулы әсәрләрен иркен уйнау осталыгына иреште. Классикларның әсәрләрен уйнарга гына өйрәнеп калмыйча, һәр композиторның музыка тудырудагы шәхси стиль үзенчәлекләрен аера, таный белә башлады. Аның спектакльләргә язган көйләрендә, бизәлеш өчен файдаланылган халык көе булсынмы ул, үзе иҗат иткән музыка булсынмы, аларда композиторның шәхси интонацияләре, үзенә генә хас теле һәм оркестровкасы беленә башлады. Музыканы ишетү белән, бу – Сәйдәшнеке, дигән тойгы уяна иде. Бигрәк тә «Казан сөлгесе», «Сүнгән йолдызлар»да Сәйдәш интонацияләре ачык ярылып ята. «Сүнгән йолдызлар»га язган «Увертюра»сы аның спектакльләргә язган иң беренче оригиналь әсәре булды. Армиядә хәрби оркестрга дирижёрлык иткәндәге өйрәнчеклекнең инде эзе дә калмады. Ул дирижёрлык иткәндә, оркестрантлар үзләрен иркен тоталар, җиңел уйныйлар иде.

Итагатьле, белемле, югары эрудициягә ия булган Валентина Мухина белән очрашу һәм арада кабынып киткән мәхәббәт ялкыны аны шулай ук яңа бер дәрт, күтәренкелек белән эшләргә рухландырды. Шулкадәрле тыгыз, киеренке, һәр сәгате исәпле булган эш көне аны һәрчак үзен югары тонуста тотарга мәҗбүр итә. Ул моңа һич тә зарланмый, киресенчә, шатлана гына, көненең файдалы, кирәкле мәшәкатьләр белән үтүе аңа зур ләззәт, канәгатьләнү бирә иде. Валя аларда көн саен була. Үзбәк белән шөгыльләнгәннән соң алар пианино алдына утыралар, Глинка, Бизе, Верди кебек рус һәм чит ил композиторларының партитураларын өйрәнәләр.

Салихның Валентина белән артык якынаеп китүе өйдәге ике кодагыйның эчләрен пошыра башлады. Алар арасындагы мәхәббәт, яратышу чаткылары әле күренә генә башланган беренче көннәрдә үк Мәхүпҗамал улына кисәтү ясарга ашыкты:

– Салих, бәбкәчем, бу марҗа кызы белән тиешеннән артык якынаясың түгелме? Шәригать кушмаганны эшләп ташлый күрмәгез тагын, – диде.

Салих елмайды һәм әнисен кочаклап:

– Хәй, әнкәй, бәгърем, без бит минем эшем буенча шөгыльләнәбез. Валя – музыкадан белемле кыз, мине өйрәтә, үзенең белгәннәрен күрсәтә. Бу начармыни?

– Юк та инде дә. Барыбер дә артык якынайма, арагызга Иблис-мазар кермәсен. Ул Адәм белән Һаваны да җәннәттән кудырткан Аллаһы Тәгаләдән.

– Адәм белән Һава кавышмасалар, без дә булмас идек. Аның ни гаебе бар? Борчылма, әнкәй, берни дә булмас.

– Шулай була күрсен. Җизнәң Зәйнәп янына килеп йөри торган Берниязны да өнәп бетерми әнә. Сиңа да ризалыгын бирмәс. Атаң урынына калган кешең, берүк кәефен кыра күрмә.

– Валя бит минем янга түгел, Үзбәкне укырга өйрәтергә йөри, җизнинең үзе чакыруы буенча. Аның белән эше беткәннән соң калган буш вакытта гына музыка белән утырабыз. Моның ни гаебе булсын?

– Үзегез белә торгансыздыр. Ләкин минем эшем кисәтү. Мин дә әйтмәсәм, тагын кем кайгыртсын синең тәүфигың хакында?

– Ярар, әнкәй, бер дә борчылма, бар да әйбәт булыр, – диде дә, Салих сүзне шунда бетерергә ашыкты.

Мәхүпҗамал улын кисәтсә дә, үзе Валентинаны ярата, ул кергәндә, һәрчак ачык йөз белән каршы ала, сөйләшә торган иде. Чөнки кыз бик итагатьле, ягымлы, ачык чырайлы, олыны олы, кечене кече итә белә. Кодагые Зөләйха да, кыз вакытында кермәсә, эше чыгып тоткарланса, аны юксынып:

– Нишләптер бүген Валентина күренми әле, – дип сөйләшә башлый торган булды.

Ләкин әнисенең кисәтүе генә Салихның хисләренә богау сала алмый иде инде. Ул Валентинага көннән-көн ныграк гашыйк була барды, көннән-көн аның керүен сагынып көтеп алды. Ул кермәгән көннәрдә, төрле сәбәп табып, үзләренә йөгерде. Анатолий белән уртак эшләре дә булганга, ул Мухиннар өендә һәрчак көтелгән үз кеше булды. Егетнең кызлары Валя белән үзара мөнәсәбәтен сизеп алган Анна Ивановна да аны яратты, үз күрде.

Ә беркөнне Салих Валяга тәкъдим ясады.

Гадәттәгечә, Үзбәк белән математика һәм рус теле буенча дәресләргә әзерләнеп утырганнан соң алар фортепианода көндәге күнекмәләрне үткәч, Салих өйгә кайтырга җыенган Валяны озатырга чыкты.

Салих әле генә фортепианода үзе уйнаган классик көйләр тәэсиреннән айнып бетә алмыйча, Шопен сонатасының көен кабатлап атлаган Валяны иңнәреннән алып туктатты да колагына пышылдап:

– Сиңа әйтәсе сүзем бар, – диде.

– Минем дә, – диде Валентина.

– Әйдә, син әйт. Бер үк нәрсә турында уйлыйбыз микән? – диде Салих.

– Беләсеңме, Салих, минем дә синең кебек үк яхшы музыкант буласым килә.

– Син миннән дә яхшырак уйныйсың бит көйләрне. Фортепианода да, скрипкада да өздерәсең генә.

– Юк, мин тагын да яхшырак уйнарга телим. Моның өчен минем Мәскәүгә барып, консерваториягә укырга керәсем килә.

– Охо, кая үреләсең!

– Ә нәрсә?! Әйдә икебез дә тотабыз да китәбез Мәскәүгә. Бергә керәбез укырга. Бергәләп уку җиңелрәк тә булыр.

– Укырбыз, мин каршы түгел, тик соңрак. Киләчәктә. Ә хәзер уку елының уртасы җитте бит инде.

– Ну ярар. Аңлашылды, синең әйтергә теләгәнең минеке белән туры килми, димәк. Ә син нәрсә әйтергә теләгән идең?

– Минме? Мин... – Салих туктап, кызны иңнәреннән алды һәм үзенә таба тартып китерде. – Мин сиңа тәкъдим ясарга теләгән идем.

– Нинди тәкъдим? – диде кыз.

– Тәкъдим бер генә төрле була. Өйләнешергә.

– Өйләнешергә?

– Әйе. Күпме йөрергә була болай ике йорт арасында? Өч ел таптыйбыз бит инде шушы сукмакны.

– Ә син ничек күз алдыңа китерәсең безнең өйләнешүне?

– Ничек инде, гап-гади. Әниләребезнең, туганнарның ризалыгын алабыз да бергә яши башлыйбыз. Ике йорт арасындагы бу йөрүләрне туктатабыз.

– Ә минем мәңге шулай йөрисем килә, дисәм. Өйләнешкәч, без өй кошлары булып, урамга да чыкмыйча, гомер буе шулай пыскып яшәп ятачакбыз. Аннары, кем бирә әле сиңа ул рөхсәтне? Әниең мине озатырга чыгып киткән чакта артыңнан әнә ничек карап кала. Мине әллә күрми дип беләсеңме?

– Ә без аңа әйтеп тормабыз алайса. Өйләнешеп куярбыз да, без өйләнештек, котлый аласыз, дип кенә әйтербез.

– Шулай җиңел генә мөмкин булыр дип, уйлыйсыңмы? Мин риза, Салих. Мин синең белән җир читенә китәргә дә риза.

– Алайса, булды гына. Мин бер җаен табармын да сиңа әйтермен. Килештек. Иртәгә хәтле. Бар, кер, югыйсә салкын, туңасың.

Алар шулай аерылыштылар.

Икенче көнне Салих репетициядән соң дусты Мансурны эзләп тапты.

Февраль аеның салкын көне иде. Көн кичкә таба авышып бара. Мансур, бәхеткә, өйдә иде.

Кичкә каршы шулай суык ияртеп килеп кергән дустын күреп, ул бераз аптырап китте.

– Нишләп йөрисең болай бу вакытта? – дип сорады ул. – Бер-бер эш килеп чыктымы әллә?

– Бик җитди мәсьәлә килеп чыкты. Чишәргә ярдәм итсәң, син генә итә аласың.

– Ни булды тагын?

– Мансур, беләсеңме, өйләнергә булдым бит әле.

– Ничек алай, ни яз, ни җәй, ни көз түгел. Гадәттә, көз көне, урак беткәч, каз өмәләре җиткәндә өйләнешкәннәр. Табын мул вакытта. Ә син кышның зәмһәрир суык көннәрендә өйләнәм дип йөрисең.

– Туйдырды ике йорт арасындагы сукмакны таптап йөрүләр. Валя да каршы түгел. Тотабыз да өйләнешәбез. Өйдәге ике әби генә риза түгелләр, рус кызына өйләндерәселәре килми.

– Шулай диләрмени?

– Шулай димиләр үзе. Әмма татар егетенә марҗага өйләнүне шәригать кушмый дип сөйләнәләр.

– Хәзер нишләргә инде исәбегез?

– Бер уй бар иде. Берәр атна югалып тору күзләреннән. Шул бер атнаны ширбәт атнасына әверелдерергә.

– Ничек иттереп?

– Мин Валяга Кызыл Байракка барып яшик берәр атна дигән идем, эштән китә алмыйм, ди.

– Ә үзең китә аласыңмы?

– Үзем берәр җаен табар идем әле. Театрда эшләр ул кадәр тыгыз түгел. «Ашказар»ны гыйнвар уртасында ук чыгардык. Декабрьгә хәтле яңа әйбер планлаштырылмый. Быел гастрольләргә чыгып китәргә җыенабыз, җәйгә таба. Әле шуңа хәзерлек бара, башлыча. Минем ул кадәр тыгыз түгел эш графигы. Артистлар рольләрен кабатлый.

– Алайса, безнең дачаны тәкъдим итә алам.

– Үзем дә шуны уйлап килгән идем сиңа. Ерак та түгел, Казанга кайтып йөрергә дә уңайлы. Өйдән югалып торсак берәр атнага, әллә ни хафага төшмәсләр әле. Зәйнәпкә әйтеп китәрбез. Ул ничек тә тынычландырыр әнкәйләрне.

– Бик әйбәт. Алайса, менә ачкычлар, – дип, Мансур шкаф тартмасыннан дача йорты ачкычларын эзләп табып, Салихка тоттырды. – Дачага бара беләсең, анысына мин кирәкмимдер, – диде.

Салих ачкычларны алып, дустына зур рәхмәтләр әйтеп чыгып китте дә, кош тоткандай сөенә-сөенә, ике атлыйсын бер басып, җәяүләп кенә, өйләренә элдерде. Юл буе ул дачага нәрсәләр алып барырга икәнен, атна буена җитсен өчен азык-төлекне күпме алырга икәнен уйлап, өч ел буе сөеп-сөешеп йөреп тә, кулларыннан тотып иркәләүдән, дөньяларын онытып үбешүдән еракка узмаган мәхәббәт мөнәсәбәтләре хакында искә төшереп кайтты. Аңа егерме биш яшь, өйләнергә күптән вакыт иде инде. Әнисе дә шул хакта гел исенә төшереп тора башлаган иде. Тик менә Валя белән дуслашуын өнәп бетерми дә, шуңа өйләнеп куюыннан гына коты очып йөрде. Менә хәзер, үзләрен көтелмәгән хәл алдында калдырсам, ризалыгын алмыйча гына килен алып кайтып куйсам, ни белән бетәр икән бу эш? Өйдә кеше күп: ике әни, җизни белән Әминә апа, өч балалары, Өбрә кызлары икәү. Шулар өстенә тагын килен дә алып кайтып куйса, унбер авыз ашарга сорап торачак. Артык күпкә китә. Салихларга үз куышларын табарга кирәк булыр. Валяларда тору да килешеп бетмәс. Йортка керү – утка керү, дигәннәр бит борынгылар. Үз куышларын табудан да дөресе булмас.

Ул шуларны уйлый-уйлый өйгә кайтып җиткәндә Валя да Үзбәк белән дәресләрен тәмам итеп килә иде. Бу юлы алар фортепиано янында утырып тормадылар. Эше беткән кызга, Салих, сөйләшәсе сүз бар дип, элгечтән пәлтәсен алып кигертте. Иңенә шәлен салды да өйдәгеләргә: «Мин хәзер кайтам», – дип ашыгып чыгып та киттеләр.

– Кая болай ашыгасыз, ут капкандай, – дип, Мәхүпҗамал аларны ишектән озатып калды.

Урамга чыккач, Салих Валяга Мансур Мозаффаров дустыннан дачаларының ачкычын барып алуы турында әйтте.

– Өйдәгеләргә әйтеп торасыңмы, юкмы, мин иртәгә үк Мансурларның дачасына барырга тәкъдим итәм. Шунда берәр атна үзебез генә яшәп алыйк та, без өйләнештек дип кайтып әйтербез.

– Белмим инде, Салих, ничектер кинәт кенә була бит. Көтмәгәндә, уйламаганда.

– Ә нәрсә уйлыйсы, без инде өйләнешү яшен узып барабыз. Нәкъ вакыты. Быел елы да уңайлы, әллә ни эш тә юк. Алда гастрольләр тора торуын. Зыяны юк, бераз аерылышып тору мәхәббәтебезнең ныклыгын сынау гына булачак.

Алар килештеләр. Иртәгә өйдән эшкә дип чыгып китәбез дә, эштән кире кайтмыйча, Мозаффаровларның дачасына барып кунабыз, дигән фикергә килделәр. Икесе дә эштә бер атналык ял сорарга булдылар.

Салих өйгә кайткач планнары хакында Зәйнәпкә әйтергә кирәк дигән фикергә килде.

– Зәйнәп, матурым, синең белән генә уртаклашасы бер серем бар. Кешегә чишмәссеңме?

– Нинди сердер бит.

– Бик мөһим сер.

– Ә мин беләм ул сереңне.

– Каян?

– Беләм инде.

– Кем әйтте?

– Ул.

– Валямы?

– Валя.

– Аһ, каһәр! Миңа әйтмәгән була, үзе кешегә үк сөйләп бетергән.

– Ә син сөйләмичә генә шулай югалмакчы идеңме?

– Нишләп югалыйм, менә бит, сиңа ачмакчы идем серне.

– Тынычлап өйләнешегез. Валя бик акыллы, зирәк кыз. Бөтенесен дә алдан уйлап эшли. Бик әйбәт хатын булачак ул сиңа.

– Рәхмәт инде сиңа. Өйдәгеләр борчыла башласа, тынычландырырга берәр нәрсә уйлап чыгарырсың инде.

– Борчылма, Валя Анатолий белән Юрийга да әйтәм диде. Алар да белеп торачак. Әниләрен ничек тә тынычландырырлар.

– Рәхмәт инде сиңа. Син дә бик акыллы кыз. Кемне генә бәхетле итәрсең инде?..

– Ярар, ярар, үзегез турында уйлагыз. Минем бәхетем дә ерак йөрми, үзең беләсең, – диде Зәйнәп.

– Беләм, беләм.

**11**

Төп-төгәл җиде көннән, ширбәт атнасын үткәреп, яңа өйләнешкән ир белән хатын булып кайтып төшкән Салих белән Валентинаны табын корып, тәмле чәй ризыклары пешереп, бәйрәмчә каршы алды Зәйнәп.

Иртән эшкә дип чыгып киткән җирләреннән кич әйләнеп кайтмаган яшьләр Әхмәровлар өендәгеләрне дә, Мухиннарны да хәйран хафага салганнар иде.

Табын әзерләвен әзерләде, ләкин сәбәбен берсенә дә әйтмәде.

Уллары кайтмаган көнне борчуга калган ике кодагыйны, театр бер атнага гастрольгә чыгып киткән, Салих эшкә барганда белмичә калган

булган, үзем барып белештем, дип тынычландырды Зәйнәп. Икенче көнне кызы Салихларда кунып калды микән әллә дип белешергә кергән Анна Ивановнага ул яшертен генә серне чиште. Яшьләрнең шундый нәрсә уйлап чыгаруына анысы куанды гына. «Башлары эшләгән, карчыкларны борчып тормаганнар, – диде. – Ә кайткач инде эш узган була, бераз борчылырлар да кичерерләр», дип уйлады.

Кышкы салкын ияртеп килеп кергән Салих белән Валентинаны Мәхүпҗамал аптырап:

– Гастрольгә бергә чыгып киткән идегезмени суң? – дип каршы алды.

– Бергә чыгып киткән идек шул, – диде Салих.

Алар чишенделәр, туннарын салып, чөйгә элделәр дә, үзләрен көтеп карап торган Мәхүпҗамал белән Зөләйха кодагый каршына килеп бастылар.

– Мин гаепле, әнкәй, бүген синең алда. Ләкин улыңны кичерүеңне телим. Без Валя белән өйләнештек. Бүгеннән ул синең киленең. Ассаң – ас, киссәң – кис, – диде Салих.

– Ишкәнсез икән ишәк чумарын, – диде Мәхүпҗамал, аннары яулык очы белән яшьләнгән күз читләрен сөртеп алды. – Кайсы гына ана баласын бәхетсез итеп күрергә теләсен?! Үзегез хәл иткәнсез, сезгә яшисе. Бәхетле булыгыз, – диде ана һәм килененең кулыннан тотып, кочагына алды.

– Әйдәгез, табын янына, – диде Зәйнәп, һәм барысын да зал түренә әзерләнгән өстәл тирәсенә чакырды. Өбрәдәге Бикмөхәммәт абыйларының аларда яшәүче кызлары Сәгадәт белән Зәкияне үзенә ярдәмгә дәшеп, берсенә Валентинаның әнисе Анна Ивановнаны чакырып керергә кушты.

– Йөрмә, Сәгадәт, – диде Салих. – Алар белә. Без башта алар янына кереп чыктык. Хәзер үзләре керергә тиеш.

Ул арада ишектә Анна Ивановна белән уллары Юра һәм Анатолий күренде.

– Эһ, табын түгәрәк буласы иде, абый гына юк, – дип борчылу белдерде Зәйнәп, бу көннәрдә Кызыл Байракта өйләр салдыру белән мәшгуль булган Шиһап абыйсын искә төшереп.

– Борчылма, ул да хәзер кайтып җитәргә тиеш. Театрдан шалтыратып сөйләштек, – диде Салих.

– Сез әллә инде театрда да булдыгызмы?

– Булдык, театрда да булдык. Анда да беләләр. Озак көттермәбез, килеп җитәрбез диделәр Кәрим абый белән Заһидә апа.

– Без монда кызлар белән тагын үзебезгә генә, унбиш кешелек кенә табын әзерләгән идек.

– Борчылма, Зәйнәп, күңелең иркен булсын. Сыешырбыз. Мондый көндә без басып торырга да әзер, – диде Салих, Валясын кочып.

Табын артына утырышырга да өлгермәделәр, өйгә шау-гөр килеп Кәрим белән Заһидә Тинчуриннар, Зәки белән Мәрфуга Баязитскийлар, Маһисәрвәр белән Нури Сакаевлар килеп керде. Алар чишенеп утырышуга, Кызыл Байрактан Шиһап җизнәсе, хатыны белән аның энесе Хәйрулла да кайтып җиттеләр. Шиһап бу хәбәрне ишеткәч, Казанга туп-туры Насретдин баҗасы белән Рауза җиңгәләренә кайтып төшкән, мәҗлескә аларны да алып килгән иде. Көтмәгәндә, каяндыр ишетеп, иң соңгы кунак булып, Мансур Мозаффаров килеп керде.

– Мондый мәҗлестән каламмы соң инде?! Ишетүгә йөгереп килеп җиттем! – диде ул ишектән керә-керешкә.

Кая китеп юк булулары хакында беркем берни белми дип йөргәндә, Салих белән Валентинаның өйләнешүен билгеләп үтәргә бер өй халык җыйналды. Халыкның да ниндие генә әле. Бернинди тамада, артистларың да кирәк түгел, үзләре артистлар, үзләре тел осталары. Мәҗлесне алып баручы ролен үзеннән-үзе Тинчурин кулына алды. Түр башына Салих белән Валяны утырттылар. Салих ягына әнисе Мәхүпҗамал, апасы Әминә белән Шиһап җизнәсе урын алды. Валя ягына Анна Ивановна белән уллары Юра һәм Анатолий утырды. Барысына да урын табылды. Мәҗлесне башларга Тинчурин сүзне Салихның Шиһап җизнәсенә бирде:

– Әйдә, Шиһап абый, әниләреннән кала монда иң өлкәне син, булмаса, син алып бар мәҗлесне, – диде.

– Кых-хым, – дип тамак кырып алды башта Шиһап. – Җәмәгать, безнең Салих гади генә кеше түгел, өйләнүе дә кешечә генә булмады. Бер кешегә дә әйтми-нитми бер атналык гастрольдә йөреп кайтканнар. Театрда да белми калганнар хәтта гастрольне. Билеттан җыйган акчаларын «Кызыл Байрак» авылын төзү фондына тапшырырлар инде. Үзләренә бер йорт салып бирербез, Алла боерган булса.

– Җәле, шаяртып сөйләмә әле, – дип куйды Мәхүпҗамал. – Гастрольдә булмаганнармыни?

– Булганнар, дим бит инде. Йә, ярар. Яшьләргә бәхет телим. Әниләрен һәм безне шатландырып, бәхетле, матур тормышта яшәсеннәр. Сәвит иленә игелекле уллар, кызлар табып үстерсеннәр. Менә шул. Шуннан артыгын тагын ни сөйләп торасың?

– Рәхмәт! Иң кирәклесен әйттең. Үзең әйтмешли, шуннан артыгы кирәк тә түгел. Йә, ярый, җәмәгать, ашап-эчеп утырыгыз. Кызлар бик тәмле ризыклар пешергәннәр. Бик матур табын хәзерләгәннәр.

– Син ашауга кайтарып калдырма әле, Кәрим туган, бу мәҗлесне. Өйләнү түгел сөйләнү, дигән Тукай да. Өйләнер өчен зур батырлык кирәк. Бигрәк тә Салих очрагында, – дип, Нури Сакаев сүз алды.

– Әйтмә дә, – дип, аны хуплап куйды Шиһап. – Җәле, сөйләп җибәр, Сакай, нинди батырлык кылган инде безнең Салих?

– Нинди, нинди?! Өйләнгән! Шул батырлык! Бөтен егетнең дә хәленнән килә торган эш түгел бит әле ул. Яучы җибәрмичә генә, кыз кулын да сорап тормыйча, тоткан да өйләнгән. Урлаган, кыскача гына әйткәндә!

– Кыз урлау дигәннән, бер нәрсә язып ятам бит әле мин бу көннәрдә. Беттеме сүзең, Сакай? Әгәр бетсә, сезгә дә сөйлим хәзер шул нәрсәдән бер хикәятне, – дип, Нурины бүлдерде Тинчурин.

– Сөйлә, сөйлә! – дип, кыстый башладылар хатыннар.

– Тәк. Менә болай ул. Кыз урларга хыялланып йөрүче бер егет турында. Ә мин кыз урлауны ат урлауга әйләндердем. Менә, тыңлагыз.

Барысы да, дөньяларын онытып, Тинчуринның хикәятен тыңларга колакларын торгыздылар. Тинчурин сөйләсә сөйли инде. Һәрвакытта да яңа язган бер әсәреннән өзек булып чыга. Аннары беркадәр вакыт узгач, шул нәрсәкәй сәхнәгә дә менә.

– «Их, егетләр, ат дигәч тә йөрәкләргә зәмзәм сулары койган төсле

булды. Белмисез, егетләр, ат урлауның рәхәтен, ләззәтен белмисез. Менә караңгы төн, ди. Ындыр аркылы корсак өстеннән генә килеп, сырт капканың алдына туктыйсың. Йортта эт өрә башлый. Син тыныңны чыгармыйча, күләгә төсле тын гына торасың. Шул арада аргамак, җаныем, абзарында пошкырып куя. Йөрәкләр тиздән кавышуны сизгәнгә, кытыкланып китә, сулышлар кысыла башлый. Капка астын казып, йортка керәсең дә, салават укып, агуланган икмәк, ит кисәкләрен эткә ташлый торасың. Бер ярты сәгатьтән, Аллага тапшырып, эт тончыга. Аргамакның ишегендә чабата хәтле бикләнгән йозак була. Бисмилла әйтеп, отмычка белән келт итеп бер борасың да, йозак шылт итеп борынын күтәреп куя. Абзар ишеге ачылуга, карабодай басуындагы төсле хуш исләр аңкып китә. Аргамак, җаныем, көяз кызлар төсле, кызыл билле прәннек кимергән кебек шыгыр-шыгыр печән кимереп ята, сылу кызлар көлгән төсле, көязләнеп пошкырып куя. Барып ялыннан сыйпагач, бәгърем, килдеңме дигәндәй, пуф итеп бер сулап ала. Шуннан иренен боргычлап, акрын гына сырт капкадан чыгарасың да, әгүзе-бисмилла әйтеп атланып, әйдә... Тфф! Менә шул чагындагы рәхәтне әйтәм, кыз куенына керүләрең бер якта кала шул. Калтырап, дерелдәп торган нык гәүдәсен аякларың белән шундый итеп кочаклыйсың, Таһир Зөһрәсен дә алай кочаклый алмагандыр. Йөрәкләрең оҗмах рәхәтләрен сизә инде шул чагында. Сикергән саен бөтен гәүдәсе уналты яшьлек кызның күкрәкләре дерелдәгән төсле дер-дер килә. Менә шул дерелдәүләрдән йөрәк майларың эреп китә. Әйтерсең, зәмзәм күлендә йөзәсеңмени, малай... Аның көчле күкрәгеннән болыт-болыт булып чыккан сулышларын, дулкын-дулкын булып җилбердәп уйнап торган ялларын, тояк тавышларын, матур кызлар кулында уйнаган кайчы төсле колак уйнатуларын, барысын-барысын да йөрәк белән сизеп торасың. Шул чакларда үзеңнең гәүдәңне аның гәүдәсе белән бергә туып үскән төсле сизәсең, аның җаны синең җаныңа тоташып, ат белән кеше бер була да кала, шулкадәр җанлы якынлык була... Их, егетләр, ат урлауның тәмен, ләззәтен белмисез. Ул әле сезнең борыныгызга кермәгән. Их, шайтан алгыры, тел юк аны аңлатырга!..»

– Бер дигән монолог! Үземә бирерсең, Кәрим! Шулхәтле рольгә кереп утырдым, тыңлаганда ук, – диде Нури Сакаев.

– Хикмәт ат урлауда түгел бит, туганкайлар. Сүз бит кыз урлау, беренче мәртәбә кыз куенына керү турында бара. Сизмәдегезмени?! Безнең арада бүген монда Салихтан да бәхетле егет юк. Беренче тапкыр кыз куенына керү ләззәтен кичергән ир бит ул бүген безнең арада! Менә шундый егет хисләрен күңелемнән кичереп язганга уңышлы чыкты да ул монолог. Әллә мине ат урлап караган кеше дип уйлыйсызмы? Юк, бер тапкыр да юк, Аллам сакласын, бәласеннән баш-аяк. Ә кыз куенына кергән бар, – дип, Кәрим янында утырган бичәсе Заһидәнең иңнәреннән кочып алды.

– Һәй, оятсыз, – дигән булды Заһидә. – Кеше алдында сөйләп утырмыйлар инде андый нәрсәне.

– Йә, ярар, туктатыйк, – диде Тинчурин. Аннары шыпырт кына тыңлап утыра башлаган Шиһапка сүз кушты: – Шиһабетдин туганкай, үз вазифаңны өстеңнән төшердең. Халык минем авызга карап утыра башлады монда. Тукай әйтмешли, сүз башы бит Шүрәле!

– Әйе шул, күреп торасыз, без монда Салих энекәш белән Валя сеңелнең

өйләнешүләрен билгеләп үтәргә җыйналдык. Гаилә коргач бит инде аның икең бергә тора башларга кирәк булачак. Ашарга пешерергә хатын бар. Но пешерер өчен кәстрүл кирәк. Менә безнең Баязитский туган шуны истә тотып, яшь парларга театр исеменнән бүләк алып килгән, дип ишеттек. Сүз сезгә, хөрмәтле Зәки әфәнде!

Зәки Баязитский торып басты да, өстәл яныннан чыгып, ишек төбендә киемнәр элгече янында торган кәгазь тартманы барып алып килде.

– Менә без, җәмәгать, театрда шундый фикергә килдек. Кәстрүлен табарлар, кәстрүлен куеп ашын пешерер өчен примусы да кирәк булачак, дип, сөйләштек тә, примус бүләк итәргә булдык. Рәхим итеп кабул итеп алыгыз. Котлауларга без дә кушылабыз. Бәхетле матур тормыш корып, балалар үстереп, рәхәт яшәгез.

Баязитский каршына барып баскан Салих та, рәхмәт әйтеп, тартманы алып, Валяга тоттырды:

– Менә сиңа булыр бу инструмент. Моннан соң скрипкә түгел, примус тотып уйнарсың, – дип шаяртты.

– Әйе, җәмәгать. Ике музыкантның өйләнешүен котларга җыйналдык та сүз боткасына әвереләдереп утырабыз. Түр башында җыр-музыка булырга тиеш монда бүген! – дип, Шиһап моңаеп ук утыра башлаган абыстайлар ягына карап алды да Зәйнәптән гармун алып килергә сорады: – Кая, сеңелкәй, алып кил әле Салихның тальянкасын. Иң беренче уйнарга өйрәнгән гармунын.

Ул арада Салих торып, фортепиано янына барып утырды. Валентина да барып, пианино янындагы тумба өстендә яткан скрипканы кулына алды һәм кылларын чирткәләп, уйнарга хәзерләнде. Салих клавишаларга баскалап, беренче аккордларны алды да йөгертеп кенә көй башлап җибәрде. Бу Шопенның вальсы иде. Валя скрипкада пианинога кушылды. Залга искиткеч моңлы, йөгерек музыка аһәңнәре таралды. Салих үзләренә карап утыручыларга:

– Биергә торыгыз, биегез, – дип кычкырды.

Кәрим торып басты һәм реверанс ясап, янында утырган Заһидәсен вальс биергә чакырды. Алар артыннан парлашып, Баязитскийлар, Сакаевлар, Зәйнәп белән Хәйрулла серле дә, сихерле дә торган музыкага вальс әйләнергә тотындылар.

Вальстан соң Салих гармунда уйнап алды. Хатыннар чәй эчтеләр, тәм-томнардан авыз иттеләр. Артистлар үзара сөйләште, Салих белән Валяны котладылар. Мәҗлес озак дәвам итте.

Тинчурин соңыннан гына:

– Нәрсә син монда кунар агачы, сайрар куагы булмаган кош кебек борыныңны салындырып утырасың? – дип, бер читтә моңаеп, уйга баткан Мансурга сүз катты.

– Менә дустыма карап, сокланып утырам. Нинди яр тапты үзенә! Икесе дә пар килгәннәр.

– Шулай булгач, әйт сүзеңне, дусларыңны котлап.

Мансур торып басты.

– Игътибар! Игътибар, җәмәгать. Сүз Салихның балачак дусты Мансур Мозаффаровка бирелә!

Мансурның килгәндә дустын котлап, әллә нинди нотыклар тотарга дигән уйлары бар иде. Көтмәгәндә генә сүз бирелгәч, ул аларның бөтенесен дә онытып бетергән булып чыкты. Ни әйтергә дә белмичә, ык-мык килеп торды да:

– Котлыйм, дустым, парлы тормышка аяк басуыгыз белән. Бәхетле булыгыз! – диде.

– Менә әйбәт тост! Кыска да, оста да! Тикмәгә генә «кыскалыкта osталык!» дип әйтмиләр шул. Рәхмәт! Шуның белән мәҗлес тәмам, дуслар. Таралышырга вакыт. Атна буе йокы күрмәгән кешеләр бар арабызда. Аларга тыныч йокы телик тә таралышыйк, – диде Кәрим Тинчурин, тамада вазифаларын үз өстенә алып.

**12**

1925 ел зур кайгы да алып килде. Салих белән Валентина өйләнешеп, аерым йортка күчеп яши башлаганнар гына иде, Зәйнәп сөйгән егете кулыннан һәлак булды. Казакъстанның Татарстандагы хәрби вәкиллегендә эшләүче Бирнияз Кулиев исемле егет белән яратышалар иде алар. Бирнияз Зәйнәпнең кулын да сорады. Ләкин кыз әнисенең һәм Шиһап абыйсының рөхсәтеннән башка чыгарга теләмәвен әйтте. Ә Шиһап сеңлесенең казакъ кешесенә кияүгә чыгуына катгый каршы иде. «Өйләнешерсез дә, кире үзенең Казакъстанына алып кайтып китәр», – диде. Ә анда дөньялар тыныч түгел. Әледән-әле басмачларның һөҗүмнәре хакында хәбәрләр килгәләп тора иде.

Ул кичне Шәрык клубында булган хәйрия кичәсеннән соң алар Бирниязның өенә кайттылар. Алар вәкиллекнең берничә хезмәткәре белән бер йортта күршеләр булып яшиләр иде. Бирнияз бик кискен куйды мәсьәләне:

– Синнән башка үземнең тормышымны күз алдына да китерә алмыйм. Бүген син минеке булачаксың, бетте-китте, вәссәлам! – диде.

– Юк, Бирнияз, бәгърем, мин абыемның ризалыгыннан башка беркемгә дә чыкмыйм. Чөнки ул минем әтием урынына калган кешем. Ул мине тәрбияләп үстерде, белем бирде, кеше итте. Мин аңа каршы бара алмыйм.

– Димәк, син мине яратмыйсың.

– Яратам, Бирнияз. Ләкин без бергә була алмыйбыз. Без бүген аерылышырга һәм башка беркайчан да очрашмаска тиешбез.

Бирнияз бик кырыс холыклы, үҗәт, үз сүзен сүз итмичә туктамый торган рәхимсез бер кеше иде. Шул ук вакытта ул Зәйнәпкә дә чын күңеленнән гашыйк булган, аны тирән хисләр белән ярата һәм үзенең киләчәген чынлап та аннан башка күз алдына да китерә алмый иде.

– Юк, димәк, син башканы яратасың. Югыйсә абыеңның сүзенә генә карап тормас идең. Әнә Салих туганың марҗа кызы дип тә тормады, яраткач, әнисенең каршы килүенә карамастан, өйләнде дә куйды.

– Аларның үз эше. Ә мин әниемә һәм абыема каршы килергә теләмим.

Шунда Бирниязның күңелендә рәхимсез уй туды, ул кобурасыннан наганын чыгарды.

– Минеке булырга теләмәсәң, башкаларныкы да булма! – диде дә наганын Зәйнәпнең күкрәгенә терәде.

Зәйнәп аннан мондый адымны көтмәгән иде. Ул күкрәге белән егеткә ташланды. Шул вакытта ату тавышы яңгырады. Кыз куллары белән Бирниязның иңнәренә асылынган җиреннән акрын кына идәнгә сыгылып төште һәм шул минутта ук җан бирде. Идәнгә аның күкрәгеннән ургып чыккан кан җәелде. Бирниязның күзләре акайды, «Нәрсә эшләдем мин?!» дигән сорау миен бораулады. Ул иелеп, Зәйнәпне күтәрергә маташты.

– Зәйнәп...

Шулвакыт ишеккә дөбердәтә башладылар. Күршеләренең: «Бирнияз, ни булды? Син өйдәме?» – дигән тавышлары ишетелде. Ул арада ишеккә көчле итеп тибәргә тотындылар, кемдер аны ватып, бүлмәгә керергә тырыша иде. Бирнияз яңадан наганының курогын корды, бикле ишек көчле итеп тибүгә чыдамыйча йозагы ватылып, ачылып китте. Шул вакыт Бирнияз наганын күкрәгенә терәп, курогын тартты һәм кан эченә батып идәндә яткан Зәйнәп өстенә барып төште.

Бу канлы вакыйга Әхмәровлар, Сәйдәшевлар гаиләсен генә түгел, бөтен Казан халкын тетрәндерде. Икенче көнне үк Казанда «Наган көе» дигән бәет чыкты. «Атмачы, наган, атмачы, / Йөрәккәем өзгәләнә / Шул наган тавышыннан...» – дигән сүзләре булган бу бәеткә, «Кара карлыгач микән, / Сары сандугач микән, / Аны үстергән әнкәсе?» – дигән сүзләре булган җырның көен алганнар иде. Бер үк вакытта көнләшүдән үзенең сөйгәнен һәм үзен атып үтергән хәрби начальник турында төрле риваятьләр дә сөйләнде.

Унике яшеннән бирле үсмер чакларында бергә уйнап, шаярып үскән, яшьлекләре бергә үткән, төрле кичәләрдә катнашып, яңа тормышка аяк баскан елларда бергә хыялланып, төрле планнар корып яшәгән, инкыйлаб елларында беркадәр аерылып торгач та, 1922 елда яңадан бер түбә астында яшәп, хатыны Валяның ахирәт дустына әверелгән шаян, шук, тормышны сөя торган кызның шулай аянычлы үлем белән араларыннан китүен Салих та, Валя да бик авыр кичерделәр. «Ул бит тормышны ярата иде! Ул үләргә тиеш түгел иде! Ул әле гомеренең башында гына, аңа яңа аяк атлаган яшендә генә иде!» дип әрнеде Салихның йөрәге. «Аһ, никадәр рәхимсез бу дөнья! Никадәр кешелексез бу кеше дигән тереклек иясе! Нигә кирәк иде инде шулай яраткан кешеңнең гомерен өзәргә?!» Салих бу сорауларга җавап таба алмыйча тинтерәде. Аның күңеле киселде, ни дә булса кулга тотып эшләргә теләге калмады. Ләкин яшәргә кирәк иде. Дөньясына үч итеп яшәргә һәм эшләргә!

Бу елны театр ике генә спектакль – Фәтхи Бурнашның «Камали карт» һәм Мирхәйдәр Фәйзинең «Ак калфаг»ын гына чыгарды. Гастрольләргә дә йөрелмәде. Башлыча театрның үзендә тамашалар алып барды. Ә менә 1926 ел театр тормышында да, Салих иҗатында да вакыйгаларга шактый бай булды. Ул югалту ачысын онытыр өчен тагын да зуррак дәрт, теләк белән иҗат эшенә чумды.

Ел башында бер-бер артлы Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану», Фәтхи Бурнашның «Таһир-Зөһрә», «Яшь йөрәкләр», Гадел Кутуйның «Балдызкай» спектакльләрен чыгардылар. Аннары татар театрының 20 еллык юбилеен бәйрәм иттеләр. Юбилей тантанасы «Мәдәният йорты» бинасында узды. Юбилейга багышланган бу тантаналы җыелышта театрга академия

дәрәҗәсе бирелде. Ул Татар дәүләт академия театры дип атап йөртелә башлады. Шулай ук юбилей елын татарлар яшәгән барлык төбәкләргә гастрольләр белән билгеләп үтәргә, дигән карар чыгарылды. Мәскәү, Оренбург, Кызыл Орда, Ташкент, Сәмәрканд, Әстерхан, Донбасс, Ростов-на-Дону, Царицын, Сарытау – бу гастрольләр буласы калаларның исемлеге. Гастрольләр репертуарында алдагы елларның иң уңышлы дип табылган «Казан сөлгесе», «Сүнгән йолдызлар» һәм «Камали карт» спектакльләре иде.

Салих белән Валя өйләнешкәч, үзләреннән ерак та булмаган бер йортка фатирга чыгып яши башлаганнар иде. Берничә айдан Валяның бәбигә узганы билгеле булды. Салихның гастрольләргә чыгып китәсе, ә аларның майдан башланып, октябрьдә генә тәгәлләнәчәге ачыклангач, Валяга әнисе янына кайтып торырга дип хәл иттеләр.

Никадәрле генә ашкынып эшләсә дә, бөтен җанын, вөҗүден спектакльләргә бирсә дә, Салихның күңеле тыныч түгел иде. Ул хатынын өзелеп сагынды. Гастрольләрдән аны күрәсе килеп, ашкынып кайтты. Валя инде йөклелекнең соңгы аена кергән иде. Хатынының йөкле көннәрен, карынындагы баласы үзенең барлыгын, тиздән мин дөньяга туачакмын дип типкәләнеп, үзен сиздереп ятуын ул бөтенләй күрмәде. Ә Валя Салихны уйлаган чакларында акрын гына карынында яткан баласы белән сөйләшә торган иде. «Малай булырсыңмы син, кыз булырсыңмы, исән-сау гына ту, әти-әниеңнең саф мәхәббәтләренең татлы җимеше булып дөньяга аваз сал!» – дип эндәшә иде. Бик еш кына ул фортепиано алдына утырып, моңлы гүзәл көйләр уйный. Ул уйнаганда баласы тыныч кына тыңлап ята да тыпырчынып җавап бирә, нидер әйтә. «Эһ, боларның берсен дә әтисе күрми бит. Күрсә, ничек сөенер иде ул!» дип уйлый иде Валя.

Гастрольдән кайтып эшли башлагач, буш вакыты булуга ул гел өйгә, Валясы янына ашыкты. Гөнаһ шомлыгына, буш вакыт дигәнең бик аз туры килде. Чөнки ел ахырына рәттән ике спектакль чыгару планлаштырылган иде. Ноябрьдә Гадел Кутуй пьесасы буенча – «Балдызкай», һәм декабрьдә – Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл» драмасы.

Ике әсәрне дә гастрольдә йөргәндә укып, рольләрен бүлештеләр. «Балдызкай» гадирәк пьеса булып, Салих алдына аны музыкаль яктан көйләр, җырлар белән бизәү бурычы гына куелды. Ә «Зәңгәр шәл» – Тинчурин әсәре. Салихлар өйләнешеп кайткач җыелган табында укылган ат карагы монологы менә шушы әсәрдән булып чыкты.

Драманы артистларга Кәрим Тинчурин Донбасс гастроле вакытында укыды. Барысы да тын да алмыйча, йотлыгып тыңлады. Һәркем үзенә роль сайлап утырды.

– Борчылмагыз, барыгызга да роль җитәчәк, – диде Кәрим артистларга.

Драмада егермедән артык персонаж, әллә ничә урында күмәк күренешләр кертелгән иде.

– Бик көчле әсәр бу! – дип мактадылар артистлар драманы.

– Егетләр, сез үзегезгә карагыз, Булат ролен үзем башкарам, – дип белдерде Тинчурин баштан ук. – Ә Мәйсәрә – Галия булыр.

– Чибәр кызны сайлыйсың, Кәрим абый. Әле ширбәт аеннан айнып бетмәгән Ситдыйк ни дияр икән соң? – дип шаяртты Салих.

Ел башындарак кына Ситдыйк Айдаров белән әле Казанда театр техникумында укып йөрүче Галия Кайбицкая Оренбургтагы гастроль вакытында өйләнешкәннәр генә иде. Салих аларның туенда тамада вазифасын башкарды.

– Ничава, Ситдыйкка да роль табарбыз. Мәйсәрә тирәсендә бөтерелер ул да, – диде Кәрим.

– Ә мин Миңлегали булырмын, пожалуй, Кәрим энекәш. Ат карагы монологын син Салихларда укыган чакта яратып калган идем. Миннән дә оста итеп сөйләүче булмас, – диде Нури Сакаев.

– Юк, Нури абый, сиңа Ишан ролен бирергә дип уйлап тора идем.

– Ә юк, Кәрим туганкай, андый зур рольне тарта алмам, миңа шул ат карагы Миңлегали дә ярап торыр. Нишләптер йөрәк сиздерә соңгы араларда.

– Йөрәк барыбызда да бар инде ул. Үзеңә кара инде алайса. Менә Зәйни туган баш тартмас иде. Бер дигән ишан, карап торышка ук.

– Рәхәтләнеп! Дүрт-биш хатын кочагында кайчан рәхәтләнерсең, шул спектакльдә генә булмаса, – дип, халыкны көлдереп алды Зәйни Солтанов.

– Укый башлаганыгыздан бирле Мәйсәрә ролендә хис итеп утырган идем үземне, Кәрим абый, – дип, дәгъва белдереп алды Кушловская.

Зәйни Солтанов шунда шаяртуын дәвам итеп:

– Кара син аны, ишан хатыны буласы килгән, – дип куйды.

– Рольләр барыбызга да җитәчәк. Әмма эшнең иң күбе монда, Салих, сиңа булыр, мөгаен, – диде Тинчурин. – Һәр күренешне җыр белән башларга кирәк. Дуэтлар, күмәк җырлар, музыка, бию. Әле боларын синең белән аерым эшлисе булыр. Уйлап йөр. Казанга кайткач иркенләп утырырбыз.

– Күрәм инде мин ул номерларны, Кәрим абый. Борчылмагыз. Бер дигән булыр! – диде Салих.

Шул вакыттан башлап, Салих көнен дә, төнен дә димәсәң, хата булыр, һаман шушы драма турында гына уйлап йөрде. Вакыт чыннан да аз калган иде. Әле шуның өстенә «Балдызкай»ны чыгарасы бар. Өйдә бала көтүче сөекле Валясына ничектер ярдәм итәсе килә.

Моңа кадәр Салих барлык драмаларга да музыкаль бизәлешкә нигез итеп халык көйләрен ала иде. Ә монысында аның иҗатында тамырдан борылыш булды кебек. Ул бөтен музыкаль номерларны да үзеннән иҗат итте. Көйне үзе чыгарды. Кәрим сәхнәдә барган күренешләрдә диалоглар арасына җыр, музыка кыстыруның барысын да Салихның тәкъдиме белән эшләде. Сәйдәшевкә генә түгел, Тинчуринның үзенә дә шактый тирләргә туры килде спектакльнең музыкаль бизәлешен эшләгәндә. Чөнки Салих: «Менә монда җыр сорала, сүзен язарга кирәк», – дип, аның теңкәсенә тиеп бетте. Тинчуринның үзен дә чын мәгънәсендә опера җырчысына әверелдереп бетерде ул. Булатның хордан соң җырлый торган:

«Дусларым, каңгырып кайттым,
Дусларым, ерак илләрдән.
Шахтёрлар – батыр егетләр,
Дусларым, сәлам әйттеләр:
Матур кызларга, якын дусларга,
Син дә, кодача, өлешсез калма.

Анда юк урак, анда юк сабан,
Анда икмәкне алалар сатып.
Эшчеләр санын, номерлар тагып,
Меңәрләп кенә санайлар анда.
Һай!..» –

дигән җырын опера ариясеннән берничек тә аерып булмый бит инде. Җитмәсә, аның җырын яңадан хор дәвам иттерә. Ә Тинчуринга опера җырчысында булырга тиешле вокал осталык каян килсен? Шуңа күрә ул Салихтан үзенең чыгышын речетатив рәвешендә генә башкару өчен эшләтте. Премьерадан соңгы постановкаларда Булат ролен Айдаров башкарыр дип, аның тавышы өчен яңадан яздыртты. Кыскасы, гадәттәге музыкаль бизәлештән нык аерылып торган, драма, оперетта һәм бер үк вакытта опера элементлары да булган үзенчәлекле бер жанр килеп чыкты. Тинчурин аны «музыкаль драма» дип атарга кирәк дигән фикергә килде. Бу татар сәхнәсендә генә түгел, бөтен дөнья сәхнә әсәрләре өлкәсендә яңа, үзенчәлекле жанр иде. Моның беренче чаткылары «Сүнгән йолдызлар» белән беркадәр «Галиябану»да бар иде. Ләкин «Зәңгәр шәл» бөтенләй диярлек алардан да аерылып тора торган булды. Һәм бу жанрны тудыручы – Салих Сәйдәшев!

Ниһаять Салих түземсезләнеп көткән көн җитте! Валентина октябрьнең егерме алтысында чат үзенә охшаган, кап-кара чәчле, кара тут йөзле, кара кашлы түгәрәк кенә ир бала тапты! Салихның шатлыгының чиге-чамасы юк иде. Ләкин шатлыклы көннәр озакка бармады. Ул көннәр дә түгел, сәгатьләр арасы гына булып калды. Баласын таптырганда, табиблар ниндидер зыян китереп, каны зарарланып, 1926 елның 3 ноябрендә Валя вафат булды.

Зәйнәпнең фаҗигале үлеменнән соң йөрәгендә ясалган тирән яра әле төзәлергә дә өлгермәгән бер мәлдә тагын да тирәнрәк, тагын да тетрәндергечрәк авыр җәрәхәт салды тормыш аның бәгыренә. Ул ни эшләргә дә белмәде, канатлары сынган кош кебек, бөтен гәүдәсен салындырып, күзләрен бер ноктага төбәгән килеш сәгатьләр буе рояль алдында утырды. Башын рояль капкачына терәп, үкси-үкси елады. Аның күңелендә, аңында әллә нинди хәсрәтле, кайгылы, сагышлы матәм көйләре өермәсе бөтерелде. Ләкин ул аларны тышка чыгарырга теләмәде. Кешеләргә ул көйләрне ишеттерәсе килмәде. Болай да бик авыр иде бу минутларда.

Салих шундый сагышлы чакларында «Зәңгәр шәл»дә Булат ролен уйный башлаган Ситдыйк Айдаров турында уйлый иде. Ул да бер ел элек кенә, Ленинградта татар театрында эшләп, хатыны Әшрәф Синяева вафат булганнан соң Казанга кайтып төшкән иде. Аңа да сөекле хатынын югалту авыр булгандыр. Оренбургта Ситдыйкны Галия Кайбицкия белән кавыштырырга теләүләре дә шул югалту ачысын ничектер җиңеләйтү максатыннан булган иде.

Әшрәф үзе – Касыйм шәһәрендә туган кыз. Яшьли театр белән мавыгып, Петербург театр мәктәбендә укып чыкканнан соң ул Казанга килә, «Сәйяр» труппасында уйный башлый. Шунда Ситдыйк белән яратышып, 1918 елда өйләнешәләр. Гражданнар сугышы елларында Әшрәф театр труппасы җитәкчесе буларак, бер төркем татар артистлары белән комиссар Шамил Усманов кул астында Урта Азия шәһәр һәм кышлакларында спектакльләр

уйнап йөриләр. Татбригаданың командиры Якуб Чанышев 1920 елда аларны Мәскәүгә, укучы мөселманнар өчен спектакльләр һәм концертлар куярга җибәрә. Әшрәфнең үлеме Ситдыйк Айдаров өчен зур югалту иде. Күп еллар партнёрлар буларак, спектакльләрдә бергә уйнаган, бер-берсен сөйгән ярларның мәңгегә аерылышуы иде бу.

Берәү туа, берәү үлә. Тормыш шулай дәвам итә. Табуларны югалтулар алыштыра, югалту арты тагын кемдер дөньяга килә. Югалтулар никадәр авыр, кайгылы булсалар да, үлем артыннан үлеп булмый шул. Яшәргә кирәк. Онытырга, онытылырга кирәк. Салих та шулай уйлады. Беркемгә, берни турында әйтмәсә дә, ул бөтен кайгыларыннан эш белән онытылырга теләде. Валя вафатыннан соң бер ай узарга да өлгермәде, 20 декабрьдә «Зәңгәр шәл»нең премьерасы булды. Ул шулкадәр зур уңыш белән узды ки, бу спектакльне сәхнәгә чыгару өчен Салих куйган хезмәтнең никадәр зурлыгына, нәкъ менә аның тырышлыгы аркасында тамашаның шундый зур уңышка ирешүенә бөтен театр халкы гаҗәпләнде дә, сокланды да. Музыкаль драмада тулысынча Салих Сәйдәшев көйләре уйналды. Спектакль ике авторның – Кәрим Тинчурин һәм Салих Сәйдәшевнең хезмәт җимеше дип кабул ителде.

Спектакльне чыгаруның артистлар өчен иң зур авырлыгы аларның моңа кадәр оркестрга кушылып, бер тапкыр да җырлаганнары булмауда иде. Монда бит җырлау гына да түгел, сөйләм вакытында яңгыраган музыканы да ишетеп, шуңа туры китереп сөйләү сорала. Салихка репетициядә артистларга менә шуларга өйрәтергә туры килде. Ул моны зур түземлек белән башкарды. Барып чыкмаганда да кул селтәмичә, дәшми-тынмый өйрәтте. Артистлар шуның өчен дә Салихка зур рәхмәтле иде.

Ләкин тетрәндергеч фаҗигаләр әле бетмәгән булып чыкты.

28 февраль башкаларыннан берние белән дә аерылмаган гадәти бер эш көне иде. Ул көнне «Энҗекәй» спектакле булырга тиеш иде. Сәхнәдә егерме көн элек кенә чыгарылган шушы спектакленең репетициясе тәмамланды. Шул вакыт сәхнә артында кайсыныңдыр чырылдап кычкырып җибәргәне ишетелде. «Ни булды? Ни булды?» – дип, бер-берсеннән сораша башладылар. Ул арада «Нури абый!.. Нури абый егылды...» дигән шау-шу китте. Репетициядән соң спектакль башланганчы ял итеп алырга дип, сәхнә артына чыгып утырган җиреннән Нури Сакаевны көтмәгәндә йөрәк өянәге тотып, һушын җуеп егылган иде. Имән кебек таза, пәһлевандай мәһабәт гәүдәле, театрның төптән җигелеп тартучы кодрәтле артисты дөнья белән бәхилләшкән иде. Нибары 42 генә яшендә! Ул китте елаш! Хатыннар бер-берсеннән дә читенсенмичә үкси-үкси күз яшьләрен түкте. Нуриның җансыз гәүдәсе башында соңлап кына өйләнгән, үзеннән унбиш яшькә кече ябь-яшь хатыны Маһисәрвәр үкси.

Бу үлем Салихны да нык тетрәндерде. Әле сөекле Валясын югалту кайгысының йөрәген тырнап торуы узмаган. Икесенең дә яраткан дуслары, якын кардәшләре Зәйнәпнең аянычлы үлеме китергән хәсрәт төене бугаз төбендә утыра. Шулар өстенә тагын бер зур югалту.

Аһ, бу тәкъдир! Нинди мәрхәмәтсез! Нинди рәхимсез! Нигә соң син иң кадерле, иң газиз, яхшы кешеләрне генә алып китәсең?! Нигә соң син шулай бәгырьсез?!

Бу көнне спектакльне уйнамаска дигән карарга килделәр. Сакайның гәүдәсен өенә алып кайтып тормадылар. Табутын театр урнашкан Мәдәният йортының өске катына күтәреп, зал уртасына куйдылар. Артистларның күбесе өйләренә кайтып килделәр дә мәетне төн сакларга театрда калдылар. Ишетеп, күп кенә дуслары, язучылар, җырчылар килде.

Якын дустын югалтудан тирән кайгыга баткан Салих икенче катка менә торган баскыч астында торган рояль артына барып утырды. Аңа инде күптән тынгы бирмәгән, Зәйнәп белән Валентинаны югалтканнан соң гел күңелендә йөргән тирән сагыш, хәсрәт тулы көйләр ташып чыгып, гаять кайгылы да, газаплы да, үлем ачысына каршы торган күтәренкелек рухы белән дә сугарылган матәм маршының кәгазьдәге тамгалары булып нота рәтенә салындылар. Аның күзләреннән кәгазь өстенә яшь тамчылары тама иде. Менә ул ноталарны язып бетерде дә рояль капкачын ачып, уйнап карады. Залда хәсрәтле, авыр тойгылар уяткан матәм көе яңгырады. Музыка тавышын ишетеп, аның янына артистлар җыйналды.

Салих шунда музыкантлар өчен һәр инструментның партитураларын язарга утырды. Бер сәгать тә үтмәгәндер, матәм маршының оркестровкасы әзер иде инде. Оркестрантлар тиз генә репетиция ясап алдылар. Моңа кадәр әле дөньяда тиңе булмаган, кеше колагы ишетмәгән беренче матәм маршы дөньяга туды.

– «Сакай маршы» булыр бу, – диде Салих.

– Мин дә «Хушлашу» шигыре яздым, – диде төн сакларга килгән язучылар арасыннан шагыйрь Гадел Кутуй.

Маршны берсе дә тыныч кына тыңлый алмады. Оркестрдан агылган тетрәндергеч моң барысының да күзләреннән яшь булып тамды. Бугазларга төер тыгылды. Хатыннар үкси-үкси еладылар. Салих үзе дә тыелып тора алмады. Дирижёрлык иткәндә, ул әледән-әле кесәсеннән кулъяулыгын чыгарып, бите буйлап тәгәрәгән күз яшьләрен сөрткәләде. Соңгы бер елда югалткан якын кешеләре кайгысыннан килгән сагыш-хәсрәт аның шушы әсәрендә агылган моң булып төерләнгән иде.

Икенче көнне Сакайны мәңгелек юлга озатканда да, шул хәл булды. Марш көенә бөтен урам елый-сыктый иде.

**13**

1927 ел татар тормышына зур яңалык алып килде. Октябрь инкыйлабының ун еллыгы көнне Татарстанда радио сөйли башлады.

Татарстанда радио ачылу Шамил Усманов шәхесе белән бәйле. Әле инкыйлабка хәтле үк большевиклар партиясенә кергән ялкынлы революционер, гражданнар сугышы комиссары, каһарман сугышчы, язучы, җәмәгать эшлеклесе егерменче елларга кергәч үк радио белән кызыксына башлый. Радио эшләрен алып бару өчен Татар дәүләт академия театры урнашкан «Мәдәният йорты»нда бер кысан гына бүлмә бүлеп бирелә. Радиостудия моңа кадәр театр тирәсенә тупланып, төрле очрашуларын үткәргән язучыларны, мәдәният, сәнгать кешеләрен берләштерүче үзәккә әверелә.

Радио оештыру эшләре башланган көннәрдә үк Салих Сәйдәшев Шамил Усманов белән очраштылар. Бу күптәнге танышларның, дусларның

очрашуы иде. Салих Шамил Усманов комиссары булган Төркестан фронтында хезмәт иткәндә, алар еш очрашалар иде. Командарм Фрунзеның уң кулы булган комиссар Шамил Усманов Татбригада сугышчыларының рухын күтәрү буенча эш алып барганда, хәрби оркестрның җитәкчесе булган Салих Сәйдәшев белән тыгыз элемтәдә торды ул елларда. Аннан соң Оренбургка да Салих Шамил Усмановның тәкъдиме белән барды һәм анда да, оркестр оештырып, Шәрык музыка мәктәбенә җитәкчелек итте. Һәм менә Казанга әйләнеп кайтып, бөтен көчен, ихласын радио оештыруга багышлаган язучы беренче тапшыруларыннан ук радиода музыканың зур әһәмияткә ия икәнен аңлап алды. Радиоконцертлар оештыруда үзенә иң зур ярдәмче нәкъ менә Салих Сәйдәшев булырга мөмкинлеген төшенгән Шамил Усманов әле радио эшли генә башлаган көннәрнең берендә әдәби тапшырулар редакторы Исмәгыйль Усманов белән Салих Сәйдәшевне үзенә чакырып кертте.

– Котлыйм, егетләр! Зур эш башладык. Халык безнең эшкә ышана, көн саен дистәләрчә хатлар килә, – дип, Усманов өстәлендә яткан бер өем хатка күрсәтте. – Радио эше ул – иҗади эш. Монда без язучылардан, артистлардан, җырчылардан, музыкантлардан башка эшли алмыйбыз. Килгән хатларга җавап итеп җырлар тапшырырга кирәк. Халык радиога ышансын өчен хат язучыларның үзләрен чакырып, радиодан чыгыш ясатырга кирәк. Без радиодан көне буе сөйләп тора алмыйбыз, Мәскәү радиосы алып барган тапшыруларны өзеп, көннең билгеле бер вакытында гына эфирга чыгарга рөхсәт бирелә. Менә шул чакта җырчылар турыдан-туры эфирга чыкса, килгән радиотыңлаучыларның үзләренә сүз бирсәк, шуннан да яхшысы булмас. Ә син, Салих дускай, радионың музыкаль редакторы вазифаларын үз өстеңә алсаң, әйбәт булыр иде. Бөтен музыкантлар, артистлар, җырчылар синең күз алдында, синең кулдан үтә, кем әйтмешли.

– Минем бит, Шамил абый, театрда эшем бар.

– Театрда көне буе эшләп утырмыйсыз бит. Тапшырулар да көне буе бармый. Эфир вакыты җиткәнче чыгыш ясаучыларны әзерләп куярга мөмкин. Аннары, радиоспектакльләр җибәрергә була эфирга. Театр спектаклен турыдан-туры трансляцияләргә дә мөмкин.

Салих беркайчан да, беркемнең дә тәкъдимен кире кага белми торган йомшак кеше иде. Бу юлы да ул Усмановның сүзенә каршы килә алмады, сүзсез генә баш кагып риза булды. Инде мәсьәләне хәл ителгән дип санап:

– Шамил абый, – дип, сүзгә Исмәгыйль Усманов кушылды. – Студия бүлмәсе бик бәләкәй. Студияне театр фойесына күчерсәк ничек булыр икән?

– Ә нәрсә, бик әйбәт фикер! Спектакльләрне дә шуннан трансляцияләргә уңайлы булачак.

– Тагын бер тәкъдим бар, – диде Исмәгыйль. – Чыгыш ясаучыларны тәкъдим итәр өчен диктор штатын булдырырга кирәктер. Көн хәбәрләрен укыр өчен дә әйбәт булыр иде диктор штаты.

– Килешәм. Диктор ул инде текстны куелган яхшы тавыш белән укырга тиеш. Андый тавыш гадәттә артистларда инде. Берәр кандидатура бармы соң?

– Минемчә, артист булуы мәҗбүри түгелдер. Дикциясе әйбәт булса, дөрес итеп сөйләсә, грамотасы яхшы булса, шул җиткән дип саныйм.

Язучылар арасында да бар андый иптәшләр. Алар сүзнең, әйтергә теләгән фикернең мәгънәсен артистларга караганда да яхшырак аңлап, тыңлаучыга җиткерә алачак дип, уйлыйм. Шундыйлардан, Гадел Кутуйга тапшырсак бу эшне, әйбәт башкарып чыгар иде шикелле.

– Яхшы. Килешәм. Чакырып сөйләшегез. Эшли башласын, – диде Усманов.

1917 елдан хәрби хезмәттә булган Шамил Усманов 1927 елда отставкага чыгып, Татарстан тамаша предприятиеләре идарәсе начальнигы һәм республика Халык комиссарлары Советының радиостанция төзү буенча махсус вәкиле итеп билгеләнгән иде. Шуңа күрә театр да, радиостудия дә тулысынча аның кул астындагы оешмалар булды. Бер үк вакытта ул актив язучылык эше белән дә шөгыльләнде.

Начальник белән сөйләшү тәмамлангач, Исмәгыйль белән Салих, студия бүлмәсенә чыгып, булачак тапшыруларның графигын һәм программасын төзергә керештеләр. Татарча тапшырулар өчен эфир вакыты әллә ни күп бирелми иде. Әдәби программалар белән концертларны чиратлаштырып төзү турында килештеләр.

Гадел Кутуй тәкъдимгә каршы килмәде. Киресенчә, ул кызыксынып китте. Бу елларда Кутуй «Кызыл Татарстан» гәзитәсендә штаттан тыш хәбәрче булып эшли, ягъни редакциягә килеп-китеп йөри торган вазифада гына иде. Гәзит өчен язган хроникасын радиодан укып, халыкка җиткерү өчен бер дигән форсат ачылып тора дип сөенде ул.

Радиода эшләү Сәйдәш өчен дә зур популярлык китерде. Аның моңа кадәр театрда гына яңгыраган әсәрләрен радио аша бөтен дөньяга тарату мөмкинлеге барлыкка килде. Ләкин, икенче караганда, радио аның эшен бермә-бер арттырды да. Хәзер репетицияләр, спектакльләрдән тыш радиотапшырулар өчен чыгышлар әзерләргә, артистлар белән аерым репетицияләр үткәрергә, чыгыш ясаучыларга үзенә аккомпанировать итәргә туры киләчәк иде.

Элек җырчылар нотаны белмиләр дә иде диярлек. Бернинди дә нотагамазар карап тормыйча, турыдан-туры тамашачыга җырлыйлар иде. Шуңа күрә Салих та җырчыларга аккомпанировать иткәндә нотасыз гына, көйгә үзе теләгәнчә импровизация ясап уйный башлады. Бу аңа көйне иҗади башкарырга, яңа әсәрләр иҗат итәргә мөмкинлеген арттыра иде. Ләкин радио Сәйдәшнең күп вакытын ала һәм аңа еш кына вакытын музыкага бөтенләй кагылышы булмаган нәрсәләргә сарыф итәргә туры килә иде. Шуңа күрә 1930 елда радиостудия башка бинага күчәсе дигәч, ул радионы никадәр яратса да, сөенде генә. Аның өчен театр иң кадерлесе иде. Биредә ул үз оркестрын оештырды, дирижёрлык итте, әсәрләр иҗат итте, спектакльләргә музыкаль бизәлеш ясады, театр дөньясында үз жанрын тудырды – музыкаль драма жанрын.

1928 елда Казанга Максим Горький килеп китте.

Халык җәйге каникуллардан кайтырга өлгермәгән иде әле. «Мәдәният йорты»нда беркем юк. Радиостудиядә эшләүче бер-ике кеше йөри. Театрда әлегә эш юк дип, Салих та берничә көнгә ял алып, Кызыл Байракка киткән иде. Анда ул җизнәсенең ни эш белән шөгыльләнеп ятуын күрер өчен гел баргалап тора. Бигрәк тә җәй көннәрен шунда үткәрергә ярата торган иде.

Театрның профсоюз оешмасы тырышлыгы белән анда артистлар өчен дә берничә йорт төзетте Шиһап җизнәсе. Бу юлы да Хәким Сәлимҗанов, Таҗи Гыйззәт, Мөхәммәт Яушев белән өчәүләп Идел ярындагы Кара күлдә балык чирттерәләр иде. Салихны эзләп көндезге пароход белән Кызыл Байракка Исмәгыйль Усманов килгән. Балыкта икәнен әйткәннәр дә, әлсерәп-сусап, манма тиргә батып, күл буена килеп җиткән.

– Уф, хәлдән тайдым! – ди бу. – Көчкә эзләп таптым.

– Әйдә, кая кармагың? Балык шәп чиртә, – диде Мөхәммәт, сулуы капкан Исмәгыйльне күреп. – Ял итәрсең бераз. Югыйсә ут капкандай әлсерәгәнсең.

– Әлсерәрсең дә. Әйдәгез, сезне алып кайтырга килдем. Усманов җибәрде.

– Ни булган инде тагын?

– Бүген алып кайтып җиткер Салихны, диде. Максим Горький килә, ди, Казанга. «Мәдәният йорты»нда җәмәгатьчелек белән очрашырга тиеш, ди. Махсус концерт күрсәтелергә тиеш, ди. Очрашуны да, концертны да радиодан трансляцияләргә кушылган.

– Ә мин нишләргә тиеш? Бөтен халык ялда. Кайсы кая таралышкан. Берничә төркем гастрольдән кайтмаган, кемнәрдер ял итә, дачаларда. Кызыл Байрактагыларны җыеп алып кайтырбыз инде, – диде Салих. – Нәрсә, шулай ашыгыч рәвештә кайтып җитәргә куштымыни?

– Әйтәм бит, бүген үк табып китер, диде.

– Гаҗәп икән. Мин бит монда үзем генә түгел, Шиһап җизниләрнең өч баласын ияртеп җибәрделәр.

– Балаларны караучы табылыр. Әниләре бардыр. Әйдә, җыен, киттек, – диде Исмәгыйль, алга таба карышып торырга сүз калдырмыйча.

Таҗи белән Мөхәммәткә дә кармакларын җыеп, Салих белән бергә кайтып китәргә туры килде. Салих Кызыл Байракта ял итүче тагын берничә артистны һәм язучыны Казанга кайтырга чакырды.

Аларның кайтканын «Мәдәният йорты»нда ут йотып, Шамил Усманов үзе көтеп тора иде. Ул кул биреп исәнләште дә Салих белән Исмәгыйльне шунда ук үз кабинетына алып кереп китте.

– Бик җитди эш килеп чыкты, егетләр, – дип башлады ул сүзен.

– Белдек инде, – диде Салих. – Маяковскийдан ким булырга тиеш түгел олы кунакны каршылау.

Җәй башында Казанга Владимир Маяковский килеп киткән иде. Ул да «Мәдәният йорты»нда язучылар, җәмәгатьчелек белән очрашты. Анысында артистларны әллә ни җикмәгәннәр иде. Шамил Усмановның үзенә йөгерергә туры килде килүен. Шулай да язучыларның ТАПП оешмасы җитәкчесе Кави Нәҗми йөрде күбесенчә Маяковский тирәсендә. Ә артистлар, музыкантлар кунакка хөрмәт күрсәтүдә әллә ни катышмадылар.

– Монысы алай гына булырга тиеш түгел, – диде Усманов. – Бу юлы зур концерт әзерләргә кирәк булачак. Концертны да, халык белән очрашуны да радио аша трансляцияләүне сорыйлар Мәскәүдән.

– Мәскәүдән үкмени?

– Шуңа күрә бөтен өмет синдә, Салих дускай.

– Кайчанга кирәк инде бу?

– Вакыт калмаган шул. Тагын биш көннән. Ә син, Исмәгыйль дус, Кави белән элемтәгә кер. Язучылар белән берлектә Горькийны пароходтан каршы алуны оештырырга кирәк. Бөек пролетар язучысының Казанга килүен матбугатта да матур итеп яктыртканда начар булмас иде. Матбугат йортына барып, иптәшләр белән сөйләшүне үз өстемә алам.

– Яхшы.

– Яхшы булса, таралыштык, эшкә!

Усманов кабинетыннан чыгуга, Салих театр ягындагы үз бүлмәсенә кереп, концерт программасын төзи башлады. Дөрестән дә, Казандагы бөтен концерт эше чаралар, әдәби-музыкаль кичәләр соңгы вакытта гел «Мәдәният йорты»нда үткәрелә башлаган иде. Радиода тапшырыла торган концертлар да Сәйдәш кулыннан үтә, ул барлык җырчыларны да белеп тора, барысы да репетицияне аның белән ясый. Шуңа күрә Усмановның Сәйдәшевкә мөрәҗәгать итүе тиккә генә түгел иде.

Салих чама белән бер сәгатьлек программа әзерләде. Шуннан да артыкка сузарга ярамый иде. Әле бит Горькийның үзенең дә чыгыш ясыйсы бар. Аннары язучыларның чыгышлары. Әдипнең җавап сүзе булырга мөмкин. Җәмгысы ике сәгатьлек булса, хәттин ашкан.

Усманов программа белән үзе танышып чыкты. Барысы да әйбәт, уйланылган дип, Салихны мактады, рәхмәт әйтте. Аннары репетицияләр үтте. Һәр җырчы, музыкант эшкә җаваплы карады.

Иртәгә кунак килә дигән көнне генераль репетицияне дә Усманов үзе карады.

Һәм менә, ниһаять, Горький киләсе көн җитте. Бу көн бөтен Казан халкы өчен бәйрәмгә әверелде. Усия тирәсе пароход каршыларга төшкән халык төркемнәре белән тулды. Извозчикларга да эш булды. Халыкны ташып кына тордылар. Пароходны махсус комиссия каршы алды. Менә ерактан зур ак пароход килгәне күренде. Пароходның өске палубасында башына ак кепка кигән, инде табигать көзгә авышып барса да, җиңелчә, җәйге ак күлмәктән генә киенгән озын буйлы кеше карап торганын күргәннәр:

– Әнә, үзе! Әнә ул безнең кадерле язучыбыз! – дип кычкырыша-кычкырыша, пристань янына сөрлектеләр.

Пароходка кунакны каршы алучы комиссия әгъзаларын гына керттеләр. Менә бераздан каршылаучыларның һәм алардан бер башка диярлек биек күренгән кунакның чыкканы күренде. Горький трап буйлап пристаньга чыгып баскач, җыелган халык алдына килеп:

– Исәнмесез, кадерле казанлылар! – дип исәнләште.

Пристаньдагылар аңа:

– Исәнмесез, Алексей Максимович! Хуш килдегез! – дип кычкырып җавап бирделәр.

– Казан – минем өчен кадерле шәһәр. Биредә минем яшьлегем үтте! Биредә минем беренче университетларым үтте! Тормыш университетларым! Мин Казан халкын бик яратам! Шуңа күрә менә утыз җиде елдан соң тагын сагынып, ашкынып, сөекле Казанга кайттым! – дип, Горький кыска гына нотык тотып алды. Аннары алгы рәттә басып торучылар белән берәм-берәм кул биреп күрешеп чыкты.

Кичен Татар дәүләт академия театрының тамаша залы халык белән

шыгрым тулы иде. Анда да халыкны бары тик чакырулар белән генә керттеләр. «Мәдәният йорты»на керергә теләүчеләр урамда өелешеп калды.

Кичә симфоник оркестр башкаруында «Зәңгәр шәл» музыкаль драмасының беренче актыннан вокаль-хореографик сюита белән башланып китте. Бу номерны халык аягурә басып, бик озак алкышлады. Салих Сәйдәшевне кат-кат сәхнәгә чыгарып, бик озак кул чаптылар. Дирижёрны Горький үзе дә чыгып котлады, кулын кысты.

Беренче булып олы кунакны котлап, Шамил Усманов чыгыш ясады. Аннары Кави Нәҗмигә, аның артыннан Галимҗан Ибраһимовка сүз бирелде. Горький Ибраһимовны шәхсән белә икән, сәхнәдә ул аның белән кочаклашып күреште. Алар үзара да кыска гына сөйләшеп алдылар. Галимҗан үзендә кабаттан үпкә авыруы башлануын, чирләп китүен әйтте.

– Сиңа Кырымга барып дәваланырга кирәк, – диде Максим Горький. – Мәскәүгә кайткач, хәл итәрбез. Нык бул. Син безгә кирәк. Син әдәбиятка кирәк, – дип, Галимҗанның кабат кулын кысып, сәхнәдән залга озатты.

Аннары чыгыш ясар өчен Гадел Кутуйны сәхнәгә чакырдылар. Аның кулында «Авыл яшьләре» журналының соңгы саны иде. Журналны махсус Горькийга багышлап чыгарганнар икән. Ни арада өлгерткәннәр, журналның тышкы битенә Горькийның рәсемен дә урнаштырганнар иде.

– Алексей Максимович! Татар яшьләре сезне тәбрикли. Журналыбызның нәүбәттәге санын сезгә багышлап чыгардык, – диде Кутуй, һәм журналны әдипнең үзенә тапшырды. – Без биредә сезнең килү уңаеннан «Песня о Буревестнике» дигән хикәягезне татарчага тәрҗемә итеп бастырдык, – дип өстәде.

Горький да бурычлы булып калмады, журналны ачып битләрен караштырды да, үзе белән ияреп сәхнәгә чыккан улы Алексейның кулына тоттырып, аннан «Мои университеты» дигән китабын алып, Кутуйга язып бүләк итте.

Котлаулардан соң Горькийның үзенә сүз бирелде. Халык аны һәр җөмләсе саен алкышларга күмеп тыңлады.

Горькийдан соң очрашуның концерт өлеше башланды. Беренче булып, сәхнәгә Мохтар Мутин чыгып, зур героик пафос белән татар телендә пролетар әдипнең «Давыл хәбәрчесе турында җыр» дигән әсәрен сөйләп, Горькийның күңелен күрде. Аннан соң шагыйрьләр Кутуй, Туфан, Такташ, Әсгать Айдар чыгып шигырьләрен укыдылар.

Шагыйрьләрдән соң музыкаль өлеш башланды. Әледән-әле җырчылар чыгып, барысы да симфоник оркестрга кушылып, күтәренке рухтагы җырлар башкардылар. Горькийга аеруча Асия Измайлованың җырлавы ошады булса кирәк, аның чыгышыннан соң әдип сәхнәгә чыгып, җырчыга кул тамгасын салган китабын бүләк итте.

Концерттан соң җавап сүзе белән сәхнәгә кабат Алексей Максимович үзе чыкты. Ул үзен хөрмәтләп ясаган чыгышлары өчен барысына да зур рәхмәтләрен җиткерде. Очрашудан канәгать калуын әйтте.

– Дары мичкәсендә дары бетмәгән икән әле! – дип тәмамлады ул сүзен.

Кичә тәмамланганнан соң Шамил Усманов Горькийны сәхнә артына алып керде. Әдип анда артистларга, музыкантларга тагын бер мәртәбә рәхмәтләрен укыды.

– Кичәбезнең музыкаль өлешен менә шушы иптәш хәзерләде инде, – дип, Усманов кунакны Сәйдәш янына алып килде.

Горький концерт башында ук оркестр чыгышыннан соң Салихны сәхнәгә менеп котлаган иде инде. Бу юлысында ул аны кочаклап ук алды.

– Татар симфоник музыкасы туып килә! Булдырасыз, егетләр! – диде кунак.

**14**

Максим Горький килеп киткәннән соң озак та үтмәде, театр яңа сезонын башлап җибәрде. Планда – Таҗи Гыйззәтнең «Наёмщиг»ы. Бу Таҗиның яңа әсәре түгел иде инде. Ул аны 1925 елда Сембер шәһәрендә яшәгәндә язган булган. Беренче премьерасыннан соң инде ул төрле театрлар тарафыннан Алабуга, Бондюг, Чаллыда уйналган. Һәм менә, наһаять, һәркайда зур уңыш белән барган драманы Татар дәүләт академия театры куярга булды. Тегеләрендә ул гади драма буларак кына уйнала. Музыкасы да, җырлары да юк диярлек. Ләкин академия театры спектакльне музыкаль драма иттереп чыгарырга ниятли икән. Музыканы, әлбәттә, бу жанрга нигез салган Салих Сәйдәштән яздыртырга телиләр.

Егерме алтынчы-җиденче еллар сезонында Кәрим Тинчуринны театрдан эштән җибәргәннәр иде. Салихның шуннан бирле бер дә эшкә күңеле тартмый. Болай да тормышындагы зур югалтулардан соң кәефсезләнеп йөргән Салих, Тинчурин дустыннан да аерылгач, күңеле салынып, яңа әсәрләр иҗат итәргә бик авырлык белән генә алына башлаган иде.

«Үзе яза, үзе куя, үзе уйный. Башкаларга юл бирми», – дип, Тинчурин өстеннән кемдер шикаять язган, диделәр. Нәтиҗәдә, көннәрнең берендә тоттылар да эшеннән кыскарттылар. «Шәп булды әле, көннәр буе эштә, кич соң гына кайта. Төне буе язып утыра да иртән иртүк тагын эшкә чыгып китә. Күргән дә юк үзен, – дип, хатыны Заһидә бик куанган иде ул чакта. – Өйдә утырыр, пьесалар язар», – дип уйлаган иде. Ләкин Кәрим өйдә утыра башлагач, берни дә яза алмады. Язарга теләге дә юк, башына бер җүнле генә фикер дә килми. Шуннан ул эшкә урнашырга мәҗбүр булды. Политпросвет дигән оешмага йөри башлады. Озак та үтмәде, театрда Тинчуриннан көнләшүчеләр тагын өстеннән язып, егерме җиденең язында аны бөтенләй Казаннан сөрдерделәр. Ләкин ул Политпросветта утырганда, «Ил» дигән пьеса язарга өлгерде. Ә Казаннан Әстерханга үзе белән бергә Галия Булатова белән Галия Нигъмәтуллинаны, Әсгать Мәҗит белән Нәфига Арапованы, Мәрьям Чанышеваны ияртеп китте. Әстерханда алар кечкенә генә труппа оештырып, шундагы артистларны да үзләренә кушып, спектакльләр куеп йөрделәр. Кәрим Тинчуриннан котылганга карап, академия театрының эше алга китмәде. Өстеннән язган режиссёрлар да, артистлар да әллә ни майтара алмадылар. «Наёмщик»ны менә шуларның берсе куярга тиеш иде инде. Таҗи театрның «Наёмщик»ка алынуына бик сөенсә дә, режиссёрлар ерып чыга алырлар микән дип көенә дә иде.

Таҗи башта Салих Сәйдәшев белән күрешеп сөйләшергә кирәк дигән карарга килде һәм сезон башланган көнне үк аның янына ашыкты. Татар дәүләт академия театры өчен бу сезон «Мәдәният йорты» бинасында

соңгысы икән дигән сүзләр йөри иде. Имеш киләсе елдан ул Лядов урамына күчереләчәк икән, диделәр. Салих театрның ике кат арасындагы баскыч астындагы үзенең бәләкәй генә бүлмәсендә, рояль артында ниндидер көйгә моңланып утыра иде.

– Нишлибез инде, Салих дус? Куйдырасы да бик килә, бу җүнсезләргә ышаныч та юк. Кәрим абыйның башына җиткән ул имгәкләр булдырып чыгарлар микән? – диде Таҗи Сәйдәшевкә, янына килеп исәнләшкәч тә.

– «Талир тәңкә»не бик матур ерып чыккан идек бит, – диде Салих, Таҗиның моннан өчме, дүртме еллар элек бергәләп куйган спектакльләрен искә төшереп. – Монысында да сынатмабыз, Алла боерса.

– Мәликәнең бенефисы өчен махсус язылган, минем иң беренче әсәрем иде ул, – дип искә төшерде Таҗи, театрда суфлёр булып эшләүче хатыны белән бергә үткәргән бенефис спектакле турында. – Шактый гына акча керде безгә ул спектакльдән. Зал халык белән шыгрым тулы иде. Аннан соң да әле ул тагын берничә мәртәбә уйналды, быел аны Мәскәү татар эшчеләр театры куйды. Театрның быелгы репертуарында да бар, җәйге гастрольләр вакытында Донбасска, Урал якларына барып уйнарга исәпли театр.

– Менә бит, беренче әсәрең үк ничек уңышлы килеп чыккан. Монысы да начар булмас.

– Аны бит ул чакта Кәрим абый куйган иде. Ә бу мәхлуклардан барып чыгармы, белмим инде.

– Чыгар. Ниндирәк нәрсә яздың соң? Тегесе шикелле үк авыл тормышы, яшьләр, күңел ачулар булса, әйбәт чыгарга тиеш.

– Монысы бик күңел ачулар турында түгел шул, күңелсезрәк хәлләр турында.

– Наёмщик дигән сүзне ишеткән бар инде югыйсә. Ниндирәк сюжетка кордың соң? Наёмщик дип, бай баласы өчен солдат хезмәтенә киткән егет турында әйткәннәр бугай.

– Беләсең икән. Монысын да беренчесе шикелле үк үзем өчен акча эшләп алу максатыннан яздым. Кызыксыну булса, әйбер уңышлы чыга бит ул. Егерме бишенче елда мине бит туберкулёз аяктан егып салды. Туберкулёз диспансерында Кырымга китеп дәваланырга кирәк, диделәр. Акчаны каян табарга? Мине, ярдәм итсеннәр дип, Рабиска җибәрделәр. Сәнгать хезмәткәрләре союзына. Анда театр коллективы белән җитәкчелек итүемне белгәч, Сембердәге иң яхшы Булычёв театрын бушлай бирергә дигән карар чыгардылар. Мин шул театрда спектакль куеп, кергән акчага Кырымга китеп, бер-ике ай дәваланып кайтырга тиеш булдым. Менә шунда куяр өчен тагын да үземә пьеса язарга туры килде. Без куйган спектакльләргә кирәкле нәрсәләрне, өй җиһазларын, кием-салымны извозчик Кәлимулла абзыйдан алып тора идек. Менә шул Кәлимулла абзый бермәлне наёмщиклар турында сөйләде. Ул сөйләгән мажаралардан файдаланып, шушы пьесаны яздым. Яздым да барып укыдым губкомда эшләүче хезмәткәрләргә. Яраттылар, 5 майда Сабан туе көнне куярга булдык. «На ура» узды. Халык шыгрым тулы иде. 7 май көнне «Эшчеләр сарае»нда тагын кабатлап куйдык. Шактый гына акча керде. Артистларга да җитәрлек булды. Җәй көне Кырымга барып дәваланып та кайттым, рәхмәт төшкере. Көз көне Сембердән Алабугага күчкәч тә, берничә тапкыр куярга туры килде. Алабугада, Бондюгта,

Чаллыда уйнап, уңышка ирештек тә, менә хәзер Академия театры да куярга теләк белдерде.

– Җырлар, музыка кертик дисең, аларын яздыңмы соң әле?

– Бергәләп карап чыгыйкмы дигән идем. Кайбер урыннарын караштырган да булдым инде. Башта син дә бер мәртәбә укып чыкмыйсыңмы? Аннары утырып язар идем, – диде Таҗи һәм кулындагы күн сумкасыннан дүрткә бөкләнгән «Кызыл Татарстан» гәзите эченә тыккан кульязмасын чыгарып, Салихка сузды. – Менә бу яңартылган варианты. Син элеккесен белмисең, шуңа күрә ниләр үзгәртүем турында сөйләүдән фәтва юк. Шактый гына үзгәрешләр керттем. Элеккесе аның гади бер комедия генә иде. Бернинди социаль мотивлар да юк иде. Бары тик Иманкол мулланың улы Тимерҗан урынына солдатка барырга авылның ярлы егете Батырҗанны яллавы һәм Батырҗанның ахырдан мулладан үч алу моментлары гына. Яңа вариантка элеккесендә булмаган персонажлар, җырлар, дуэтлар кертелде. Кыскасы, карап чык та, яңадан утырып сөйләшербез.

Салих пьесаны бер кичтә укып чыкты.

– Гениально! – дип куйды ул үзалдына. – Бер дигән музыкаль драма чыгачак моннан. «Зәңгәр шәл» белән берүк дәрәҗәдәге спектакль булачак бу.

Ләкин моның өчен әле аның үзеннән дә күп нәрсә сорала. Спектакльдә «Зәңгәр шәл»дәге кебек үк халык җырларына таянып язылган һәм композиторның шәхси үзенчәлеген дә күрсәтеп торган музыка һәм җырлар да булырга тиеш. Монысы инде композитор белән драматургның үзара аңлашып эшләвеннән килә. Салихның Кәрим Тинчурин белән бу җәһәттән боткалары пешә торган иде. Ул гадәттәге җыр текстлары гына язмыйча, һәр куплетны композитор сораган ритмга салып язып бирә белә иде. Шигырь формасында язылса да, аны аерып укыганда, һич кенә дә шигырь дип кабул итеп булмый. Ә көйгә салып җырлый башласаң, мондый җыр буламыни дип тә бәйләнерлек, тел-теш тидерерлек түгел. Сәйдәш белән Тинчуринның осталыгы менә шунда. Таҗи белән дә шулай ярашып эшләп булырмы? Салихны башта менә шул сорау борчыды. Ләкин пьеса өстендә бергәләп утырып эшли башлагач, шикләренең юкка булуын күрде.

Спектакльның режиссёры итеп Сөләйман Вәлиев-Сульва билгеләнде. Салих аны Кәрим Тинчурин өстеннән язган кеше шушы булырга тиеш дип уйлап йөри иде. Шуңа күрә аны бигүк өнәп бетерми иде. Ләкин ни эшлисең, дәшмәскә, шыпырт кына эшләп йөрергә туры килә.

Көннәр уза тора. Акрын гына премьера көне якынлаша. Спектакль өчен музыка һәм җыр сүзләрен язу репетицияләр белән бергә алып барыла. Артистлар да бик теләп, яратып эшли. Кайбер күренешләр өчен музыканы артистлар эш барышында үзләре тәкъдим итәләр.

Гөлйөзем партиясен ике актриса – Кушловская белән Кайбицкая башкарырга тиеш. Шулай бервакыт Галия үзенең ариясен җырлап бетерде дә ничектер сәхнә уртасында югалып калды. Ул җыр беткәннән соң сәхнәдән кереп китәргә тиеш. Болай атлап кына кереп китсә, ничектер табигый килеп чыкмый.

– Салих абый, ә нәрсә, мин бии-бии кереп китсәм, матуррак була бит, – диде Галия.

– Музыка кирәк! Бию көе. – Сөләйман шулай диде дә Салихка карап алды. – Өлгертәсеңме, Салих?

– Яле, Галия, бәгырькәй, ариянең ахырын җырлап бетер, – диде Салих, Кайбицкаяга карап.

– Егет күңеле җилкенә,
Яхшы ат күргәч.
Бар нужасы онтыла,
Янда сөйгәне йөргәч...

Ах наян шул, ах шаян
Сылукай...

– Йә, йә, шуннан, шуннан?! – диде Салих.

– Шуннан: «Их, матур син, егеткәй, егеткәй! Бу көеңнең ахыры юк бит, егеткәй!..» – диде дә Галия биеп китте.

– Булды! Хәзер, көтегез бераз, – диде Салих һәм Таҗины ияртеп, баскыч астында торган рояль янына барып утырды.

Әйтерсең, Салих бу урында бию булырга тиешлеген күптән уйлап куйган, берничә минуттан инде ул бию көенең ноталарын кәгазьгә төшереп, репетиция ясаучы артистлар янына килеп тә җитте.

– Җә, менә тыңлап карагыз әле, чыкканмы бию? – дип, сәхнә читендәге пианино артына утырып уйнап та җибәрде.

Гөлйөзем ролен башкаручы Галия дә, Рокыя да арияләрен башкарып, биеп карадылар.

– Булган бу, Салих абый! – диде Рокыя.

– Чабаталар гына түзсен инде бу биюләргә, – дип куйды Галия.

– Кайгырмагыз, чабатасын гына табарбыз, – диде Салих. – Авылларда йөрүче труппаларга хәбәр бирергә кирәк. Икегезгә дә бишәр пар чабата үрдереп кайтсыннар авыл агайларыннан.

Менә, ниһаять, премьера көне, ундүртенче декабрь килеп җитте.

Алда торган бурычның никадәр зур һәм җитди булуын Таҗи яхшы аңлый иде. Аларның шулай ук берсен-берсе ярты сүздән аңлап эшләүләренең нәтиҗәсе яхшы булды. Музыкаль сәхнә әсәрләренең бөтен төрләрен, җырлардан башлап, арияләр, дуэтлар, хореографик күренешләр, вальс, балет сютасы, увертюра – җәмгысы егерме биш музыкаль номер язарга туры килде Салихка. Спектакль гаять зур уңыш белән, башыннан ахырына хәтле тамашачыларның көчле алкышлары белән үтте.

Зал халык белән шыгрым тулы. Оркестрның соңгы әзерлек авазларыннан зал гүләп тора. Менә Салих оркестр алдына чыгып басты һәм халыкка карап, сәламләп башын иде. Ул чыгып баскач тынып калган зал тамашачыларның алкышлап кул чабуларыннан тагын бер гүләп алды.

Салихның серле таякчыгы белән бер селтәнеп алуы булды, оркестр уйнап җибәрде. Залга кырыклап уен коралының бер тавыш белән яңгыраган халыкчан да, шул ук вакытта бу бит Салих Сәйдәшевнеке дип, әллә каян үзен танытып торган моңлы да, тантаналы да музыка агыла башлады. Тамашачылар шунда ук гөрләтеп кул чабарга керештеләр.

Артистларның бер-бер артлы сәхнәгә чыгып, үз рольләрен башкарулары,

уеннары, җырлаулары, биюләре – барысы да көчле кул чабулар белән барды. Крепостной хокук вакытындага крестьян тормышында булган наёмщик дигән персонажның нинди кеше икәнен инде онытып бетергән тамашачы өчен сәхнәдә күрсәтелгән тормыш кызык та, серле дә бер нәрсә иде. Барысы да бөтен игътибарын биреп, йотлыгып карый һәм тыңлый. Улы Тимерҗан урынына солдатка барырга авыл егете Батырҗанны яллаган Иманкол мулла да, алпавыт Абалинский да, авыл крәстияннәре Бикташ, Аскәрик, Шәрифә бикәләр дә, Батырҗан белән урам җырчысы Гөлйөзем дә – шул заманның типик вәкилләре. Сәхнәдә алар үзләренә генә хас образда, үз рольләрен шулкадәр рәвешен китереп, ышандырырлык итеп уйныйлар. Тажи Гыйззәт аларны шулкадәр дөрес итеп, үзенчәлекле иттереп сурәтләгән, тамашачылар сәхнәдә барган вакыйгаларны бирелеп, онытылып карый. Алпавыт Абалинский бераз чукраграк, үзенә мөрәҗәгать иткәндә гел башта «А?» дип сорап куя. Бу шулкадәр табигый килеп чыга, халык ихрыярсыз көлеп җибәрә. Нагрузкасы аз булса да, артист аны күңелгә кереп калырлык итеп башкара. Иманкол мулланың шәригатьне яшел тышлы һәм кызыл тышлы китаплар буенча аңлатуы да муллаларга каршы көрәш башланган бу заманда драматург тарафыннан бик оста итеп уйлап чыгарылган күренеш булып күңелгә кереп кала. Урам җырчысы, иске-москы киемнән генә сәхнәгә килеп чыккан Гөлйөземне дә тамашачы яратып, үз итеп, җырлавына сокланып кабул итә. Спектакльнең икенче өлешендә сәхнәне икегә бүлеп, бер ягында алпавыт хатынның бәйрәм ясап ятуы, икенче ягында фаҗига – богауланган Батырҗанны китергәндә, тамашачыларның сәхнәдә барган вакыйгаларга битараф калмыйча, бербөтен булып, борчылып утырулары әсәрнең никадәр тәэсир итү көченә ия булып килеп чыгуы, уңышы хакында сөйли.

Батырҗан ариясе яңгырый:

...Монда мәҗлес икән, бар да шатланганнар,
Шаулый дөнья җырлар белән биюдән.
Сөйгән ярларыңны ятлар килеп кочса,
Кул тартылмас минем каннар коюдан.

Сәхнәнең икенче ягыннан Гөлйөзем ариясе яңгырый:

Күңелкәем боек, нидер сизгән кебек,
Ач бүреләр кымсып мине күзлиләр.
Ах, Батырҗан дустым, батыр йөрәккәем,
Ни хәлләрдә икәнемне ул бит белмидер.

Гөлйөземнең сагыш тулы җырына капма-каршы темпта кунаклар хоры җыры ишетелә:

Күтәрик чашкалар баллар белән,
Үтсен гомер сөйгән яр белән.
Салыгыз тутырып, ай, балларны,
Шатлыклы үткәрик көннәрне.

Кызының күз алдында атасын үтерәләр һәм богауланган Батырҗанны

чыгаралар. Шунда спектакльнең кульминациясе булып, Батырҗанның хушлашу ариясе яңгырый:

Сау бул, минем туып үскән ямьле илем,
Сау булсыннар урман, басу, кырларым,
Сау булсыннар печән чапкан болыннарым,
Сау булсыннар даннар тоткан Сабан туйларым.

Рәхмәт сезгә, илнең батыр егетләре,
Сау булыгыз, дуслар, инде мин китәм.
Онытмагыз безнең изге эшебезне...
Иртән искән җилдән хәбәрләр көтәм.

Ситдыйк Айдаровның Батырҗан ариясен башкаруын тамашачыларның ничек кабул итүен хәтта сөйләп-аңлата торган түгел. Батырҗан-Айдаров белән Гөлйөзем-Кушловскаяның вокаль дуэтын берәү дә тыныч кына тыңлый алмагандыр. Тамашаны халык аягурә басып бик озак алкышлады.

– Авторларны сәхнәгә! – дигән чакырулар кабатланды.

Салих Сәйдәшев тә, Таҗи Гыйззәт тә көчле алкышлар астында сәхнәгә чыгып, тамашачылар алдында баш иде.

Музыкаль драма әнә шулай тәмамланды. Тирән социаль-эстетик фикерле, киң полотнолы, музыкаль әсәр иде бу.

«Моцарт, Верди, Бетховен белән янәшә торырлык музыка бит бу! Татар музыкасын Европа композиторлары белән бер дәрәҗәгә күтәргән музыка! – Салих менә хәзер, егерме елдан соң, «Наёмщик»ның 1928 елның беренче декабрендә булган премьерасын искә төшерде дә тирән көрсенеп куйды: – Боларның берсе дә булмады микәнни соң? Булса да, онытылды микәнни? Ничек шулай кыска соң бу кеше хәтере? Ә бит ничек кабул иткәннәр иде. Хәзер әнә бөтенесен онытканнар. Белергә, искә төшерергә теләгән кеше дә юк. Опера белән генә үзеңнең зур культурага ия икәнеңне күрсәтеп була микәнни? Һәр халыкның үз холкына, үз менталитетына тиң музыкасы булырга тиеш бит. Бу бит инде шул композиторлар үрнәгендә иҗат ителгән, Европа классикасы дәрәҗәсендәге әсәрләр! Пентатоника белән октава синтезы нәтиҗәсендә иҗат ителгән әсәрләр. Бу бит Сәйдәшнең үзенә генә хас авазлар системасы. Аны башка бер генә композиторның стиле белән дә бутарга мөмкин түгел».

Быел, егерме елдан соң, бу әсәрне яңадан карап чыгу, эшкәртү, эшләү өчен форсат чыкты. «Наёмщик» театрның 1948 елгы программасына кертелде. Алар аны Таҗи абыйсы белән яңадан эшләячәкләр, яңа арияләр, дуэтлар, җырлар кертәчәкләр, музыкаль яктан да, драматургия ягыннан да баетачаклар. Менә күрерсез: моңа кадәр әле татар театры тарихында күренмәгән әсәр килеп чыгачак! Опера итеп эшләвен сорыйлар. Нигә кирәк? Ул болай да музыкаль драма бит инде. 25 музыкаль номер гына бар анда!

*(Дәвамы киләсе санда.)*



Дания
Нәгыйм

# МЕҢӘР ҖАННЫҢ ӨЕРМӘСЕ МИНДӘ...

## Татар теле

Яшем туктатырлык кодрәт синдә,
Һәм елата ала бер сүзең!
Мосафирга – татлы кизләү суы,
Адашканга маяк – берүзең!

Синдә ага җирне тибеп чыккан
Меңәр чишмә, вулкан лавасы.
Синдә тургай, сандугачлар көе,
Диңгезләрнең җиләс һавасы.

Тоякларның тупырдавы синдә,
Кылычларның горур зеңләве.
Дәүләтемнең тез чүктергән чагы,
Ватанымның өнсез иңрәве.

Тимерченең тире тамган сиңа,
Бөеклеге синдә ханнарның!
Синдә күпме дога-ялваруы
Бер Илаһка изге җаннарның.

Күкрәгемә хәнҗәр кадасалар,
Синең белән бәйлим ярамны.
Синдә таптым җаным моңы булып
Каләмемнән тамар караны.

Җанны кисәр җилләр искән чакта
Ышыкланам сиңа – кыяма!
Синле чакта без – алмазның үзе!
Синсез калсак – юка пыяла.

---

Дания НӘГЫЙМ (1991) – *шагыйрә, прозаик, «Галәм агачының яфрагы мин», «Бөртекләп җыелган гомер» китапларының авторы. Казанда яши.*

Аңлы чактан бәгырь сызлавым син,
Синсез калсам – калам йөрәксез.
Син югалсаң, кояш шундук сүнәр.
Син булмасаң, мин дә кирәксез...

## И Язучы...

И Язучы, күңлең – дала,
Офыкка караш җитми.
Тик каләмнән тамганнарың
Сине ипиле итми.

Байлыкка лаек булсаң да,
Фәкыйрьлек – синең юлдаш.
Сукранмыйча көн күрәсең,
Тыйнаклык канда булгач.

Орып-орып яңгыр ява
Кайбер бакча-өйләргә.
Сиңа тама ике тамчы
Атна, айлар сөйләргә.

Еллар буе язганыңа
Эш хакы – тычкан күзе.
Ачлыктан үлми яшәргә
Раббы булышсын үзе.

Түрәләр бәлеш бүлгәндә,
Сиңа – коелган валчык.
Канәгать түгелсең икән,
Ишекләр ачык – бар чык.

И Язучы, кадереңне
Белерләр икән кайчан?
Әрнегән күңелең тәрәзен
Китабым итеп ачам.

***

Ә мин менә яза алмый торам.
Шыплап тулган йөрәк югыйсә.
Өзгәлиләр җилләр җанны, аңны,
Чынбарлыгым кырыс – юл кисә.

Йөрәгемдә күпме яра барын
Ярып карамыйча белмәссез.
Минем җаным кара квадрат сыман:
Тәрәзәсез, йортсыз, бүлмәсез.

Мең йөрәкнең сагыш күләгәсе
Бәгыремә төшкән сузылып.
Меңәр җанның өермәсе миндә
Бөтерелә төсле тузынып.

Кешеләрнең тамчы-тамчы яше
Сеңеп калган минем туфракка.
Йөрәккәем гарасаттай көчле,
Күзге яфрак төсле куркак та.

Билчәннәрдән йөрәк каный һаман,
Йолкый-йолкый учым тишелде.
Бөртекләрдән бәхет җыйган чакта,
Дулкын каплап, бар да ишелде.

Йөрәгемдә халкым сыктавы да,
Сулкылдавы милләт җанының.
Диварыма рәсемнәрен эләм
Коштай канатланган чагымның.

Бәхет җиле йомшак кына кагылып,
Кешеләргә хөрлек өләшсә.
Талпынамын күккә, оясыннан
Бала очыргандай керәшә[1].

***

Табигать мине учына
Салып, назга күмгәндә,
Зәңгәр күктән торналарның
Шат авазы иңгәндә,
Кем мине «артык» диде?
«Упкынга тартыйк», – диде?

Ходай гомер биреп, әйткәч:
«Яшә, син – адәм заты!
Бу тормышта изгелек җый,
Бәхет суларын таты!»
Кем үзен Тәңре диде?
Яшәү гөленә тиде?

[1] Керәшә – яр карлыгачы.

Бары кырмыскалар диеп,
Каһкаһәле кем көлә?
Гөлләр иң гүзәл чагында
Ник рәхимсез өзелә?
Йолкынган гөлләр өстендә
Нинди «бәхет» төзелә?

Тургай булып күккә аша
Чәчәкләрнең жаннары,
Сызландырып торыр өчен
Гомер бакый аннары.
Гомерләр чәчкә иде,
Туң төште, кырау тиде...

Табигать, салып учына,
Бишек җырын сузганда,
Мине бишектән аерып,
Шыксыз туфан кузгала...
Ертык күлмәгенә карап,
Җиһан мине кызгана...

## Йөрәк кыңгыравы

Йөрәктәге кыңгыравым
Чыңлый да чыңлый һаман.
Кыңгырау җебен тартучы
Син ул, син, газиз балам!

Синең бармагың канаса,
Минем йөрәгем каный.
Акылың, буең үссә дә,
Син миңа һаман сабый.

Гөлләр телен беләсең күк,
Күктән иңгән бүләгем.
Син дөньяга аваз салгач,
Кидем бәхет күлмәген.

Йөрәгемнең кыңгыравы
Тынгы бирми – моңлана.
Бәхеттән тукылсын иде
Тормыш юлың, и бала!

Нәни генә кыңгыравым
Чыңлый да чыңлый һаман.
Хәят илһамын бирергә
Син аны элдең, балам!..

## Солдат хатыны җыры

Төшләрем өн белән укмашып,
Көннәргә төн йоккан мәлемдә
Мин сине көтәрмен өзелеп
Ни тере, ни үле хәлемдә.

Кайт кына! Исән-сау кайт кына –
Тормышның ертыгын ямарбыз.
Коелса күкләрдән бар йолдыз,
Без яңа галәмне табарбыз.

Михнәтнең иң каты ипиен
Без манып ак өмет сөтенә
Яшәрбез! Син янда чагымда
Язмышның корымы сөртелә.

Кайт кына! Син бары кайт кына!
Һәм кысып иң кайнар кочакка
Эш аты шикелле хатынны
Әйләндер иң гүзәл курчакка.

Сулышың шулкадәр кирәкле! –
Ул икән яшәүнең учагы!
Синле төш өнемнән кадерле,
Синле уй – яшәвем почмагы.

Кайт кына! Үтенәм кайт кына!
Аякта торырлык терәк бир.
Син йөрәк парәмә – балама
Яратып, кайгыртып баккан ир.

Төшләрем өн белән укмашып,
Көннәргә төн йоккан мәлемдә
Пышылдыйм һәрдаим догамны
Җан меңгә теленгән хәлемдә...

## Кызыкма

Киек каз юлына кызыкма –
Анда юк икәүнең эзләре!
Бөреләр тулышкан яз кебек
Карашың җылыткан күзләрем.

Яфраклар вальсына көй булып
Яңгырый йөрәгем тибеше.
Учыңда – кулъяулык, сиңа дип,
Йолдызлар төннәрен чигеште.

Сулышың эретә җаныма
Суык кыш койдырган бәсләрне.
Син биргән каләмнән тамызам
Тормышка ашачак әсәрне.

Күктәге кояшка кызыкма,
Җаныңа мин кунам нур булып!
Кояшка тиңләшкәч сөюем,
Чыгармын җыр булып ургылып.

## Җылы эзләп...

Көннәремнең челлә вакытыннан
Җылы эзлим – тапмыйм.
Каешланган тунны ямар өчен
Көмеш энәм саплыйм.

Ялкынланып әйткән сүзегездән
Җылы эзлим – өшим.
Ялган болытларда дөнья гиздем...
Туйдым. Җиргә төшим.

Җылыныйм дип, мин учакка килдем –
Керфекләрем көйде.
Учагыгыз безнең ишне түгел –
Куштаннарны сөйде.

Җылы эзләп, кояш чыккан якка
Ак офыкка барыш.
Сезнең белән минем җан арасы –
Йөз миллиард карыш.

## Комсыз корт

Галәмгә күперләр суздың,
Диңгез төбенә – баскыч.
Гасырлар ача алмаган
Ишеккә таптың ачкыч.

Йолдызлардан такыя үрдең,
Күкләргә элдең бишек.
Тик җаныңда – үтәли җил,
Йөрәгең булгач тишек.

Фәннәрне буйсындырдың син,
Суырттың Җирнең маен.
Бәсәргән җаныңны сизеп,
Яшь түкте гүзәл каен.

Тамырларың буйлап ага
Кып-кызыл куе каның.
Тик «кансыз» дип мөһер суккан
Тәнеңдә чүккән җаның.

Бер тырмага ун кат басып,
Акыл җыя алмадың.
Симергән комсыз корты син
Сусыл, алсу алманың.

И адәмем, акыл сиңа
Бирәр чак керер микән?
Чаларган Җир аз булса да
Тынычлык күрер микән?

## Гомер

Гомер – чабыш аты кебек,
Мин – тамаша кылучы.
Кытыкланып куям кайчак,
Тигәч ялның кыл очы.

Гомер чабыш аты кебек
Чаба да чаба гына.
Тик тузаны йогып кала
Чабуым, балагыма.

Ярсу атка атландым да,
Чаптырдым гомер буйлап.
Офыкка җитә язганмын
Үткән юлымны уйлап.

Атым арып, пошкырыр да
Беркөнне туктап калыр.
Кулымдагы дилбегәне
Яшьләр үзенә алыр.

Юлдагы калын тузанда
Тояк эзләре генә...
Шул эзләргә болытлардан
Яңгыр коела менә...

## Уян, татар!

Син бит мондый түгел идең,
Түгел идең, татарым!
Син өметкә лаек идең,
Көттең ал таң атарын.

Көтеп кенә ятмадың син,
Төннәр белән көрәштең.
Күңелеңдә чәчәк аткан
Иман нурын өләштең.

Милләт өчен калкан булдың,
Корбан булдың, кирәксә.
Җаның – халкың арасында,
Сандугач ул тирәктә.

Син бит мондый түгел идең,
Рухың нык, сынмас иде.
Ахыргача көрәшмичә,
Йөрәгең тынмас иде.

Мин танымыйм хәзер сине,
Нишләдең син, татарым?
Бабаларың әманәтен
Җырлый-җырлый таптадың?

Кайда синең көрәш рухың,
Кайда өмет-хыялың?
Күпме гасыр агып килгән
Телне ничек тыялдың?

Сиңа бер ым җитә калды,
Бер караштан шым булдың.
Учта яткан кылычыңны
Син үзең үк сындырдың.

Әллә соң үзең үк шатмы
Сатылуга шайтанга?
Җаның мәрткә китте синең
Ничә елга, кайчанга?

Ничек сине уятыйм соң,
Өскә туфрак сипкәнче?
Уян, татар, чардуганга
Дошман көлеп типкәнче!



Зиннур
Тимергалиев

# МӘҢГЕЛЕК ХӘРӘКӘТ

ПОВЕСТЬ

Иртәнге яңгыр озак яумады, күп булса, унбиш-егерме минут тирәсе баргандыр. Яңа күтәрелеп килгән уҗымнар өчен менә дигән инде бу яңгыр. Алар, кар бетеп, кояш җылырак карый башлау белән куе шәмәхә төстәге борыннарын төртә башлый. Аннары гына яшел төс алалар, ә инде июнь урталарына сары төскә кереп, башакка тула. Бу вакытларны авыл агайлары «ашлык серкә очырган чак» дип йөртә. Әгәр дә ашлык серкә очырган иген басуын күргәнегез юк икән, димәк, илаһи гүзәллекнең ни икәнен белми яшисез. Яшькелт-сары иген кыры ул вакытларда диңгезне хәтерләтә. Шул диңгез өстендә җәйге рәшә булып, дулкыннар йөгереп уза. Бу манзараны күзәтеп торган адәм баласы үзен диңгез уртасында дип хис итә, яки эссе чүлдә сихри сагым күзәтәм дип уйлый. Иген басуы өстендә талгын җил белән дулкын-дулкын күтәрелеп, бер уңайга гына очкан арыш серкәсеннән күзләрне ала алмый сәгатьләр буе карап торып була. Җанга тынычлык иңә, шул ук вакытта ниндидер бик тә кадерле, бик тә изге нәрсәне югалткан кебек тоясың. Синдә гасырдан-гасырга, нәселдән-нәселгә югалмыйча сакланып килгән ата-бабаларның игенче геннары уяна. Ике кулыңны җәеп, басу эченә йөгереп кереп китәсең килә, бар игенне кочагыңа җыеп аласы, назлыйсы, иркәлисе килә башлый. Әйе, сез үзегезне тулысы белән шәһәр кешесе дип атыйсыгыз килә икән, иң элек серкә очырган иген басуларын күреп кайтыгыз һәм сез үзегезне инде беркайчан да: «Мин тулысы белән шәһәр кешесе», – дип әйтә алмаячаксыз. Алай гына түгел, игенчеләр нәселеннән булмавыгызны да инкарь итә алмаячаксыз. Чөнки табигать кануннарына каршы килә алган бер генә кеше дә юк әлегә.

Басу эченә кереп барган Дәнәф адым саен җирнең җылысын тоеп атлады. Җиргә түгел, ә йомшак мендәргә баскан кебек иде. Әле июльнең рәхимсез

---

Зиннур ТИМЕРГАЛИЕВ (1974) – *язучы. «Кичә яраттым» исемле китап авторы. Арча шәһәрендә яши.*

челләсе туфракны катырмаган. Җир шундый йомшак, аяк батып-батып китә. Ул кереп барган кыр иген басуы да түгел, шулай ук силос өчен кукуруз яки көнбагыш та чәчелмәгән монда. Печән басуы дип тә әйтеп булмас, ахры.

– Ай! – Дәнәф ирексездән кычкырып җибәрде.

Комбайн янында кайнашкан әтисе улы ягына борылып карады.

– Нәрсә булды?

– Куян, әти! Покос астында качып яткан, мин чак өстенә басмадым, әнә кара, нинди зур!

Раушан абый күңеле булып кеткелдәп көлеп куйды.

– Күзеңне ачыбрак йөр икенче, ярый аягыңа китереп типмәгән, куян гына димә, шырпы кебек кенә сындырган булыр иде.

– Пакуслар зур, әти, атлап кына чыгарлык түгел, каян күреп бетерәсең, ди, аны.

– Шөкер, быел иген уңды. Ә мондагы басуның туфрагы кап-кара, ипигә ягып ашап була.

– Җирне ашамыйлар ич, әти.

– Һе, ашамыйлар, ашыйлар, ничек кенә ашыйлар әле, шушы җир булмаса, ачтан үлә адәм баласы. – Авызын ачып, атасын тыңлап торган улына карамый гына эндәште Раушан абый: – Ременьнәрен тарттырдым, покослары зур, подборщик көчкә ала, тиз бушыйлар. Улым, бар, комбайнны кабыз да, подборщикны төшереп, бераз барып кара әле, ашыкма, ишеттеңме, барабанны тыгылдырсаң, муеныңны борам.

– Ярар, әти! – Малай йөгереп барып, комбайн кабинасына менеп утырды да, кабызып, подборщигын покос өстенә төшерде.

Комбайн кузгаткан тузан аша атасы ягына күз салды.

– Әйдә-әйдә, кузгал, куян куа торган вакыт түгел, – дип, Раушан абый алга күрсәтеп, кулын изәде.

Әйе, бар иде заманнар, бу басуда аркылы атлап чыга алмаслык покослар була торган иде.

Дәнәф озак еллар эшкәртелмәгән ташландык басуга кабат күз йөртеп чыкты.

– Менә шулай дус. – Ир шулай җиргә эндәште. – Өлкән прапорщик Хәсәновның кирәге калмаган кебек, синең дә хөкүмәткә кирәгең калмаган икән. Ну, ничего, яшәрбез әле без, шулаймы, менә дигән итеп яшәрбез?!

Ул ирексездән сул аягын сыйпап куйды, Таҗикстанның коры һавасына ияләнгән организм туган як һавасын әле бик кабул итеп бетерми. Бигрәк тә һава дымлы булса, балтырдагы яра төзәлсә дә, гел сызлап тора. Дәнәф кирегә борылды, анда аскы якта каенлык бар, агачлары бик карт инде аның.

Әбисе сөйләгәнен хәтерли, сугыш беткәч, көрәк белән казып утыртып чыкканнар икән аны. Очы-кырые күренмәгән полосаны ничек шулай көрәк белән генә утыртып чыга алганнар икән? Күз алдына китерүе дә авыр. Эшкә әрсез дә булган инде әбиләре. Дәнәф җәйге җилгә кушылып, туктаусыз шаулап утырган каенлыкка килеп җитте, туктап калмыйча полосадан ук аска киткән болынга таба төшеп китте. Монда да искитәрлек хәлләр бар икән. Ул болынны таный алмыйча туктап калды. Шушы болын өчен елның-елында күпме талаш чыгара торган иде авыл халкы. Көтүчеләр мал ашату өчен, печәнчеләр печән чабар өчен, якын-тирә хуҗалыклар хайван арканлау өчен

талаша торган иде. Барысы да бу болынга үз хокукларын белдереп килделәр. Август ахырларына инде монда хайван яларлык та үлән калмый торган иде. Малларга ашатып, чабып, болынны ялт итеп куя иде авыл халкы. Дәнәф, әллә ят җиргә килеп чыктыммы дигәндәй, як-ягына каранып алды. Нәрсә соң бу? Печәне билдән узган болында мал таптаган түгел, җәяүле үткән эз дә юк. Карт каеннардан коелган орлыклардан, маллар умырып ашап тормагач, яшь каеннар үсеп чыккан, орлыгын кошлар алып килгәндер, араларында нарат агачлары да матур гына  үсеп киләләр. Буйга Дәнәфне дә узганнар. Адәм баласы аяк басмагач, табигать бик тиз үзенең элеккеге халәтенә кайткан. Шушындый агачлар үсеп чыксын өчен ничә ел ташландык хәлдә калырга тиеш соң бу болын? Күптән, бик күптән, болынның кирәге беткән халыкка. Авылда маллар саны юк дәрәҗәсендә, шуңа күрә печән хәстәрләүнең кирәге калмаган. Мал асраган хуҗалыклар да чалгы белән эш итми хәзер, печәнне сата да ала. Колхоз җирләренең яртысыннан күбесенә күпьеллык печән чәчелгән. Ягулык кыйбат булгач, иксез-чиксез басуларны эшкәртү мөмкин түгел. Дәнәф печәнне ера-ера аска, чишмәгә таба атлады. Әйе, монда чишмә бар иде элек. Аны Дәнәфнең әтисе белән авылның балта остасы Ришат абый буралап, улагын да ясап куйганнар иде ул вакытта. Чишмәне күргән берсе «аһ» итә иде. Курчак өе кебек матур килеп чыкты бурасы.

Ул чишмә янына килеп җитте дә бурасына күз салды. Бура череп, мүкләнеп беткән, улагына кагылырлык түгел, кагылсаң таралып китәрлек. Көмештәй суы белән малларны, печәнчеләрне, җиләк җыярга килгән кызларның  сусауларын басып килгән чишмәнең адәм балаларына кирәге калмаган. Солдат хезмәтенә китәсе төнен ул шушы чишмә янында беренче мәхәббәте Илүзә белән үткәрде. Вәгъдәләр бирештеләр, кыз аның кочагына сыенган килеш елый-елый, кайтканын көтәчәгенә антлар бирде. Вәгъдәсе генә шушы чишмә суы кебек акты да китте. Дәнәф бер ел гына хезмәт иткән иде. Кыздан хат килеп төште: «Мин кияүгә чыгам, бүтән язма». Дуслары да Илүзәнең сүзләрен раслап, хат язды. Көтмәде аны сөйгән яры, үз авылына ук кияүгә чыкты. Ә Дәнәф өч елга контракт төзеп, солдат хезмәтендә калды, контракт вакыты беткәч, тагын контракт төзеде, тагын, тагын... Шулай итеп егерме ел үткән дә киткән.

Чишмә җырлый, диләр, юк җырламый, ул үзен оныткан кешеләргә рәнҗеп елый. Дәнәфтән биш-алты адым гына читтә чинашкан тавыш ишетелде, үз уйларына бирелеп басып торган ир, сискәнеп, тавыш килгән якка борылып карады. Инеш суында ике су күсесе яннарында адәм дигән зат барлыгына исләре дә китмичә, рәхәтләнеп шаярышып уйныйлар. Менә сиңа кирәк булса, авылга терәлеп үк торган болында яшәп тә, адәм баласын бер дә күргәннәре юк микәнни? Юкса яннарында Дәнәф басып торуга карамастан, болай иркенләп уйнамаслар иде, аны күрүгә, ояларына кереп качкан булырлар иде. Әнә камышлык арасында бакылдап, тавыш биреп утырган ата кыр үрдәге бик тиз тынды. Аңа акыл кергән, ә боларның исләре дә китми.

– Көш! – Дәнәф суга кечкенә таш ыргытты.

Күселәр чупылдаган тавышка борылып кына карадылар да уеннарын дәвам иттеләр.

Кем ышаныр икән егерме беренче гасырда авылга терәлеп торган

болында беркайчан да адәм затын күрмәгән хайваннар яшәвенә. Дәнәф башын чайкап куйды. Ә тауларда кәҗәләр, аларны ерактан күреп алуга, шундук сикерешеп юкка чыгалар иде. Әйе, алар кеше белән очрашуның яхшыга түгеллеген, адәм баласының нинди вәхшилеккә маһир икәнен яхшы беләләр. Хайванга түгел, хәтта бер-берсенә карата да.

Ул ерганакны сикереп чыкты да, билдән узган печәнне ерып, аргы як урамына таба атлап китте. Инешнең бу ягына да адәм аягы басмаган икән. Болын үләнен таптап, ул салып барган эз бөтенләй ят күренеш кебек тоела. Дәнәф урам башына менеп җитте. Әнисе кайтышлый ипи алырга кушкан иде. Юк, авыл ташландык түгел, халкы элеккеге кебек күп булмаса да, таза хуҗалыклар җитәрлек, авыл уртасыннан асфальт юл да салынган, зур гына кибете дә бар. Тик менә капка төбендә бәби саклап утырган әбиләр күренми, бала-чагасы да тузан куптарып чабып йөрми. Таза, төзек, җансыз авыл, ышанырлык түгел.

Хәерсез сәфәр хәерсез бетәр, ди. Кибеткә якынлашып килгәндә, Дәнәф каршына классташы Камил килеп чыкты. Ул – авылда торып калган бердәнбер классташы. Авылны яратканга түгел, ә шайтан суын яратканга. Ул да өйләнмәгән, яшьтән үк салырга яратты, шуңа читкә чыгып китә алмады.

– О-о-о, яшьти! Кайтканыңны ишеткән идем, кич яныңа килеп чыгармын дигән идем, менә үзең очрап торасың тагын, – дип, Дәнәфкә тирес исе сеңеп, сөялләнеп беткән кулын сузды.

– Исәнме, Камил, каян кайтыш?

– Безнең бер юл инде, яшьти, ферма да өй.

Дәнәф классташын күзәтергә тотынды. Камилнең өстендә иске генә кием, фермага ярамаган тагын дигәндер инде, чәчләрен күптән алдырмаган, кырынган үзе, махмырдан, шешенгән, куллары да калтырап тора. Аягында тирескә каткан галош.

– Фермада эшлисең алайса.

– Соң укуны бетергәннән бирле шунда, яшьти, мине бит аю табаны дип, армиягә дә алмадылар. Тирес чыгарам мин анда. Бүген махмыр өстенә транспортёр өзелде, гафу инде, парин, шуны төзәтеп ятып, миннән тирес исе килеп тора.

– Төшке ашка кайтышмы?

– Нинди аш әле монда, иртәдән бирле калтырап йөрим, кичә рәис тана суйдырган иде, үпкә-бавырын ике литрга алыштырдык та бәйрәм итеп алдык.

– Бүгенгә калдырмадыңмыни?

– Юк инде, син нәрсә? Кулга килеп керсә, төбенә төшеп җитми туктый белмибез, хет шунда чиләге белән китереп куй.

– Сыя?

– Нинди сыймаган, булсын гына. Синең бераз чамаң юкмы?

– Чамасы бар, юк түгел. Ә үзеңнең юкмыни бер дә, эшлисең бит?

– Чама булса, синнән сорамас идем, үзем сыйлаган булыр идем әле, аена алты мең төшеп бара, бу айныкын рәис миңа тоттырмаска, әнигә бирергә кушкан. Акчасын кулына алса, атна буе эшкә чыкмый дип, мине сүккән.

– Син алай атна буе эчеп йөрмә, эштән куар тагын.

Камил көлеп җибәрде.

– Кемне эштән куа, минеме? Мине дә куса, кем эшләр икән соң колхозында? Эшкә ярарлык халык әллә кайчан читкә чыгып тайды.

– Син калдыңмы?

– Безгә ярый, без түзәбез. Дәнәф, азаплама инде, мин акчасын аннары әнидән алып түләр идем.

– Сәрвәр апа үз аягында инде алайса.

– Ничек кенә әле, сиксәнне узды, ых та итми, хуҗалыкны алып бара. Миңа өйләнергә куша. Кемгә өйләним инде мин, кырыкка җитеп, кем чыксын миңа? Авылда тол хатынар бар үзе. Ну, миңа чыкмыйлар алар барыбер. Тормоз юк бит, парин, салудан туктап булмый. Әнә кибеткә әҗәткә сорап кергән идем. Илүзә эт итеп сүгеп куып чыгарды.

– Кайсы Илүзә?

– Кайсы булсын, син солдатка киткәнче озатып йөргән Шәйхи кызы.

– Ул кибетчемени?

– Ие инде, шунда. Парин, ярый син өйләнмәгәнсең әле аңа, аның кебек збир хатын авылда бер. Артыма тибеп чыгарды мине кибеттән.

– Мин ничек өйләним, мин бер ел хезмәт иткәч, башкага кияүгә чыкты бит ул.

– Ә, ие шул, пыртый малаена, ул малай аннан ике яшькә яшь иде. Ничек булгандыр, анысын мин белмим. Кияүгә чыккач, алты айдан бәбәй алып кайтты ул. Пыртый малае телгә оста иде бит, көйли белгән мәрхүм.

– Ничек мәрхүм?

– Ничек булсын, ике ел элек булган хәл. Ул бит атасын тыңлап, авылда калды. Район үзәгенә өч көнгә бер барып, охранник булып эшләп йөрде. Сабан туе көне иде, яхшы гына салып алган, и, үзең беләсең, Сабан туе җиреннән плотина аркылы кайтырга кирәк бит. Бу инде кызган баштан мотоцикл белән скоростьны киметми, плотина алдына килеп кергән. Люлькасында да, артында да кеше булмаган. Көпчәк ташка эләккән, ахры, и люлька күтәрелеп, матайны плотинага каплаган. Аны тартып чыгаручылар әйттеләр, суга егылып төшкәч, люльканың крылосы башына туры килгән, и всё шуның белән. Ике кызы калды, зурлар инде алар.

– Илүзә ялгыз гына яшәп ята, димәк.

– Ие, тол калды, түлке син аңа бәйләнә күрмә, збир ул. – Камил авызын чапылдатып алды. – Махмыр өстенә тагын син сөйләштерәсең, авыз кипте, чылатмый булмый.

– Әйдә-әйдә, бер чикүшкә алып бирәм.

– Менә бусы сүз ичмасам, алайса хатын-кыз сүзен сөйләштереп торасың. – Камил шулай сөйләнә-сөйләнә, Дәнәф артыннан кибеткә таба атлады.

Кибет эчендә халык калмаган, шуңа Илүзә чәйләп алу теләге белән, электр чәйнегенә су тутырып розеткага тоташтырды да тәрәзә аркылы урам якка күз салды. Кибеткә таба якынаеп килгән Дәнәф белән Камилне күреп алды. Күрде дә ток суккандай артка таба чигенде. Дәнәфнең кайтып төшүен аңа авыл хатыннары көне-сәгате белән җиткергәннәр иде. Тик аның белән ничек күрешүе турында уйлый алмады. Курыкмады, билгеле, шулай ук үзендә бернинди каушау да сизмәде. Дөнья көтеп, тормыш йөген тартып чыныккан ялгыз хатынны бернинди каушау да, курку да ала алмый

иде. Ахирәтләре кибеткә кереп, Дәнәф кайткан дигән хәбәрне ирештергәч, «кайтса, кайткандыр шунда», дип кенә уйлап куйды. Шулай да хатын нигәдер кечкенә көзгегә күз салды. Өс-башын рәтләгәндәй итенде, тиз-тиз генә тарак белән чәчен рәтләп алды да, башын туры тотарга тырышып, прилавка артына чыгып басты. Ул арада кибет ишегенең тимер пружинасы шыгырдады, ишектән башта авыл сәрхуше Камил килеп керде, аңа ияреп, чәчләрен ап-ак бәс сарып алган ир кергәне күренде.

– Илүзә...

– Нәрсә, тагын кердеңмени?

– Керсә, ярамый мәллә, үзем генә түгел, әнә яшьтине очраттым.

Камил артында басып торган Дәнәф алгарак чыгып басты.

– Исәнмесез!

– Исәнмесез, кайтканыгызны ишеткән идем.

Әйтерсең, кайчандыр бер-берсен өзелеп яраткан кешеләр түгел, ә бөтенләй чит кешеләр очрашты.

– Ие, кайттым менә, Илүзә.

– Ярар, кайтканның гаебе юк, яхшы булган, тик ничә еллар күзгә күренми йөрдең.

– Хезмәт, гел бушап булмады.

Дәнәф Илүзәне күзәтергә тотынды. Моны сизеп алган хатын тураеп басты: кара инде алайса, бик карыйсың килгәч. Ике кызы да шәһәргә чыгып киткәч, Илүзә төп йортта япа-ялгызы калды. Бер кат йорт эшләрен карап чыккач, ялгыз хатын өенә кереп, телевизор каршына утыра. Эч пошканнан симәнке, яки чикләвек ярып утырырга гадәтләнде. Шуңа, ахры, шактый гына калынаеп китте. Ире исән, кызлары кечкенә вакытта юанаерга ирек юк иде. Ә хәзер берүзе. Үзен-үзе карарга да вакыт җитәрлек. Чәчне мода буенча кистергән, өс-баш та начар түгел. Кыскасы, тулы гәүдәле чибәр генә ханым. Илүзә, карап туйдыңмы, дигәндәй, иргә елмаюлы караш ташлады. Кайчандыр таза гәүдәле чибәр егетнең чәчләре чаларган, аз гына алгы якка таба бөкрәя төшкән, битләрен җилләр ярган, кояш көйдереп бетергән. Үзе әледән-әле сул аягын сыйпаштыргандай итә. Тормыш моны да яхшы тәпәләгән икән дигән фикергә килде хатын. Бәлки шулай бер-берсен күз белән тикшерү озаграк та барган булыр иде.

– Кхм-м... – Үзенең барлыгын искә төшереп, Камил тамак кырды.

Ир белән ханым сискәнеп киттеләр.

– Яшьти, син мине онытмадыңмы?

Дәнәф Илүзәдән күзләрен аерып, киштәләр ягына күз ташлады.

– Әни кайтышлый ипи алырга кушты, Илүзә.

– Әнә, сул яктагы киштәдә, бүген иртүк китерделәр. – Илүзә нигәдер ачулырак эндәште.

Моны сизеп алган Камил классташына елмаеп карады. Янәсе, әйттем бит збир дип.

– Бер чикүшкә дә кирәк.

– Аңладым инде анысын, бу хәчтерүш тиккә ияреп йөрми.

– Әй, син, чамалап.

– Нәрсә чамалап, тагын типкәләп чыгарам хәзер.

– Чыгар, збир бит син.

– Сиңа зверь генә түгел, аждаһа булсаң да таманга туры килә. Кемне очратасың, шуңа теләнәсең. Бар, ычкын фермаңа, сыер тиресен чыгар әнә.

– Чыгарырмын, сине ярдәмгә чакырмам.

– Әй, ярар, талашмагыз әле, талаш тыңларга кайтмадым, өлгерермен барсына да, әлегә авылдан китәргә җыенмыйм.

– Озаккамыни, Дәнәф?

– Шулай уйлап торам, Илүзә, пенсиядә бит мин хәзер.

– Фию-ю-фит, кырык яшьтән пенсиядә, начар түгел икән синең хәлләр, миңа пенсиягә кадәр…

– Җиттеме сиңа, юкмы?! – Илүзә сүгенергә җыенган Камилнең сүзен өзде: – Әнә, алып биргәннәр икән чикүшкә, чык та ычкын моннан.

– Өйрәтмә, яме. Үзем белермен мин. Яшьти, син ничек, бәлки минем белән берәрне...

– Юк, Камил, башка вакытта.

– Ну, ярар алайса. – Камил, кош тоткандай, чикүшкәне куенына яшерә-яшерә, кибеттән чыгып китте.

– Алып бирмәскә иде, Дәнәф, авызына ун грамм керсә, калганын таба ул. Сәрвәр апа кызганыч.

– Ярар, бәлки бүген алай итмәс.

– Ие, гомере буе сәрхуш булган да, бүген икенчегә әйләнгән, ди, Камил. Син ничек пенсиядә, иртә бит әле.

– Тарихы озын Илүзә.

– Сөйлисең килми?

Дәнәф юк дип башын селкеде.

– Ярар алайса, син кем инде хәзер, полковник, әллә генералмы?

Ир елмаеп куйды.

– Юк шул, өлкән прапорщиктан узып булмады.

Хатын да елмаеп куйды.

– Ярар инде, булганы үзеңә җиткәч, кибеткә кергәлә.

– Бер дә кермичә булмас, әле авылдан китәргә җыенмыйм. Хушыгыз.

– Хушыгыз.

Илүзә нигәдер Дәнәфне ишеккә кадәр озата килде. Ир артыннан кибет ишеге ябылуга, эчтән бикләп тә куйды. Аннары тәрәзә форточкасын ачып, еш-еш сулыш алырга тотынды. Хәзер үтә ул, үтә, ул гел шулай итеп үткәрә аны. Илүзә ничек кенә тырышмасын, бу юлы булдыра алмады. Әйтерсең кайдадыр күмеп калдырылган яшьләр чишмәсен кемдер ерып җибәрде. Илүзә ике кулы белән битен каплап, юылмаган кибет идәненә чүгәләде. Ул башта үзенең елый башлавына ышанмый, тыелып үксемәскә тырышып карады. Юк, кабат булдыра алмады анысын да. Елады да елады. Ни өчен елаганын ул үзе дә белмәде. Бәлки алданган кыз чагын кызгангандыр, бәлки вакытсыз китеп барган ир канатын искә алгандыр, алданса да, начар тормады бит ул аның белән, бәлки үсеп буйга җиткән кызларының бәхете өчен шатлангандыр. Бәлки чәчләрен бәс сарган яшьли сөйгән яры каршындагы, вәгъдәсезлеген күз яшьләре белән юып төшерергә теләгәндер. Ә бәлки бары тик хатын-кыз булганы өчен генә. Кибет ишеген кемнәрдер килеп тартып карады, хатын эндәшмәде, кесә телефоны моңлы көй уйнарга тотынды, хатын алмады. Буш кибет эчендә идәнгә чүгәләп утырган хатын

үкси-үкси елады. Әйе, ул көчле хатын, шулай булса да, аның еларга хакы бар, аңлыйсызмы сез шуны? Хакы бар-р-р-р.

Кибеттән кайтканда, Дәнәф Илүзәне үзе хәтерләп калган яшьлек сурәте белән чагыштырды. Әй, аның каршында, бар нәрсәдән кызык табып чыркылдап көлә алган кыз түгел иде бүген. Тормышның бар сукмагын да курыкмыйча үтә ала торган, көчле рухлы хатын басып тора иде. Калынаеп та киткән, Дәнәфнең бер учына сыеп бетә торган янбашлар, колач җитмәслек булганнар. Кибеттә халык белән талашыптыр инде, телгә дә үткенләнгән. Ничек диләр әле, авызына бармагыңны тыга күрмә, тешли дә өзә, диләрме андый кешеләр турында? Әйе, ул өзелеп яраткан кыз юкка чыккан. Яшь, чибәр, көләч Илүзәне көчле рухлы ханым алыштырган. Авылга кайткач, тәүге яры белән очрашасын ул аңлады, билгеле. Төрлечә күз алдына китереп карады очрашуны. Билгеле инде, аның хыялында оялып, гаепле караш белән чыгарга тиеш иде Илүзә. Алай булмады, хатын аның күзенә туп-туры карап сөйләште. Ә Дәнәф үзе нишләде соң? Берни дә эшләмәде, әйе, йөрәге дә аны күргәч кысылып куймады, хатынга бөтенләй таныш түгел кеше кебек итеп карады. Ни өчен? Егерме ел эчендә, күңеле мең төрлегә әйләнгән шул инде. Шуңа күрә йөрәге тыныч калып, сулкылдап типмәскә өйрәнгән. Әллә егерме еллык солдат хезмәте (әле нинди генә) аны җансыз бәндәгә әйләндергән микән?

– Солдофон! – Дәнәф үзенә шулай мыскыллап эндәште.

Туган йортының капкасын ачып кергәч кенә, уйларыннан арына алды ул. Капкадан керүгә, әтисе кирпечтән күтәргән гаражга күзе төште. Гаражның ике ишеге дә шыр ачык. Монда инде гомерен техника янында үткәргән Раушан абыйның бар байлыгы. Нинди генә техникага запчасть юк монда. Саный китсәң, көн җитмәс. Мондагы тимер байлыгын әтисе күз карасы кебек кадерли, аның рөхсәтеннән башка берәү дә гаражга аяк атлап керә алмый. Ә үзе әз генә вакыты булдымы, шунда кайнаша, юаныч, күптән яше алтмышны узса да, шушы тимер-томыр өеменнән аерыла алмый яши әтисе.

Капка тавышын ишеткән Раушан абый гараж ишегеннән башын чыгарып карады.

– Малай, монда кил әле.

Малай... Кырыкта да Дәнәф әти кешегә малай булып кала.

Дәнәф арыган булса да, әтисе янына гаражга таба китте. Килеп җиткәч, гараж ишегенең яңагына тотынып, сул аягын сыпырып куйды.

– Нишли, сызлыймы?

– Сызлый, әти. Ияләнеп булмый һаман мондагы һавага.

– Ул ияләнә алмас инде, улым. Әнә бабаң, минем әти, сугышта өздереп кайткан кулы белән гомере буе азапланды. Төннәр буе сызланып, ыңгырашып ята иде, мәрхүм. Урыны оҗмахта булсын.

– Төннәр буе дип, әти,\ мин дә ыңгырашып ятмыйммы соң?

– Юк, ыңгырашмыйсың. – Раушан абый, әй, дигәндәй, кулындагы әйберен читкә ташлаган булып, улыннан күзен яшерде.

– Әти, мин сине аңламадым, ник башыңны читкә борасың?

– Юк, улым, әйберне генә алып куйдым бит. – Раушан абый үзен тыныч тотарга тырышып, тәмәкесен кабызган булып азапланды.

– Әти, миңа кырык, әйт дөресен, күреп торам бит, ничек йоклыйм мин?

Раушан абый бераз уйга бирелеп, тиз-тиз тәмәкесен суырып алды.

– Атакага барасың, граната ыргытасың, таулар арасында ур-ра кычкырып чабып йөрисең.

Дәнәф атасын эндәшми генә тыңлап торды. Аңа бу турыда хезмәттәшләренең күп тапкырлар әйткәне бар иде инде. Хәер, алар үзләре дә беркайчан да саташмый йокламадылар.

– Күпме шулай саташып ятам инде мин?

Раушан абый улына түгел, ә ераккa карагандай эндәште.

– Таңга кадәр сугышасың, ярый әниең колакка катырак, ул ичмасам ишетми, – дип, абзый гараж кырыендагы утыргычка барып утырды.

– Әти, бәлки үз вакыты белән бетәр.

– Белмим, бабаң мәрхүм бакыйлыкка күчкәнче немесләр белән сугышты, ярый әниең колакка катырак, – дип, ахырдан тагын кабатлап куйды әтисе.

Дәнәф тә әтисе янына килеп чүгәләде. Шулай, янәшә утырган хәлдә, һәрберсе үз уйларына баткан ата белән ул тынып калдылар.

Тик ата кеше болай эндәшмичә озак утыра алмады. Малай кайтканнан бирле аны бер сорау борчый. Тормыш бит бер көн генә түгел.

– Алга таба нишләргә уйлыйсың инде, улым?

Дәнәф иңбашларын җыерып куйды.

– Белмим дә, әти, кесәдә теләсә кайсы шәһәрдә бушка фатир алырга сертификат бар, пенсияне җайлыйсы бар. Пенсиясе саллы чыгачак, диләр.

– Алай икән, бушка фатир алып, яхшы пенсия белән түшәмгә төкереп кенә ятасы икән.

– Кызма инде, әти, алай димәдем бит. Аннары пенсия генә түгел. Хәтсез акча белән кайттым. Хөкүмәт ашатты, киендерде, акча тотылмады диярлек. Аннары, туздыра торган урыны да ул түгел иде.

– Урыны ул булмагач, нигә кайтмый йөрдең, ә? Хатың килә, бер карыйбыз, Армения дип язылган, икенче карыйбыз – Таҗикстан, ул арада Чечённән килеп төшә хат. Рәсәйнең кайда арты кычыта, шунда барып кашып йөрдең инде. Ни йортың, ни хатының, ни балаларың юк.

– Соң инде, әти, мин саклама туган илне, син саклама, кем сакларга тиеш соң аны?

– Мин менә, улым, югары белемле кеше түгел, шулай да әйтим әле. Бабаң, мәрхүм, илне саклап, сугышка китте. Бусы аңлашыла, танклар белән чикне узып кергән, бар халыкны рәттән кырып килгән немескә каршы. Бусын аңлыйм, ә менә син кемнән сакладың инде, әйтик менә мине, әниеңне, сеңлең белән абыеңны, ә?

– Алайса, тыңла инде мине дә, әти.

– Әйт, әйт, тыңлап карыйм сине дә.

– Таҗикта идек, приказ бирделәр Әфганга чыгып барган кәрванны тоткарларга дип. Без чыгып киттек билгеләнгән урынга, җәяү бардык таулар арасыннан, вертолёт белән ярамый, бандитлар сизенәчәк. Шул, барып җиткәч, кабат приказ, кәрванны тоткарлаганда атмаска. Без аптырап киттек. Ничек инде атмаска? Алар бит баштанаяк коралланган. Соңыннан качып яткан җирдән күреп алдык. Озын кәрван якынлаша, кәрванда барысы да кораллы, шулар арасында куллары бәйләнгән егермедән артык ундүрт-унсигез яшьлек кызлар бара. Елап шешенеп беткәннәр, ялан тәпи

үзләре, киемнәре ертылып беткән. Коллыкка алып баралар аларны шулай, аңлыйсыңмы, әти, япь-яшь кызларны? Җаннар аяк астына тәгәрәде, бер карауга чәчләр агарырлык, егерме беренче гасыр бит. Ә монда коллар.

– Нишләдегез соң, улым, атарга ярамагач?

– Төнлә ташландык алар өстенә, кызларны коткардык, ә менә минем взводтан дүрт егет шунда ятып калды.

– Алай…

– Тик бит, әти, аларны ил чигендә токарламасак, монда үтеп керәчәкләр. Ирек, дин, дип кычкырган булалар үзләре. Чынлыкта төкерәләр алар барысына да. Бар теләкләре үз артларыннан сугыш ияртеп килү, шул сугыш аркасында үз кесәләрен калынайтырга исәпләре. Наркотиклар, корал, тере кешенең әгъзаларын кисеп алып сату.

Минем кебек егетләр ил чигендә торганга күрә генә, син тынычлап яшисең. Аларга барыбер, татармы, русмы, син бары тик кол, бетте-китте.

– Һмм, аңлыйм да, улым, яңалыклар карап барам, аннары син дә дөрес дисең, үз күзләрең белән күргән кеше бит син. Ачуым килгәнгә генә әйтәм.

– Нигә ачуың килә инде, әти?

– Мин хөкүмәткә унсигез яшьлек тап-таза малай үстереп бирдем. Ә ул миңа кырык яшьлек, чәче агарып беткән, җитмәсә, күкрәге тишек, аягы тишек малай кайтарып бирде.

– Язмыш.

– Һай Аллам, утырасың философ, язмыш әнә торырга йортың, янында хатының белән балаларың булса гына була. Язмыш, хе, дүңгәләк дисәң аңлап була.

– Соң, кайттым бит, әти. Булыр әле барысы да.

– Шуны сорадым да бит инде, алга таба нишлисең дип.

– Әти, ярар инде, талашмыйк, әле атна да узмады кайтканга, ашыкма.

– Ярар соң, ашыкма, имеш, әйтерсең, унсигез яшь үзенә. Ашыгу түгел, чабарга кирәк. Әй лә... – Раушан абый торып басты.

– Раушан, Дәнәф, әйдәгез, ашарга керегез.

Ата белән бала йорт ягына таба борылып карадылар. Анда Рауза апа тәрәзәдән башын чыгарган да ашарга чакырып кычкырып тора икән.

– Хәзер, әнисе, керәбез.

– Ә?

– Хәзер керәбез, дим, – дип, кабат кычкырды Раушан абый. – Әйдә, ашап алыйк, улым, – дип, борылып, улына эндәште ата кеше.

Икенче көнне Дәнәф район үзәгенә китте, документ эшләре күп иде. Башта хәрби комиссариатка кереп, учёттан төште.

Хәрби билетына пичәт сугып биргәндә, военком:

– Нишли прапорщик, булды, җитте, дисеңмени?! – диде.

– Булды, бар гомергә җитәрлек булды.

– Алай-болай эш дисәң, туры үземә кил, безгә яшьләрне өйрәтү өчен синең кебек ветераннар бик кирәк.

– Сез аларны болай да начар өйрәтмисез, трибунага басып, ватанпәрвәр чыгышлар ясап торасыздыр әле. Алай бик җайлы бит, барып сугышып йөрисе юк, стаж да бара, шулаймы, иптәш полковник?

– Ну син, Хәсәнов, ветеран булдым дигәч тә, алай бик шапырынма

инде. Районга бер син генә җәһәннәмнән кайтмыйсың, әле дә булса хезмәт иткәннәре дә бар. Аннары, мине юкка тыл күсесе, дип уйлыйсың. Чечнаның беренче кампаниясенә эләктем, ул вакытта капитан гына идем. Боевиклар чолгап алган Грозныйдан ротадан бары тик җиде солдатымны гына исән килеш алып чыга алдым. Барысы да манчыды безне анда. Бер яктан – боевиклар, икенче яктан – үзебезнең артиллерия.

– Гафу итегез, иптәш полковник.

– Зыян юк, сез ветераннардан төртмәле сүзләр күп ишетәм мин.

– Җиде солдат барысы, дисез инде.

– Әйе, җиде, исемә төшүгә, әле дә җаннар телгәләнә.

– Хәзер башкача сугышалар инде, иптәш полковник, элеккеге бардак бетте дисәң дә була.

– Шуңа да шат инде мин. Егетләрнең әти-әниләре алдына бер дә калай табут китереп куясы килми.

– Ышанам.

Военкоматтан чыккач, Дәнәф ГИБДДга кадәр үзен-үзе сүгә барды. Бер белмәгән килеш нигә полковникка авыр сүзләр әйтеп ташлады инде, ә? Дөрес әйтте бит полковник, туган илне бер ул гына сакламый.

ГИБДДда үзенең иске машина йөртү таныклыгын яңасына алыштыргач, пенсия бүлегенә китте. Монда документлар белән эш кичкә кадәр сузылды. Дөрес чамалаган икән, кайнар ноктада булган, берничә батырлык медале, аннары яраланган өчен Дәнәфкә саллы гына пенсия килеп барачагын әйттеләр. Ә менә табибларга керә алмады, кич җиткән иде инде. Ул авылга кайта торган юл чатына чыгып басты да юл уңае туры килгән машина туктату исәбе белән кулын күтәрде. Машиналар выж да выж узып китәләр. Туктарга исәпләре юк, машина алмыйча булмас, дигән фикергә килде Дәнәф. Озак торырга туры килде аңа, җәй ае, шуңа караңгы тиз төшми. Шулай да монда төне буе басып торуың да бар икән, сәгать сигезенче китте бит инде. Дәнәф узып киткән машиналарны кулын күтәреп сәламләмәс булды. Шулай ир өметсезлеккә бирелеп басып торганда, аның яныннан выжлап узып киткән машинаның тормозлары чинады. Ул арада машина артка чигенеп, Дәнәф каршына килеп туктады. Рульдә утыз яшьләр тирәсендәге чибәр генә хатын иде.

– Дәнәф абый?!

– Әйе, мин!

– Авылгамы?

– Авылга иде шул.

Дәнәф текәлеп карады. Үзен танып эндәшкән гүзәл затны танымый иде ул.

– Әйдә, утырыгыз, минем дә авылга кайтыш!

Ир, ялындырмыйча, җәһәт кенә машина салонына кереп утырды, район үзәгенә чыгып киткәндә, өстенә бары тик футболка гына кигән иде, кичкә бераз суытты, монда җылы.

– Озак торгансыз, ахры, Дәнәф абый, туңгансыз?! – дип, аңа кабат үз итеп эндәште ханым, кузгалып киткәч.

– Ие, суык үткән икән.

– Язгы җир әле җылынмаган, шуңа кичкә җирдән бераз суык бәрә.

– Ахры шулай, – дип, Дәнәф кабат ханымга текәлеп карады.

– Танымыйсызмы, Дәнәф абый?

– Кичерегез, танымыйм шул, озак вакыт авылга кайткан юк бит минем.

– Ие, сез юкка чыккан идегез шул. Раушан абый: «Кайтсын гына, сугышын күрсәтәм мин аңа», – дигән иде, эләктердеме бераз?

Ир көлемсерәп куйды.

– Кичә колакны борды.

Ханым рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

– Ай, әйбәт иткән икән.

Аңа кушылып, Дәнәф тә көлде. Бу ханым үзләренең авылыннан, димәк, этисен дә белгәч.

– Ник әйбәт булган дисең?

– Туган йортка кайтмый йөргәнгә.

– Менә кайттым бит.

– Тагын чыгып китәсезме аннары?

– Юктыр инде, – диде ир, кабат ханымны хәтерләргә тырышып, текәлеп карап тора башлады.

– Тәки таный алмыйсыз мине, Дәнәф абый?

– Юк! – дип җавап бирде ир, ханымны танудан өметен өзеп.

– Ну ярар, алайса исегезгә төшерәм.

– Әйдә, тырышып карагыз.

– Гөли-Гөли гөлдергән, Гөли күкәй чәлдергән! – дип такмаклап алды ханым.

Дәнәф көлеп җибәрде.

– Рашат абый кызы Гөлия.

Соң, Гөлия бит инде. Раушан абый белән Гөлиянең этисе – авылда балта осталары. Рашат абый эшкә кызын да ияртеп килә торган иде.

Аңа кушылып, ханым да көлде.

– Ие, Гөлия. Ну ачуым да килә торган иде, сез шулай үчекләгәч. Син үзең – күкәй карагы, дип әйтә идем, исеңдәме, Дәнәф абый?

– Исемдә, билгеле, син бит мин солдатка киткәндә, кечкенә идең әле.

– Өченче класста идем, әле Илүзә апага үпкәләп тә йөрдем.

– Нигә.

– Сиңа кульяулык чигеп бирмәгәне өчен, ә мин чиккән идем.

– Ник бирмәдең соң?

– Син бит иртүк киттең, мин йоклап калганмын, еладым аннары.

– Озак вакыт үтте шул, егерме ел эчендә кечкенә кызлар үсеп җитә инде алар.

– Сезнең кайтканны көтмәдек, билгеле, үсеп тә җиттек менә.

– Шулай булган шул, ә хәзер син кайдан болай килеп чыктың?

– Кайдан булыйм инде, яшьләрнең юлы бер генә – шәһәр дә авыл.

– Ә-ә, шәһәрдә эшлисең инде алайса, Гөлия?

– Ие, кулинар булып, бер атна эшлим, бер атна ял итәм.

– Эштән авылга кунакка кайтыш алайса?

– Кунакка дип, Дәнәф абый, бер атна ялны авылда үткәрәм. Ә шәһәрдә бергә эшләгән дүрт кыз сөйләшеп, бер бүлмәле фатирга кереп торабыз. Бер атна ике кыз тора, бер атна калган икебез. Унике сәгать бара смена. Анда йокларга гына кайтабыз. Дүртәү булгач, түләп бару да кыйбатка чыкмый.

– Ә ирең сүз әйтмиме соң, алай атна буе кайтмый йөргәч.

– Белмим, – дип, елмаеп иңнәрен җыерды Гөлия. – Булса, бәлки алай йөрмә, дигән булыр иде, булмагач – сүз әйтүче юк.

– Ничек?

– Шулай, кияүгә чыгып караган юк әлегә, Дәнәф абый, – дип, кабат елмаеп куйды кыз.

– У-у-у, бик озак кыз булып йөрисең икән инде, нигә чыкмыйсың соң кияүгә?

– Очрамый бит җүнле кияү, Дәнәф абый. Безгә дигәне әллә үсеп җитмәгән, әллә картаеп үлгән, ә, бәлки, сезнең кебек кайтырга юл таба алмый адашып йөридер.

– Җә юл кырыенда басып каладыр, – дип елмайды Дәнәф, – тагын утыртмый китте, дип елыйдыр аннары.

– Юк, Дәнәф абый, юлда кеше утыртырга куркам мин, сезне дә танымаган булсам, туктамый идем.

– Ие, анысы да бар, заманасы шундый. Әти-әниең исәннәрме соң?

– Исән икесе дә, Аллага шөкер, ике апа да кияүдә инде күптән, шул ук шәһәрдә торалар, мин менә ике арада эленеп калдым әлегә, – дип, кабат көлеп куйды кыз.

Дәнәфнең дә күңеле күтәрелеп китте, Гөлиянең матур итеп елмаюын ошатты инде әллә? Кыз бер дә төшенкелеккә бирелә белми, ахры. Ул читтән кызны күзәтә башлады. Причёска астыннан күренеп торган матур колак, аңа тагылган алка җем-җем итеп балкып ала. Озын керфекләр, җыйнак кына борын, күпереп торган иреннәр. Аккошныкы кебек шома ап-ак муен. Киң иңбашлары, калку күкрәкләре кыз сулыш алган саен бер күтәрелеп, бер аска төшеп торалар, алардан көчкә күзен аерды Дәнәф. Аста, машина караңгылыгына риза булмыйча, итәк астыннан йомры тез башлары ялтырап тора. Дәнәфнең битләре кызышып китте, ул оялып, кызның көләч йөзенә кабат күтәрелеп карады да башын читкә борды. Аны кыз, күз кырые белән күзәтеп барган, ахры, машина көзгесенә карады да елмаеп куйды. «Нәрсә, күрдеңме без нинди?!»

– Ник тынып калдыгыз, Дәнәф абый?

– Болай гына, – дип, җаваптан котылды ир.

Кыз кабат елмаеп куйды – «ярар, болай гына булгач».

Шулай бер-берсенә кырын караш ташлый-ташлый, авылга да кайтып җиттеләр.

– Менә кайтып җиттек, Дәнәф абый.

Дәнәф кызга акча сузды.

– Рәхмәт, Гөлия.

– Китегез инде, сездән ничек акча алыйм, ди, инде мин, – дип карышып, кулын селкеде кыз.

– Әҗәтле булып калам бит.

– Ярар алайса, әҗәтле булып калырга теләмәсәгез, безгә кунакка килегез, әти ярата иде сезне, кереп, хәлен белсәгез, әйбәт булыр иде.

– Ярар, керермен, әти дигәч искә төште, әти кибеткә кереп, тәмәке алырга кушкан иде, онытканмын.

– Әйдәгез, мин дә сезнең белән, – дип, машина эченнән чыгып басты кыз. – Авыл кибетенә күптән кергәнем юк, сезнең белән кереп карап чыгыйм әле, нәрсәләр бар икән?

Кибет киштәләрен сөртеп чыгармын да аннары бикләп кайтып китәрмен дип, кулына чүпрәк тотып торган Илүзә, ишек ачылган тавышка күтәрелеп, шул якка таба борылып карады. Ишектән, уен-көлке сөйләшә-сөйләшә, Дәнәф белән Гөлия килеп керделәр. Аларны күреп, кибетче хатын чак кибет прилавкасына тотынып калды. Нәрсә-нәрсә, менә шулай була ала дип, башына китергәне булмады аның. Аныңча, кыз алдында авызын җыя алмый торган ир бары тик аныкы гына була ала. Инде күпме вакыт узган, үзенең ике кызы үсеп җиткәнен онытып җибәргән иде ул Дәнәф белән очрашкач. Ул кызны күзләре белән ашарлык булып тураеп басты.

– Исәнме, Илүзә.

– Исәнмесез, Илүзә апа.

– Ярый, үлмәгән, исән, – дип, төксе генә җавап бирде хатын.

– Әти тәмәке кирәк дигән иде, «Прима».

Илүзә алып бирде.

– Сиңа нәрсә кирәк? – дип, кыздан сорады кибетче.

Тик сорау, сиңа ни калган аның янында, дигән кебегрәк яңгырады.

– Мин болай гына кергән идем, Илүзә апа, карап кына чыгыйм дип.

– Алайса, кара инде.

– Ярар, башка вакытта, – дип, ишеккә таба борылды Гөлия, кибетче хатынның дорфалыгына хәтере калып. Дәнәф аңа иярде:

– Ярар, хуш, Илүзә, – дип, ашыгып саубуллашты да кыз артыннан чыгып китте.

Илүзә тәрәзәгә килеп капланды.

Юк, бергә китмәделәр. Әнә кыз машинасын кабызды да үзе генә кузгалып китте, ә Дәнәф өйләренә таба җәяү генә атлады. Илүзә борылып, кибет стенасына сөялде. Бәлки алай ук куркыныч түгелдер. Ие, шулай бит, Дәнәф район үзәгенә киткән иде бүген, эше күп булган да соңлаган. Аннары, Рашат кызына туры килеп утырып кайткан. Ие, бары тик шул гына, шул гына.

Туган йортка төнката гына кайтып керде Дәнәф. Раушан абый белән Рауза апа йокларга ятканнар иде инде. Ул әти-әнисен уятмаска тырышып, плитә янына килде дә чәйнеккә су салып кайнатырга куйды. Аннары өстәл янына килеп утырып тынып калды. Гаҗәп, Гөлиянең көлгән тавышы әле дә колагыннан китми тора иде.

– Солдафон!

Бар тормышын солдат хезмәтенә бәйләгән ир дөньяның иң гүзәл заты хатын-кыз барлыгын да оныткан мәллә? Юк, хезмәт иткән җирләрендә очрашып йөргән кызлары булды аның. Тик бүген машина белән янына килеп туктаган кыз икенче. Валлаһи, икенче, аерым бер алиһә зат.

Аның чәй куеп йөргән тавышына Раушан абый да уянган, урыныннан торып, улы янына чыгып утырды.

– Соңладың.

– Шулай килеп чыкты шул, әти, документ эше пенсионныйда озаграк барды.

– Ничек кайттың?

– Рашат абыйның төпчек кызы очрады.

– Ә-ә-ә, яхшы булган. Рашат дусның өч кызы да акыллы кызлар булып үстеләр. К-х-м, улым, сиңа сүзем бар иде.

– Тыңлыйм, әти.

– Ни, теге элек инженер булып эшләгән Галәү абыеңны хәтерлисеңдер?..

– Ие, хәтерлим.

– Шул, күптән зиратта инде ул. Балалары берсе дә авылда калмады. Быел март айларында әниләрен дә җирләделәр.

– Урыннары оҗмаһта булсын.

– Ие, шулай булсын. Балалары әтиләре торган йортны сатарга йөриләр икән, к-х-м.

– Аңламадым, әти, Галәү йортын аласың киләме әллә, синекеннән артык җире юк бит ул йортның?

– Юк ла. Ул мыштым Галәү нинди заман якынлашканын яхшы сиземләгән.

– Сизенеп нишләгән инде ул?

– Колхоз гаражында инженер иде бит.

– Сузма инде, әти.

– Сузма дип, ничек булдыра алгандыр, бер «Беларусь» тракторын үзенә алып кайтты ул колхоздан, ие, үз исеменә яздырткан аны. Аннары сука, тырма, күлти, копалка кебек нәрсәләрне дә үзенең гаражына җыеп тутырган иде.

– Соң?

– Соң дип инде, балалары барысын да бергә сатабыз, diләр, син хәтсез акча белән кайттым дигәнгә генә әйтүем.

– Алыйк дисең инде алайса, әти.

– Алсак, хуҗалыкка ярап куяр, дим инде, кешегә ялынасы булмас иде.

– Күпме сорыйлар?

– Йөз илле мең.

– Ник арзан?

– Арзан дип, ул мәнсезләр техниканың кадерен белмиләр, аннары тимердән котылып, тизрәк йортны сатып җибәрәселәре киләдер.

– Ярар, әти, иртәгә барып алырбыз. Арбасы бармы соң тракторның?

Раушан абый җанланып китте.

– Бар-бар, арбасы да, үзе күтәртә торган арба.

– Ярар, әти, алырбыз.

Раушан абый торып, улының иң башыннан кагып куйды да:

– Рәхмәт, улым, – дип, бүлмәсенә йокларга кереп китте.

Икенче көнне әйткән сүзендә торды Дәнәф. Иртүк барып тракторны сатып алып кайттылар, җир эшкәртә торган агрегатларны шул трактор арбасына салып ташыдылар.

– Ай Аллам, бала башын катырып, карт җүләр, гаражыңдагы тимер җитмәгән идеме сиңа? – дип сукранды бу гамәлләрне күреп торган Рауза апа. Тик Раушан абый корткасына ачуланырлык хәлдә түгел иде бүген. Кайтканнан бирле улының бер алдына, бер артына төшеп йөргән хатынына матур гына җавап бирде:

– И, ярар инде, әнисе, менә кешегә ялынып йөрмәбез, үзебез бакчаны эшкәртербез. Үгезгә дә печәнне чабып алып кайтырбыз.

– Нәрсә дисең?

– Үгезгә печән алып кайтырбыз, дим, – дип кычкырып кабатлады Раушан абый.

– Ишетмим.

– Әй, бар сана, синең белән сөйләшкәнне, аргы як урамнар да ишетте инде, – дип, Рауза апаны йортка таба куалады Раушан абый, – бар, чәеңне куй, хәзер керәбез.

Әти-әнисенең үзләренчә сөйләшкәннәрен, Дәнәф елмаеп, читтән карап, тыңлап торды.

Алдагы атнасын Дәнәф әтисе белән техника янында үткәрде. Сигезенче класстан әтисе янында комбайнчы ярдәмчесе булып эшләгән, аннары кышкы, җәйге каникул көннәрендә шулай ук трактор белән җенләнгән Дәнәф үзенең югалткан бик кадерле нәрсәсен тапкан кебек тойды бу атнада. Тракторны да, җир эшкәртү агрегатларын да аталы-уллы кабаттан бер карап, төзәтеп, майлыйсы җирен майлап, чистартып, юып куйдылар. Күптәннән шундый эшләр белән шөгыльләнмәгән Раушан абый, әйтерсең, егерме елга яшәреп китте. Яңадан бер карап чыккан техниканы гараж янына тезеп тә куйдылар. Менә бит ни җитмәгән икән Раушан абый хуҗалыгына – тормышын алып барыр өчен хуҗалык техникасы.

– Эх! – Раушан абый, яшәреп китеп, бер кулы белән Рауза апаны кочып алды.

– Кит, нишлисең инде, карт җүләр, – дип, күңеле булып, кеткелдәп куйды хатыны. – Картаеп беткәч, ишегалдында кочаклашып торасың.

– И-и-и әнисе, аңламыйсың да инде, ә, менә бит алар, җанашларым, рәттән тезелеп басып торалар.

– Һай Аллам, инде шушында череп тә бетәрләр, нишлисең инде болар белән? Шул елына яз, көз, ике сәгатькә кирәкләре чыгар инде. Бакчаңны да әйтер идем, яртысына печән чәчкән.

Бу сорау Дәнәфне дә борчыды, атасының күңеле булсын дип ризалашты да. Тик бит техника уенчык түгел, техника гел хәрәкәттә булырга тиеш. Бу турыда аның үзенең фикере туып килә иде инде.

– Әти, безнең пай җирләре шул килешме ул?

Раушан абый яшен суккан кебек ерык авызын җыеп куйды.

– Ник аны сорыйсың, улым? Шул килеш ул җирләр, документка кертеп межаланмаган. Тик колхозга арендага бирелгән булып саналып тора. Каенлык өстендәге басу, син аны үзең дә беләсең.

– Ие, беләм, барып карадым мин ул басуны.

– Аның нәрсәсен карыйсың. Ун елдан артык ни сука, ни культи кергәне юк ул басуга, чүп басып ята. Башта колхоз сыерлары шунда йөри иде көтүдә. Хәзер, деловал дигән нәрсә салып куйгач, көтү дә чыкмый. Исең китәрлек, сыерлар көтүдә йөрсә, сөтләре аз була икән. Әнә, соңгы сыерым абзарда ятмады, көтүгә йөрде, сөтен савып бетерерлек түгел иде. Анаң картайгач, бетердем сыерны, бер үгез калды. Анысын да, өйдә тик ятып, тилегә чыкмас өчен генә асрыйм. Әниеңнең дә, минем дә, элеккеге кебек умырып ит ашарга тешләр калмады инде.

– Ә безгә күпме тиеш инде ул пай җирләре?

Раушан абый иңнәрен җыерды.

– Минекенә, анаңныкына да кушып, син монда пропискада булгач, сиңа тиешлесен дә кушсаң, унбиш гектар чыга.

– Әллә, әти, межалап, үзебез эшкәртеп карыйбызмы?

Әти кешенең күзләренә гөлт итеп очкыннар кунды.

– Ай, ул җирләр, ипигә ягып ашарлык. Нәрсә үстерәбез инде анда?

– Бәрәңге утыртырбыз димәс идем, әти, монда эшкәртүе кыйбат, сатсаң, акчасы бик аз, диделәр.

– Юк, бәрәңгенең файдасы юк. Аннары бит аны вакытында алып та бетерергә кирәк. Кем чүпли аны бушка?

– Ә көзгә сөреп, арыш чәчеп калдырсак?

– Арыш, дисең инде? Мал тоткан кеше килосын бер сумга гына төшерсәң дә, фуражга сатып алып бетерәчәк.

– Ничек, әти, тырышып карыйкмы?

– Кәгазь эше күп бит аның, көзгә кадәр өлгерерсең микән?

– Вакыт бар, өлгерермен. Кара, әти, синең чалгылар исәнме алар?

– Әй, кая китсеннәр инде алар? Яз саен эш юктан карап куям шунда. Тоткан юк аны, акчасын түләсәң, печәнне түге белән китереп бирәләр. Бер үгезгә күп кирәкмени?

– Каенлык астындагы болынлыкка төшкән идем. Печән билдән булган. Анда барып караган кеше бөтенләй юк, ахры.

– Кем барсын анда, яшьләр юк, картлар чалгы селтәп йөрми. Ә чишмәне күрдеңме, бурасы ничек?

– Череп беткән, әти.

– Эх, Рашат ахир белән курчак өе кебек ясап куйган идек.

– Барып, бераз печәнен чабып карыйм дигән идем.

– Болын печәненең исе дә үзгә инде аның, колхоз печәне түгел. Хайван өчен меңләгән витамины бар. Бар, артың кычытса. Барыбер тик йөрисең, әнә гараж чормасында алар.

Чалгылар караштырып йөргән вакытта Дәнәф янына әнисе Рауза апа килеп басты.

– Улым, кая җыенасың?

– Каенлык астындагы болынга иде, әни!

Рауза апаның Дәнәф кайтканнан бирле, улын йорттан чыгарып җибәрәсе килми, гел янында булырга, аны күз алдында тотарга тырышты.

– Йөрмисең мәллә, улым, аягың да сызлый, аннары уң як күкрәгеңне дә күрдем. – Әни кеше улының күкрәгенә кулын куйды: – Авырттымы, улым?

– Юк, әни, бик аз гына авыртып алды ул, тиз төзәлде.

Чынлыкта бу ярадан исән калу икеле иде, тик Дәнәф аякка баса алды, хәрби комиссия белән ул вакытта кычкырышып бетте. Аны шул беренче ярасыннан ук пенсиягә чыгармакчылар иде. Ә ул хәрби хезмәттә кала алды. Кайтып китәргә вөҗданы кушмады, чөнки бик хәтәр вакытлар. Егетләрне калдырып, тыныч тормышка күчү аның өчен хаинлек белән бер иде.

– Улым, йөрмә, авырлык килер тагын үзеңә.

– Борчылма, әни, аз гына авырта башласа да, чалгыны ташлармын да кайтып китәрмен.

– Бик көчәнмә, алайса, әнә сумкага әйрән тыгам, баруга чишмә суына утыртып куй. Тик, артык суык булса, шундук эчә күрмә.

– Ярар, әни, – дип, Дәнәф әнисенә рәхмәт әйтте дә чалгысын алып, болынга таба китте.

Карт каенга оя корып, күкәй басып утырган тилгән дә, җәйге җилдә иңсерәп утырган йомран да, карт сөякләрен кояшта җылытып, агач

башында йокымсырап утырган козгын да – кинәт барысы бергә сискәнеп киттеләр.

– Чож …

Нәрсә бу? Тик торганда, кем аларның тыныч тормышын боза әле монда?! Алар барысы бергә тавыш килгән якка борылып карадылар. Тавыш кабат кабатланды.

– Чож, чож, чож.

Инеш суында коенып, күңел ачкан су күселәре дә ярга чыгып, арт тәпиләренә басып, тавышның хуҗасын күзәтергә тотындылар.

Дәнәф аларның берсен дә күрмәде, билгеле. Ике куллап чалгысын тоткан да, селтәнә бирә. Үлән әле чәчәктә генә утыра, нәкъ чабып ала торган вакыты. Аның артыннан яңа чабылган хуш исле покос кала. Авыл баласы күпме ел үтсә дә, чалгыны онытмый икән. Аның куллары да, тәне дә, әйтерсең, Дәнәф кичә генә печән чабып кайткан кебек, барысын да бик оста эшләделәр. Сагынылган. Ир печән чабу ләззәтеннән туктый алмыйча, чалгы белән селтәнде дә селтәнде. Покос янына покос килеп ятты, берәү икәү, өчәү... Ул чапкан җиреннән туктап, маңгай тирен сөртте дә каен күләгәсендә калдырган әйрәнне барып алды. Чабыласы печән җирен таптап, әйрәнне чишмәгә төшереп куясы килмәде аның.

– Би-и-и-п.

Дәнәф сискәнеп, артына борылып карады. Гөлия икән, машинасы белән килеп туктаган. Ян тәрәзәсеннән башын чыгарып, Дәнәфне сәламләде кыз.

– Алла куәт бирсен печәнчеләргә!

– Сәламәт бул. Каян килеп чыктың монда?

– Әни бәрәңге чүбен утарга кушкан иде. Арт бакчага чыксам, болынлыктан чалгы тавышы килә. «Нинди җүләре чалгы белән печән чаба икән?» дип күрергә килдем.

Кыз маташтыра, алар бакчасыннан болынлык уч төбендә кебек күренә, шулай булгач, чалгы белән печән чапкан җүләрне күрү өчен аның монда килеп йөрисе юк. Тик Дәнәф кызны ялганда тотмады.

– Күрдеңме?

– Күрдем, ник чалгы белән селтәнәсең, Дәнәф абый? Хәзер бит моторлы чалгылар бар. Әтидән сораган булсаң, биреп торган булыр иде.

– Юк инде, чалгыга җитми, Гөлия, аннары тәнне дә яздыра. Әйдә, чык машинаңнан, кил монда, әйрән эчертәм.

Кыз, машинасыннан чыгып, ишеген япты да Дәнәфкә таба килә башлады. Ай, җаным, йөрешләре дә инде, күз алмалы түгел.

Гөлиянең килеп җиткәнен аякларын сузып, каен төбенә утырган килеш көтеп алды Дәнәф.

– Кая, бирегез, эчеп карыйм, Рауза апаның әйрәне тәмле микән? – дип эндәште кыз, килеп җиткәч.

– Утыр инде, дип, ир аңа үз яныннан, каен төбеннән урын күрсәтте.

Гөлия Дәнәф кебек аның янына аякларын сузып утырды да ул сузып торган әйрәнне эчеп куйды.

– Уфф. Тәмле икән. – Аннары каенга аркасын терәп, тирә-якны күзәтергә тотынды кыз. – Монда матур икән, Дәнәф абый.

– Ие, тыныч та, матур да монда.

– Минем монда әтиләр чишмә бурасын ясап куйганнан бирле килгәнем юк икән. Бакча башыннан күренеп тора бит безгә болын, шуңа бик ис китмәгән. Әнә тегендә, – кыз чишмә ягына таба төртеп күрсәтте: – ике аягым белән дә ләмгә тездән кереп баткан идем. Раушан абый күреп тартып чыгарган иде.

– Нигә ләмгә килеп кердең соң?

– Әти анда кыр үрдәгенең оясы бар, камышлар эчендә, дигәч, күкәйләрен карарга кергән идем.

– Менә бит, димәк, белеп үчекләгәнмен «күкәй карагы» дип.

– Әй, Дәнәф абый, көлмәгез инде.

– Көлмим, тик бер шарт белән.

– Тыңлап карыйк шартыгызны, абзый.

– Миңа башка абый димичә, Дәнәф кенә дип эндәшергә.

Кыз, башын кырын салып, уйланган булып, бераз аңа карап торды да:

– Ярар, алайса, Дәнәф абый, башка абый дип әйтмәм, – дип җавап бирде.

– Килештек, алайса?

Кыз, уйнап, иргә уң кулын сузды:

– Килештек, Дәнәф абый.

Кабат көлешеп куйдылар.

– Ярар, килешкәч, – диде Дәнәф, кызның кулын учыннан чыгарасы килмичә. – Печәнне дә чабарга кирәк.

– Ә ник чапкан печәнне таратып бармыйсың, Дәнәф?

– Бераз чабыйм инде, Гөлия, аннары таратырмын.

– Әйдә, үзем таратам.

– Ә бакча чүбе?

– Әй, барлы-юклы ун бураэна, бер сәгатьлек эш, өлгерәм.

– Ярар, алайса, син булышсаң, мин аңа шат кына! – Шат кынамы соң! Дәнәф, яраса, кызны үзеннән бер адым да читкә җибәрмәс иде.

– Мин хәзер, машинадан яулыкны гына алып киләм дә, көне эссе, башка кагар тагын, – дип, кыз машинасы янына йөгерде.

Дәнәф кабат чалгысына тотынды. Менә хәзер чабып күрсәтер ул сезгә. Янында Гөлия барында ул, туктамыйча, болынның бар печәнен чабып чыга ала.

– Дәнәф абый.

Ул артына борылып карады, Гөлия килеп баскан икән.

– Мәгез.

– Кулъяулык?

– Әйе, кулъяулык, кызчык чагымда сезгә дип чиккән идем, алыгыз, бизәге матур булмаса да, дүрт ягын төйнәп, башыгызны каплап куегыз, көне эссе, башыгызга капмасын.

– Кызлар чиккән кулъяулыкның бизәге ямьсез булмый инде ул.

Дәнәф кызның кулыннан кулъяулыкны алды да, почмакларын төйнәп, баш түбәсен каплап куйды.

– Менә бит киткәндә бирә алмагансың, аның каравы, кайткач бирдең, рәхмәт, Гөлия.

– Дәү үсегез.

Кыз шулай сүзне уенга борып җавап бирсә дә, бу иргә кулъяулыгы белән

бергә йөрәген биргәнен дә аңлады. Ул покос саен йөгерә-йөгерә, печән таратырга тотынды. Эшләве дә бик рәхәт, җиңел, болын өстендә күбәләк булып очасы килә. Аннары тау башына басып «Дә-н-ә-ә-ф!» дип кычкырасы килә. Тагын билдән өстен чишенеп печән чапкан ирнең артыннан йөгереп килеп кочып аласы, чаларган чәчләреннән назлыйсы килә. Аннары, аннары әллә нишлиселәр килә. Күңел төбендә яралган мәхәббәт ялкыны аңа бертуктаусыз, син бәхетле, дип кабатлап тора. Бу таныш түгел хискә бирелеп, шашып-шашып көләсе килә башлый, шул ук вакытта кинәт үкси-үкси елыйсы да килә. Хисләр ташкынына бирелеп, болында күбәләк кебек очынып йөргән кыз күрми калды.

Дәнәф кыз каршында гайрәтләнеп, бар көченә селтәнеп печән чапканда, кинәт арттан Гөлиянең чырылдап кычкырып җибәргән тавышы яңгырады:

– Ай!

Ул артына борылып карады, кыз уң аяк балтырын тотып, покос өстенә ауган иде.

– Гөлия, ни булды? – дип, чалгысын ташлап аунап яткан кыз янына йөгерде.

Еларга җитешеп, иреннәрен тешләгән кыз үлән арасына төртеп күрсәтте, анда шуышып кара елан качып бара иде.

– Елан... чакты, – дип, көчкә телен әйләндереп әйтә алды кыз.

Дәнәф кызның кулларын ычкындырып, аның аягына күз салды. Гөлиянең балтырында ике теш эзе күренеп тора.

«Тәк-тәк, Хәсәнов, смирно! – дип, үзенә үзе команда бирде Дәнәф, – прекратить панику. Синең мондый хәлләргә тарган солдатларны коткарганың бар».

Ул ярага авызын тидереп, тиз-тиз ярадагы канны суырып төкерергә тотынды. Аннары башыннан кыз биргән кулъяулыкны алып, жгут ясады да аркылы таяк тыгып, шуны бора-бора, яралы аякны кысып бәйләп куйды.

– Дәнәф абый!.. – Кыз авыртуга чыдый алмыйча печән өстендә бәргәләнде.

Ул кызны кулына алды.

– Түз, Гөлия, түз, бәгърем, шунсыз ярамый, юкса агу канга таралачак.

Гөлия аның муеныннан кочып алды.

– Дәнәф, нигә шулай, мин бит сине сагынып көткәнмен. Син кайттың, ә мин? Нигә дөреслек юк, Дәнәф абый? – дип пышылдады, аңын югалта барган кыз.

Дәнәф, кызны күтәргән килеш йөгереп, машина янына килеп җитте дә Гөлияне арткы утыргычка салды. Аннары рульгә утырып, зур тизлек белән кузгалып китте. Ул өлгерергә тиеш, өлкән прапорщик Хәсәновның өлгермәскә хакы юк, өлгермәсә, бу тормышның бернинди дә яме калмаячак аның өчен. Әйе, ул өлгерәчәк, һичшиксез, өлгерәчәк.

Төнне Дәнәф авылга кайтып китмичә, кыз янында палатада кунды. Бик үтенеп ялваргач, табиблар рөхсәт бирделәр. Ике якка да шалтыратып, әти-әниләрен тынычландырды.

– Гөлиянең температурасы юк, йоклый, сулышы тыныч, – диде ул аларга.

Өстенә ак халат салып, ул тумбочка янындагы табуреткага килеп утырды да бер кулына таянып, урамны күзәтергә тотынды. Бүлнис ишегалдында

искитеп күзәтеп утырырлык берни дә юк. Шуңа, үз уйларына гына бирелде. Таулар арасына аяк астына карамый йөргән егетләрне кобра чаккан вакытларын искә төшерде. Анда таулар арасында һушсыз калган егетләрне алып кайту җиңел түгел, ярый елан чаккан булса. Аяксыз, кулсыз, эчләрен пуля тишеп кергән егетләрне күпме үз җилкәсендә ташыды ул. Ә үзен ике тапкыр шулай күтәреп алып чыктылар вертолёт төшәрлек җиргә. Их, адәм баласы, ниләр генә күрмисең син?! Ә монда тыныч, сине бертуктамый борчып торган киеренкелекнең эзе дә юк. Халыкның шулай гамьсез тынычлыгы өчен күпме егетләр көн-төн сакта торалар. Аяксыз-кулсыз калалар, калай табутта туган нигезләренә кайталар. Юкка түгел бит, кем-кем, ә боларның барысы да юкка түгел икәнен үз күзләре белән күргән Дәнәф бик яхшы аңлый. Билгеле, берәүнең дә башын саласы килми, ә бит илне алар  сакламасалар, кем саклар соң? Мондагы тыныч тормыш минут эчендә юкка чыгачак бит, башкача булса. Шуның өчен ирләр дә бит инде без, илне саклар өчен ир булып туганбыз, хатын белән түшәк өстендә аунар өчен генә түгел.

– Дәнәф! – Гөлия уянган икән. – Син мондамыни?!.

– Әйе, монда, Гөлия, беркая да китмим, синең янда гына утырам бүген.

– Китмә! Бүген дә, иртәгә дә, гел янымда гына бул, яме.

– Гел яныңда гына булам, Гөлиям, синнән беркая да китмәм.

 Кыз, үрелеп, ирнең кулын учларына алды.

– Китмә, яме. – Кыз кабат йоклап китте.

Дәнәф Гөлиянең хәлен белер өчен көн саен бүлнискә сугылды. Ә көн саен район үзәгендә булыр өчен сәбәбе дә бар,  пай җирләрен закон нигезендә үзенә теркәтү өчен авыл белән район үзәге арасын хәтсез таптарга туры килде. Устав буенча барысы да тәртиптә, аңлаешлы тормышка өйрәнгән Дәнәфкә гранит фундаментта утырган бюрократия белән көрәшүе бик авыр булды. Кайчак, ниндидер документ сорыйлар, алып килеп бирәсең, ә ул документның нигә кирәген чиновниклар үзләре дә аңламыйлар. Башта ул тавышланып карады, кая ул, тавыш чыгарган саен документ эше арта гына торды. Соңыннан прапорщик Хәсәновны бюрократия барыбер җиңде. Беркая да барып зарланып булмый икән. Бар җирдә дә таныш-белеш, туган-тумача, ул-кыз, дигәндәй, бюрократик клан булып, идарә кәнәфиләренә менеп утырганнар. «Юк» дигән сүздә дә ике хата ясаган миңгерәвенә кадәр чиновник. Дәнәф, риза булып, озын чиратларда торырга өйрәнде, бер карусыз алар сораган документлар артыннан чапты. Утырып чабарга машинасы да булмагач, читен. Миңа әлегә кирәкми, дип, үзенең тугызлы машинасына доверенность язып, ачкычы белән кулына тоттырды Гөлия. Бусы бик ярап куйды, юлда йөрү азап булмый башлады.

Гөлия белән Дәнәф турындагы хәбәрне авыл халкы минуты-сәгате белән кибеткә китереп җиткерде. Тагын шул кыз белән булган икән дип уйлады Илүзә. Дәнәфнең үзе өчен булмавын ул кабул итә алмый иде. Ялгыз тормышта кабынган өмет уты, сүнми, гел пыскып торды. Кызлары да бар бит, гел кайтып, әниләренең хәлен белеп торалар. Олысы кияүгә дә чыгып куяр кебек. Очрашып йөргән егетен алып кайтып күрсәтте. Тик бу башка шул, ялгыз күңел парын эзли, әле бит йөрәге карт түгел, сөясе-сөеләсе килеп торган чак.

Кибет ишеге ачылып китте, Камил килеп керде. У-ф-ф, шундый вакытта ул гына җитмәгән иде.

– Исәнмесез.

– Исән инде исән, тагын әҗәткә сорап кердеңме? Беләсең бит, бирмим.

– Кирәк түгел, эчмим мин, – диде Камил.

– Кит инде! – дип, ботларын чапты Илүзә. – Кояш икенче яктан чыгар, әллә ниләр сөйләмә.

– Чыксын, барыбер эчмим.

– Сәер, аек килеш берсенең дә күргәне юк бит сине. Һай, кара, өстеңә яңа кием кигәнсең түгелме? Абау, чәчеңне алдыргансың, нәрсә булды сиңа, Камил?

Камил әйтмим дип, башын селкеде. Тик Илүзә хатын-кыз бит. Нигә Камилнең болай үзгәрергә уйлаганын белә алмыйча төпченүдән туктамады.

Ул килеп, ирне култыклап алды да, үрелеп аның йөзенә карады, хатын-кыздан яшереп буламы соң? Камилне эченнән нәрсәдер борчып торганы күзләренә чыккан.

– Камил, ни булды? Тотма эчеңдә, әйт менә миңа, берәүгә дә әйтмәм, чынлап.

Ир аннан beләгеn ычкындырды да кибет эчендә йөренеп алды.

– Көлмисең дәме?

– Көлмим.

– Көлмә яме, әрлә, тик көлмә.

– Әрләмәм дә, Камил, тотма эчеңдә, әйт.

Ир беткән баш беткән дигән кебек ботларына сугып куйды.

– Өченче көн эштән соң Рәйсәттәйнең сарык тиресен чыгарып бирдем.

– Соң шуннан ни булган, бөтен кешегә эшләп йөрисең бит син.

Ир аңа ачулы караш ташлады.

– Бүлдермә.

– Юк, юк, башка бер сүз дә әйтмим, сөйлә, Камил, ни булды?

– Шул Рәйсәттәй миңа ярты литр теге куган нәрсәне бирде. Мин аны капка төбендә үк эчеп бетердем дә, өйгә кереп, идәнгә егылдым. Әни, көндәгечә тирескә баткан киемнәремне салдырып, мине урынга өстерәп алып барып салган.

– Күрмәгәнен күрде синең белән, Сәрвәр апа.

– Илүзә.

– Бетте, бетте.

– Шуннан мин бераз айнып китеп, күзләремне ачтым, әни, догаларын укып бетергән дә Ходайга ялвара.

– Сине каргап утыра мәллә?

Камил, юк дигәнне белдереп, башын селкеде.

– Юк, «Ходай, миннән калгач, ятим итмә бу баланы, исерек килеш урамнарда аунап, өшеп үлә күрмәсен, ач тамагын туйдыра алсын, өсте-башы чиста була күрсен», – дип ялвара.

– Соң, әни кеше бит.

– Әни кеше! – Камилнең күзләрендә очкыннар кабынды. – Мине тапкан, баккан әнием, мин аңа бер тапкыр да җылы сүз әйткәнем булмады, аек килеш кайтып кергәнем булмады, туксанга җиткән әнием берүзе тормыш

тартып барды, әлегә кадәр. Ә мин, мәнсез, кабахәт кеше. Ул бит мине намазлыкка утырып каргый да ала иде. Ул, киресенчә, миңа бәхет сорап, Ходайга ялвара.

Ул Илүзә каршына килеп басты.

– Менә әйт әле син миңа, әйт, кеше дип атала аламмы соң мин хәзер?!

Илүзәнең Камил сөйли башлаганда ук күзләре яшьләнә башлаган иде инде.

– Боларны аңлый алгач, бөтенләй өметсез түгел икәнсең бит әле, Камил.

– Юк, син ышанасыңмы миңа, Илүзә, мин башка бер грамм да эчмәячәкмен, кайтып, әнинең аягына егылып, гафу үтенсәм, кичерер микән ул мине?

– Кичерер, ник кичермәсен, ул бит сиңа бары бәхет кенә тели. Акчаң бармы кесәңдә, Камил, булмаса, биреп торам.

– Нәрсәгә?

– Менә хәзер тәмле чәй алдырам үзеңә, кәнфит, лимон алып кайтып, Сәрвәр апа белән чөкердәшеп, чәй эч, әни кешегә күп кирәкмени, азы бик җиткән, – дип, Илүзә, ирнең башыннан сыйпап, киштәләр янына алып китте.

Кибеттән чыгып киткәндә, кулындагы нәрсәләрен кочаклаган килеш Камил кабат эндәште:

– Эчмим мин башка, Илүзә, син ышанасыңмы миңа?

– Эчмә, Камил, беркайчан да эчмә, ышанам, – дип, күз яшьләрен яшерә-яшерә озатып калды аны Илүзә.

Август – елның иң тук ае, шушы айда инде авыл халкының хуҗалыгына олау-олау мал керә. Җаның ни тели, барысы да бар. Авыз тутырып, шатырдатып, алма ашыйсың киләме, рәхим ит. Кыяры, помидоры, күпме телисең, җый да ал. Башка – чия, шомырт кебек җиләкләр телиме күңелең, әнә бар, өз дә аша. Әйе, табигать көзгә якынлаша. Авылга терәлеп торган болынга да акрынлап сары төс куна башлады. Дәнәфне санламый уйнаган су күселәре дә ялгыз түгел, үзләре кебек берничә шома, ялтыравык йонлы балаларын инешкә ияртеп алып чыкканнар, аларны баш өстендә берничә тилгән күзәтә, карт козгын гына, бернигә дә исе китмичә, шул ук агач башында кояшның соңгы җылы нурларына кинәнеп утыра. Ул, якты дөньяда озак еллар яшәп, искитәрлек нәрсәләрнең барысын да күреп бетергән инде, шуңа күрә гамьсез.

Дәнәф пай җирләрен межалап, үз исеменә теркәп бетерде, җәй үтте документ эшләре белән йөреп. Менә хәзер бу җирләр тулысы белән үзенеке булачак. Әтисе белән сөйләшеп, хәзер үк җирне сукалап, эшкәртеп, көзгә арпасын чәчеп куярга кирәк дигән фикергә килделәр. Сукасы да, тырмасы да, чәчкече дә бар. Ашлык өлгергәч, җыясы булыр, комбайны әлегә юк. Ул кабат үзенә тиешле басуны әйләнеп чыкты да, машинаны полоса янында калдырып, чишмәгә төшеп китте. Әйе, чишмәне кабат төзекләндерергә кирәк, болай ташландык хәлдә калдыру ярамас. Озак утырды ир үз уйларына бирелеп чишмә янында. Яңадан башланып киткән тыныч тормышка ияләнде ул, ияләнде генә түгел, аның бу тормыштан аерыласы килми дә хәзер. Дәнәфнең аркасына тигәнәк килеп ябышты. Ул артына борылып карады. Гөлия икән.

– Икәү бергә басу карарга барабыз дигән идең, ник кереп алмадың?!

Кызның кулында тигәнәк башлары, ул кабат бер баш алып Дәнәфкә ыргытты.

– Борчыйсым килмәде.

– Кемне, минеме, үзең чакырып, үзең килмәгәч, киресенчә, борчылыр дип уйламадыңмы? – Кыз кабат аңа тигәнәк ыргытты. – Ярый безнең бакчадан күренеп тора болын.

– Ыргытма әле шуны миңа.

– Ыргытсам, нәрсә булган? – Кыз кабат тигәнәк ыргытты. – Ярамыймы әллә?

– Ярамый, тотсам кирәгеңне бирәм.

– Ие, тоттырдылар, ди, берәүләр! – Бу юлы тигәнәк Дәнәфнең җилкәсенә килеп кунды, кыз телен чыгарды: – Мә-ә-ә.

Дәнәф торып басты.

– Ну, мин сине хәзер.

– Әй, әй! – Кыз курыккандай артка чигенә башлады.

– Кая качмакчы буласың, качма?!

– Кая телим, шунда качам! – Бу юлы берничәсе бергә укмашкан тигәнәк башлары, чалбар балагына килеп кундылар. – Мә-ә-ә-ә!

– Булды, үзеңне беттем дип сана, кызый! – Дәнәф Гөлия янына ыргылды.

– Дә-нә-ф! – Кыз аннан кача башлады.

Тик ерак китә алмады. Дәнәф аны куып җитте дә кочагына кысып алды.

– Эләктеңме?!

– Эләктем, нишләтәсең инде мине хәзер?

– Ашыйм!

– Ничек?

– Менә болай! – Ир аның муенына иреннәре белән үрелде, аннары үбә-үбә күкрәкләренә якынлашты.

Бу назга кызның каршы торырлык көче калмады.

– Дәнәф! – дип пышылдады кыз, ирнең башыннан кочып торткан килеш, – Дәнәф!

Әгәр дә шунда ир «нәрсә?» – дип сораган булса, кыз башка бер сүз дә әйтә алмас иде. Тик Гөлия ирнең назына бирелеп, бертуктаусыз аның исемен кабатлады.

Кичке ашны ашагач, басуны карарга киткән улын көтеп җиткәрә алмады Раушан абый, төн җиткәнче Дәнәфне көтеп утырса да, малай кайтмады. Шуңа өметен өзеп йокларга ятты ата кеше. Йокы аралаш машина килеп туктаганын ишетсә дә, чыгып йөрмәде. Иртүк торып, Рауза апа белән чәй эчтеләр. Дәнәф уянып, чоландагы бүлмәсеннән чыкмады. Эшен башларга кирәк бит инде.

– Анасы, – дип эндәште ул гомер иткән хатынына. – Кая, бар, малайны уят инде, эшкә тотынырга кирәк!

Чоланга улын уятырга чыгып киткән Рауза апа тиз әйләнеп керде. Күзләрендә ниндидер бер әсәренү очкыннары.

– Нәрсә булды, ник малайны уятмадың?

– Атасы, Раушан, анда ни.

– Нәрсә, ни тагын?

– Анда дүрт тәпи.

– Кайда дүрт тәпи?

– Чоланда.

– Каян килгән анда дүрт тәпи? – дип сорады, һаман төшенә алмый торган Раушан абый.

– Дәнәфнең юрган астыннан дүрт тәпи чыгып тора, атасы, – дип, ниһаять, аңлатып бирә алды Рауза апа.

– Ничек?! – Раушан абый бу яңалыкка аптырып китте.

Рауза апа, «белмим» дигән кебек, иңнәрен җыерды.

– Алай... – Ата кеше дә бу вакытта ни дияргә белмәде.

Аларның кычкырып сөйләшкән тавышларын чоландагылар да ишетеп алганнар, анда җанлану сизелде.

– Анасы, монда кил, әнә керәләр, ахры, – дип, Раушан абый хатынын үз янына чакырды.

Шулчак йорт ишеге ачылып китте, аннан башта елмаеп, Дәнәф килеп керде, аңа ияреп кергән хатын-кыз башы күренде, анысы оялып, малай артына сыенды. Тукта, Рашат кызы Гөлия түгелме соң бу? Раушан абый танып алды кызны.

– Хәерле иртә, әти-әни, – дип, шат күңел белән исәнләште алар белән уллары.

– Белмим инде, хәерле була күрсен, – дип кенә әйтә алды ата кеше.

Дәнәф артында посып торган Гөлияне алгарак этәрде.

– Менә, әти-әни, таныш булыгыз, киленегез Гөлия.

Өйгә тынлык урнашты, бу вакытта ни дияргә икәнен берсе дә белми иде. Кинәт Рауза апа атылып барып, урын өстеннән мендәр тартып алды да Гөлия алдына китереп салды.

– Төкле, йомшак аягың белән, килен.

Өйдәгеләр барысы бергә җиңел сулап куйдылар, әйе, бүген өйгә килен төште, инде йортта моңа беркем дә каршы килә алмый иде.

– Рәхмәт, әни! – дип, Гөлия килен булып төшкән нигезгә таш кебек ятарга риза булып, мендәр өстенә ике аягы белән басты да, елмаеп, Дәнәфкә карады.

– Ярый, әйдәгез, балалар, башта чәйләп алыйк, аннары күз күрер алга таба нишләсен, – дип, Раушан абый аларны өстәл янына чакырды.

Рауза апа, чәй ясыйм дип, чәйнеккә тотынган иде:

– Әни, бир үзем, – дип, чая килен аның кулыннан чәйнекне җайлап кына тартып алды да өйдәгеләргә чәй ясый башлады.

Рауза апа моңа бик риза калып, карты янына барып утырды. Нәрсә-нәрсә, яшь киленнең беренче чәе бик кадерле дә, тәмле дә була.

Авылда бер генә нәрсәне дә яшереп калып булмый. Төнлә буламы хәлләр, көндезме – әһәмияте юк. Бар яңалык минуты-сәгате белән авылга тарала. Рашат абыйга иртән үк төн кайтмаган кызы кайда икәнен күршеләре кереп әйтте.

Дәнәфләр матур гына чәй эчеп утыралар иде, капка ачылган тавышка барысы да тәрәзәгә күз салды.

– Әти! – дип, Гөлия тиз генә торып, мич артына сызды.

Капкадан ашыга-ашыга, Рашат абый килеп керде. Гомере буе җилкәсе белән бүрәнә күтәргәнгә, бераз алга бөкрәйгән, ачуы йөзенә үк чыккан ата, атылып, йортка да килеп керде.

– Кайда ул? – исәнлек-саулык сорашу да юк.

Раушан абый сорауны кире кагып азапланмады.

– Бездә, – дип җавап бирде.

– Чыгарыгыз монда!

– Нигә?

– Алып кайтып китәм.

– Ни бит, кода, бездә килгән киленнәрне кире бирә торган гадәт юк.

– Ничек юк?

– Менә шулай, юк.

– Бабай! – дип эндәште, ниһаять, тик кенә утырган Дәнәф. – Гөлия белән икәү шулай сөйләштек, мин аны сиңа кире тоттырып җибәрмим.

– Сөйләшкәнсез, – дип, өстәл янына килеп утырды Рашат абый, – унсигез-егерме яшь булса икән үзегезгә, ике тиле аларны уздыргансыз. Нишлибез инде хәзер?

– Нишлибез, дип... Туй итәбез инде, кода, тагын монда нишләп була?

– Нәрсә утырасың анда, посып, атаң тапмас дип уйладың мәллә, чык монда! – дип, мич артына карап, кызына эндәште.

Гөлия мыштым гына чыгып, ир канаты артына басты.

– Һе, кара моны, яклаучы тапкан!

– Әти, ачуланма, мин бу йорттан беркая китмим.

– Ярар, китмәсәң, – дип җавап бирде аңа Рашат абзый. – Кызый, кара аны, Раушан белән гомер буе ахириләр булып, дустанә яшәдем. Әгәр битемне кызартып, кода-кодагыйның зарлануын ишетәм икән, матри аны! – дип, йодрыгын селкеде.

– Аңладым, әти, зарланырлык итеп яшәмәм, – дип җавап бирде аңа ир канаты артыннан чыкмый гына кызы.

– Син, әйдә, кода, озаклап утырма монда, мин хәзер мулланы алып киләм, син бар, тиз генә кайтып, кодагыйны алып кил.

Рашат абый:

– Ие, мин киттем, озак тормам, – дип, ишектән чыгып китте.

Рашат абыйның дуылдап, капкадан кереп киткәнен күрше-тирә күреп калды. Шуңа күрә эш тапкан булып, кереп китмичә, капка төпләрендә таптана бирделәр. Кызык бит, ахыры ничек бетәр? Тик барып чыкмады, күршеләр көтеп, капка төпләрендә басып калдылар. Рашат абый капка аркылы чыкмыйча, кодасының бакчасы артыннан гына өенә кайтып китте.

Икенче көнне Гөлия чын хуҗабикә исәбендә авыл кибетенә килеп керде. Аның Дәнәфкә кияүгә чыгуы турында бар авыл хәбәрдар иде инде. Шул исәптән Илүзә дә. Яратмыйча, төксе чырай белән каршылады ул яшь киленне. Гөлия кәрзиненә кер порошогы, азык-төлек җыйды да кибетче каршына килеп басты.

– Күпне күтәргәнсең, сынмассыңмы соң? – дип, киная белән сорады кибетче хатын, аның күзенә карап.

Гөлия аның тел төбен аңлады.

– Борчылмагыз, сынмам.

– Минекен алдың.

– Минем кешенекенә кагылганым юк, үземә тиешлесен алдым.

– Ә бу юлы минеке иде.

– Юк, Илүзә апа, солдатка китеп бер ел үтүгә, синеке булудан туктаган иде инде ул.

– Мин бит алдандым.

– Ә мин менә алданмадым, егерме ел буе тик аны гына көттем.

Илүзә Дәнәфнең аныкы түгел икәненә тәмам ышанды, улмы соң хәзер бу яшь килен белән алыша ала, юк, билгеле. Буш өмет, нигә аның белән алданып яшәргә, ә яңа тормыш корам дисәң, авылда бетмәгән аның кебек ялгыз ирләр.

– Син бәхетле ит аны, яме, сеңлем.

– Итәрмен, Илүзә апа, рәхмәт, – дип, яшь килен кибеттән чыгып китте.

Бу минутларда Дәнәф белән әтисе тракторда үз җирләренә килеп туктаганнар иде инде.

– Ничек, әти, башлыйбызмы, Аллага тапшырып? – дип сорады малае, атасыннан.

– Әйдә, башлыйбыз, тик беренче буразнаны мин сызам, улым.

Дәнәф иңнәрен җыерды.

– Мин каршы түгел, әти, әйдә, утыр тракторга.

Раушан абый трактор кабинасына менеп утырды да сука төрәнен батырып, күптән ташландык хәлдә яткан басуны сөреп, кузгалып китте. Төрән артыннан кара җир кайтарылып кала. Дәнәф, иелеп, яңа сукаланган җирне учына алды да борынына китерде. Ипи исе килә, әчкелтем ис, сулавы рәхәт. Ул җирне кулы белән уып карады, җир көл кебек таралды да китте. Игелекле җир, озак еллар тик яткан, уңышны мул бирергә тиеш. Ул күтәрелеп, ераклаша башлаган тракторга карады, сука узып китүгә, кара җиргә дәррәү булып карга-чәүкә көтүе ябырылды. Суалчан чүплиләр. Хәтта карт козгын да, агач башыннан очып, җир өстенә төшкән. Яңа гына җир өстенә чыккан суалчанны сагынган, ахры, бик бирелеп чүпләнә. Ул арада Раушан абый әйләнеп тә килде. Трактордан төшеп, үзе сөргән җир өстендә йөреп алды, нигәдер сикереп карады, күңеле булып елмаеп та куйды.

– Менә шулай барса, бик яхшы, улым.

– Әти, бәлки тагын бер әйләнерсең.

Раушан абый, юк дип, башын селкеде.

– Юк, улым, хәзер барысы да синең кулда, җирне бозарсың дип, курыкмыйм. Миңа булды, бер утырып әйләндем, шул җитә, – диде дә авылга таба китте.

Дәнәф әтисен карашы белән озатып калды.

Басу юлы буйлап бабай кеше атлый. Ул, бер күтәрелеп, кояшка карый, бер болытларны күзәтеп ала, баш очыннан очып үткән карлыгачларга күз сала, юл буенда үсеп утырган чәчәкләрне дә игътибарсыз калдырмый. Дәнәф белеп тора, басу юлы буйлап атлаган атасы, табигать көндәлеген укып бара. Ул шушы туфракта туып, сугыш арты елларында, ачлы-туклы, ялан аяклы балачагын үткәргән. Шушы туфракта үз парын табып, гаиләсен корган. Шушы туфракта үз нигезен булдырып, балалар үстергән. Ашаган ашы, өстәлендәге ипие, эчкән суы да аның шушы туфрактан. Шуңа күрә табигать үзенең көндәлегенә бүген ни язган, шуны бер дә ялгышмый укый ала бабай кеше. Әйе, ул шушында туды, шушында яшәде, вакыты җиткәч шушы туфрак аны үз куенына алачак. Шушы ук туфракны ярата белгән,

кадерли белгән улына бүген, бер дә шикләнүсез, киләчәкне ышанып тапшырды бабай.

Дәнәф атасын озаткач, трактор кабинасына менеп утырды да, шушы ук туфракка беренче буразнасын сызып, кузгалып китте.

Покос аркылы атлап чыгыйм дип, Марат аягын гына күтәргән иде, кинәт үлән астыннан яшендәй атылып, кыр куяны килеп чыкты. Көтелмәгән хәлдән малай кычкырып җибәрде.

– Ай!

Комбайн янында кайнашкан Дәнәф, ялт итеп, улына таба борылып карады.

– Нәрсә булды, улым?

– Куян, әти! – дип җавап бирде аңа улы, көтелмәгән хәлдән исе китеп, – покос астында качып яткан, мин аны күрмәдем дә.

Дәнәф кеткелдәп көлеп куйды.

– Карабрак йөр, куян гына, димә, үзен яклый белә ул. Шөкер, быел ашлык уңды, покосларны атлап чыгарлык түгел.

– Әти, мин комбайн белән бер әйләнеп килим әле.

Тугызынчы класста укыган Марат атасы белән басуда инде беренче ел гына эшләми, комбайнны биш бармагы кебек белә. Шуңа Дәнәф улы кулына техниканы бер дә курыкмый тапшыра ала.

– Бар, мин бераз ял итеп алам.

Маратка шул гына кирәк тә, комбайн кабинасына очып менеп утырды да кузгалып та китте. Дәнәф, басу кырыена чыгып, каенга сөялеп утырды. Быел ашлык мул булды. Гөлия «ГАЗ» машинасы белән ташып кына тора, хатыны әйләнеп килгәнче бункер инде кабат тулып чыга. Көне кояшлы, өлгерерләр алар ашлыкны сугып бетерергә. Ул, күтәрелеп, авыл ягына таба карады. Басу юлыннан кулына зур сумка аскан бишенче каласста укучы икенче малае Рәис атлый. Сумкасында – әтисе белән абыйсы өчен төшке аш. Авыр булса да, малай зарланмый. Аннары аның төшке ашны илткән җиреннән кире кайтып китәргә бер дә исәбе юк, ул кичкә кадәр абыйсы, әтисе белән кыр корабында иген диңгезендә йөзәчәк. Бәлки әле аңа әтисе комбайнны йөртеп карарга да рөхсәт бирер. Әйе, билгеле, шулай булачак.

Дәнәф икенче малаен көтеп тора башлады. Шушы юлдан әтисе, туган туфракны аңа ышанып тапшырып кайтып китте. Шушы юлдан ук Дәнәфнең алмашчылары атлап килеп, тормышта беренче буразналарын сызалар. Әйе, билгеле, Дәнәф кече улы Рәискә комбайн белән идарә итәргә рөхсәт бирер. Малайга эшкә хөрмәт, җир кадерен сеңдерү өчен эшләр ул моны. Озак та үтмәс, әле бишектә генә яткан төпчеге дә үзенең тормышында беренче буразнасын сызар өчен шушы басу юлыннан атлап китәр. Ә Дәнәф, Раушан абый кебек, бер шикләнүсез, шушы туфракны дәвамчылары кулына тапшырып, өенә кайтып китәр. Башкача мөмкин түгел, чөнки бу мең еллар элек табигать көйләп куйган хәрәкәт. Мәңгелек хәрәкәт!



Рәсимә
Гарифуллина

# ШУЛ ИСЕМНЕ АКЛАП, АТЛАП КИЛӘМ...

## Гомер бер генә

Бер гомер  бирелгән кешегә,
Бер гомер – гөр килеп яшәргә.
Кирәксә, ут булып янарга,
Кирәксә, яшендәй яшьнәргә.

Бер гомер, бары тик бер генә,
Кадерле сиңа да, миңа да.
Шатлыгы-кайгысы – бербөтен,
Алмашы юк аның яңага.

Бер гомер сыйдырган барсын да:
Җил-давыл, яңгырын-буранын.
Сөюнең иң татлы мизгелен –
Гомергә бер килгән туйларын.

Сабыйлык, үсмерчак, яшьлекнең
Иң матур еллары бар анда.
Онытылмас минутлар булган ул –
Парлы чак, балалар туганда.

Барсын да кадерләп яшибез,
Тормышта сынмыйча, сыгылмый.
Рухы нык, көчлеләр җиңелми,
Чабышка барганда егылмый.

Сил бәрә язмышны, җил кайый,
Ихтыяр көчлеләр нык тора.
Алдагы уңышка чакырып,
Иҗатта туасы җыр тора.

---

Рәсимә ГАРИФУЛЛИНА (1957) *– шагыйрә; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Бүген ярат», «Яшәү мәңгелек», «Зәңгәр дуга» һ.б. китаплар авторы. Балык Бистәсендә яши.*

## Мин – бөртек

Мин – бер бөртек.
Бәлки, алма бөртегедер,
Бәлки, алтын бөртектер,
Бәлки, энҗе бөртегедер.
Сүнеп бетмәгән учакның
Бер бөртек күмередер.
Очкынлы күмередер...

Гади генә бөртекнең дә
Илаһи көче була –
Гаҗәеп көчле була.
Әмма гади бөртекләрдән –
Синең, минем кебекләрдән,
Алтындай башак тула.
...Бөртекләр төрле була.

Яшәеш серле шуңа.

## Җаннан җан ярала...

Бала туа – җаннан җан ярала...
Яңа кеше Җиргә аваз сала.
«Мин тудым!» – дип әрнеп елый-елый,
Бар җиһанга оран сала бала.

Кешелекнең иң серле һәм иң зур
Могҗизасы шушы: бала туа.
Елый-елый җиргә килә кеше,
Яшәр өчен дөнья куа-куа.

* * *

Кендек бавым, белмим, кем кискәндер,
Матур исем табып куйганнар.
Тәүге тапкыр каным качырганда
Зәңглә суы[1] белән юганнар.

Көмеш тәңкә салган тозлы суда
Бер чирканчык алган йөрәгем...
Белмәгәнмен кендек әбисенең:
«Әтиеңә якын бала бул», – дип,
Әткәм күлмәгенә төргәнен.

Авызландырганнар бал каптырып,
Аннан май тидереп иренгә.
Саның сау булсын дип, сөя- сөя,
Олы бәхет  сорап ил-көнгә.

Дога укып теләк теләгәннәр:
«Күңелең пакь, йөзең ак булсын!
Мул ризыклы һәм гомерле булсын,
Барыр юлы һәрчак яктырсын!»

Кендек әбиемә охшап, бәлки,
Мин аз сүзле булып туганмын.
Бал каптырып авызландырганга
Татлы, йомшак телле булганмын.

Йөрәгеннән чыккан моңы белән
Әнкәм бишек җыры көйләгән.
Бәби мунчасында юындырып,
Ак биләүгә мине биләгән.

Мин нарасый әле, яңа туган,
Дөнья мәшәкате күрмәгән.
Әтекәем талдан бишек үреп,
Тирбәтергә урын көйләгән.

Күчтәнәчләр килгән мине котлап,
Тәм-том менгән сыйлы табынга.
Әле берсе, икенчесе килгән...
Көн дә сыйлар кеше табылган.

Бала тапкан ана өзлекмәсен,
Кырык кылы башта ялгансын.
Авыр эшләр белән интекмәсен,
Бала карар өчен хәл алсын!

Җиде көннән кендек җебе төшкән,
Кендек күлмәге дә салынган.
Ул күлмәкне башка кимәгәнмен,
Затлы чәчәклесе табылган.

[1] Зәңглә суы кою – зәңглә авыруына каршы кан качыру. «Зәңглә, кач!»дип, яңа туган баланы, гадәттә, тал яки каен суы белән коендыралар.

Кендек күлмәк кисә гел елар дип,
Сандык төбенә үк салганнар.
Йоласы шул: йортта бала туса,
Ул күлмәкне кабат алганнар.

Үзем төпчек булгач, күлмәгемне
Кидерергә бала тумаган.
Әнкәм сандыгында сакланган ул,
Кендек бавым – биек чормада.

Мулла исем кушкан азан әйтеп:
Фәлән кызы Фәлән булырсың!
Кояш төсле якты йөзле бала,
Сый-нигъмәтле йортта торырсың.

Күркәм исем биргән, затлы исем,
Юраганы аның юш килгән.
Шул исемне аклап, атлап киләм
Гомер үзәненең түреннән.

## Кызлар җыры

Айлы төннең утлы күкрәге – күк.
Күк түбәсен бизи йолдызлар.
Төн пәрдәсен ярып кызлар җырлый.
...Ник моңлана икән бу кызлар?

Җанны айкый матур тавышлары,
Ерак төркиләрнең моңы бар.
Каян килә бу кадәрле сагыш,
Каян килә мондый моңлы зар?

Ак сәйләннән калфак чигә-чигә,
«Гөлҗамал»ны кызлар җырлыйлар.
Айлы төннең күчермәсе төсле –
Ак калфакта ай һәм йолдызлар.

«Гөлҗамал»ны көйләп җемелдиләр,
Моң сибәләр, гүя йолдызлар.
«Энҗе мәрҗән кызларның кул бавы»...
Кызлар булган җирдә сөю бар.

## Кыр казлары китә

Язын гына очып килгән казлар
Каңгылдаша кабат күкләрдә:
«Көзләр җитте, инде китеп барыш,
Җылы җәйләр кала үткәндә...»

Кыр казлары тагын юлга чыккан,
Саубуллашыр вакыт җиткән дә.
Чулмансуга каурый ташлый казлар,
Җылы якка очып киткәндә.

Билге итеп каурый ташлап китә,
Кайтыр юлларына төс итеп.
Хәерле юл теләп карап калам,
Вакыт тизлегенә ис китеп.

Күчмә кошлар оя алыштыра,
Күктә уйный казлар чылбыры.
Гомерләрне барлар вакыт икән,
Бер искәртү – киек каз җыры.

Озын юлда өзелмәсен генә,
Кайтыр юлларының чылбыры.
Кыйгак-кыйгак... казлар китеп бара,
Бер кисәтү – киек каз җыры.

Киек каз юлыннан килгән идем,
Килгән юлым күктә югалган.
Җиргә алып килгән юлларымны
Эзләп йөрим хәзер Чулманнан.

## Рәсем астындагы язу

Сагынганда бер карарсың әле,
Истәлегем булсын бу рәсем.
Күзләремдә сиңа таныш булган,
Бу тормышны сөйгән сурәтем.

Син булганга җылы минем күңел,
Өметләрем сүнми, мин яшим.
Туган җирдә калган газиземә
Истәлегем булсын бу рәсем.

## Бүләк...

Чит-читенә пар күгәрчен чигеп
Ак кулъяулык бүләк иттең син.
Кул җылыңны җан түремә салып,
Ил чигенә сакка киттем мин.

«Көт мине!» – дип, сагынып хәбәр салдым,
Еракლардан язган хатларда.
Чиккән кулъяулыкны алып карыйм
Бик күрәсем килгән чакларда.

«Көт!» – дидем дә, озак кайталмадым,
Ил сакларга киткән юлымнан.
Яралангач, дуслар табып алган
Кулъяулыкны, күкрәк турымнан.

Вәгъдә төсе итеп алган идем,
Ак кулъяулык канга буялды.
Солдат хезмәте ул – хәтәр хезмәт,
Туган якка юллар ураулы...

Иген иккән көчле кулларымда
Тук башаклар түгел, кораллар.
Туган якка таба кайта тора
Кайгы тутырылган олаулар...

## Яратмыйча яшәп булмый

Борчымыйча гына бер-беребезне,
Өйрәндек без аерым яшәргә.
Читенсенеп, телефоннан гына
Бәйрәмнәрдә котлап дәшәргә.

Ялгыз ятакларга ияләштек,
Парлы мендәрләрдә ятсак та.
Яңа очрашулар көтмибез без,
Сагыну-сагышларда янсак та.

Синең телдә хәзер ят исемнәр,
Син башкага сөеп карыйсың.
Әрем тәме килә мәхәббәттән.
Ничек түзим, чыдый алыйм соң?

Ияләштек кебек барсына да:
Очрашканда күрми китәргә.
Сөю тулы карашлардан качып,
Исәнләшми генә үтәргә.

Без дәшмибез, ә йөрәк кычкыра,
Бар көченә сине чакыра.
Хыяллардан китә барган саен,
Ераклашкан саен сагына.

Хыялларны җилгә очырдык шул,
Йөрәк тоташ яну-көюдә.
Ерагайган саен ашкынам мин,
Сыенасым килеп сөюгә.

Яратмыйча гына яшәп булмый,
Онытып булмый җирдә син барын.
...Бүген тагын телефоннан гына
Туган көнгә котлау юлладым.

Ияләшеп булмый яратмаска...

## Дуамал мәхәббәт

*(Баллада)*

Җил егете гашыйк булды кинәт,
Ак ромашка күреп юлында.
Алар сөюенә сокландылар
Барча матур гөлләр болында.

Җил-егетнең тәмам баш әйләнде –
Ак ромашка матур, хуш исле.
Иркәләде назлы тынын өреп,
Таҗларыннан сыйпап гел исте.

Мәхәббәттә тыйнак иде чәчәк –
Нәзакәтле генә яратты.
Җилнең сөюенә җавап итеп,
Тирә-якка хуш-ис таратты.

Җил талымсыз иде мәхәббәттә,
Теләктәшлек көтте хисләре.
Җилнең ярсуларын басалмады
Ромашканың хушбуй исләре.

Җил-егетнең дәрте кайнар иде,
Болын буйлап исте тилереп.
Ромашканың сабаклары сынды,
Давыллады ярсып, илереп.

Бик нәзберек иде сылу чәчәк,
Түзалмады җилнең көченә.
Давыл кочагыннан атылды ул
Болындагы үлән өстенә.

– Бар көчемне сиңа биреп истем,
Шашып сөйдем, шашып назладым.
Ник сыгылып төштең болай, гөлем,
Нигә сулды синең таҗларың?

Гөлне терелтәм дип иләс гашыйк
Ирек бирде ярсу хисенә.
Соңгы көчен җыеп әйтте чәчәк:
– Назлы иркәм булып ис кенә...

Мәхәббәтнең көче давыл түгел,
Ачы җилләр аны аямый.
Назларыңны сөеп бирү кирәк,
Чама белми ярсу ярамый.

Мәхәббәтнең көче илаһи зур,
Ташкын итә синең хисеңне.
Әгәр чынлап яратасың икән,
Сөю белән расла көчеңне!

Мәхәббәтен үтерде ул бүген,
Фаҗигасен соңлап аңлады.
Ни үкенеч, үзе харап итте,
Сөеклесен саклый алмады.

## Бер яну хакына

Аңлаша алмадык, нигәдер...
Сөюдә мин ялкын төслерәк.
Ныграк янам күк, бары тик
Хисләрем алгысак, көчлерәк.

Син йөргән юллардан күз алмыйм,
Каршыңа йөгереп чыгамын.
Күп юллар уздым мин эзеңнән,
Сүндерми өметем чырагын.

Бер сөю, бер яну хакына:
Яшим мин ышанып – өметтә.
Мин синнән аз гына тилерәк –
Килмисең көтми дә, көтеп тә...

Гомерем буена яратам,
Вакытлар сагышка дәвамы?
Кайда соң, кайчан соң очрашу?
Булырмы сөюнең җавабы?
Булырмы сөюнең дәвамы?

## Син минеке түгел...

Син минеке түгел, башканыкы,
Тик сөюдән тыя алмыйлар.
Шул кадәрле ерак һәм якын да,
Юллар гына сиңа бармыйлар.

Бер көч тә юк безне аерырдай,
Бер көч тә юк безне кушардай.
Ерактагы иң якыным минем,
Бер зат та юк сиңа охшардай.

Сулар һавам минем, тыным, көнем,
Яшәү көче биргән хыялым.
Син теләгем, син минеке – җанда.
...Хисләрем ташкынын тыямын.



Тәлгат
Галиуллин

# ТӨЕРЛЕ ПЫЛАУ

хикәя

Чир рөхсәт-мазар сорап тормыйча килә дә аяктан егып сала, дигән әйтемнең тормышчанлыгына үз башыма төшкәч, тулысынча ышанырга мәҗбүр булдым. Аның да әле инсульт (халыкта паралич) дигән зәхмәтлесе хастаханәгә үк китереп «салды». Аңыма килер-килмәс хәлемдә мине ул чорда «обком бульнисы» дип йөртелгән хастаханәгә, ике кешелек палатага кертеп урнаштырдылар. Беренче көннәрдә суымны алып биргән, кулыма кашык тоттырган күршем белгечлеге буенча элемтәче, шулай ук инсульт кичергән, үзен миңа караганда яхшырак хис иткән кеше булып чыкты.

Таныштык. Наил Җамалиев исемле икән. Ипле генә яши башладык шикелле. Берничә көннән соң күршем янына 14-15 яшьләрдәге улын һәм берничә яшькә кечерәк кызын ияртеп, хатыны килде. Мин аның өчен шатланып ук куйдым, димәк, кешенең тулы гаиләсе, кайгыртырдай якыннары бар. Әмма кара тут йөзле, уртача буйлы, тыйнак кына киенгән ханым ни сәбәптәндер, бурычка әйбер сорарга кергән теләнче кебек ире янына тартынып, һәр адымын санагандай, акрын гына якынлашты. Өчесе дә, бер-берсенә юл бирергә теләгәндәй, бүлмә ишеге янында тукталып-төртелеп калдылар. Чирле әтиләрен бимазалаудан читенсенәләрдер дип уйлап куйдым. Үз өстемә җаваплылык алып, аларга: «Түргәрәк узыгыз, нишләп ят кешеләрдәй бусага янында торасыз», – дип, сүз каттым. Дивар ягына борылып яткан күршем кунакларны күрмидер яисә йокыга киткәндер дип уйлап:

– Наил, тор, балаларың килгән, – дип өстәдем.

Минем эндәшүдән соң, ятагы кырыена торып утырган әтиләре янына балалары якынрак килеп, җиңелчә генә сыенуштылар да әниләренә урынны бушаткандай, читкәрәк китеп бастылар. Ханым кулындагы төргәген

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН (1938) – *язучы, тәнкыйтьче; филология фәннәре докторы. Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе. «Замана балалары», «Дәгъва», «Мәһдиев йолдызлыгы» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

урындыкка куеп, песи шикелле атлап, бик акрын гына ире янына килеп туктады.

– Хәлләрең ничек, Наил? Терелеп киләсеңме? Без бик борчылдык. Реанимациягә дә килгән идек, кертмәделәр.

Иркенләп күрешсеннәр, кочаклашсыннар, кирәк булса, пәп итешсеннәр дип, читкәрәк борылган идем, колакларыма теләсә кемне егып салырлык сүзләр килеп бәялде.

– Мин бит сиңа килеп, борчып йөрмәгез дип, кат-кат әйттем.

– Балалар әтине күрәсебез килә дип, теңкәмә тигәч алып килдем инде, – диде ханым, әллә каян еракта килгәндәй төксе, гаепле тавыш белән. – Мин үзем сине борчып йөрмәгән дә булыр идем. Кызың сине бик сагына, елый, төшемдә әтием башымнан сыйпады, чәчләремне рәтләп куйды, саташып беттем, – ди.

– Мин бит сиңа башка хатын янына китәм дип, кат-кат әйттем. Килде-китте төшләр сөйләп, нервымда уйнап йөрмәгез!

Ханым башка бер сүз әйтмичә, урындыктагы төргәген кулына алып, кая куярга белмичә уйланып, икеләнеп торганнан соң, минем якка борылып: «Абый, мин пылау пешереп алып килгән идем, сезгә калдырыйм әле», – диюгә, мин күз карашым белән генә тумбочкам өстенә күрсәттем. Бу адымымны хәзергәчә аңлата алмыйм. Ни өчен шулай, боламык кебек җебеп төшеп, чит ханымның төргәген алып калуымның сәбәбен тапмыйм. Чөнки ул «төерле» пылау булып чыкты. Иренең турсаеп ятып, ризыктан баш тартуын хупламасам да, арадашчы булырга ни хакым бар? Аң төпкелемә ана сөте белән кергән ашамлыкка ихтирам шуңа этәрдеме, әллә хатыны, балалары чыгып киткәч, Наил белән бергә утырып ашарбыз дип уйладыммы, билләһи дим, бу «сентиментальлегемне» һич кенә дә тәртәгә сыйдыра алмыйм.

Кинәт ашыгыч эше исенә төшкәндәй, тиз-тиз атлап, әүвәл ханым, аның артыннан ирлек горурлыгы уяна башлаганы сизелеп торган малае чыгып киттеләр. Кызы ишек янында туктап, ятагына җәелеп ятарга өлгергән әтисе ягына карлыгандай кара күзләре белән мәңгегә саубуллашкандай, гаҗизләнеп, томырылып карап калды. Аларда рәнҗү, өмет, ярату, гарьләнү, сагыш, үкенү – барысы бергә укмашкан иде. Инсультның бер үзенчәлеге – күңел йомшару, күз төбендә тулышып, һәрдаим тышка бәреп чыгарга әзер булып көтеп кенә торган тозлы күз яше.

Кыз ишеккә таба янә бер адым ясап, агач бусаганы атлап чыгарга да өлгермәде, бүлмәбезгә өермәдәй атылып, яшь, чибәр бер хатын-кыз заты килеп керде. Ул уяткан җилдән кыз бала егылып китә язгандай тоелды. Артыннан ишекне ябып тормыйча, керә-керешкә затлы җиңел көн пальтосын Наил караваты янындагы урындыкка ташлады да «привет, милый» дигән сүзләр авызыннан чыгып җиткәнче үк, ятагыннан күтәрелергә азапланган элемтәчене урынына төртеп яткырды, битеннән, күзләреннән, иреннәреннән шаша-шаша үбәргә тотынды. Күзебезгә акыл хуҗа, дип ышандырырга тырышсак та, кызыксыну (бәлки, нәфестер) хисе һәрнәрсәне җиңә икән. Күзләремнең оятсызланып, минем якка арты белән торып, ярым бөгелеп, Наилне иркәләгән хатынның озын төз аякларын, йомры арт санын күзәтүен тыя алмадым. Хәтта бер мизгелгә югары әхлаклы педагог

абзагыз теге нарасый турында да онытып җибәрә язды. Ишекне кайсыдыр ныклап ябып куйган икән. Ә монда бушлай тамаша дәвам итте. Авызлар бушаган мизгелләрдә: «Ты зачем так долго не звонил? Я потеряла всякое терпение, ведь я очень соскучилась по тебе, мой зайчик» кебек җөмләләр һавага эленә торды. «Я здесь больше оставаться не намерена, как ты обещал, мы срочно переезжаем в Москву. Ты ещё до болезни говорил, что тебе подыскали работу, квартиру пока снимем». Бу сүз тезмәләре артык примитив күренсәләр дә, аларның нигезендә мәхәббәт төтене – «фәлсәфи фикер» – элемтәчене тирәлегеннән, гаиләсеннән аерып алып китү нияте ятканы мөгез кебек алга чыгып тора иде.

Озакка сузылган үбешүдән, русчадан бурычка алынган җөмләләрдән соң, «шулай бит, матурым, китәбез дигәч китәбез» кебек татарча тәгъбирләргә дә урын табылды. Бүрәнә астында калган кешене хәтерләткән элемтәче, ясалма икәнлекләре артык төчелекләреннән аңкып торган аңлашуларны, бәйләнешсез җөмләләрне, ихлас, чын күңелдән дип кабул итә иде бугай.

Ниһаять, чакырылмаган кунагыбыз, үз бәясен белеп, Наил өстеннән акрын гына күтәрелде дә монда тагын бер бөҗәк бар икән, дигәндәй, минем якка күз салды. Ханым рәсемнән төшкән тере сын кебек чибәр иде. Озын буй, нечкә бил, төз аяклар, затлы иннек-кершәнне мул кабул иткән йөзкә тараеп төшкән бит дисеңме, җилкәсенә таратып салынган куе коңгырт чәчкә дәһшәти көч биреп, очкын чәчеп торган күзләр һәм бөтен гәүдәсенә, басып торышына иңгән серле эрелекне әйтәсеңме – һәммәсе урынында. Мондый һавалы тәкәбберлек ерактан килгән затлы нәсел дәвамчыларында яисә арка терәге нык, ышанычлы кешеләрдә генә була. Бу түтинең таянычы паралич кичергән элемтәче Җамалиев кына булмавында бер кәррә дә шигем калмаган иде.

Димәк, бу чибәркәйнең башка, кайсыдыр югарылыкта йөнтәс кулы бар. Үзләрен артык югары бәяләгән бәндәләр еш кына тәҗрибәсез беркатлы, артык ышанучан булалар һәм тормышның кырыс чынбарлыгына барып терәлгәч уалып төшәләр, югалып калалар, дип тә уйлап куйдым.

– Исәнмесез, – дигән, өстән минем карават дәрәҗәсенә төшкән сүз, чынбарлыкка кайтарып, айнытып җибәрде. Ханым бу сәламләүдән соң, карават кырыена утырып, йомры тезләрен минем игътибарга калдырып, янәдән русча-татарча шул ук сүзләрен кабатлый-кабатлый, яраткан шөгылен – элемтәчене ялавын дәвам иттерде. Мин әле аякка басмаган, бүлмәдән чыгып та китә алмыйм, икенче якка борылып кына ята беләм. Бичарадан ничара дигәндәй, берәүләрнең фаҗигасенең, икенченең сөенеченең шаһиты булып, бушлай тамаша кылам.

Үбешеп туйганнан соң, олы бурычын үтәгән кешедәй, ханым, «чао, милый»га кул изәвен кушып, истәлеккә кыйммәтле хушбуй исен калдырып, чыгып та китте. Рәнҗетелгән, кимсетелгән никахлы хатынынннан аермалы буларак, кунак кызының кулында төргәк-мазар юк, нәрсәдер күтәреп йөрү дәрәҗәсенә төшмәгән иде.

Ханым чыгып киткәч, андый очракларда булырга тиешле тынлыктан соң, мин сүз алдым.

– Минем тумбочка өстендә хатының сиңа күчтәнәч калдырды. Пылау

диде бугай. Ашап куябызмы? Минем тамагым тук булса да, тәмләп карый алам, – дидем.

– Юк, мин ачка үлсәм дә, аны ашамыйм. Алып калгансыз икән, үзегез сыйланыгыз, – дигән, тез астына китереп бәргән җавапны ишеткәч, ялган демократлыгым белән үземне нинди авыр хәлгә куйганымны бөтен гаҗизлеге белән тойдым. «Ризыктан өстен булырга ярамый» дигән ислам тәгълиматына хуҗаның исе дә китми, хатыны, балалары күтәреп килгән пылауга кагылырга да теләми. Мин дә башка кеше өчен пешерелгән тәгамны авыз тутырып ашап утыра алмыйм бит инде. Тамагым бик ач булса, бүлмәгә хуш ис таратып утырган пылауны капкалап та куйган булыр идем дә, гүр иясе хатыным Галия, авыр туфрагы җиңел булсын, һәр көнне иртәнге тугызга кайнар өй ризыгы алып килеп, мендәргә терәтеп утыртып, ашатып, савытларымны түгеп, чистартып китә торган иде.

– Соң, егетем, синең өчен махсус пешерелгән пылауны берүзем уртлап утыра алмыйм инде. Хатыным алып килгән пилмәнне күптән түгел генә ашап бетердем.

Инде дустым булмаса да, яхшы ук танышым – элемтәчем миңа тагын да катырак бәрелде.

– Алып калган вакытта нәрсә уйлагансыздыр, анысы миңа билгесез. Хатынымны ошаткансыз икән, ул хәзер иректә, рәхим итегез!

Мондый авыр гаепләүне ишеткәч, минем дә җен ачуларым чыкты, авырудан ныгып җитмәгән һөҗүмчән психлыгым уянды, нәрсә әйткәнемә җавап бирмәс дәрәҗәдә туарылдым.

– Мин, егетем, яшем, җәмгыятьтәге урыным белән дә синнән өлкәнрәк. Ни сөйләгәннәреңне чамалап әйт! Мин бу төргәкне хатыныңның хезмәтен, балаларыңны, аеруча куян баласы кебек ягымлы кызыңны кызганып алып калдым. Чибәр Гайшәне кулга төшердем, дөресрәге, аның җәтмәсенә эләктем дип кенә гаиләңә шулай миһербансыз булырга ярамый. Хатының да тыйнаклыгы белән миңа ошады. Ошау белән җенси азгынлыкны бутама.

Дөнья куласа, берәү дә кем кулында соңгы сулышын аласын белми. Әнә бит бөтен ил дөньясын онытып, ябырылып, телевизорның эченә керерлек булып караган «Язның унҗиде мизгеле» фильмының сценарий авторы Юлиан Семёновны паралич суккач, Германия дә, Израиль дә аякка бастыра алмагач, бай, исән вакытында типтереп яшәгән хатыннарына-сөяркәләренә килеп алырга тәкъдим иткәннәр. Барысы да баш тартканнар. Синең шикелле ташлап киткән беренче хатыны риза булып, карап, гомерен дә азмы-күпме озайтып, кадерләп соңгы юлга озаткан.

Элемтәченең мине чыгырдан чыгаруы шулчаклы көчле булды ахрысы, караватта яткан килеш мондый озын нотыкны гомеремдә тотканым юк иде. Хәтта Наил иптәш тә мине беренче кат күргәндәй, хөкүмәт мендәреннән башын күтәреп, гаҗәпләнеп, сәерсенеп тыңлады. Ә мин татарга акыл, нәкъ мәкальдәгечә, төштән соң кирә икән дип, үземне кызган табада «сикертә», тәрбияли башладым.

«Вәт шыр тиле, ахмак. Ни пычагыма кирәк иде сиңа ул үзбәк ризыгы, элемтәче төрттергәнчә, эчеңдә ач бүреләр улыймы, әллә ризыкның

тәмле исе борыныңны кытыклап, нәфесеңне тыя алмадыңмы? Кемгәдер яхшатланып, кемсәнеңдер җәберсетелгән, ташланган хатынын җәлләгән имеш, Саламторхан, буш демократ. Ирләрен янында тота алмаган мәхлук хатыннар буа буарлык. Хәләл җефете башкага күз салган икән, димәк ки, гаеп үзендә дә бар. Әлеге түти кебек урынына төртеп егып, шашып-шашып үбә, мәхәббәте турында сафсата сата, иркәли белмәгәндер. Сиңа нәрсә җитмәгән? Үз хәсрәтең генә азмыни? Әле үзең дә аягыңа баса, яраткан эшеңә кайта алырсыңмы? Ярым мәет булып хөкүмәт караватында аунап ятып, җимерелгән гаиләләр кайгысы белән чәбәләнергә булдыңмы?»

Үземне шул рухтарак шактый тәрбияләдем, уттан алып, салкын суга ташладым.

Шактый вакыт борын шәрифләрен (аңа бераз салкын тигән иде) шыгырдатып ятканнан соң, элемтәчем миңа тикмәгә шулай каты бәрелгәнен аңлады бугай.

– Гафу итегез инде, абый. Минем чыннан да ашыйсым килми. Элек пылауны бик ярата идем. Хәзер ул ризыктан биздем.

Шактый озак тоелган тын алыштан соң өстәп куйды:

– Бер җитди сәбәбе бар. Ул хакта соңрак.

Икебезне дә бизәмәгән әңгәмә алып барган мәлдә бүлмәгә даруларын, уколларын күтәреп, шәфкать туташыбыз килеп керде. Күк капусы ачылгандай булды, ми шәрифләрем: «Менә бит бер гаепсезгә кимсетелгән пылауга хуҗа», дип пышылдады. Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына, дигәннәре шулдыр инде.

– Гөлназ, тастымал белән төрелгән пыяла банкада бик тәмле (ашап караган кеше кебек) пылау. Шуны алып чыгып, кызлар белән безнең исәнлеккә тәмләп куегыз әле!

– Үзегез ник ашамыйсыз?

– Без тукландык инде. Зинһар, алыгыз, юкса бозыла башлар.

Шәфкать туташы, ялындырып тормыйча, дустан дошманга әйләнә башлаган төргәкне алып чыгып киткәч, өстемнән тау төшкәндәй булды.

Форсаттан файдаланып, шуны да искәртәсе килә: хастаханәләрдә эшләүче шәфкать туташларының күпчелеге Казан, Чистай, Минзәлә, Алабуга медицина көллиятләрендә укып чыккан итагатьле, ягымлы, чын татар гаиләсендә тәрбия алган кызлар. Хәтта башка милләт балалары да алар йогынтысына биреләләр. Халат кесәләренә «авыз тәмләтеп алырсыз», дип, алма, әфлисун, шоколад, груша ише вак-төякне салсаң да, мәгънәле елмаеп кабул итәләр. Бу үзенә күрә чирлене ихтирам итү, ә безнең яктан кылган игелекләре өчен рәхмәт әйтү кебек санала.

Ә элемтәченең мәхәббәт маҗарасы һәр көнне берүк сценарий буенча дәвам итте: яшь хатын, кичектермәс эшен башкарырга килгән кеше кебек ашыга-кабалана, бүлмәгә килеп керә, өске киемен урындык артына ташлап, Наилне ятагына төртеп яткырып үбә, иркәли башлый. Тулышкан яскынуын бастырганнан соң гына, бүлмәдә янә бер мәхлук аунап ятуын искә төшереп, минем якка, әллә кимсетүле, әллә кызганулы караш ташлап, нечкә иреннәре арасыннан «исәнмесез» сүзен кысып чыгара. Аннары сүз икесенең дә булган акчаларын җыеп, машиналарын сатып, Мәскәүдә торак

юнәтү мәсьәләсенә күчә. Беренче кәлимә шул ук: «Ты обещал, ты мужчина, должен сдержать свое слово!»

Аллаһы Тәгаләнең телевизор карый, концертларга йөри алмаган өчен миңа бушлай тамаша җибәрүе булгандыр, дисәң, кемнәр өчендер (әйтик, элемтәченең хатыны, балалары) биредә чын фаҗига төенләнеп ята.

Ханымның табигый һәм ясалма матурлыгын танырга мәҗбүр булган хәлдә дә, мин Наилне әгъвалаучыдан җитешсезлекләр, килешеп бетмәгән яклар эзли башладым. Борыныннан аска таба очлаеп киткән йөзе ниндидер кошнымы, җәнлекнеме хәтерләтеп тора. Үбешүдән туя белмәгән бәндәләр ягына тәнкыйди караш ташлагач, элемтәчем миңа козгынга җим дәрәҗәсенә төшкән яралы аккош булып күренде. Бу «табышым», ач карынга көчле хәмер эчкәндәй, бөтен барлыгымны җылытып җибәрде. Каян килеп керде соң әле бу козгын сурәте? Баш миенең исән калган сул ягы хуҗасына ярдәмгә килде. XX йөз башы татар шигъриятенең күренекле сүз остасы Дәрдемәнднең «Козгын» исемле, эчтәлеге, мәгънәви тирәнлеге белән һәр чорда заманча яңгыраган шигыре бар. Тиешле бәясен алмаган бу әсәр шагыйрь мирасында аерым урын тота. Хикмәт шунда: вакыйгалы сюжетны өнәмәгән, фикерен, хисен лирик кичереш аша чагылдыруга өстенлек биргән философ шагыйрь «Козгын»да әйтергә теләгән фикерен укучысына драма алымы – ике ерткыч җәнлекне «сөйләштерү» аша җиткерә. Тамагы ач козгынның ярдәм сорап мөрәҗәгать итүенә икенчесе: «Мин җим табамын», – ди һәм аны «Яшел тугайда алдап үтерелгән батыр» янына алып килә. Баксаң, анда бик күп козгыннарга җитәрлек азык ята икән. Кем ул егет, нинди язмыш аны шундый аяныч хәлгә төшергән?

Шагыйрь, детектив әсәрләргә хас төенләнеш үрнәгендә, үтерелүнең сәбәбен җәһәт кенә ачып салмый, киресенчә, «Кемдер егетне үтергән, Алган йөгерек атын...» дип, ярдәмче сәбәпне алга чыгарып, серне тирәнгәрәк яшерә. Хәзергечә әйтсәк, ялланган киллер яхшы атына хуҗа булу өчен генә батыр егетнең җанын алмагандыр. Алдагы юлларда фаҗиганең сәбәбе тирәндәрәк ятуы, яхшы уйланылган мәкергә барып тоташуы, иң якын булырга, киресенчә, егетне сакларга тиешле кешенең хыянәте нәтиҗәсендә тууы ачыла.

Нибары унике юлдан торган шигырь образлар бәйләменнән, сүз-сурәт байлыгыннан бигрәк адәми затның табигатьтәге иң миһербансыз ерткычлардан да явызрак була алуын искә төшерә.

Шигырь тәэсирендә мин, чит язмышларга бәя бирергә хакым юклыгы турында онытыбрак җибәреп, элемтәчегә киңәшләремне биреп маташтым.

– Бар мал-мөлкәтеңне үз исеменә яздырганнан соң, «җимешең» (бу сүзгә көчле басым ясадым) «мин яшь, мин чибәр» дип, синнән йөз чөереп, урамга куып чыгарса яисә «Козгын»дагы ханым кебек, заманча әйтсәк, киллер яллап, үзеңнән котылу юлын сайласа, нихәл итәрсең? Гаиләңне ташлап, ашыкмыйсыңмы, егетем?

Әлбәттә, мин көтелгән саллы җавап та алдым.

– Абзый, сез тормыштан, заманча яшәүдән артта калып барасыз. Кешеләрне берьяклы, китапча бәялисез. Без бер-беребезне үлеп яратабыз. Регинамның вак-төяк мавыгулары булгаласа да, ул миңа чаклы берәүне дә яратмаган. Мин аны очратканчы, үземне никчёмный кешегә санап йөри

идем, хәзер ачылып киткәндәй булдым. Чиремне тиз җиңүемдә (минем тарафка мыскыллы карашын уйнатып алды) мәхәббәтем төп таянычым булды. Сез: «әгәр ташласа, нишләрсең», – дип сорыйсыз. Андый хәлләргә төшкәнче, мин аның рәхәтен татып, сихри бишектә тибрәлеп калам әле. Андый сылу гәүдәне яратмыйча буламы соң?

– Бераз тыйнаграк кыланса да, зарар итмәс иде, – дип мыгырдануым янган учакка коры утын өстәү генә булды.

– Ә ни өчен матурлыкны яшереп торырга? Кәкре йә артык нечкә аяклы хатын-кыз гына җитешсезлеген ирләр чалбарына яшерә. Минем җимешем рәхәтләнеп, тар итәк, төрле төстәге колготкалар киеп, битенә, күз төпләренә кыйммәтле майлар сөртеп, үзен һәм дөньяны бизәп яши беләм. Көнбатыш илләре ни өчен шулай алга киткән? Алар им-томга, гайбәткә, катып калган әхлак кануннарына ябышып ятмыйлар, үзләре теләгәнчә яшиләр.

Минем «ну-ну» дип, исән кулым белән тимер караватартына тотынып, дивар ягына борылып ятудан башка юлым калмаган иде. «Моралист абзый» белән төнге бәхәсне дәвам итүнең мәгънәсе юклыкны икебез дә аңладык.

Таякка һәм диварга таянып, бүлмәдән чыгып йөри башлагач, чибәр ханым килеп керүгә, коридорга юл ала торган булдым. Анда да дөньяви мәшәкатьләрдән котылып булмый икән. Коридорның безгә якын башында утыручы апаныңмы, сеңелнеңме уфтануы, ыңгырашуы колагыма чалынды. Ханым миңа таныш булып күренде. Бәрәч, бу элемтәче Наил балаларының анасы түгелме соң? Ул җыйнак гәүдәсе, тыйнаклыгы, бигрәк тә бохар мәчесенеке кебек куе күгелҗем күзләре белән хәтеремә кереп калган иде. Иренең кырыс мөнәсәбәте, көндәше белән очрашасы килмәве аркасындамы, ул шулай ишек төбендә йөренеп торырга мәҗбүр икән. Башка берәү булсамы, «Мин аның законлы хатыны!» дип, Наилнең җимешен бүлмәдән пыркылдатып куып чыгарыр, чәчләрен йолкып бетерер иде. Чын татар хатыны шул.

Иң гадәти әхлак кагыйдәсе буенча тынлыкны мин бозарга тиеш идем.

– Исәнмесез! Хәлләрегез ничек, балаларыгыз сау-сәламәтме?

– Аллага шөкер! Барыбыз да исән-имин. Менә авыл тавыгы белән бәрәңге кыздырып алып килгән идем. Кызым җылый-җылый, «Әнием, бик тәмле булган, этигә дә илтеп кайт, син бармасаң, үзем чыгып китәм», – дип, тәмам теңкәмә тиде. «Аптыраган үрдәк арты белән суга чумган», дигән шикелле, риза булдым да хәзер бүлмәгезгә керергә базмый йөрим. Шул зәхмәте алдында түбәнсенәсем килми. Теге көнне иремнең гаиләсен чит-ят кешеләрдәй кабул итүе йөрәккә тиде, рәнҗетте... Сау булыгыз дип тә әйтмәде. Ярый, мине якын итми, мәхәббәт узды, ди, ә балалары, балалары... Аларның ни гөнаһлары бар? Шулайдыр бит? – дип, ханым мине дә «почмакка» китереп кысты.

Иренә алып килгән ризыкны янәдән минем аша тапшыру теләге барын сөрмә күзләреннән «укып», сүзне башкага күчермәкче булып, сорау бирдем:

– Наилең бу ханымның кармагына күптәннән каптымы соң? Балаларына да этинең иң кирәк вакыты, – дип, беренче соравымның урынсызрак яңгырашын аз булса да, шомарту нияте белән акыл сатып алу юлына төштем. – Минем аңлавымча, кызы этисен бик ярата. Улың үзен ирләрчә тота, мескенләнми, ялынмый.

Ханым балаларына бәямне читтә калдырып, җавап божрасына беренче соравымны алды.

– Өйдән киткәненә өч ай. Теге нәмәстәкәйнең фатирына күчте дә үзенә инсульт булды. Паспорты буенча ул бездә торган булып санала, табигый ки, больницадан өйгә шалтыраттылар. Шуңа гына килгән идек ул көнне. Явыз чиргә таргач, күңеле йомшарыр дип уйлаган идем. Зәхмәте моңа теше-тырнагы белән ябышкан. Байлыгын алып бетергәч, үзен чыгарып ташлар әле. Соңыннан барыбер балалары кулына калачак, шуны аңламый. Минем күңелем катты. Үзен яратсам да, гафу итә алмам шикелле. Сукыр мәхәббәтемә күзләр куелгандай булды, – диде дә ханым, өерелеп килгән хисен тыя алмыйча елап ук җибәрде. Аның фикерләү рәвеше, татарча матур итеп сөйләве мине гаҗәпләндерде. Шул хакта соравыма ул: «Мин әүвәл татарча педучилище тәмамладым, аннан соң химия-технология институтында белем алдым», – дип җавап бирде яшьләрен сабыйлар шикелле йодрыгы белән сөртә-сөртә.

Язучы һәм әле генә дөнья мәшәкатьләре белән кызыксына башлаган кеше буларак, Наилнең бу Гайшәне каян, ничек табуы, мөнәсәбәтләренең ни дәрәҗәдә җитдилеге, тирәнлеге турында беләсем килү эчтән кымтырыклап торса да, шул мәүзугъка килеп чыгачагыбызны җиденче тоемым белән сиземләп, үземне тыеп кала алдым. Кеше дигән бөек затның кем беләндер серен уртаклашасы, минем кебек тыңлаучы булганда, эчен бушатасы килүен аңлау өчен дипломлы психолог булуның кирәге юк иде. Ханымның рухи халәте шундыйрак, бугазыннан буып алган хәсрәтен чыгарып ташлыйсы килүе, кинәт битенә бәреп чыккан кызгылт тимгелләр буенча сизелеп тора иде. Бераз икеләнеп алгандай булды да яныма ук утырып, тормыш йомгагын, ачы тәҗрибәсен сүтүне дәвам иттерде. Су буаны бер тишеп чыкса, аны тиз генә туктату турында хыялланма.

– Шәһәр элемтә бүлегендә яхшы гына эшләгән Наилне Казанның бай ширкәтенә белгечлеге буенча эшкә чакырдылар. Элемтәчеләр бит болай да нефтьчеләр, газовиклар, электр белән эш итүчеләрдән һәм түрәләрдән кала иң югары хезмәт хакы алучылар. Өйгә яңа җиһазлар кайтардык, күн тышлы диван, кәнәфиләр алдык, барыбызга да затлы киемнәр юнәттек. Царицино бистәсендә күптәннән төзи башлаган коттеджның очына чыктык. Кыскасы, тормышыбыз тәмам рәтләнеп, кешечә яши башлагач кына, беркөнне эштән кайтсам, фатирыбызга угры кергәндәй, һәрнәрсәнең асты-өскә килгән. Шактый аптырап, аңымны югалткандай утыргач, өнемә килеп, Наилгә шалтыратыйм дип, телефон янына барганда, өстәл өстендә кош теле хәтле генә язу күрдем, кат-кат укыгач кына, хатның эчтәлегенә төшендем. «Рәмзия! Мин башка хатынны яраттым, аның янына күчеп китәм. Фатир сезгә кала, теге йорт үземә. Син акыллы хатын, аңларсың, тавыш күтәреп, кеше көлдереп йөрмәссең дип ышанам. Наил».

Яшь балаларыбыз хакына, горурлыгымны җиңеп, иремнең кесә телефонына шалтыратып, «нәрсә булды, җинаятьче кебек чыгып качкансың, кешечә аңлашып аерылышып булмый идеме?» дип сөйләшеп алмакчы идем, җавап бирмәде, телефонын сүндереп куйганмы, башка номерга алыштырганмы, ул хәтлесен аңларга башым җитмәде. Сулкылдауларын басарга тырышып, чигәләремне ике яклап кулларым белән тотып,

уйга чумдым. Шундый хәтәр мизгелләрдә ми үзенең йоклап яткан мөмкинлекләрен эшкә җигә икән. Шулай ярым миңгерәп утырганда, Наилнең күлмәген юарга салганда, күкрәк кесәсеннән чыккан, ул вакытта бик гадәти күренгән бер хат кисәге искә төште. «Наиль, сегодня тебя не смогла увидеть, с работы не отпустили, вечерком брякни домой. Регина», дип язылган иде анда. Эше буенча берәр танышы яисә Самарада институтта бергә укыган сабакташы дип уйлап, игътибар итмәгән идем бу язмага. Шунда миңа эчке тоемым Регина атлы ханымны эзләп табарга дигән «киңәшен» бирде. Бу көнчелек булдымы, әллә мине кемгә алыштырган икән дип кызыксыну гына идеме, киттем ирем эшләгән ширкәткә. Анда керү, кеше турында ниндидер мәгълүмат алу сират күперен кичкәннән дә хәтәррәк булып чыкты. Баласы бик каты чирләп китте, әтиләрен эзләп килдем, телефонын алмый дип, паспорттагы тамгаларны тикшергәч кенә, эчкә үткәрделәр. Өлкәнрәк яшьтәге каравылчыдан «минем әле монда Регина исемле туганнан туган сеңлем эшли, аны да күреп чыгармын дигән идем», дип шомартуым тиз генә нәтиҗә бирмәде. «Монда меңләгән хатын-кыз арасында Региналар бик күп, татар бит шундый, бер исемгә ябышса, бер төсле кычкырган дивана күке кебек, башка матур исемнәрне оныта», – дип, акыл сатарга ярата торган, күп сүзле абзый булып чыкты. Башка мөмкинлек күрмәү сәбәпле, җыйнак кына сакаллы каравылчыга, үзем күзаллаганча юнәлеш бирергә тырыштым. Наилнең гади эшче, ашханә хезмәткәре белән бәйләнмәячәген чамалап, «Сеңлем бик чибәр, каядыр контора, кадрлар бүлеге, бухгалтерия тирәсендә хезмәт итәргә тиеш, бүген аны туган көнемә чакырмакчы идем», – дип, үзем ышанырлык итеп ялганларга керештем.

– Иң югары түрәләрнең секретаремы, тагын кемедер булып эшләүчедер, бер Регина бар. Тик ул озын буйлы, сиңа бөтенләй охшамаган, – диде абзый, буемны үлчәп карагандай, кечкенә күзләре белән мине үтәли сөзеп карап. Мин икенче кат мәкергә, алдашуга барырга җөрьәт иттем.

– Без аның белән бөтенләй бер-беребезгә охшамаганбыз. Чөнки без кодачалар, – дип, тагын нәрсәдер өстәмәкче идем, бәйләнчек кигәвенне кугандай, абзыем өч катлы зиннәтле йортка төртеп күрсәтте дә икенче якка ук борылып китте. Каравылчы күрсәткән бинаның беренче катында, шул ук сораулар белән җыештыручы хатынга мөрәҗәгать иттем. Белгәнен кем беләндер уртаклашасы килгәнен яшермәгән татар апасы, сөйләгәннәрне тыңлап, иремнең мине кемгә алыштырганын белгәч, гарьлектән күз алларым караңгыланып китте, аның артыннан үзем дә пычрак базга тәгәрәп төшкәндәй булдым. Шул ук хатынның аңлатуынча, Регина Хәйруллина дигән чибәр ханым ширкәтнең башында торучы егетләрнең берсенең сәркатибе саналып, чынлыкта аларга ашарга әзерләп, башка барлык ихтыяҗларын канәгатьләндереп торырга тиеш булган, бу җәһәттән аның вазифалары чикләнмәгән икән. Кызый күпне белә, таләп итә башлагач, аңардан иплегенә котылу әмәлен эзли башлыйлар һәм аны бу мәсьәләдә тәҗрибәсез, талымсыз, боламык Наил белән таныштыралар. Элек мондый давыллы, оста ханымны күрмәгән өй тавыгы тәмам изрәп, чын-чынлап гашыйк була.

Әлбәттә инде, минем иремнән сөйрәлчекләренең ни-нәрсә белән шөгыльләнгәнен яшерәләр, кәгазь эшләрен белә, гаять таләпчән сәркатип

дип, күкләргә чөеп мактыйлар, үзебезнең аны читкә җибәрәсебез килмәсә дә, ул гашыйк булдым, гаилә корып җибәрер, балалар үстерер вакытым җитте, мине тоткарламагыз дип, безне ышандырды. Кешенең бәхетенә аяк чалырга хакыбыз юк, дигәннәр, имеш. Шул ук хатынның курка-курка, мәгәр гаепләп, әрнеп сөйләвенә караганда, бу бай егетләр «сәркатиплеккә» конкурс белән яшь, ышанучан кызларны сайлап алып, зур эш хакы түләп, фатирлар биреп, берничә елдан соң, үзләрен туйдыргач, аны шул рәвешле, борынгы алпавытлар кебек кияүгә бирәләр. Гаҗәеп, тирән уйланылган мәкер, сарык та исән, бүре дә тук.

Үзен чир бәреп екканчы ук, Наил коттеджын, машинасын сатып җибәргән бугай. Мәскәүдә фатир юнәтеп, шунда күчеп китмәкчеләр.

– Башкалада нәрсә белән шөгыльләнмәкче була икән ул?

– Ширкәт егетләре әлеге сагыздан коткарган өчен рәхмәт йөзеннән, Мәскәүгә чыгып, белгечлеге буенча эш тапканнар, дип ишеттем.

Ханым сөйләгән маҗаралы вакыйга-хәлләргә ышаныргамы, юкмы, көнчелек хисенә бирелеп, үзе генә уйлап чыгармаганмы дип икеләнеп, шул ук вакытта авырткан башка тимер таяк кебек килеп төшкән бу мәгълүматлар миңа ни пычагыма кирәк инде дип, үземне битәрләп торган мәлдә ханымның теге көндәге шикелле алып килгән ризыгын миңа тапшырып китәргә җыенуын сиздем.

– Сез моны алыгыз әле? Рәхәтләнеп бергә ашарсыз, кызым хаклы, чыннан да, кетердәп, авызда эреп тора.

Бу юлы абзагыз, селәгәен агызып, җебеп төшмәде: ризык тәменә дә, борын тишекләреннән үтеп, ихтыярын кипкән камыш кебек сындырырга ирек куймады.

– Рәхмәт, ханым, үзегез кертеп бирегез. Бер кулым начар тота, йә төшереп җибәрермен. Үз хатыным китергән мантыйны да ашап бетерә алганым юк. Теге юлы сезнең пылауны кызларга бирдем.

Соңгы җөмләмә ханым батып баручы саламга ябышкандай тотынды.

– Карагыз әле, бу бит шәп идея. Мин дә сестраларга калдырам да, кызым сораса, «әтиең ашады», диярмен. Алдый алсам сабыемны.

Әйләнеп торган көпчәккә эләккән тиен кебек бәргәләнгән хатынны шунда калдырып, бүлмәмә кереп китү ягын карадым. Ятып торасым да килә башлаган иде.

Ашыкмыйча гына булса да, көн артыннан көн уза торды, акрынлап «пылау фетнәсе» тудырган киеренкелектән арынып, бераз тынычлангач, элемтәче күршем белән кешеләрчә аралаша башладык. Олы мәхәббәтемне таптым дип әтәчләнсә дә, аңа да җиңел түгелдер, нинди генә таш йөрәкле кеше дә психик яктан кагыйдәгә сыешлы акылы, хисе булса, балаларын ташламый. Вакыт күп, дәрескә соңга калам дип кабаланасы юк, Наил белән тормыш, адәм баласының язмышы, бездән берәр нәрсә торгандай, татар халкының киләчәге турында сөйләшүләребез шактый булды. Яңа хатыны белән ничек танышуы, аның кем булуы турында җәелеп китеп, мәхәббәт көймәсен селкетәсе килми егетнең. Минем дә белгәнемне ачып салырга хакым юклык аңлашыла булыр.

– Дустым, синең беренче хатының сабыр, итагатьле, акыллы күренә, үзен яратмасаң, балаларың өчен булса да түзәргә, ә җимешеңне (ул аны

шулай гына атый) болай гына «чеметкәләп» йөрергә идең. Гашыйк булган саен хатын алыштырган ирләр сирәк. Андыйларны рәсемдә генә сакланган динозаврлар шикелле кабул итәләр безнең заманда. Үткән гасырның бөек артистларыбызның берсе нәрсә дигән: «Кайсыбыз гына катыннар белән йөрмәгән дә, кайсыбыз гына аны кайтып, катынына сүләгән инде».

– Юк, абзый, мин алай булдыра алмыйм. Дөресе, болай гына очрашып-яратышып йөрүгә ул риза булмады, өйләнү, бергә тору шартын куйды. Мин өйләнергә вәгъдәләр биреп ташладым. Регина эшкә чумган, берәү белән дә буталмаган, мин аны беренче күрүдә үк унҗиде яшьлек егет кебек «втюрился».

Артыгын ычкындырып ташлаганын аңлап, элемтәчем шып туктап калды, мин дә телем бәйдән ычкынып китмәсен, дип, аны аркылыга тешләп, сүз елгасын башкарак агымга күчердем. Гамлетның бөтен дөньяны кубызында биеткән «to be or not to be» кәлимәсе кебек безнең дә очына чыгып җитмәгән «пылау мәсьәләсе» бар иде бит әле.

– Теге көнне пылауны ашаудан баш тартуыңны тәки аңламый калдым. Синең борын чөюең аркасында мин дә ризыкны авыз итмичә калдым.

– Алдыгызда торды. Ашарга идегез!

– Һм...

– Минем аңа кагылмавымның җитди сәбәбе бар.

– Барыбер үзеңне аштан өстен куярга ярамый.

Ул бу абзыйга ачылыргамы, әллә кабык эчендә калыргамы дигән төсле, янәдән икеләнеп торганнан соң, миңа шактый көлке тоелган серен уйдырып салды.

– Пылау пешерүченең, ягъни минем хатынның им-том белән шөгыльләнүче таныш чуваш карчыгы бар. Регинаны ташлатып, кире янына кайтарыр өчен өшкертеп китергән булу ихтималы бар иде. Рәмзия барысын да булдыра. Пылауны бик яратсам да, үземне тыеп кала алдым.

Мин үзем андый хорафатларга, им-томнарга, сихерче карчыкларга ышанмый торган кеше буларак, Наилнең мондый юрамасын шик астына алдым.

– Син шул әкияти юк-барга ышанасыңмы, замана баласы? – дип белдерүемә ул:

– Шуның аша узган кеше буларак, үземне сакларга тырышам. Биш-алты ел элек башка хатын янына китәргә җыенгач, «кичке ашны соңгы тапкыр бергә утырып ашыйк та, аннары дүрт ягың кыйбла», – дип алдады. Йөз грамм салып, җылынып киткәч, кунарга өйдә калдым. Иртәгесен шашынып, дөньямны онытып яратып йөргән теге чибәр ханым миңа мунча пәрие булып күренә башлады, – диде элемтәчем.

Беренче хатыны Рәмзия аны боламык, өй тавыгы, ди, ә ул шактый «эзләнүчән», тынгысыз, көнбатыш әхлагы беләнрәк яши торган кеше икән. Егетнең интеллекты тирән түгеллеген чамалап, мишәрең әйтмешли, берцәк акыл сатырга булдым.

– Син үзең тиктормас кеше икәнсең. Гомер буе мәхәббәт нурында коенып кына яшәп булмый. Минем туган авылым Кычытканлының философы Әбелгаяз абый «хатын беренче айда гына чәчәк, гомернең калган өлешендә тигәнәк», ди торган иде. Без бит бал корты кебек чәчәктән чәчәккә сикереп

йөри алмыйбыз. Тигәнәкне дә үзеңә җайлаштырырга, аның файдалы ягын таба белергә кирәк.

Ачылып киткән Наилнең кемгәдер эч серләрен сөйлисе килүен сизеп, сорау бирмәдем.

– Беренче ялгышуымда Рәмзия үзе гаепле. Дәртем уянганда, үзенә җибәрми интектерде. Йә арыдым, йә теләгем юк, йә синең өчен бала алдырырга йөрисем калмаган дип, үзеннән биздерде. Бер дустыма

– Синең хатының да шулай интектерәме? дип зарланган идем.

– Мин андый хатынны акылга утыртуның әмәлен беләм, – димәсенме бу.

Мине дә өйрәтмәссеңме дип сорагач, ул шунда ук:

– Бүген кичкә мин кунакка чакырулы. Бергә барабыз, – диде.

– Нинди мәҗлес ул? Ире нәрсә әйтер? – дим.

– Хуҗабикә – тол ханым. Аерылган.

Шампан шәрабы, чәчәк букеты, конфет тартмалары күтәреп кергән кунакларны җылы каршы алдылар.

Берсенең дә ире юк. Икебезгә җиде хатын. Әүвәл мәҗлес оештырган җаваплы кешене котладык. Үзләрен ташлап киткән ирләрен гаепләп, хурлап туйгач, җырлый, бии башладылар. Авылларда иң өлгер әтәчләр кычкыра башлаган вакытта гына таралыштык. Хуҗабикә «өстәлләрне урыннарына куясы бар» дип, мине җибәрмәде. Кунакларны озатып, ханым куеныма килеп кергәч, эш турында оныттык.

Агач – җимешеннән, адәм кыланышыннан беленә, ди халкыбыз. Элемтәчем шул хәлләре турында сөйләгәч, мин хәтта аның «җимеше» – Регинаны да кызганыр дәрәҗәгә җиттем. Хәер, иш ишен табар, дигән әйтем дә бар бит әле мәгърур телебездә.

Икенче көнне элемтәчемне, кулына «выписан с выздоровлением» дигән кәгазь тоттырып, хастаханәдән чыгарып җибәрделәр. Тәрәзәмнән чыгу капкасы күренмәсә дә, аны каршы алырга балалары белән никахлы хатыны да, затлы машинада Регинасы да килгәнлеккә шигем юк иде. Наилнең кемгә ияреп киткәнен сизенсәм дә, җаваплылыкны һәм гөнаһын өстемә аласым килми...

Шул көннән соң ошбу хикәямдә бәян иткән каһарманнарымның берсен дә очратмадым. Инде Җамалиевның улы да, кызы да үсеп җитеп, үз гаиләләрен корып җибәргәннәрдер. «Элемтәче мәхәббәте» исемле бәянымның чишелеше дә, бетеме дә юк. Ул – ирексездән шаһит булган бер вакыйга, кем өчендер фаҗига, кемгәдер күңелле вакыт уздыру турындагы гадәти язма гына. Нәтиҗә ясауны да укучының үзенә калдырам.



*Социаль челтәрләрдәге шигырь сәхифәләрен барлаганда, кайчак кызыклы гына табышлары булган шигъри әсәрләргә дә юлыгып куясың. Балтач районының Көшкәтбаш авылы тумасы, 1990 елның 30 ноябрендә дөньяга килгән Зөһрә Рамазанова шигырьләрен күздән кичергәндә дә, башымнан шул уй йөгереп узды: «Хәтта тигез вәзенне сындыручы ритм чатаклыкларына тиклем шигырь булып җырлый». Баксаң, Зөһрә инде башлангыч сыйныфларда укыганда ук, шагыйрә булырга хыялланган, дәфтәр битләреннән китапчыклар төзеп, шуларга үзенең дүртьюллыкларын язып уйнаган, соңрак мәктәпнең «Шигъри тәлгәшләр» әдәби түгәрәгенә йөргән, шигырьләрен район газетасы битләрендә бастырган, 2015 елда хәтта «Бәхет төсе» исемле шәхси җыентыгын бастырып чыгаруга да ирешкән. Шигърияткә мәхәббәт уятуда ул татар теле һәм әдәбияты укытучысы Лилия Мөнир кызына чиксез рәхмәтләрен җиткерә. Ләкин, ул кечкенәдән иҗатка тартылса да, тормышын икътисадчы һөнәре белән бәйли. Әүвәл Казан банк мәктәбен, аннан КНИТУның икътисад бүлеген тәмамлап, район үзәгенә кайтып, эшкә урнаша.*

**Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ**

Зөһрә Рамазанова

# КӨН САЕН ДЕЖАВЮ...

## Гает алдыннан

Төн йокламый әнкәй камыр баса,
Бисмилласын әйтеп, җай саен...
Кичтән тәмамлаган бөтен эшен,
Хәстәрләгән онын, ак маен.

Мамык кебек төтен күтәрелә
Бәйрәм рухы иңгән һавага.
Агач кашыгыннан җайлап кына
Камыр төшә кызган табага.

Шул арада чәе кайнап чыга,
Чыжлап тора зур-зур табалар.
Пешеп чыккан коймак өсләрендә
Эрегән майлар гына чабалар.

Газиз әнкәй! Таң тууга бүген
Караядыр ап-ак мичләрең...
Читтә булып, тойган кебек булам
Мичтә пешкән коймак исләрен.

## Әбиемне сагынганда

Сөт өстедәй ак яулыгың ябып,
Күмер кебек кара чәчләреңә,
Шундый ачык, гүя кичә кебек,
Төшәсең син минем исләремә...

Маңгаеңнан нәкъ урталай ярып,
Җәһәт кенә чәчең тарый идең...
Азрак үреп төшкәч, толымыңа
Матур алсу тасма ялгый идең...

Кара чәчең калын толымнарга
Әйләнә дә, төшә билгә чаклы...
Шундый тасма күргән саен һаман
Күз алдыма килә балачагым...

Калын чәчең сере нидә булган?!
Шампунь юк ла, аны син белмәдең.
«Башларымның авыртканын ала
Бары әче суым», – дияр идең.

Чәчләремне үстерәсем килә
һәм үрәсе, нәкъ синеке кебек.
Танышлардан үртәтәсе килә:
«Нәгыймәнең пәрәмәче» диеп!

Үпкәләмәс идем, мактау итеп
Кабул итәр идем шушы сүзне.
Түгәрәк йөз, кара чәчләр уртак,
Охшатканнар икән икебезне.

Сөт өстедәй ак яулыгың каплап
Күмер төсле чәчең өсләренә...
Сагындырдың, әби! Күп сорамыйм,
Керче бары бер кич төшләремә...

***

Ә кызым таганда атына...
Күкләрне гизәргә талпына.
Шундый киң уйлары сабыйның,
Сыядыр җиһанга чак кына...

Менә ул сикереп менгән дә
Туздыра мамыктай болытны.
Ә безнең күңелләр бигрәк тиз
Эчкерсез хыялын онытты.

Без дә бит кояшка талпындык,
Шомыртның очына үрмәләп,
Сиртмәле карават өстеннән
Күренер күк булган бар галәм.

Салават күперен сәпиткә
Атланып үтмәкче идек лә,
Балачак иленнән кителгән
Күз ачып йомарлык тизлектә.

Гел җиргә төбәлгән карашны
Күкләргә ташлыймын тын гына.
Кысага күнеккән хыяллар
Ирекккә чыгалар, йа Хода!

Ә кызым таганда атына...

***

Сөйләмә.
Сүзләр күп, ни мәгънә
Аларны болгатып уйнаудан?!
Буш сүзләр, буш күзләр, буш йөзләр –
Дөньяның өлгесе югалган.

Югалган кыйбласы җиһанның,
Кем идек, кем булдык? Әйт әле?!
Намусын сатканнар – сатсыннар,
Сатылмый калганнар җитәрлек.

Уйлама!
Уйласаң, хушларың китәрлек...
Сагынып самими кичәне.
Иртәгә – билгесез. Мизгелдә
Үзгәрде Җиремнең күчәре.

Үзгәрде кешеләр,
Замана кызганмый –
Карайта күпләрне.
Күкләрне.
Күзләрнең
Сагышы күз белән үтәрме?
Бу калеб агарып бетәрме?!

Эндәшмә...
Һәр тараф сафсата сатканда,
Мең тапкыр артыктыр тынуың!
Бик мөһим дөньясы тынарлык
Күнелдә тынычлык булуы...

***

Таң сызыла...
Ялыктырды җәйнең салкын иртәләре.
Бу ярату.
Син ничек соң?
Шашып, ташып,
Һәм ут йотып бүген сине көтәләрме?
Йөртәләрме уйларында тәүлек буе?!
(Баш миемдә
Һәр күзәнәк синең белән тулы!)
Назлы карашларын ташлыйлармы
Күзләреңә, миндәй карап туры?
Сөяләрме, бар җиһанны,
Бар дөньяны бары синдә күреп?
Үбәләрме иреneңнән,
Кочалармы?
Син бит минем сулар һавам, диеп?
Күкрәгемә шыплап тулган хиснең,
Җанны ертып, авырттырган мәле...
Язны тоймый, салкын җәйгә керәм.
Булырмы соң синнән башка, яме?
Ялыктырды йокысызлык.
Бүген тагы
Ике сәгать йокы күргән килеш.
Өметемне өзмә... һич югында,
Минем хәлне танышлардан белеш.

...Һәм бу җәйгә кабат синсез кереш...

***

Офыкта ал кояш.
Мин аңа елмаям,
Ә аннан,
Качырам иренне пәлтәмнең эченә.
Март алдый... мин кабат алданам,
Язларның һәм синең җылыту көченә.

Соң очкын чыгарган учактай,
Янам да сүнәм мин.
Һәм тынам.
(Борчылам – мин һаман шул әле!)
Җайлап йөр. Юлларда ак томан...

Мин юләр, ахрысы.
Янымда тоям да үзеңне,
Хәлләрне сөйлимен.
Сөюең никадәр булды соң?
Әйт әле...
Мин һаман белмимен.
Юк, әйтмә.
Сер булсын.
Әнә бит,
Кояш та яшергән томанга нурларын.
Тынычтыр күңелгә уйлардан,
Кайвакыт...
Яхшырак сүзләрнең булмавы.

Көн саен дежавю.
Гел шулай:
Иртәгә җылырак киенәм,
Диям дә,
Онытам.
Уемда исемең кабатлыйм,
Һәм атлыйм.
Башыңа киеп йөр,
Кичләрен суыта...



Сания Әхмәтҗанова

# САБЫР СӨЮ САГЫШЫ

ПОВЕСТЬ

**1**

Ания быел педучилищеның соңгы курсында укый. Баштагы ике елда рус кешеләрендә торды. Укырга керүе билгеле булгач, әнисе Рәхимә апа аның белән килеп, фатирга Артамоновларга, Югары Ослан кызы Удалова Татьяна янына үзе урнаштырды. Училищега да якын, русча өйрәнергә дә әйбәтрәк булыр, диде.

Аниянең сигезенчене тәмамлаганда, барлык фәннәрдән дә «5»ле иде, анысы. Яраткан фәне рус теленнән дә. Рус теле укытучысы Фәнзия апа, кызның телләр өйрәнүгә сәләтен сизепме, аның белән дәрестән тыш, өстәмә дә шөгыльләнде: үзе җитәкләгән факультативка йөртте, бәйрәмнәрдә озын-озын русча шигырьләр ятлатып сөйләтте, класслары дежур торганда, бөтен мәктәп алдында хисапны русча бирдертте... Ания, иптәшләреннән оялса да, укытучысына ничек каршы килсен? Каршы килеп кенә карасын, Фәнзия апасының холкы әнисенекеннән бер дә ким түгел. Класс җитәкчесе дә әле җитмәсә. Тора-бара кыз рус телен дә, әдәбиятын да барлык фәннәргә караганда да ныграк ярата башлады. Ара-тирә русча сүзләр кыстыргалап, артистланып сөйләшә торган булды. Классташ кызлары моның өчен «кыланчык» дигән кушамат тактылар-тагуын үзенә. «Апа сине яклый», дип тә әйткәләделәр. Ания үзе дә сизә: Фәнзия апасы аңа игътибарны, чыннан да, башкаларга караганда күбрәк бирә иде кебек. Педучилищега укырга керергә дә ул киңәш итте. Мәктәптән соңгы имтиханны тапшырып кайткач, бу турыда Ания әтисенә әйткән иде, ул: «Нәрсә диим, кызым, яхшы булыр, әниең белән дә сөйләш», – диде, йомшак кына итеп. Әнисе дә кызының педучилищега укырга керү теләген хуплады. Сәбәбен дә аңлатты: «Якында булырсың, атна саен кайтып йөрерсең. Отыры олыгаябыз, булышырга кеше кирәк». Аниянең уйлавынча, әнисенең каршы килмәвендә, моннан тыш, тагын бер мөһим сәбәп бар иде.

Бервакыт бәрәңге төбе өйгәндә, Аниягә әнисе үзе сөйләде. Ул яшьлегендә укытучы булырга хыялланган. Каһәр төшкән сугыш чыкмаса, шулай булыр иде дә, әлбәттә. Арчага, хәзер Ания белем алган педучилищега барып, берничә ай укыган да әле ул. «Кырыгынчы ел иде. Ул елны бер мин генә түгел, бик күпләр, укырга кереп тә, береаздан кире кайтып китте. Уку өчен безнең кебекләрнең хәленнән килмәслек акча түләргә дигән карар чыккан ел иде шул ул елны...» – дип ачынып сөйләде әнисе. Ания бу турыда соңрак, укырга кергәннән соң, тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы – класс җитәкчеләре Хөсәен Фатыйхович биргән бер юкарак кына китаптан укып та белде: «Уку елының икенче яртыеллыгында студентлар күпләп китүгә РСФСР Мәгариф халык комиссариатының 1940 елның 2 октябрендә чыккан, педучилищеларда укуны түләүле итү турындагы карары гамәлгә керү дә тискәре йогынты ясый. Край, өлкә һәм автономияле республикаларда уку өчен елына 150 сум түләргә кирәк була. Инструкция буенча, уку хакын түләмәгән укучыларга училищега ишекләр ябылган», диелгән иде анда.

***

Менә хәзер яшәгән фатирны – Гарәфи бабайларны да әнисе сайлады. «Бабайга хәтерен югалткан Мәймүнә әбине дә карашырсың, укудан кайткач, шәләй-вәләй йөрмәскә яхшы булыр», – диде. «Шәләй-вәләе» нәрсәдер, анысын әйтеп тормады. Әнисе сүзне кыска тота, әмма җелегеңә үтәрлек итеп әйтә. Ания аны карусыз тыңлап күнеккән инде. Әнисе әйтте – кыз күнде... Ә менә бүген ул, әнисе белән киңәшеп тә тормыйча, үз гомерендә беренче мөстәкыйль адымын ясады. Ике дә уйлап тормыйча, чәчен кистереп кайтты... Чәч кенәме – билен узып киткән калын толымын... Дөресен әйткәндә, мөстәкыйльлекне ярамаган эштән башлады бугай ул.

Ания ялт кына сикереп торды да түрдәге шифоньер каршына басып, ишегендәге зур көзгедән үзен күзәтә башлады. Болай бик килешсез түгел-түгелен. Йөзенә ниндидер бер серлелек өстәлгәндәй тоелды аңа. Татар теле укытучысы Гөлсинә апасы кебек итеп әйтсәк, яңа образ туды!

Фатирдаш дусты Мөслимә озаклады. Аниянең модалы сессон стрижкасын күргәч, ул нәрсә дияр икән? Нәрсә дисен? «Кызый! Тилердең мәллә син?» – дияр. Бу – аның яраткан сүзе.

...Ания, бәйләвен кулына алганчы, урта ишекнең пыяла тәрәзәсеннән кече якка күз салды. Әби чыгып китмәсен тагын алай-болай. Шундый гадәте бар әбекәйнең. Бабай күрми калса, кулына ни эләкте, шуны төенчеккә төйни дә, әниләргә барып кайтам әле дип, капкадан ук чыгып китә. Андый көннәрдә, йә Ания, йә Мөслимә укудан кайтканчы, урамда йөри Мәймүнә әби. Әкрен кыймылдаса да, шактый ерак киткән була үзе. Җәяүле сукмак туп-туры Арча үзәгенә алып төшә. Әбекәй дә шул сукмактан читкә чыкмый тагын. Бүген, рәхмәт төшкере, тыныч көне. Аркага арка терәп, «мыш-мыш» килеп яталар карт белән карчык. Ания, ян тәрәзә буендагы урындыкка барып утырып, урамны күзәтә башлады. Күк аяз. Тик Аниянең кәефе генә болытлырак. Бәйләү теләге дә, уку дәрте дә юк иде бүген кызыкайның.

– Һәй наяннарым!

Күршеләрнең күлләвектә су чәчрәтеп чыркылдашкан балаларына тәрәзәдән яратып карап, шулай дип дәшкән булды да өзелгән уй очын кабат ялгап җибәрде Ания.

...Әнисе Рәхимә үзләреннән җиде-сигез чакрым гына ераклыктагы Сикертән авылында Гыйльмулла бабасы белән Бәгыйдә әбисенең тугыз балалы ишле гаиләсендә сигезенче бала булып дөньяга килгән. Әнисенә биш яшь вакытта бабасы Гыйльмулла, авырып, гүр иясе була. Бәгыйдә әбисе тугыз баланы бер ялгызы кеше итә.

Әнисе, укуын калдырып кайткач, бер-ике ел элек кенә күрше Гөберчәк авылында ачылган тегү артеленә эшкә урнаша. Ул баштарак әзер киемгә төймә, элгеч тагу, күлмәк итәге бөгү кебек эшләрдән башласа, соңрак, сугыш вакытында, фронтка җибәрергә тиредән бияләй, бүрек ише катлаулырак әйберләр тегәргә, күкрәкчә (душегрейка), телогрейкаларга кадәр сырырга өйрәнә. Ике-өч елда ул үз эшенең остасына әйләнә. Гөберчәктә артельне оештырган, шунда цех җитәкчесе булып эшләгән Хәнәфиев Рәхимулла абый, сугышка киткәндә, Аниянең әнисен үз урынына цех җитәкчесе итеп калдыра. Моңа, әнисенең әйтүенчә, русчасының шактый яхшы булуы да сәбәп булгандыр. Русчаң әйбәт дип, әзер товарны Арчага йә Казанга тапшырырга барганда, Рәхимулла абый еш кына Рәхимәне дә үзе белән алып бара торган була.

...Аниянең уенча, педучилищега керүенә әнисенең куануының мөһим сәбәбе шул: үзенең яшьлек хыялын кызы тормышка ашыруга өметләнде бугай ул. Авылга кунакка кайткан очучы абыйсы әтисе белән әнисе дә ишетерлек итеп әйтте шул вакытта Аниягә: «Нигә унынчыны тәмамлап, институтка кермисең, сеңлекәш? Менә мин, академия бетермәгәч, подполковниктан ары китә алмам, бик теләсәм дә. Югары белем алырга кирәк!» – дигән иде. Әтисе дәшмәгәч, эчтән генә авыр сулап, әниләре җавап бирде: «Балалар укыта-укыта, бик арыдык инде без, улым, яшебез дә хәйран, чама да шул кадәр. Училищесен бетерсен дә дәлшесен үзе карар. Эшләп укыр!» – диде, ике уйларлыкны калдырмыйча.

Училищега документларын тапшырырга класс җитәкчесе аны үзе алып барды. Мәктәпне «5» легә генә тәмамлаганга күрә, ул укырга имтиханнарсыз гына, әңгәмә нигезендә кабул ителде. Әңгәмә дигәне имтиханнан да кыенрак булып чыкты: тикшермәгән теманы калдырмадылар. Диктант та яздырдылар, мәсьәләсен дә чиштереп карадылар... Фәнзия апасының иң шатланганы шул булды: Ания диктантны өтерен-өтергә, ноктасын-ноктага туры китереп, бер хатасыз язды. Математикасы бераз кайтышрак иде. Алай да ерып чыктылар. Алар Арчадан кызның педучилищега кабул ителүе турында тәгаен белеп кайттылар.

Русча сөйләшү дәрестә җавап бирү генә түгел икән шул ул! Беренче фатир хуҗасы Анатолий Петрович Анияне русча шома сөйләшә башлаганчы шактый «азаплады»: хаталарын төзәтте, үз артыннан кабатлатты, юри сорау биргән булып, тегене-моны сораштырды. Русчасы күзгә күренеп яхшыргач, беркөн Ания белән татарча сүз башламасынмы! Хәйран гына татарча сукалый булып чыкты дядя Толя. Рус теле «практикасы» ике ел дигәндә шулай уңышлы гына тәмамланды. Уллары Петя армиядән кайткач, кызларны фатирдан чыгардылар.

***

Әби белән бабай ваемсыз гына изрәп яталар. Ания, өстенә плащын элеп, ишегалдына чыкты. Кызык та, сәер дә бер ачыш ясады ул: озын чәч төз басып, ипле йөргәнне, әнисе сүзләре белән әйткәндә, түтәпкеллекне, ягъни мәсәлән, һәр яктан чама белгәнне «ярата» иде, ә менә кыска чәч шаярасыны, кәҗә бәтие кебек уйнаклыйсыны китерә. Бу баш белән «Каз канаты»н биеп булмас шул инде хәзер. Ишегалды читендә торган тумран өстенә сикереп менеп, көндез радиодан ишеткән «Танец на барабане» җырындагыча, түмәркәне барабан итеп тыпырдап карыйсы килде аның. Башка вакыт булса, Ания нәкъ шулай итәр иде дә. Тиккә генә классташлары аны биюче дип йөртә мәллә? Хореографиядән дә «5» ле, беләсегез килсә, бу «кыланчык»ның!

«Сәхнәдә – биюче кызыбыз Ания Шәрәфиева»! Ул ишегалды түрендә үлән чемченеп йөргән ике-өч кара тавык белән озын торыклы әтәчкә шулай дип игълан итте дә үзе яраткан «Каз канаты»н көйләп, аяк очларында капкага таба «йөзеп» китте. Мөслимәнең укудан кайтканын ул капка төбендә көтәргә булды.

Кыйшаеп, җиргә сеңә башлаган артсыз агач эскәмиягә утырып, аяз күк йөзенә текәлде. Кызык, кояш шәфәкъка күмелгәнче үк, Ай гүзәлкәй зәңгәр гөмбәздә үз урынын алырга өлгергән инде. Шулай да бик чекерәеп тормый, шәйләнер-шәйләнмәс кенә күренә. Үсеп килгән яңа ай. Астрономия укытучысы Шамил абыйлары бу күренешне аңлаткан иде кайчандыр. Тик Аниянең моңарчы мондый хәлне үз күзләре белән күргәне булмады. Бик болай күккә багып, эшсез утыру тәтеми шул! Гаҗәеп манзара: көпә-көндез диярлек чиксез галәмнең ике бизәге икесе берьюлы аны күзәтә. Тик беләләр микән алар бу хыялый кызыйның нәрсә уйлаганын?! Ания, үз алдына сөйләнгәндәй, күңеленә килгән шигырь юлларын көйләде:

Ай нурларын кушып тараганга,
Толымнарым булды микән озын?
Таңда чишмәләрдән су китергән
Авыл кызы бит мин, авыл кызы.
Тибрәндереп толымнарым, суларга бара идем,
Мин бит туган авылымда бәхетле бала идем...

Иртәгә беренче дәрес – әдәбият. Гөлсинә апасы, яңа темага керешкәнче: «Йәле, Шәрәфиева, нинди яңа шигырь алып килдең безгә, укып күрсәт әле», – диячәк. Ул күп вакыт шулай итә. Аннан шигырьне бөтен класс белән бергәләп тикшерерләр, һәркем үз фикерен әйтер, Гөлсинә апалары проблемалы сорау куяр. «Ә сезнеңчә ничек, укучылар?» – дияр...

Әнә Мөслимә дә кайтып килә. Анияне күреп алуга, беренче сүзе шул булды:

– Ания, кызый! Тилердеңме әллә син?!

...Ания төне буе саташып чыкты. Имеш, киселгән чәч толымы еланга әйләнгән икән дә аңа таба шуыша икән... Ул арада әллә каян әнисе килеп чыгып, еланны кумакчы була. Ул әнисе түгел, симез бармаклы бер юан хатын икән. Анияне куып тотарга әйтә. Ания аннан качмакчы була, тик йөгерә алмый. Аяклары тыңламый. Хатын Аниянең толымын кисмәкче икән. Ания: «Әни!» – дип кычкырырга әйтә, әмма тавышы чыкмый...

– Кызый! Бастырыласың, ахры, борылып ят! – дип, әле дә ярый Мөслимә уятты. Ул әле йокларга ятмаган. Дәрес әзерли. Мамык шәленә төренгән үзе. Иреннәре тонык ут яктысында зәңгәрләнеп күренә. Күшеккән бугай. «Ничек син җүнләп дәрес тә әзерләмичә, «5»легә генә укыйсың соң, кызый?» – дип аптырый ул. Ничек-ничек? Укытучыны яхшылап тыңлап утырасың, киләсе дәрес алдыннан шул теманы бер тапкыр кабатлыйсың. Мөслимә дәрес әзерләүгә күп көч куя. Параграф ятлап утыра әнә, дога укыган кебек, авызын селкеткәләп. Тырышлыкны бирсә бирер икән Ходай! Һәр көн өч-дүрт сәгать кымшанмый да утыра шулай. Ничекләр түзәдер кыз?!

Бу шомлы төннең икенче яртысында Аниянең күзенә йокы кермәде. Төнлә утны озак яндырып утырганны Гарәфи бабай бер дә өнәми. Электр күп чутлый, ди. Лампочканың да сүрәнрәк яктырта торганын бора. Мөслимәгә тагын эләкте... Бабай чыгып тамак кыргач, «кавыштыра торган» – сеткалы караватка Мөслимә килеп ятты – Ания торып китте. Арчаның якты урам утлары да, урак ай да Ания яклы бүген. Кыз, бәйли башлаган кофтасын алып, тәрәзә янына ук килеп утырды. Тик бәйләү энәләре генә башка вакыттагы кебек үзләреннән-үзләре күзәнәкләр өстеннән йөгереп китәргә ашыкмады. Уйлары да җырлы бизәк булып бәйләменә күчми. Ания, кул эшен читкә куеп, капка төбендә утырганда, күңеленә килгән шигырь юлларын теге зәңгәр тышлы дәфтәренә язып куярга булды. Портфеленнән дәфтәрен алыйм дип үрелгән генә иде, кулы куш биткә төрелгән чәч толымына килеп орынды. Артык хискә бирелмичә генә аны, зәңгәр косынкасына төреп, авылга кайтып йөри торган сумка кесәсенә салды. Онытылганчы, шигырьне язып куясы бар иде аның:

Толымнарым алгач кулларыңа,
Ап-ак булды кинәт, әни, йөзең.
Бәхетләрең киселә күрмәсен, дип,
Кабат-кабат дога кылдың үзең...

Шигырь язылып бетмәде... Таң да ялындырып кына атты.

***

... Бүген Гөлсинә Рәхмәтулловна никтер кәефсез кебек тоелды Аниягә. Укытучы апа керә-керешкә тәрәзә янына килеп басты да урамны күзәткән кыяфәттә кул сәгатен боргалый башлады. Аннан класска карап, гадәттәге җөмләсен башлады:

– Йәле, Шәрәфиева...

Тик сүзе башкача тәмамланды:

– ... нишләдең син, Ания?

– Ник, килешмиме әллә, апа? – дип сораган булды Ания. – Әнә Рауза да, Хәлбәрия дә, Мөсфирә дә... бүтәннәр дә ошатты.

– Килешә, матур... тик син элек башкаларга охшамаган – үзгә идең... Хәзер башкалар кебек булгансың...

Башкаларга охшамагансың... Аңлатыгыз шуны Аниягә: нәрсә соң ул – «башкаларга охшамаган»? Сорау бирелмәде. Җавап алынмады. Гөлсинә апа бүген Аниядән яңа шигырен дә сөйләтмәде... Дәрес бик акрын үтте...

**2**

...Атна башланырга өлгерми, бетәргә дә тора. Бүген пәнҗешәмбе икән бит инде. Үзәккә – «Спорткультттовары» кибетенә төшеп менәргә кирәк булыр. Энесе рәсем ясый торган пумала сораган иде. Алып менеп куйсын әле ул. Рәсем укытучысы Әбүзәр абыйлары өйрәткәнчә, тиен кылыннан ясалганын – йомшагын алыр.

Ания кулындагы шигырь дәфтәрен иплəп кенә портфеленә шудырды да кече якка чыкты. Гарәфи бабай – үзеңә кирәк булганда дәшсәң, гел ишетмәмешкә сабышып аптыраткан карт – бу юлы стенага карап яткан чагы булса да, Аниянең чыгып китәсен әллә кайдан сизенеп, әби аша мүкәләп чыгып, торып ук утырды. Элек милициядә эшләгәндәге гадәте китмәгән тәки картлачның, әллә һәр хәрәкәтеңне тыңлап ята шунда. Каш астыннан гына карап, тамак кыргалап, коры гына әйтеп куйды:

– Каядыр җыенасың бугай, кызый... Мөслимә дә озаклады бүген...

– Алар класслары белән киногa киттеләр.

– Ниткән кина ди ул тагын, акча туздырып?

– «Последний побег»... Яңа фильм.

Бабайга «кина»ның исеме ошады бугай. Башка вакытта озын-озак сөйләшергә яратмаган карт:

– Бандитлар турындамыни? – дип сорап куйды.

– Юк, интернат-мәктәптә укучы ата-анасыз балалар турында. Витя Чернов дигән малай шуннан качкан, – дип, үзенчә тырышып аңлаткан булды Ания. Ул бу яңа фильмны әлегә үзе карамаган булса да, аның эчтәлеген беркөнне, шигырьләре чыкмаган микән дип, «Коммунизмга»ны караштырганда укыган иде.

– Беләм, – диде хәйләкәр карт, «син белгәнне мин чыгарып элгән» дигән кыяфәт белән. – Беркөнне гәҗиттә язганнар ие...

Гарәфи бабайга кая барасын әйтте дә чыгып китәм дип ишек тоткасына үрелгәч кенә, картлач кызны янә туктатты:

– Озак йөрмә. Комганга җылы су тутырып куярмын. Кайткач, юындыртып, әбиеңнең эчке киемнәрен алыштырырсың...

– Ярар...

Кибеткә алардан ун-унбиш минутлык кына юл. Хәзер төшеп менәр...

Ишегалдына чыккач, кызга урамда өйдәгедән җылырак сыман тоелып китте. Ул, һава алмашынуданмы, җиңелчә генә калтыранып куйды. Мичкә ягыйк, дими әле һаман саран картлач. Үзләре көне буе юрган астында яткач та...

Әмма яшьлек үзенекен итә шул! Бер-ике адым атлауга, бабай белән әби кайгысы онытылды, кызыбызны яңадан үз уйлары биләп алды.

Гәрәбә көз инде узып бара,
Сагыш кына китми күңелдән...
Сөю гөле көзгә бирешәме? —
Өмет чәчәгенә күмелгән.

Җәяүле сукмактан йөгерә-атлый кибеткә төшеп барганда, Ания шигъри хисләрен Арча урамына әнә шулай яңгыратты да үзеннән-үзе көлеп куйды.

Кеше-кара ишетсә: «Бик үк тулы түгел, ахры, бу кызый», – дип уйлый инде. Күңеленә килгән һәр шигырьне язып барсамы, бер китаплык булыр иде инде күптән! Беркөнне түгәрәккә килгәч, Гөлсинә апасы: «Кыюрак бул! Күңелеңне йозакка бикләмә. Шигърият читлектә яши алмый. Әнә Сибгат агабыз: «Кол җанда хөр шигырь туа алмый», – дигәнме әле? Әллә башкача әйткәнме? Китабын бирермен, үзең карарсың», – дигән иде. Монысы ярар инде. Начарлыкка әйтми укытучы апасы. Менә башкалар белән генә чагыштырмасын иде. Янәсе, Аниянең шигырьләре гадилек белән алдыра, ә Зифада образлылык көчлерәк... Укучыга барысын да аңлатып бирергә кирәкми, үзенә уйларга да урын калдырырга кирәк, янәсе. Зифа менә шулай яңа образлар тудыра белә икән... Ә үзләре, Хөсәен Фатыйхович белән икесе, аны гел читлеккә кертмәкчеләр. Әллә әнисе белән сүз куешканнар шунда! Үпкәләмәс тә иде. Яз көне училищега очрашуга Казаннан бер төркем яшь шагыйрь килгәч, әдәби түгәрәккә йөрүчеләр башта сәхнәдән шигырь укыдылар, соңыннан бергәләп фикер алыштылар да, Зәйдуллин фамилиялесе әйтә: «Кызлар, цын-цынлап әйтәм, фикер алышуны дәвам иттерү өцен, берәр сәгатьтән кунакханәгә төшегез», – ди. Зифа ул тәвәккәл! Үз башы белән хәл итә. Ул көнне алар, ике юләр – сабакташы Бәдертдинова Миләүшә белән Ания – шагыйрьләр янына төшү өчен Хөсәен Фатыйховичтан рөхсәт сорамакчы булдылар. Класс җитәкчесе Анияне читкә чакырып алды да: «Алыштыгыз бит инде фикер, Ания! Шуны онытма: син – булачак йолдызыбыз! Өйгә кайтсагыз, яхшырак булыр», – дип, киенгәннәрен көтеп торып, кайсы якка киткәннәренә кадәр карап калды. Ания укытучысына сорау биреп тормады. Тавышыннан ук аңлап алды: Ания ярамаган эш эшләмәкче икән.

«Ирекне чиклиләр бит безнең, Миләүшәкәй!» – дип батырайган булды ул, кайтып барышлый. – Гөлсинә апа нәрсә диде: «Кол җанда хөр шигырь туа алмый!» «Хокук даулау» йөзеннән, ярты юлдан борылып, Рифә төшкәч, безгә дә ярар дип, шагыйрьләр янына кунакханәгә төшеп китмәкчеләр иде, өч-дүрт адым атлауга, Миләүшә кире уйлады. «Төшәсең килсә төш, минем контроль эшкә әзерләнәсем бар», – дигән булып, кайтыр юлга борылды. Контроль эш, имеш! Анияне сизми дип уйлый! Солдатыннан хат килмәгәнме дип, тизрәк фатирына чаба. Тегесе генә хат язу саранлыгына юмартрак шул... Дусты Миләүшәгә иярде инде Ания дә, берүзе төшсенмени? Җитмәсә, кара-каршы фатирларда торалар. Гарәфи бабай тәрәзәдән күреп алса, Миләүшәнең иртә кайтканын, җелегеңә төшкәнче «допрослаячак».

...Ул көнне Ания бик гарьләнде. Туктагыз әле, нишләп сез барыгыз да Аниягә акыл өйрәтәсез соң әле?! Тege ярамый! Бу килешми! Нигә башкаларга барысы да килешә, ә менә аңа – юк? Нигә бергә укыган дус кызларына ирек куелган? Тәнәфестә үзләре үк сөйләп торды әнә: дәрестән соң күрше егетләре мотоциклга да утыртып йөргән, бер генә яңа фильмны да карамыйча калмыйлар, дискотекага да баргалыйлар икән. Укулары да яхшы: гел «5»легә үк булмаса да, стипендия алалар. Аларның да әти-әниләре бар бит югыйсә! Ания башкаларга охшамаган, имеш. Әнисен дә әйтер идем! «Күзгә чекерәеп кереп торган чибәрлегең юк. Егетләрне акыллы, тәүфыйклы булуың белән генә карата аласың. Тәүфыйгыңны сакла!» – дип, җанына тоз сала, җай чыккан саен. Менә шул сүзләр төп

сәбәпчедәдер дә әле аның чәчен кистерүенә. Кайсы гына кызның чибәр буласы да, егетләр каратасы килми икән соң? Үз әниең «җете чибәрлегең юк» дип торгач! Ания сер итеп кенә бу уйларын апасына әйткән иде дә, тегесе бурлат кебек кызарганчы рәхәтләнеп көлде генә. «Әни, – ди апасы, – син үсенеп китмәсен өчен генә юри әйтә. Син – бик мөлаем кыз. Кара ул билләреңне. Миндә булсын иде әле синеке кебек фигура. Тьфү! Тьфү! Тьфү! Ул сиңа күз тидерүдән курка, – ди чандыр гәүдәле апасы. – Әни кеше өчен үз баласыннан да матур, үз баласыннан да газиз зат юк», – ди. Тынычландырыр өчен генә әйткәндер инде. Алла бирса, кызы булса, Ания аңа мәңге «син чибәр түгел» димәячәк. «Син – дөньядагы иң матур кыз!» – диячәк ул кызына... Әнисенә дә: «Мин берәүдән дә ким түгел. Әни! Нигә миңа алай дип әйтәсең?!» – диячәк.

И җаным! Шулай дия алса, моңарчы әйткән булыр иде инде. Әйтә алмый шул менә, каршы дәшә алмый Ания! Кыюлыгы җитми. Аулакка качып елый гына. Үзен рәнҗеткән кешегә, иптәш кызлары шикелле тозлап-борычлап җавап та кайтара белми бит ул! Кая инде әнисенә әйтү! Нигә куркак булгандыр шул кадәр? Бу кадәр әтисенә охшар икән. «Ярар, Рәхимә... шулай, Рәхимә...» – әтисенең бар белгәне шул. Алай дисәң, сугышта фашистларны тукмап, күкрәк тутырып, орден-медальләр тагып кайткан батыр фронтовик аның әтисе! Ярамый гына торсын әле! Әтисенә охшасамы – күрсәтер әле ул сезгә нәрсәнең яраганын, нәрсәнең ярамаганын!

Батыр булып кылануы үзенә дә ошап китте – Ания көлемсерәп куйды. Йә, булды, Ания, ярсыма. Боларның баш күтәрү йөзеннән генә әйтелгән сүзләр икәнен үзең дә яхшы беләсең. Тиңләш-тиңләшмә – Зифа, чыннан да, шәп яза. Шагыйрьлек тумыштан бирелгәндер аңа. Кыюлыгы да бәхәссез. Ядрә кебек кыз. Университетына да керер, чын шагыйрә дә булыр... Бәлки, алай гына да булмас... Матур да әле, җитмәсә... Курчак кебек... Кем әйтмешли, җете чибәр... Тукта әле, Такташчарак килеп чыга түгелме соң бу? Бүген Аниядә ике «мин» үзара кылыч кисештерде. Беренчесе аның «коммун» яклы, икенчесе – каршы... мин сиңайтим...

...«Спорткультьтовары» Үзәккә төшкән шәпкә почмакта гына. «Башта «Галантерея»га кереп чыгарга кирәк», дип уйлап куйды Ания, әрсез уйларыннан арынырга теләп. Ул кибет арырак, чаттан борылгач, ике катлы таш бинаның өске катында урнашкан. Ания баскычтан, бию хәрәкәтләре ясагандай, сикергәләп менде. «Раз, и два, и три! Бә – рәң – ге – не азрак аша, А – ни – я! Менә шулай, раз, два, три!» Ания бу кибетне аеруча ярата. Исенә кадәр затлы шул, җанга ятышлы... Монда бәйләү җепләре дә кайткалый, аннан соң бизәнү әйберләре сата торган бүлек тә бар. Юк, бер әйбер дә алмас ул бүген дә. Болай гына, карап кына чыгар. Акчаны да җиткерәсе бар... Әлегә күңеленә хуш килгән муенсаның да очраганы юк. Бизәнү әйберләренә битараф булмаганын белгәч, әнисе Аниягә әбисеннән калган гәрәбә муенсаны бирәсе иде дә, Ания үзе алмады. «Картларский муенса тагып йөрмим... Хәзер төрле төстәге ясалма ташлы әйберләр модада!» – диде ул әнисенә ул чакта, ничектер кыюлыгы җитеп. Әнә, энҗегә охшатып ясалган озын ак муенса кайткан. Кара водолазкасы белән бик матур булачак, билгеле. Ания «алыргамы-алмаскамы» дип, озак кына уйлаганнан соң (акчасын санап караганнан соң инде), муенсаны алырга булды. «Берәү генә

калды», – ди бит сатучы апа да. Кыйммәт тә түгел алай. (Икенче көнне ярты классның ак муенса тагып киләсен белми иде әле ул бу минутта.)

Кыз урамга чыкканда, хуҗалык товарлары кибете янында шактый кеше җыелган иде. Нәрсәгә чират торалар икән, дисә, печенье пешерә торган форма-таба саталар булып чыкты. Ах! Аниянең әнисе дә күптән кызыга андый табага. Әби-чәбиләр бер-ике атна чират торгандыр инде аңа, исемлек төзи-төзи. Бардым-алдым гына түгел шул. Эх, менә шушы табаны әнисенә алып кайтып бирсә Ания, чәчен кискәненә бик исе дә китмәс иде бәлки. Уйлап тапты! Ания әнисе биргән биш сумны юк-барга тотмый. Бер айлык ризык төяп килде, ашарына җитә. Партадаш дусты Раузаның Нурзидә апасы Арча станциясендә товар базасында эшли. Бик үтенеп сораса, «по блату» гына табып бирәчәк ул табаны... Чәчен кистергәненә үкенү хисен җиңәргә маташып, кызыбыз шуларны уйлады.

***

...Ания гозер-үтенечен Раузага икенче көнне иртүк әйтергә булды. Педагогика дәресендә укытучы Шәйхенур абый (алар телендә – Коменский) тактага нидер язган арада, тиз-тиз генә хәлне партадашына аңлатып бирмәкче иде... Тик тәнәфескә кадәр көтсә яхшырак буласы икән дә бит!.. Белә юкса «Коменский»ның холкын. Кызларның пышылдашканнарын укытучы ишетеп алды да бирде генә Аниянең кирәген! «Сине Фәнзия апаң (авылдагы рус теле укытучысы – Аниянең класс җитәкчесе инде – заманында шулай ук «Коменский»да укыган) шуңа өйрәттеме? Үзең булачак совет укытучысы! Отличница, җитмәсә! Сиңа хөкүмәт югары стипендияне дәрестә сөйләшеп утырган өчен түлиме? Син шундый булгач, башкалар нишләмәс!» Китте, китте тезеп... Фәлән-төгән-фәсмәтән! Ах, Гөлсинә апа, Гөлсинә апа! Тапкансың икән ирне! Әйтәм аны, кайчакта дәрескә кергәндә, кәефең булмый. Андый чакларда Ания: «Апа гел елмаеп кына сөйләшсә дә, нигә шул назлы елмаюы артында үзәкне өзеп ала торган бер моң, бер сагыш бар икән аның?» дип уйлап куя. Яраткан укытучысын юатасы килә. Бүген шул соравына төгәл җавапны тапкандай, сәбәпне вулкан холыклы Шәйхенур абыйсында күрде. «Коменский синең дә үзәгеңә үтә булыр, апа!»

Укытучы шыбыр тиргә батканчы «тәрбияләде» дә Анияне, кабинеттан ук куып чыгарды. Нигә һәрвакыт шулай: гел Аниягә эләгә? Авыл мәктәбендә дә, монда да. Әнә, узган җәй Рауза имтихан билетының бер генә соравына да җавап бирә алмагач елап җибәргән. «Ник елыйсың?» – дип сорый икән моннан «Коменский». «Әти – инвалид, әни – авыру. Печән чаптым, әзерләнә алмадым, абый», – ди икән Рауза. «Әти-әниеңә ярдәм иткәнең өчен «4» ле куям, сеңлем. Материалны беләсең син, җавап кына бирә алмадың», – дип мактый-мактый озаткан тегене укытучы абый. Әйбәт кеше инде ул үзе болай... Методика дәресендә өйрәнгән «Һәр укучыга шәхси якын килү» шул буладыр инде, күрәсең. Әти-әнисенең авыру икәнен белгәч, Ания, партадашын кызганып, «югары» стипендиясенең 5 сумын ай саен аңа биреп бармакчы да булган иде, кире уйлады ул чакта. Саранлыктан да түгел, кышкы пальтосы кечерәйгән иде. Колхозда бәрәңге чүпләгән өчен бирелгән акчасы гына җитеп бетмәде үзе кызыгып йөргән «капюшон»лы пальтога. Шуңа күрә иптәшләре белән Мәскәүгә экскурсиягә дә бармый

калды ул. Хөсәен Фатыйхович бик үгетләп карады. «Мәскәү качмас әле, ә пальто менә качарга мөмкин», – дигән иде кыз ул чакта, еламас өчен көлеп җибәргән булып.

Әллә нәрсәләр килә бу башка, җүнле уй бер дә керми! Менә ул әзерләнми кергән булса имтиханга, күрсәтер иде аңа «Коменский» күрмәгәнен! Хөсәен Фатыйхович әйтмешли, «йолдыз» булсаң, бер кечкенә генә гаебеңне дә күтәрә алмый укытучы халкы. Һәр адымың, һәр гамәлең бизмәнгә куела. «Отличница», имеш! Эх, Әлтафи, Әркәшә! Бик аңлыйм мин сезнең хәлне... Ничек кенә аңлыйм әле! Мөхәммәт Мәһдиев абыебыз дөресен язган икән. Сез укыган кырык беренче ел тәртипләре һич кенә дә үзгәрмәгән икән шул бу училищеда! Буыннан-буынга тапшырылып килә, ахры, мондагы «тәрбия алымнары». Сездән кырык ел элек укытучылар мыскыллы рәвештә «шовинист», «натуралист» дип көлгән булсалар, якташыгызны бүген «отличница» дия-дия җәберләделәр.

Аниянең шулай коридор диварлары белән сөйләшеп, дулап-ярсып, кабинет төбендә басып торганын алай да кеше-кара күрми-белми калды. Бәхеткә, икенче дәрес – җәмгыять белеме, класс җитәкчеләре Хөсәен Фатыйхович дәресе иде.

...Чем кара бөдрәләренә урыны-урыны белән уч-уч көмеш сирпелгән өлкән яшьтәге укытучы абый, калын кысалы күзлеген төзәтә-төзәтә, аталарча миһербанлылык белән күбрәк укучылар өчен үзе җавап бирә-бирә, өй эшен тикшереп алгач, һәрвакыттагыча тәрәзәләрне кара пәрдә белән томалады да фильм күрсәтергә әзерләнә башлады. Һәр дәрестә диярлек куллана торган яраткан эше ул аның. Ут сүнде. Укытучы проектор янында мәш килә. Плёнкасын ялгыш куйганмы абыкай – хәйран матавыкланды. Класста чыш-пыш китте. Анияләр артында утыручы мыштым Җиһангир дә никтер кыбырсый, боргалана башлады. Менә ул, капыл гына урыныннан кубып (Ания моны урындыкның арткарак шуып китүеннән аңлады), алга таба иелде дә, баян каешын кигәндәй, ике яктан җайлы гына шуып кереп, Аниянең «пар алма»сында бармакларын биетеп алды. Монысы нәрсә булды инде тагын? Ания ни булганын абайлап өлгергәнче, егетебез, шул ук җитезлек белән артка да тайпылды. Менә сиңа мышты-ым! Башкалар түгел, хәтта Аниянең янәшәсендәге Рауза да аны-моны аңышмый калды бугай. Экранда хәрәкәт башланды. Укытучы, классны игътибарлы булырга өндәп, сукрангандай итеп, үзалдына «мыдыр-мыдыр» нидер сөйләнде. Фильм караган кыяфәт китереп утырган Аниябез ачудан дөрләп кабыныр дәрәҗәгә җитте. Шулай да ул «ответный удар»ны бераз кичектерергә булды. Ут янсын әле класста! Белер ул нишләсен! Ну эләгәчәк сиңа, Пошалым «уфалла»сы! Игътибарын туплый алмыйча, дәрес ахырын көч-хәл көтеп җиткерде ярсулы кызыбыз. Кыңгырау яңгырауга, барысы да дәррәү кубып чыгарга кузгалды. Ания дә, Җиһангирдан алдарак торып, берни булмагандай тынычлык саклап, чыгу юлына атлады. Укытучы өстәле янына җитүгә, ул кинәт кенә артына борылды да каерылып, егеткәебезнең яңагына – «шалт берне Мөхәммәтҗан!» Чамасызрак кыланды бугай – класс тәрәзәләре зеңләп куйгандай тоелды. Педагогика дәресеннән куылу мәсхәрәсе, «пар алма»га һөҗүм – барысы өчен дә Җиһангирга эләкте!

Кызлар-егетләр өнсез катып калды... Кызыл төймәсенә баскач, пәрдәләр үзеннән-үзе ачыла-ябыла торган җайланманы эшләтә алмый аптыраган Хөсәен Фатыйхович та күзләрен мелт-мелт йомгалап, сүзсез генә Ания белән Җиһангирга төбәлде. «Нәмәкәй булды, апаем? Бәй, ул кадәр үк кыланмасагыз ни була?» – дип, алар янына староста Фәйрүзә йөгереп килеп җитте. Башкалар җилкәләрен генә җыерды... Җиһангир кып-кызыл булды да класстан атылып чыгып китте. Хөсәен Фатыйхович берни сорамады. Ания янына килеп: «Шулай кирәк булгандыр», – дип, үзенчә нәтиҗә генә ясады.

Сөйләгәндерме-юкмы Җиһангир бу турыда башкаларга, әмма шул көннән башлап Аниягә класстагы бер генә егет тә якын килмәде... Фәйрүзәләр, Рәсимәләр, Рафиләләр тәнәфестә чыркылдашканда, кайчакта ачуы килеп, кайчакта кызыгып-көнләшеп тә, урынында ялгызы гына утырды Аниябез. Бу хәл турында Җиһангир да, Ания дә ләм-мим – кабат искә алмадылар... Җиһангир аннан читләште.

### 3

Ания әнисе белән Арча кибетендә күлмәклек сайлый. «Моңа кадәр мин теккәнне кидең, рәхмәт. Инде күзләрем дә элеккечә күрми, машинам да үзем белән бергә картаеп бара, яңа мудыны да белеп бетермим. Чыгарылыш кичәсенә, әнә «Азат хатын»нан карап, әртилдә тектер. Бер киеп ташларлык булмасын. Затлы итеп тектер – син интиллигин буласы кеше», – дип киңәш итте Рәхимә апа кызына. Әниле-кызлы икесе берьюлы зәңгәрсу төстәге ефәк тукымага барып тотынгач, кибетне яңгыратып көлештеләр дә күлмәклеккә шуны алырга булдылар.

...Ания озын киң итәкле, түшенә ак лалә чәчәге беркетелгән зәңгәрсу ефәк күлмәген киеп, шифоньер ишегендәге зур көзге каршына килеп басты. Коңгырт чәче айлап түгел, көнләп үсә, әнә инде иңнәренә төшеп дулкынланып тора. Чәченә дә шундый ук ак чәчәк кирәк икән. «Саубуллашу вальс»ын көйләп, бил бөгелешләрен дәртле уйнатып, бер-ике әйләнде дә көзгедәге Аниянең борынына чиртеп:

– Менә шундый хәлләр бездә, Зәңгәр күз! Синең теләкләр чынга ашарга охшап тора, – дип, колхозга бәрәңге алырга баргач гашыйк булган егете белән соңгы тапкыр очрашуларын күз алдына китереп, моңсу гына елмайды сылу кызыкай.

...Бәрәңге эшләре тәмамланып, хезмәт хакларын алгач, Анияләр авылда саубуллашу концерты оештырдылар. Концерттан соң, ит комбинатына мал төяп илтә торган зур трактор арбасына, көлешә-көлешә, барысы бергә төялештеләр дә, авыл егетләре аларны Арчага кадәр озата килде. Араларында Зәңгәр күз дә бар иде. Ул, курткасын чишеп, Анияне җилдән ышыклап барды.

– Ания! Сеңлем! – дип башлады ул сүзен, кызны кочагына алып. – Ошаттым мин сине. Алдамыйм... Тик әллә мин туарга ашыкканмын, әллә син соңлабрак тугансың... Хыялыңны чынга ашыр: училищедан соң институтка кер. Мин бик теләгән идем дә сезнең егетләр кебек оста гармунчы булырга... Армиядән соң әнине ялгызын ташлап китә алмадым... Авылда безнең ишеләрнең чиләнгәне дә бик җиткән. Сиңа язгы-көзге пычрак та, мәңге

бетмәс авыл эше дә төс түгел! Шәһәргә кит. Яз шигырьләреңне, шагыйрә апа, – дип елмайган булды чибәр егет. Аның иреннәре гадәттәгечә киң булып җәелеп китсә дә, ай яктысында тагын да зәңгәррәк булып күренгән күзләрендә аңлатып булмаслык тирән бер сагыш бар иде.

Җиһангир баянда «Авыл көе»н уйнап җибәрде. Кызлар-егетләр җыр башлады:

Китәм инде, китәм инде,
Китәм инде, каласың.
Мин киткәчтен кемнәр сөяр
Син сандугач баласын?

Җиһангирдан баян Илгизгә күчте. Илгизне Нәкыйп алыштырды. Аннан соң Рамил, Рафилә ягына карый-карый, аның яраткан «Зирек алкалары»н уйнады. Фердинанд «Арча кичләре»н башлаганда, ерактан бистә утлары балкып күренә башлаган иде инде... Зәңгәр күз Анияне трактор арбасыннан, биленнән нык куллары белән тотып, очыртып кына төшерде... Колхозда башланган танышлыкның бу соңгы аккорды иде.

***

Педучилищеда чыгарылыш имтиханнарын тапшыруга (Аниябез, көтелгәнчә, Кызыл диплом алды!) Казан педагогия институтыннан бер төркем укытучы килеп, студентларны читтән торып уку бүлекләренә укырга кабул иттеләр. Ания рус-татар бүлегенә укырга керде. Институтны тәмамлый алса, ул киләчәктә, Фәнзия апасы кебек, рус теле һәм әдәбияты укытучысы булачак.

Аларның чыгарылышыннан рус телен яхшы белүчеләрнең күбесен шәһәр мәктәпләренә билгеләделәр. Ания дә шулар арасында. Аерылмас дуслар Рәйсә белән Миләүшә дә, Рәсимә дә Казанга ыргылды. Раузаның юлламасы Зәйгә иде, ахры. Ничек итсә-итте Аниянең партадашы, тәки Казанга китү ягын карады. «Барыгызга да шәһәргә китәргә димәгән, авыл җирендә дә укытучылар бик кирәк», – дип, рус теле укытучысы Фәния Кашаповна ни үгетләп караса да, Раузаның фикере үзгәрмәде. «Авылдагы күршеләренә кунакка кайтып йөри торган Казан егете сәбәпче түгел микән моңа?» дип, мәсьәләгә ачыклык кертергә тырышты барысын белеп-күреп торучы Мөсфирә. Ул үзе инде колхозга баргач танышкан егетенә укуын тәмамлар-тәмамламас ук кияүгә дә чыгып куйган иде, шуңа күрә аңа баш ватасы булмады. «Шагыйрә» Миләүшә педучилищеда комсомол секретаре булып калды. Дүрт ел бергә уку дәверендә туганлашып диярлек өлгергән егетләр-кызлар кайсы-кая төрле якларга таралышты.

Хуш, Арча! Хушыгыз, курсташлар! Начарлык белән искә алмагыз безне, кырыс-гадел укытучыларыбыз Хөсәен Фатыйхович, Гөлсинә апа, Шәйхенур абый-Коменский!.. Сау булыгыз, Гарәфи бабай, Мәймүнә әби, Мөслимәкәй! Аниягез Казанга китә, башлангыч класслар укытучысы булып.

Нишлисең бит, Арчаларда калып булмады... Үзенә насыйп бәхетен эзләп, яшь укытучы – авыл кызы Ания – башкала якларына юл тотты.

***

Рус мәктәбендә, рус классында укыткан ун ел гомере Анияне шигырьләрдән, татар мохитеннән, татарлыгыннан да читләштерде бугай. Училищеда укыганда башлаган зәңгәр тышлы шигырь дәфтәрен кулына алмаганга да биш былтыр. Ул хәзер «Учительская газета»ны, «Начальная школа» журналын алдыра. Арчада чакта Гөлсинә апасы Миләүшә белән икесенә берне яздырткан «Совет мәктәбе»нә дә хыянәт иткәндәй, үзен гаепле сизә кыз. Кайда калдың син, сөекле укытучыларың зур өмет баглаган татар кызы Ания? Рухың чүккән, җаның нәүмиз... Күңелең дә үзеңнән разый түгел бит синең! Шушы идеме әниең, Гөлсинә апаң, Шәйхенур абыең тәкрарлаган «башкаларга охшамаган» Ания?! Ул инде кияүдә, ике ул үстерә. Алай ук гөнаһлы түгелдер-түгелен: ни генә булса да, Ания балаларын Аллаһ Үзе әманәт иткән туган теленнән аермады. Әни вазифасын төгәл үтәп, аларны үз телендә сөйде, назлады, сөйләшергә өйрәтте. Балаларын татар балалар бакчасына бирә алмау үкенече генә аның күңеленә корт булып төште.

Гүя Күкләр Аниянең теләкләрен ишетте. Тарихи 1990 ел барысын да үзгәртте дә куйды. Әлбәттә, бу кисәк кенә булмады. Татарстан суверенитеты турында Декларация кабул ителү, татар теленә киң мөмкинлекләр ачылу Анияне «Совет мәктәбе»нә кире кайтарды.

Анияләр, «Яшьләр торак комплексы»ннан фатир алып, Казанның башка районына күчеп киттеләр. Рус мәктәбендә ун еллап тәҗрибә туплаган укытучы ханым, ике баласын да янына алып, яңа ачылган балалар бакчасына татар төркеменә тәрбияче булып эшкә урнашты. Югары белеменә караганда, Арча педучилищесын тәмамлау турындагы Кызыл дипломын кулында әйләндергәләп, «нәкъ безгә кирәк кеше икәнсез» дигәндәй, баштанаяк бер сөзеп карагач, бакча мөдире Аниянең үзенең дә тәрбияче булып эшкә килү шарты белән генә улларын бакчага аласы итте. Берәм-берәм татар сыйныфлары, татар төркемнәре ачылган ул елларда телне камил белгән, яхшы методик әзерлекле педагогик кадрларга ихтыяҗ зур иде.

«Совет мәктәбе» журналы да, үзенең тарихи башлангычына кайтып, яңадан «Мәгариф» исемен алды. Ания кабат яздыра башлаган үз журналы, инде фикерләве, теле шактый шомарган укытучы сүзләре белән әйтсәк, Татарстан Республикасының дәүләт телләре турындагы канунын тормышка ашыруга, республика гражданнарының үз туган телендә белем алуга Конституция билгеләгән хокукларын гамәлгә куюга, мәгариф өлкәсенең милли тәрбия бирү системасы эшчәнлеген үстерүгә саллы өлеш кертә башлады. Яңа социаль юнәлешләр билгеләнү һәм элеккеге идеологик кыйммәтләрнең акрынлап юкка чыга баруы шартларында тиражы ике дистә мең чигенә җиткән журналга укытучылар һәм тәрбиячеләр дистәләп-йөзләп тартылдылар.

Өч-дүрт ел балалар бакчасында, аннан алты-җиде еллап татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшләү тәҗрибәсе Ания Юныс кызын республиканың югары категорияле педагоглары сафына бастырды. Алай гына да түгел, «Ел укытучы»сы конкурсында районда җиңү яулаган тәҗрибәле педагогка «Мәгариф» журналы җитәкчеләре дә «күз төшерде».

Аниянең иҗат кешеләре, язучылар дөньясына якынаю теләге, каләменең яңадан «аягүрә» басуы аның эш алыштыру уен ныгытты.

Ире:

– Мин шагыйрьгә түгел, укытучыга өйләндем, – дип, үз сүзен кистереп әйтте. Әнисе дә, укытучылыгын кызы түгел, үзе ташлаган шикелле чын кайгыга төшеп, аяк терәп каршы чыкты:

– Гаиләңне, балаларыңны кара. Редакция тирәсендә җыен семьясыз, ялгыз ир-ат инде анда, – дип, үзе күреп-белгәндәй, «җитди» сәбәп уйлап тапты.

Ания әҗәл авыруы тиеп түшәктә яткан әнисенә, җайлап кына аңлаткандай итте:

– Әни, мин бит укытучылар журналына барам, теләсә кая түгел. Үзең беләсең, җырларым да танылды, шигырьләр дә язылып тора. Балалар үсте бит инде. Әни, минем язасым, китап чыгарасым килә... Аннары, «Мәгариф»тә хезмәт хакы да укытучыныкыннан ике-өч тапкыр артыграк икән, – диде Ания, ял иттерергә үз аркасына терәп утырткан авыру әнисенең башына башын куеп. Ана кеше:

– Мин арыдым, кызым... Үзең кара... Уең трамвай мөгезе кебек – күккә, аягың, трамвай рилселәргә тоташкандай, җиргә нык береккән булсын. Туры юлыңнан чыкма, – диде алҗыган ана, сулышын көчкә ала-ала, ястыгына ымлап. – Мин арыдым, балам...

Ания әнисенең «арыдым» сүзендә әллә ничә төрле төсмер ишетте. Тамагына төер утырды. Әтисе вафат булганнан соң да бик бетереште әнисе. Сөйләшмәс булды, гел уйланып, айлар буе хаста сыман йөрде. Аннан каяндыр менә бу «өч хәрефле» зәхмәт килеп чыкты. Гомер буе төпкә җигелеп тормыш йөген тартудан, булган хәл-егәрен, яшәү дәртен алган чиреннән хәлсезләнгән ананың «үзең кара» дигәнен ул хәер-фатиха дип кабул итте. Ания, әнисен җайлап яткырып, кече якка чыкты. Аның китәргә җыенасы бар иде.

Китәр алдыннан Рәхимә апа кызын янына чакырды.

– Ач әле шул сандыкны, – диде ул, карават башында торган зәңгәр сандыгына таба кулы белән төртеп күрсәтмәкче булып. Кулы, яралы кош канатыдай, аңа буйсынмыйча, караватка салынып төште. – Элегрәк тә бер бирмәкче идем... Әбиеңнең төсе гәрәбә муенсаны ал... Уң як тартмасында, зәңгәр шакмаклы кызыл тастымалга төргәндер. Анысы да әбиеңнән калган истәлек. – Әнисе, хәл җыйгандай, төсе качкан иреннәрен кысып, беравык күзен йомып торды. – Сандык төбендә... сул як почмакта... үзеңнең юка зәңгәр яулыгыңа төргән, теге чакта мине һуштан яздырган чәч толымың... Алып кит... Дөньяның төрле хәле бар... Акчага тилмергән чагың да булыр... Ни генә булса да, сакла аларны. Мине сагынганда, сөйләшәсең килгәндә, алып карарсың... Сиңа дигән башка әйберләрем... чигүле ак төенчеккә төргән. Аларын мин киткәч алырсың. Киленгә әйттем, аннары бирер, – диде ана, сулышын авырдан алып. – Әле күрешәбез, беләм... елама, балам... Ана белән кыз кочаклашып аерылыштылар.

...Яраткан хатыны җайлап-көйләп, эштән китү теләген ышандырырлык итеп әйткәч, хезмәт хакларын да аңлаткач, ире, «теләсәң кая кит» дигәндәй, кулын гына селтәде.

Мәктәп директоры Илүзә Исмәгыйль кызы, күз төбәп торган алдынгы укытучысының беренче гаризасын ертып, җилкәсе аша артка чөйде. Икенче гариза секретарь аша теркәлеп керде. Аниягә яңа уку елыннан завучлык эшен дә тәкъдим итеп карадылар. Әмма китү карары кабул ителгән иде инде. Эш алыштыру мәсьәләсе шулай хәл ителде.

**4**

Ания Юнысовна редакциягә килгән хатларны укып-барлап утыра. Менә берсенең конвертында «Матур язу» дәфтәре үрнәгендәге кебек тигез энҗе бөртекләредәй хәрефләр тезеп язган таныш кулны танып, озак кына ачарга кыймыйча торды. Хат педучилищедагы укытучысы Шәйхенур абыйсы Гайнетдиновтан – «Коменский»дан – аның шактый вакыт элек язган хатына көтелгән җавап иде.

Вак хәрефләр белән дәфтәрнең куш бите шыплап тутырып язылган бу хат аны яшьлегенең иң саф, иң самими еллары узган газиз Арчасына алып кайтты. Күз алдына әнисе кебек якын күргән Гөлсинә апасы килеп басты. Якты бер сагыш белән елмаючы укытучы апасы... Ул юк инде... Әмма елмаюы күз алдыннан китми. Шәйхенур абый ничекләр яши икән ансыз?

Ания ханым күзләренә мөлдерәп тулган күз яшьләре элпәсе аша хәрефләрне аермачык күрмәсә дә, хатны ашыга-ашыга укый башлады.

«Исәнме, хөрмәтле Ания!

Син миңа язган көннәрне мин Арча хастаханәсендә йөрәк инфаркты белән авырып ята идем. Икенче мәртәбәсен. Хәзер, Аллага шөкер, чыктым. Менә язам.

Бик зур рәхмәт, язмамны журналның 10 нчы санына планга кертүегезгә.

Соңлап булса да, сине яраткан журналыбызда бүлек редакторы булып эшли башлавың белән чын күңелемнән котлыйм һәм эшеңдә уңышлар телим. Гөлсинә апаң да сөенер иде. Аның 70 еллыгына багышлап «Мәгърифәт» газетасында чыгарган мәкаләң өчен аерым рәхмәт!

Менә шундый хәлләр, Ания... Дүртенче ел инде аның юклыгына ияләнә алмыйм. Апаң, минемчә, бертуганнарының фаҗигале үлеменең кайгысын күтәрә алмады. Элегрәк бер ятып авырмаган да килеш, кинәт баш миенә кан савып китеп барды шул. Бер генә дә исемнән чыкмый... Бәрәңге тәпкеләгәндә, туганнары фаҗигасеннән соң эче тулы кайгы булса да, балаларга сиздермәс өчен, көлә-көлә: «Әнкәй менә шулай тәпкели иде» дип сөйләнә-сөйләнә, бураэнага кинәт авып төшә. Ике яктан ике киленебез – Фәридә белән Рузалия тотып торгызалар. Көлгән вакытында күзләрен ничек йомган булса, кабат ача алмады. Реанимация бүлегендә соңгы сулышын алды. Шул елмайган килеш гүргә иңдердек. Ләхеттә дә шул килеш ятадыр инде. Мине ул вакытта яшен суккандай булды. Һаман айный алмыйм. Зиаратыннан кайтып кермим.

«Мин укыганда Гөлсинә апа түгәрәгенә йөрдем, шигырьләр яза идем», – дигәнсең. Ничек хәтерләмәскә! Гөлсинә апаң синең белән бик горурлана иде. Дөресрәге, икебез дә синең уңышларга сөенә идек. Апаң кинәт шулай китеп баргач, күңелне тынычландыру өчен, аңа багышлап альбом төзедем. Ул альбомның бер битенә апаң белән бергә төшкән фотокарточкаңны

куйдым. Хәтерлисең микән: педучилищега Гомәр Бәширов, Сибгат Хәкимнәр килгәч төшкән бик матур фото ул...

Апаң, бакчада ялгыш сынып төшкән сып-сырма җиләкле бер кура ботагын вазага алып кереп утыртып, синең «Кура җиләк» җырыңны җырлап, икәүләп сине искә алып, горурланып утырган идек бер. Шул да искә төште менә.

Арчага кайтсаң, туп-туры безгә кил. Мин улыбыз Хәлил, киленебез Рузалия, оныкларым Җәлил, Илгизәр һәм бәләкәй оныкчыгым Гөлсинә белән яшим. Кайткач, керми калма. Бер сөйләшеп утырырбыз.

Бу хезмәтеңдә дә, иҗатыңда да уңышлар теләп хат язучы Шәйхенур абый дип белерсең.

27 август, 2000 ел».

Ания Юнысовнага кинәт никтер уңайсыз, хәтта оят булып китте. Училищеда укыганда, Гөлсинә апасы бераз кәефсезрәк булса, ул моны гел Шәйхенур абыйсыннан күрә иде. Шуңа күрә аңа эчендә ачу да саклагандай йөрде. Менә бу хатны укыганда, аның күңелен бер үкенү хисе биләп алды. Укытучысыннан кичекмәстән гафу үтенәсе килде. Уйлары бертуктаусыз алар тирәсендә бөтерелде. Гөлсинә апасы киткәннән соң туган оныкчыкка әбисенең исемен кушканнар. Кемгә охшаган икән сабый?

Менә чын укытучы нинди була ул! Аның сиңа төпле белем бирүе әле бер нәрсә, ул бит үзе укыткан укучыларын үзенеке саный. Аларны кеше итәсе килә. Тикмәгә генә тотып орышамы ул сине, үз баласын орышкандай! Күр ничек горурланганнар аның белән укытучылары. Ялгышлык җибәрмәсен, түбән төшмәсен дип, аталарча, аналарча кайгыртканнар аны. Хөсәен Фатыйхович та, хәтта Гарәфи бабай да тикмәгә генә артыннан саклап йөрмәгән инде. Тиле-миле чаклары. Сабыйлыктан чыкмаган 15-16 яшьлек кыз бала. Ялгышып куюы да бар, дигәннәр бит алар. Синең белемең өчен генә түгел, тәүфыйгың, сафлыгың, иманың сагында да торганнар. Шатлыгыңны-кайгыңны да үзләренеке иткәннәр. Укып чыгып, еракка киткәч тә, һәр уңышыңны үзләренеке дә санап горурланалар, кечкенә генә ялгышыңның да сәбәбен үзләреннән күреп, йокысыз төннәр кичерәләрдер.

...Ания ханым, өйгә кайткач та, бер кат эшләрен тәмамлагач, училищеда укыганда алып барган көндәлек дәфтәрен эзләп тапты.

Үзе истәлекләр укый, үзенең күз алдында мәрхәмәтле, нурлы йөзле, күркәм холыклы Гөлсинә апасы. Гади генә киенер, кершән-фәлән кулланмас иде. Өстендә һәрвакыт диярлек зәңгәрсу төстәге трикотаж костюм-итәк булды. Юкарак коңгырт чәчен артка шома итеп тарап, җыйнак кына итеп йөртер иде. Ул чакта укытучы апалары илле яшьләр тирәсендә булган икән. Шәйхенур абый язганча, йөзе гел балкып торыр, үзе, күзләрен кысып, гел елмаер иде җанашым. «Җанашым» диясе генә килә бит якты сагыш иясе Гөлсинә апаларына! Дүрт ел уку дәверендә Ания аның үзләренә бер генә тапкыр да тавыш күтәргәнен хәтерләми. Бәлки моңа сәбәп тә булмагандыр. Барысы да Гөлсинә апаларын яраталар, сүзен тыңлыйлар, аны рәнҗетергә кодрәтләреннән килмәс тә иде шул. Янәшәсендә – бераз корырак, дары кебек «дөрт» итеп кызып-кабынып китүчән, әмма тиз кайтып төшүчән, гадел йөрәкле Шәйхенур абыйлары. Бәхетле һәм бер-берсенә бик тиң булганнар икән бит алар! Яраткан бит ул Гөлсинәсен! Ания теге чакта уйлаганча,

юк, «үзәгенә үтмәгәндер»... Яратмаса, яшьлегендә үк, әле өйләнешкәнче, «Укытучы Гөлсинә» дип аңа багышлап җыр язар идеме? Бу җыр хакында Шәйхенур абыйсы хатында искә алган. «Элегрәк «Совет мәктәбе»ндә чыгарган идем», – дигәч, Ания Юнысовна эзләп тапты ул җырның сүзләрен. Тырыша-тырыша рус мәктәбенә хезмәт иткән, журналны алдырмаган чагы булган шул, югыйсә күрми калыр идеме?!

Укытучы булып кайтты авыл кызы Гөлсинә.
Мәктәптә ул балаларга белем нурлары сибә.
Укытучы Гөлсинә,
Белем нурлары сибә.
Ягымлы елмаю белән балаларны карата.
Укучылар, ата-аналар шуңа күрә ярата.
Җәйгә чыккач, поход ясап, баралар калаларга.
Мәңге онытылмаслык хисләр уята балаларда.
Укытучы булып калды авыл кызы Гөлсинә.
Көндез – эштә, кич клубта белем нурлары сибә.
Укытучы Гөлсинә,
Белем нурлары сибә.

Җырны үзенчә көйли-көйли, Ания ханым көндәлеген укуын дәвам итте. Ә-ә-ә, менә, менә! Бу юлларны 1978 елның 1 октябрендә язып куйган булган:

«Бүген шигырь сөючеләр түгәрәгенә язылдым. «Тукай якташлары» дип атала. Җитәкчесе – татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гөлсинә Рәхмәтулловна. Һәрберебездән кайдан килүебезне, әти-әниләребезне сорашып чыкты. Гөлсинә ападан да үзе турында сөйләвен үтендек. Ул Сарман районыннан икән. Авылларының исеме бигрәк кызык – Күтәмәле. Алабуга педучилищесын тәмамлаган, шунда ике ел укытучылар институтында белем алган. Аннары Казанда да институтта укыган әле. «Яраткан укытучыгыз бар идеме?» дигәч: «Иң яратканы – күренекле шагыйрь, әдәбият белгече һәм фольклор галиме «Кәрим Җаманаклы» псевдонимы белән йөргән Рәшидов абый иде», – ди апа. Кабатлатып, шигырь дәфтәремнең артына язып куйдым. Кызлар миңа: «Журналист мәллә син?» – дигән булалар. Көндәлеккә язып куясым бар димәдем инде.»

Гөлсинә апа дәрестә үзе күп сөйләми иде. Ул тема, юнәлеш бирә, эзләндерә, яздыра, укыта, сөйләтә. Хәзерге яңа белем стандартлары да нәкъ шуны таләп итә бит инде. Эзләнүчән иҗади шәхес тәрбияләүне. Гөлсинә апа шул вакытта ук хәзерге стандартлар белән белем биргән булып чыга түгелме соң? Укучыларын белем алуга илһамландырган. Аниянең язган шигырьләрен беренчеләрдән булып ул күргән, олылаган, күңеленә канат куйган. Сагына ул Гөлсинә апасын, бик сагына!

***

Шәйхенур абыйсы белән хат аша аралашулары шактый дәвам итте. Ания ханым аларны көтеп ала торган булды. Хатларның берсе аның тирән кайгысын уртаклашып язылган һәм аңа гына түгел, гаиләсенә багышланган иде.

«Исәнмесез, Ания, җәмәгатең, балаларыгыз!

Сезнең олы кайгыгызны уртаклашып хат язабыз, җаныкайларыбыз.

Әнкәйдән дә олы кеше юк дөньяда. Ни хәл итмәк кирәк, Ания! Әниегезнең урыны оҗмахта булсын!

Район газетасыннан кайгыгызны уртаклашып язган хәбәрне укыдым. Сине юатып хат язасым килде. Үземнең әнием вафат булгач, Гөлсинә апагыз белән безнең нинди хәлдә булуыбызны искә төшереп, «Гаилә альбомы»мнан хатларымны укыдым. Ул көннәргә багышлап, Сибгат ага Хәкимнең «Шигъри дәфтәре»ннән «Әнкәй истәлегенә», «Курыкканы суык иде», «Күңелең синең ак, улым» шигырләрен күчереп язып, шул хатларым янына ябыштырып куйганмын икән.

Иң якын дусларым булган шофёр Фәттахка (малайлык дустым), институтта бергә укыган Илгизгә шигъри хатлар язганмын.

Менә кайбер юлларын гына укып кара әле, Ания.

Әнәй үлде!
Бу төн...
Үз иркенә куйдым хисләремне,
Ул төн буе елап «эредем».
Иртәгесен, «берни булмагандай»,
Дәрес бирдем, тыныч йөредем.

Мин ул чакта завуч булып эшли идем. Гөлсинә апаң татар теле укыта. Бер атна гына алдан кайтып, әнәй белән бәхилләшеп килгән идек. Апрель ае. Кама иделе ташыган чак. 108 км ара. Язгы ташуга – Камага үзе төшеп харап булыр дип, миңа ашыгыч хәбәр җибәрмәгәннәр. Үзләре кадерләп җирләгәннәр.

Укыганың бардыр, бәлки, Сибгат аганың әнисенең вафатына язган шигырьләреннән бер генә строфасын языйм әле:

Курыкканы суык иде аның,
«Җылы чакта алсын, – дип, – кабер»,
Әйтә иде бик еш...
Әнкәй үлде.
Үч иткәндәй, тышта – декабрь...»

Ания ханым хатны укып бетерә алмыйча, сулкылдый-сулкылдый еларга тотынды. Аның әнисе дә бит, нәкъ Сибгат ага язганча, җылы чакта китсәм иде, ди торган иде. Үч иткәндәй, менә ноябрь ахырында, җир туңдырып, кар яугач вафат булды...»

Шәйхенур абый хат ахырында Ания ханымга сабырлыклар, җиңеллек теләгән, кунакка чакырган иде.

Аниягезнең яралары яңа шул әле, Шәйхенур абый. Алардан кан саркый. Тыелгысыз сагыш һәр күзәнәген әрнетә.

Хат 27 ноябрьдә, Ания ханымның әнисенең вафатының икенче көнендә үк язылган иде.

Аһ, Шәйхенур абый, аһ!

Сез дөнья бәһасе, зирәк акыллы педагог кына түгел, Аниягезнең шатлык-кайгысын, аталарча, үзенеке итеп кабул иткән олы йөрәкле чын егет солтаны да икәнсез бит! Сез сөекле хатыныгыз Гөлсинәнең хәтеренә мәңге хыянәт итмәячәк, шагыйрь җанлы «мәҗнүн» дә икәнсез! Сез өч улыгызга

кырыс-таләпчән ата гына түгел, тудырып-үстергән әнәй-әнкәегезне бар җаны, вөҗүде белән яраткан, хөрмәт иткән, кадерләгән, аның әле дә сабый күңелле улы икәнсез!

...Шәйхенур абый, инде сирәгрәк язса да, хатларында гел язмыш-тәкъдиргә ышануын, балаларыннан, киленнәреннән разый булуын әйтә, Аниягә дә изге теләкләрен, аеруча сабырлык тели, ике сүзнең берендә Аллаһы Тәгаләне искә ала иде.

Чын ихластан, вакытын, көчен кызганмыйча язган, кайчак – озын, кайчак кыска гына әлеге хатлар Аниягә тормыш дәресе, ачыктан-ачык әйтелмәсә дә, юл араларына салынган үгет-нәсихәт, бу дөньяда, аеруча укытучы кешегә, бар яктан үрнәк шәхес булып яшәүнең никадәр зур, җаваплы вазифа булуына ым-ишарә дә иде.

Шәйхенур абый, сизелмичә узган еллар агышында, укучысы Аниянең бер-бер артлы чыккан китаплары, аның сүзләренә язылган җырлар, алган исемнәре, дәүләт бүләкләре өчен, үз уңышларына сөенгәндәй сөенә; хәл белешеп торганга рәхмәт укый; педучилищега очрашуга кайтса, чамасы барында килә иде.

«Авырып торам әле. Менә бераз хәл кергәч, Гөлсинә апаң янына барып, синең уңышларыңны сөйләп куандырып кайтырмын, сәламеңне тапшырырмын», дип яза иде.

Көннәрдән бер көнне Арчадан хат-хәбәр килмәс булды. Шәйхенур абый, соңгы вакытта язган бер җырындагыча: «Пар канатым сынгач, Гөлсинәкәй, таба алмадым алмаш, җанашым» дип, гел елмаеп төшләренә кергән Гөлсинәсен юксынып, аның артыннан китеп барды.

Ания ханымның җанын баштарак иң кадерле кешеләрен югалту бушлыгы биләде, исенә төшергән саен, үзәк бәгырендә мәңгегә аерылу ачысы сулкылдап-әрнеп торды. Ни гаҗәп, тора-бара бу сызлануны башка бер хис алыштырды. Ул кадерле укытучылары Шәйхенур абыйсы белән Гөлсинә апасын элеккечә, ерак яшьлегендә күреп иянгәнчә, гел янәшә күз алдына китерде.

«Мәңгелектә кавышканнардыр....?» дип тә уйлап куя иде. Шул вакытта, йөрәк тибешенә кушылып, аның бар калебен, вөҗүден, Гөлсинә апасының назлы елмаюы сыман, якты сагыш биләп ала, аңа газиз укытучыларының әманәтен – Күкләр насыйп иткән кадәр гомереңдә чын кеше булып яшәргә кирәклекне исенә төшерә иде.



*Әминә Хиса кызы Газаева (1993) – Кабарда-Балкар Республикасының Яникой авылында туган. Бала чагыннан шигырьләр яза. Шигырьләре мәктәптә укыганда ук «Заман», «Тау кызы» («Горянка») газеталарында, «Мәңге Тау» журналында басылып чыккан. 2008 елда Төньяк Кавказ республикаларының яшь шагыйрьләре киңәшмәсендә катнаша. Кабарда-Балкар аграр университетын (2015), Кабарда-Балкар дәүләт университетын ((2021) тәмамлый. 2021 елдан «Эльбрус» нәшриятында эшли. 2016 елдан Кабарда-Балкар һәм Россия Язучылар берлекләре әгъзасы.*

Әминә
Газаева

# ЙӨРӘГЕМ ЯКТЫРА КҮҢЕЛЛЕ УЙЛАРДАН

## Айлы төн

Айлы төн, күгендә җемелди йолдызлар,
Салмак җил тарата гөлләрнең хуш исен.
Йөрәгем яктыра күңелле уйлардан,
Алладан барсына ярлыкау телисең.

Йолдызлы диңгездә тулган ай чайкала,
Яктыртып җир өстен үзенең нурында.
Айлы төн тып-тыныч, изерәп йокыга
Талган да төш күрә ярату турында.

Йокла син, Балкарым, мин бишек җырымны
Багышлыйм синең һәр авылың, йортыңа.
Йокысыз чишмәләр көен мин күбәләк
Канаты җилендә аламын җырыма.

Таралыр җырларым Ватаным өстенә.
Тынычлап йокла син, и минем Балкарым.
Тынлыгын илемнең күктә ай сакласын,
Айлы төн яктысын алсын ал таңнарың.

* * *

О хатын-кыз! Күлмәгеңнең
Итәге бүген кыска.
Кайда гадәт, оят кайда?
Атлап килеше үк әйтә:
Минеке бул, кил, әйдә!

Акылга буйсынмый кулы,
Алдана ул, күлмәгенең
Итәге ерык төптән.
Һай ачы да соң язмышы,
Шәрабы кебек, эчкән...

## Тәкъдир

*Ил авызы – иләк.*
Әйтем

Шигырьләрдә ялвару бар, теләк...
Бертуктаусыз или безне иләк.
Он өеләр бара зур күч булып,
Торып кала төптә тик кибәк.

Камыр басам аннан мин ул оннан...
Нәтиҗәсе булып эшемнең,
Икмәк булып пешеп чыксын өчен,
Көче кергән күпме кешенең!

Рәхмәтем зур! Мин олылап сезне,
Алдыгызда чүгәм теземне.
Шикләнмичә кабул итегез, дим,
Ихлас әйткән рәхмәт сүземне.

Гел буш түгел минем басуым да:
Урам, сугам, җыям икмәген.
Заманыма торыр уңышым бар –
Язган җырым – минем иккәнем.

* * *

Без китсәк тә яңа көнне котлап,
Яшел чирәм чыгачак шытып.
Йөрәгемдә бүген якты бер уй
Күңелемне тора җылытып.

Ямьсез уйлар качсын күңелләрдән,
Зарланудан безгә ни файда?
Яңа көнгә карап шатланыйк без,
Матурлыклар күреп дөньяда.

Без китсәк тә яшь агачлар үсәр,
Тормыштан бит гыйбрәт алырлык.
Бу дөньяда бөтен бәндәне дә
Аллаһ сынар, биреп авырлык.

Беләм, калыр җирдә итагатьлек,
Ни буласын алда кем белгән.
Вакытлыча яшибез бит җирдә,
Ник куркабыз икән үлемнән?

* * *

Нинди матур бу тормыш:
Таш та ятмый юлыңда.
Бәхетең үз кулыңда,
Агач та сау, чишмә дә...
Нинди матур бу тормыш!

Нинди гүзәл бу тормыш:
Болытлар йөзә күктә.

Өмет уты йөрәктә,
Тау яшәрә еракта.
Нинди гүзәл бу тормыш!

Нинди татлы бу тормыш,
Беркем белдерми дәгъва,
Иркенлек – хис-уйларда!
Аллаһ күрә барысын.
Тормыш гел шулай барсын!

*Балкарчадан* **Рафис КОРБАН** *тәрҗемәләре.*

# ӘДӘБИЯТ ФӘНЕ АКСАКАЛЫ

## ТӘЛГАТ ГАЛИУЛЛИНГА 85 ЯШЬ

Без, җир кешеләре, ике үлчәмдә яшибез: вакыт һәм урын киңлекләрендә. Әмма аларның яшәү өчен биргән мөмкинлекләре бер-берсеннән нык аерыла. Урын киң күңелле, әле йөрәгең тибә икән, ул үзенең бер мөешендә тереклек итү мөмкинлеген кызганмый. Ә менә вакыт бу яктан кырысрак, ул гомерне чикләргә ярата.

Мондый уйланулар күңелебезгә Тәлгат Нәбиулла улы Галиуллин шәхесе һәм эшчәнлеге турында фикер йөртү барышында туа икән, бу, мәгълүм бер җырда әйтелгәнчә, һич тә юкка түгелдер. Каләм ияләренең иҗат нәтиҗәләрен, язучымы, шагыйрь булсынмы, әллә әдәбият белгече, яки тәнкыйтьче дисеңме, эзлекле рәвештә вакыт яктылыгына куеп караучы, еллар, чорлар рентгены ярдәмендә үтәли күз ташлау сәләтенә ия шәхеснең асылын ачыклый башласаң, шулай ук Тәлгат Галиуллин исеме дә аңга килә. Китап киштәләребезгә ул куйган хезмәтләрнең исемнәрен генә хәтердән уздырыйк: «Еллар юлга чакыра», «Безнең заман – үзе җыр», «Заман сулышы», «Гомер учагы», «Замана балалары»... Әлеге «заман», «еллар», «гомер», «гасыр», «дәвам» сүзләренең вакыт төшенчәсе белән бәйләнешле гыйбарәләр икәнлеге бәхәс тудырмый. Аларны шушы рәвешле киң мәгънәдә кулланучы авторның вакытка төшенчә итеп кенә түгел, бәлки ниндидер тирән мәгънәләр салырга омтылганы шәйләнә. Әйе, иң гадел һәм дөрес хөкемдар – вакыт. Т.Галиуллин кыл иләкне эстетик бәяләүнең төп коралы итеп алган икән, бу аның хакыйкый үзәкне табуны тәэмин иткән акыл камиллегенә ия икәнлеген күрсәтә.

Иҗат, фән белән кызыксынып китү бервакытта да очраклы урында гына барлыкка килми. Моның өчен элгәрләр тудырган тәҗрибә һәм мохит булуы шарт. Бу бик күп олуг шәхесләр мисалында расланган хакыйкать. Т.Галиуллинның бәхетенәдер, аңа остазларның да фәндә иң абруйлылары туры килә. Әйтик, күренекле галим Х.Госман, университетта эшләвенең башыннан ук, биредә татар шигърияten һәм нәзари, һәм гамәли яктан эзлекле өйрәнү мәктәбенең фәнни нигезен салды. М.Бакиров, Ш.Садретдинов, З.Мәҗитов, Х.Миңнегулов, Ә.Шәрипов кебекләр шушы мәктәпнең талантлы шәкертләре булды. Алар шигъриятебезнең тамырларын барлауны ерак дәверләрдән башладылар һәм ныклы нигезгә куйдылар. Бу өлкәдәге борынгы традицияләрне хәзергеләре белән үреп өйрәнүдәге Н.Юзиев эзләнүләрен аерым искә алырга кирәктер, чөнки ул хезмәтләре белән бу өлкәдәге үсешне тагын да бер баскычка күтәрде һәм эстафетаны Т.Галиуллинга тапшырды. Тәлгат Нәбиулла улы, моңа кадәр эшчәнлеген башка мохитләрдә дәвам иттерсә дә, үзенең шушы фәнни мәктәп шәкерте икәнлеген онытмады, өлкәннәрдән мирас булып калган юнәлешне тиешле югарылыкта дәвам иттерүне намус эше дип карады. Аннан инде, альма-матерга әйләнеп кайтып, турыдан-туры әлеге фәнни мәктәпнең эшчәнлеген тагын да бәрәкәтле итеп җәелдереп җибәрүдә үзен тынгысыз галим һәм оста оештыручы итеп раслады. Шул рәвешле, Казан университеты күп еллар буена татар шигърияте фәненең үзәгендә торды дип, авыз тутырып әйтәбез икән, шуңа бәйле рәвештә ике гасыр арасында шушы эзләнүләрнең уртасында булган Т.Н.Галиуллин хезмәтләрен дә тәкъдир итәбез дигән сүз.

Татар әдәбияты белемендә, тәнкыйтендә, соңрак проза әсәрләре тудыруда, бөек шагыйребез әйтмешли, «ат уйнаткан», белем-мәгърифәт таратуда армый-талмый эшләп килүче Тәлгат Галиуллин, чыннан да, үз тормышында нинди генә игелекле юллар

сапмады да, үзе белән иҗади сәфәргә алып чыгып, кемнәрне генә хәерле сукмаклардан кертеп җибәрмәде? Алар тора-бара үзләре дә, әлеге сукмакларны киңәйтә-киңәйтә, алгарышны тәэмин итүдә остазлары үрнәгендә хезмәт куялар.

Татар шигърияте – төрки халыклар арасында аеруча камиллеккә ирешкән сүз сәнгатьләреннән берсе. Егерменче гасырга ул бик зур казанышлар белән килде. Аның бүгенге хәлен өйрәнү өчен, гасырлар түрендәге үсеш тарихын һәм кануннарын белү таләп ителгән кебек, үткәне турында уйланганда да, хәзерге казанышларын исәпкә алып эш итми булмый. Шигъриятебез зур булган кебек, шөкер, аны өйрәнүче галимнәребез дә була торды. Бу юнәлешнең дәвамчанлыгын тәэмин итәргә, сүз сәнгатебез фәнен аның үзенә бәрабәр югарылыкта тотарга кирәк иде. Фән үсешенең барышы, телиме-теләмиме, Т.Галиуллин җилкәсенә дә әнә шундый йөк салды.

«Телиме-теләмиме» дип әйтү сүз сөрешендә генә килеп чыккан гыйбарә. Теләмиме соң? Дөресендә, Т.Галиуллин шушы миссияне үтәү өчен туган кебек тоела. Ул бу хакта үзе дә уйланган. Тәрҗемәи хәленә багышланган бер язмасында болай ди: «Табигать-хуҗабыз, туган анам сурәтле фикерләү хасиятен иңдереп тудыргандыр». Чынлыкта да ул шигъриятне өйрәнүне башыннан ук кыйбла итеп алды да шул юлыннан бервакытта да тайпылмады. Аны шигъряткә тагын да гашыйк итүче Г.Тукай булды дип әйтү дөрес булыр. Т.Галиуллин бөек шагыйребез иҗатын гомер буе өйрәнә, башка авторларга мөнәсәбәтле, яки гомуми темаларга карата язылган хезмәтләрендә дә даһиебыз мирасына мөрәҗәгать итү аның өчен гадәти хәл. Шунысы мөһим, Г.Тукайны, милли сүз сәнгатебез кысаларында гына түгел, дөнья әдәбиятлары контекстына караш ташлап бәяләргә дә омтыла. Нәкъ менә шул чолганышта, ягъни дөнья классикасы югарылыгында фикерләүдә, Г.Тукайның милли һәм хосусый хасиятләре ачыла да. Шул рәвешле, фәнни тикшеренү юнәлеше үзе иҗади диалоглар мәйданына алып чыга. Галимнең җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп иткән «Г.Тукайның Казан чоры иҗаты – дөнья әдәбияты белән керешүдә югары баскыч» дип исемләнгән мәкаләсе аның бу мәсьәләдәге җыеп әйтелгән сүзе буларак кабул ителә. Үзе икрар иткәнчә, әле Г. Тукай иҗатында рус һәм Көнчыгыш әдәбиятлары параллельлеге мәсьәләсе төгәл генә ачыкланып бетмәгән. Әмма бу чикләрне киңәйтүдә, әлеге аспектны Көнбатыш Аурапа әдәбиятлары мәйданында карауда күпмедер башлангычлар булса да (әйтик, Э.Г.Нигъмәтуллин хезмәтләрендә), әмма аны канәгатьләнерлек дәрәҗәдә хәл ителгән дип карап булмый. Галим әлеге гамьне фәнни җәмәгатьчелек алдына кую ягыннан гына түгел, бәлки бу юнәлешне гамәлдә дәвам иттерергә алынуы белән хөрмәт уята. Галим җыйнак кына мәйданда шушы зур бурычны хәл итүнең юлларын күрсәтә һәм Г.Тукайның, шагыйрь һәм фикер иясе буларак, дөньякүләм танылган корифейлар янында һич тә икенче планда калмавын, бәлки алар фикер йөрткән юнәлешләргә һәм образлылык тудыру чараларына милли төсмерләрне табигый кушу юлы белән үзеннән өлеш өсти алуын күрсәтә.

Бу җәһәттән хезмәттә Г.Тукай тарафыннан У.Шекспир, Һ.Һейне, Ф.Шиллер, В.Гёте мирасларыннан этәрелеп китеп иҗат ителгән әсәрләр яки ирекле тәрҗемәләр тикшерү объекты итеп алына. Галим әлеге дөнья классикларының образлы фәлсәфи фикерләүләренең хасиятләрен яхшы сиземли һәм шуларның татар шагыйре иҗатына саркып чыгуының нечкәлекләрен күзәтү һәм билгеләүдә кыенлык кичерми. Әлеге мәкалә, күләме белән зур булмаса да, зур тикшеренүләр үткәрүне таләп иткән һәм бу юнәлешле әдәбиятны шактый җентекләп өйрәнү нәтиҗәсе булып барлыкка килгән. Чит телләрдә дә басылып чыккан очракта, ул бөек шагыйребез шәхесен һәм иҗатын дөньяның башка төбәкләрендәге фикер ияләренә танытуда мөһим бер адым булыр иде.

Әллә кечкенәдән үк шигырь яраткангамы, әллә Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә шигъряткә аерым бер игътибар биреп укытулары нәтиҗәсеме, ул татар шигъриятенең бөтен үсеш тарихын үзе барлап чыгуны ният итә. Югары белем алып, туган уку йортында бер-ике ел ассистент булып эшләү чорында аның бу омтылышы тагын да ныгый төшә. Әмма әлеге колачлы өлкәнең кайсы кырыеннан тотынып тикшерә

башларга? Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләүче, халык авыз иҗаты буенча беренче фән докторы Х.Ярми аны бирегә эшкә чакыра, аспирантурага да ала. Биш-алты елда, шактый киеренке эшләү нәтиҗәсе буларак, «Хәзерге татар поэзиясе һәм халык иҗаты» дигән темага диссертация әзер була, һәм ул уңышлы яклана.

Сүз дә юк, диссертация әзерләү – дәвамлы һәм җаваплы эш. Шунысы мөһим, чын фән әһеле үзе ирешкән әлеге фәнни дәрәҗәсен аннан соңгы хезмәтләре белән даими аклап торырга тиеш. Утыз яшьтән узып баручы галим моны яхшы аңлый. Дөресендә, фәнни эзләнүләр инде аның яшәү рәвеше булып әверелә. Ул ел арты ел әдәби җәмәгатьчелеккә яңадан-яңа хезмәтләрен тәкдим итеп килә. Мондый эзлекле, максатчан үсеш тагын да югарырак нәтиҗә бирергә тиеш иде. Шулай булды да. Ниһаять, 1981 елда Т.Галиуллин, Алма-Атыга барып, тугандаш казакъ галимнәре алдында иң югары фәнни дәрәҗә алу өчен имтихан тота – докторлык диссертациясен яклый. Шулай итеп, татар әдәбияты белеме даирәсендә тагын бер тынгысыз эзләнүче пәйда була.

Ник дигәндә, аның һәрбер хезмәте әдәби сүзнең кадерен белүчеләр тарафыннан игътибарсыз калдырылмый, алардагы фикерләр, карашлар башка коллегаларының аңына күчә, цитаталар рәвешендә төрле авторларның мәкаләләрендә, монографияләрендә урын ала бара. Бу аның фән даирәсендә генә түгел, гомумән, җәмгыятьтә тоткан урынын да билгели. Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис әйткәнчә, «галим һәм тәнкыйтьче абруйлы шәхес булганда гына язучы аның сүзенә колак сала, укучы ышана». *(Харис Р. Заманга диагноз куючы // Ватаным Татарстан. – 2019. – 2 апрель. – Б. 3).* Шунысы бар, абруй үзеннән-үзе генә барлыкка килми, ул кешенең шәхси сыйфатларыннан, кылган игелекле эшләреннән, халык алдындагы бурычларына намуслы мөнәсәбәтеннән җыела. Аны казану дәвамлы һәм күп хезмәт куюны таләп итсә, шул ирешелгәннәрне саклау һәм үстерү гомер буена барырга тиешлеген дә йөкли.

Т.Галиуллин – XX йөз татар шигъриятенең үсешен бербөтен итеп өйрәнгән галим. Үзебез дә шул гасырдан килүчеләр буларак, бик яхшы беләбез, артта калган йөз еллык ил халкы өчен, гомумән алганда, бик катлаулы булды. Болар, әлбәттә, чынбарлыкның сәнгатьчә чагылышы буларак, матур әдәбиятка да кагылды. Галим гасырның төрле борылышларындагы шушы хәрәкәт барышының шигърияттәге гәүдәләнешен шактый эзлекле концепциягә нигезләнеп өйрәнде. Шунысын да искәртергә туры килә: бу очракта шигърияттәге дип кенә әйтү аның хезмәтләрен тарайтыбрак күрсәтү булырга да мөмкин. Аның уйланулары, чынбарлык каршылыкларының әдәбияттагы гәүдәләнешен өйрәнүдән килеп чыгучы фәнни нигезләнгән нәтиҗәләре сүз сәнгатенең тулаем торышына да карый иде. Бу нәрсә әдәби мираска – ул аерым бер иҗатчыга карыймы, әллә билгеле бер чоргамы – гомуми тенденцияләрне күрү максаты белән якын килү ихтыяҗын да тудыра. Һәм шуңа күрә, мәсәлән, бер жанрга караган әсәрләр турында фикер йөрткәндә, тулаем әдәбиятка хас сыйфатларның шәйләнүе гаҗәп түгел.

Сыйнфыйлык идеологиясе хакимлеге чорында бу бигрәк тә шулай булды. Чөнки әдәбиятка (сәнгатьнең башка төрләренә дә) уртак таләпләр куелу, алардан идеология ягыннан бертөрлелекне таләп итү бу «бергәлекне» тагын да көчәйтте. Сәяси карашлар өстенлек итү сәбәпле, сәнгатьлелек икенче урындагы бурыч булып калды. Әмма эстетика кануннары буенча, матур әдәбият иң әүвәл образлылык, сәнгатьлелек гәүдәләнеше булырга тиеш. Менә шушы сәяси-иҗтимагый шартларда сәнгатьлелеккә урын каламы? Калса, күпме дәрәҗәдә? Һәммә өлкәдә пролетариат диктатурасы шигарьләре хакимлек иткәндә, аның кагылгысыз үтәлергә тиешле таләпләре астында сәнгатьлелек үзенең яшәүчәнлеген ни дәрәҗәдә күрсәтә ала?

Т.Галиуллин исә егерменче-утызынчы еллар шартларында да аерым шагыйрь-әдипләребезнең халык тарафыннан яратылып укылырлык, эстетик ләззәтләнү алырлык әсәрләр иҗат итә алуларын күрсәтергә омтылды. Ягъни аның бу теманы күтәреп чыгуы, нигездә, шушы максатны күздә тотты. Дөрес, әле аның хезмәте язылган җитмешенче

елларда да мәгълүм идеология басымы юкка чыкмаган иде. Ләкин инде сүз бара торган унъеллыклар тарихка тапшырылган, бигрәк тә сугыш елларында язучылар үзләрен кысып торган кыршауларның бераз гына булса да бушануларын сизеп калган, һәм, ниһаять, алтмышынчы еллар башындагы «җепшеклек» чоры булып узган иде. Димәк, Т.Галиуллин хезмәте бөтенләй башка шартларда язылды, автор ул көннәр өчен дә шактый чамалы булган мөмкинлекләрне үз ниятләрен тормышка ашыру максатларында файдалана алды. Билгеле булганча, «җепшеклек» чоры нәтиҗәсендә бераз тышаулардан арынган каләм ияләрен алтмышынчы еллар урталарыннан соң яңадан киртә арасына кертү омтылышы инде барып чыкмады, шул көенчә алар әкренләп сиксәненче еллар урталарыннан «үзгәртеп кору» елларына барып тоташты. Нәкъ менә шушы вакытта әлеге социалистик реализм дигән үз заманында нык тамыр җәяргә тиеш булган кыршауга дәлилле бәя бирергә кирәк иде. Моның өчен нык әзерлек, татар әдәбиятыннан тыш, ил һәм дөнья сүз сәнгатьләреннән дә яхшы хәбәрдар булу кирәк иде. Әдәбияттагы, алдарак искәртелгән реализм, романтизм кебек төрләрнең бихисап хасиятләрен, гамәли каләм тибрәтүдә дөнья илләрендәге тенденцияләрне, стильләренең тотрыклы һәм үзгәрүчән табигатьләрен, бигрәк тә индивидуаль иҗаттагы чагылышларын татар сүз сәнгате яктылына куеп карау таләп ителә иде.

Фәнни фикерләү барышының ачык һәм дәлилле булуын тәэмин итүнең төп шарты – өйрәнү өчен алынган мәүзугны төбенә төшеп белү. Шуннан башка җәмәгатьчелек көткән мондый колачлы хезмәтләрнең барлыкка килә алмавы бәхәссез. Т.Галиуллин моңа әзер иде. Шуңа күрә ул китапларында һәм башка чыгышларында совет чоры шигъриятендә реализм традицияләре үсешен «социалистик» дигән аергычсыз гына карауга өстенлек бирә дә. Һәрхәлдә, гомуми контексттан моны аерып карау кыенлык тудырмый. Рус телендә әлеге мәсьәләгә багышлап чыгарган монографиясен «Дыхание времени» дип атавы да юкка гына булмавын әйтергә кирәк. Эстетик фикерләүгә заман мохите ясаган тәэсирне ачыкламый торып, алга куелган мондый бурычны башкару мөмкин түгел иде. Шул ук вакытта Т.Н.Галиуллин, җитмешенче еллардан торып, узган унъеллыкларны бары тик кара буяулар белән сыйфатлау юлыннан да китмәде. Чөнки идеология беренчел дип каралган бу чорда да бездә бөтенләй үк сәнгатьчә камил әсәрләр тумады дип кистереп әйтүдән сакланырга кирәк иде. Т.Галиуллин моны яхшы аңлады, иң мөһиме укучыларына да төпле итеп җиткерә алды. Бүгенге көндә юк-юкта совет чоры әдәбиятына тулаемы белән бары тик тискәре мөнәсәбәт күрсәтергә омтылучыларга да аның хезмәтләре дәлилле җавап булып торалар. Аларның бүгенге һәм киләчәк өчен әһәмиятле якларының берсе шунда.

Т.Галиуллин, күпчелек әдәбият галимнәренә хас булганча, фәнни эзләнүләрне хәрәкәттәге эстетика булган тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеге белән бергә үреп алып бара. Аның каләменең бу ягы беренче мәкаләләрендә һәм җыентыкларында ук күренде. 1972 елда басылган «Яңа үрләр яулаганда» исемле китабында әлеге сыйфат тәмам ачыкланган иде инде. Ул «Тормыш – шигърият чишмәсе» дигән бүлек белән башлана. Яшь галим игътибарын шигъриятебезне колачлап өйрәнүгә туплый. Каләменең бездәге авторларның иҗат мөмкинлекләрен, үзенчәлекләрен һәм әсәрләрен нигезле белеп тибрәнүен күрми мөмкин түгел. Менә шушы сыйфат аңа шагыйрьләрне берәм-берәм дә, төркемләп тә тиешле чолганыш яктылыгына куеп карау мөмкинлеген тудыра. Шуңадыр, ул биргән бәяләр бүген дә үз көчендә кала.

Шулай да аның аеруча мәхәббәт белән караган шагыйрьләре бар: Хәсән Туфан һәм Сибгат Хәким. Бу очраклы хәл түгел, әлбәттә. Чөнки әлеге аксакал осталар үзләренең каләмле сизгер кулларын алтмышынчы-җитмешенче еллар шигъриятенең йөрәк пульсында тоттылар, әсәрләрендә замандашларының уй-хисләрен аеруча калку итеп бирә алдылар.

Әдәбиятка ышанычлы адымнар белән кереп баручы Т.Галиуллин иң әүвәл шигъриятебездәге соңгы унъеллыклардагы куанычлы хәлләргә сөенә, шушы нәрсә аның үзенең дә күңелен эзләнүләргә этәрә. «Муса Җәлилнең героик лирикасы

аны дөнья киңлекләренә алып чыкты. Нахакка җәберләнгән Хәсән Туфанның поэзиясе яңадан укучыга кайтты. Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәнд, Нәҗип Думави кебек шагыйрьләрнең иҗаларына да тиешле бәя бирелде» *(Галиуллин Т. Яңа үрләр яулаганда / – Казан: Татар. кит. нәшр., 1972. – Б. 3.)*. Ул дөрес билгеләгәнчә, шигърияттә яңа хәл туа: әле тәкъдир ителгән шагыйрьләр иҗатының дәвамы булырлык талантлы каләм тибрәтүчеләр бар икән. Шул фонда иҗат итүчеләрдән тагын да өлгергәнлек, сәнгатьчә камиллек таләп ителә. Алар шуңа ирешкәндә генә, шигъриятебезнең гомуми торышы алга китәчәк. Менә шушы йогынтының көче алга таба да Т.Галиуллин тарафыннан барлана, исәпкә алына. Бу җәһәттән ул хәзерге шигъриятне үзе табынган Г.Тукай, С.Хәким, Х.Туфан, М.Җәлил, Ф.Кәрим иҗат көзгеләренә куеп карауны кулай күрә.

Т.Галиуллинга, шул рәвешле, шигъри әдәбиятны тирән өйрәнү, колачлы итеп иңләү һәрвакыт яңа сүз әйтү мөмкинлеген бирде. Борынгы мифологиягә, урта гасырлар әдәбиятыбызның байлыгына, аннан соңгы дәверләр шигъриятенә таянып фикер йөртү аның язганнарын ышанычлы һәм дәлилле итә. Алай гына да түгел, аның хезмәтләрендә аерым шагыйрьнең кайчандыр үзе тудырган традицияләрне үстерү юнәлешендәге иҗади хәрәкәтен эзлеклелектә тикшерү вә өйрәнү уңышлы юлларның берсе булып кабул ителә. Әйтик, шул ук Х.Туфанның «Ант» поэмасы турында сүз алып барганда, Т.Галиуллин нәкъ шулай итә дә. Шунысы мөһим: бу әле Х.Туфан үзе исән вакытта башкарылды, аның хуплавына лаек булды.

Галимнең тагын бер күзәтүе кызыклы. Ул утызынчы елларда халык иҗатына мөрәҗәгать итүнең гомуми төс алуын билгели. Фольклордан, мифологиядән аерылган әдәбиятның тамырсыз агач кебек ямен җуюы күптән расланган. Бу юлда, чыннан да, «Алтынчәч» (М.Җәлил), «Котып батыр» (Ш.Маннур), «Зөлхәбирә» (Ә.Фәйзи), «Асылгөл» (Ә.Ерикәй) һәм башка әсәрләр иҗат ителә. Сугыш вакытында фольклор мотивы тагын да көчәеп китте, җырларда, шигырьләрдә аеруча урынлы яңгыраш тапты. Галим, боларны этрафлы өйрәнеп, әдәбиятыбыз үсешендәге мөһим катламнарның барлыкка килү юлларын ачып бирә.

Т.Галиуллин тикшеренүләрендә, шул рәвешле, шигъри-эстетик тарихыбыз билгеле бер вакыт аралыгында гына тукталып калмый. Әлеге дәверләр аның өчен бербөтен итеп карала. «Хәзерге шигърият» дигән мәкаләсе *(Мирас. – 1996. – № 7-8. – Б. 98-122)* шушы яктан кызыклы. Ул Н.Юзиев тарафыннан әйтелгән бүгенге шигъриятнең хасиятен билгеләүче фикерләрне китерә дә шулар турында укучылар белән бергәләп уйлана. Нәтиҗәдә элгәренең карашларын һәм төгәл фикерләрен тагын да баета, әдәбияттагы яңалыкларны бер-бер артлы күздән кичереп, саллы гомумиләштерүләр ясый. Х.Туфан, С.Хәкимнәргә ялганып киткән, ә кайберләре бергә атлаган шагыйрьләребез Н.Арслан, Г.Афзал, С.Сөләйманова, И.Юзеев, Ә.Баянов, Р.Харис, Р.Фәйзуллин, Ш.Галиев, Роб.Әхмәтҗанов, Р.Миңнуллин, Р.Гатауллин, Р.Мингалим һәм башкаларның гаять бай иҗатларының, гомуми тенденцияләрдән аерып алып, индивидуаль үзенчәлекләрен объектив бәяләү җиңел бурычлардан түгел. Моның өчен Т.Галиуллиндагы фәнни әзерлек һәм фикер үткенлеге булу кирәк.

Ә менә Ә.Рәшит иҗатына ул монографик планда килә. Моны ул Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьярның йөз еллыгы уңае белән эшли *(Галиуллин Т. Тарих мизгелләре // Казан утлары. – 1997. – № 11. – Б. 171-175)*. Эш шунда: Ә.Рәшит тарихи шәхесләребезгә багышлап трилогия иҗат итте. «Сөембикә», «Колшәриф», «Мөхәммәдьяр» дип аталган поэмалары шул еллардагы әдәбиятыбызда сизелерлек вакыйга булды. Бу әсәрләр турында язган Т.Галиуллинны без тарихны һәм хәзергене оста үреп уйланучы фәлсәфәче сыйфатында күрәбез.

Сиксәненче еллар урталарында ул «шигъриятебез олыгая бара түгелме?» дип чаң сукты, яшь талантларның көттереп кенә килүләренә хафаланды. Шигъриятне яшьлекнең яратуы бәхәссез хакыйкатьтер. Талантның көттереп кенә тууы да табигый нәрсә, әлбәттә. Г.Тукай әйтмешли, көтеп алынган кадерлерәк була. Тик шулай да ул бу елларда олы шигъриаткә килүдә өзеклек хасил булуын күрде. Шигырь язучылар күп, ләкин

«Таныш моңнар»ны иҗат итеп, шунда ук шигъриятнең түреннән урын алган И.Юзеев кебекләр һаман да көттерә шул әле. Шушылый олы таләпләр куеп сөйләшкәндә, әлбәттә, Т.Галиуллин сүзендә хаклык бар иде. Бәхеткә, егерме беренче йөз башында бу җәһәттән уңай якка үзгәрешләр сизелерлек булды, әдәбиятка талантлы яшьләр килү ешайды.

Бу елларда ул иҗатчыларны «Кайда сез, Нәфисәләр?» дигән сорау куеп та сискәндерде. Ил күләмендә яңгыраш алган «Намус» романыдай әсәрләрнең сирәк язылуына игътибар юнәлтте. Хәзерге иҗатчының утыз-кырык ел булган элгәрләреннән нык аерылуы образ тудыруга яңача якын килүне сорый, – диде ул. – Яңа буын кешесе, кылган гамәлләре буенча гына түгел, фикерләве белән дә бөтенләй башкача сурәтләнергә тиеш. Хәер, бу тормышның үзендә дә шулай иде инде. Шул ук Г.Бәшировның Гайнаны («Җидегән чишмә»), Ә.Баяновның Нажары («Мәңгелек бәхәс»), А.Гыйләҗевнең Бибинуры («Җомга көн, кич белән») әйләнә-тирәдәгеләрне рәссамнарча үтәли караш ярдәмендә күзәтүдән барлыкка килгән образлар. Шулар янына Т.Галиуллинның «Сәет Сакманов» трилогиясе дә өстәлде.

Т.Галиуллинның әдәбият, аерым алганда, проза алдына куйган төп таләбе, һәрвакыт күз алдында булсын өчен, һәр әдипнең эш өстәленә эре хәрефләр белән язып беркетеп куярдай менә бу сүзләрдә гәүдәләнә: «Әдәбият һәрвакыт яхшыны раслау, матурлыкны кеше күңеленә сеңдерү нияте белән яши, идеалга омтыла. Аның төп гаме – заман кешесен сурәтләүдә каләмдәшләренең талымлырак, киләчәккә карабрак эш итүләрен күрергә теләү. Бу – аксиома. Иҗат кешесе, чор белән яши-яши дә, дөнья мәнфәгатьләрен бер мәлгә онытып, үзенең уй-хыяллары, борчулары белән язу өстәле янында берүзе кала. Индивидуальлек дигән нәрсәнең төбендә художник буларак шәхеснең өлгергәнлеге ята».

Боларга аерым тукталуның сәбәбе бар: әлеге проза турында уйланулары юкка гына булмаган икән, аның иҗатында борылыш барлыкка килә – ул проза әсәрләре иҗат итә башлый. Моңа аның каләмдәшләре дә гаҗәпләнде. Чөнки шигъриятне өйрәнүче галим шигырьләр дә язса, табигыйрәк булыр иде сыман. Күрәсең, аның күңелен борчыган, кулына язучылык каләмен алырга этәргән сәбәпләр, шигырь кысаларына гына сыймаган, роман киңлекләрен даулаганнар. Бу – аның прозага багышланган иң уңышлы мәкаләсе булса кирәк. Биредә язучылар өчен дә, галимнәргә дә методологик нигез булырлык фикерләр һәм халкыбыз тарихына кагылышлы гаять гыйбрәтле фактлар һәм алар турында уйланулар тупланган. Шуннан соң Т.Галиуллин иҗатында алгы планга публицистика да чыга.

Шунысы әһәмиятле, Т.Галиуллин тормыш ваклыкларыннан һәрвакыт югары булып кала белде. Ул – табигате белән олы җанлы, киң колачлы кеше. Югары идеаллар хакына, халкыбыз, әдәбиятыбыз мәнфәгатьләре өчен, дөреслек һәм гаделлек тантанасы намена кайчак ул үзенә зыянга да эшләргә мөмкин икән. Аның каравы ул кешеләр күзенә тыныч карый ала, кулыннан килгәнне вакытында гамәлгә әверелдерүе аңа канәгатьлек китерә. Эш-гамәлләрендә гадел, матур уйларына тугры калу – ислам динебезнең нигезендә ята торган төп таләп. Тәлгат Нәбиулла улының хаҗ сәфәренә баруы да юкка гына түгел. Мондый гаять мәшәкатьле олы юлга чыгарга күңелендә изге ниятләр булмаган кеше җөрьәт итә алмый. Күрәсең, аның нәсел-нәсәбендә үк пәйгамбәрләрне олылау, аларга тартылу көчле булган. Әтисенең исеме шул турыда сөйли булса кирәк. Нәби, исем компоненты буларак, пәйгамбәр, илче мәгънәсенә туры килә. Без Тәлгат Нәбиулла улын хәзер хаҗи дип йөртәбез икән, бу аның барлык кылган игелекле эшләренә, яшәү рәвешенә, кешеләргә булган ягымлы, әмма таләпчән мөнәсәбәтенә ихтирам билгесе булып та яңгырый.

Тынгысыз каләм иясе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Тәлгат Галиуллин һаман әдәбият фәне, тәнкыйте, проза өлкәсендә өзлексез эзләнә, укучыларга яңадан-яңа әсәрләрен һәм хезмәтләрен тәкъдим итеп яши. Аның иҗатының озын гомерле, үрчемле һәм зәвыклы булуы әдәбият сөючеләрне сөендереп тора.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН,**
*филология фәннәре докторы*

# СӨББУХ РӘФЫЙКОВ ЯДКЯРЕ

ДОКУМЕНТАЛЬ БӘЯН

## Репрессия ташкыны

*Репрессия гарасатына дучар ителгән шәхесләребез истәлегенә багышлыйм.*

ТАССРда 1937 елның сентябрендә Эчке эшләр комиссариатының яңа җитәкчесе итеп – В.Н.Михайлов, урынбасары урынына М.И.Шелудченко билгеләнгәч, зур террорның иң фаҗигале айлары башлана. Суд белән генә чикләнеп калмыйча, судтан тыш орган – «өчлек» төзелә. Аның составына НКВД халык комиссары, милиция идарәсе җитәкчесе, прокурор, бераздан партия өлкә комитетының беренче секретаре да кертелә. Атып үтерү турында карарларның иң күбесен шул «өчлек» чыгарган. «Өчлек» судсыз репрессия органы булган. Бөтен ил күләмендә «халык дошманнары»н юк итү һәм төрмәләргә озату күренеше колач җәйгән. Сәяси суд та махсус ялган сценарий буенча оештырылган. Физик көч куллану сәбәпле, рухи көчсезләндерелгән гаепләнүчеләр, ахыр чиктә, булмаган гаепләрен танырга мәҗбүр ителгәннәр.

1937 елда Татарстан китап нәшриятының астын өскә китерәләр, дөресрәге, әдәбият өлкәсендә эшләүче нәшрият хезмәткәрләрен кулга алалар. Партия өлкә комитеты, нәшриятның эшен тикшерергә дип, вәкил җибәрә. Нәшриятның матур әдәбият бүлеге халыкка зыян китерүдә – корткычлыкта гаепләнә. Корткычлар исемлеге төзелә. Шул бүлекнең мөдире Гомәр Гали 9 мартта кулга алына. 15 август көнне суд карары аны ун елга ирегеннән мәхрүм итә һәм тагы биш елга гражданлык хокукларын чикли. Әдәбият галиме, тәнкыйтьче, язучы үзенең төп хөкем срогын Норильскидагы сәяси тоткыннар лагеренда үтәчәк. Анда ул нәкъ Сөббух Рәфыйков кебек металлургия заводын төзешәчәк. Срогын тутырып, Казанга кайтачак. 1949 елның 23 июнендә янә кулга алыначак һәм Красноярск краена гомерлек сөргенгә җибәреләчәк. Шул сөргендә эшләгәндә, 1954 елның 5 июлендә бер хезмәттәше тарафыннан кыйнап үтереләчәк...

Шагыйрә Зәйнәп Бәширова 1935–1937 елларда Татар дәүләт нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты секторында өлкән редактор хезмәтен башкара. Ул да, кулга алынып, сөргендә яшәргә мәҗбүр була.

Котырган репрессия ташкынына 1937 елның август аеннан Татарстан дәүләт нәшриятының балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты секторында редактор булып эшләп йөргән Сөббух Рәфыйков та эләгә. Шул елның 17 октябрендә кулга алынган 24 яшьлек шигъри күңелле язучыны Совет хәрби мәхкәмәсе «халык дошманы» дип игълан итеп, ун елга ирегеннән мәхрүм итә, башта Казан Кремле астындагы Плэтән төрмәсенә китереп кертә, аннары Соловки төрмәсенә һәм Төньяк Себердәге металлургия комбинаты төзелешен башкара торган «Норильлаг»ка илтеп ташлый.

Боларга өстәп, ул тагы биш елга гражданлык хокукларыннан да мәхрүм ителә. Бу – аңа Казанга кайту, матбугатта иҗаты белән катнашу катгый рәвештә тыела дигән сүз. Ул иҗат иткән, аңа күз карасыдай кадерле булган өч китабы һәм яңа кульязмалары

да шул кичне үзе белән бергә кулга алынуына аның йөрәге һаман әрни... Сөббухны Галимҗан Ибраһимов исеменә язылган күмәк хатка имза куйган көннән соң ярты елга якын вакыт үткәч кулга алалар. Ә хат язу вакыйгасы һич онытылмый.

Матбугат йортының өченче катында «Кызыл яшьләр» (1956 елдан – «Татарстан яшьләре») газетасы редакциясендә Сөббух белән бергә эшләүче егерме алты яшьлек шагыйрь Галимҗан Мөхәммәтшин, әдип Галимҗан Ибраһимовны илле яше тулу уңае белән котлап, тәбрикләү хаты язарга тәкъдим итә. Чөнки яшьтәш дусты Ибраһим Салахов биш минут элек кенә аңа июнь аенда Ялтага дәваланырга баргач, классик язучыны күрәчәген сөйли. Газета хезмәткәре Ләбиб Гыйльми белән мөхәррир Касыйм Шәйхетдинов та хат язуны хуплыйлар. Хатның текстын бик җиңел һәм хәрәкәтчән Мөхәммәтшин үзе төзи. Галимҗан аганың әсәрләре яшьләр тарафыннан яратып укылуы, өйрәнелүе, әдипне гомер бәйрәме белән тәбрикләүләре, аңа сәламәтлек һәм озын гомер теләүләре, яңа әсәрләрен көтеп калулары, ихтирамнары турында яза. Текстны кат-кат укып, бергәләп үзгәрешләр дә кертәләр. Иң ахырда, сүзне очлап, Сөббух: «Октябрьнең егерме еллык тантанасына Галимҗан аганы кунакка чакырыйк», – ди. Аның тәкъдимен дә хуплыйлар. Бүлмәдәгеләр барысы да куана-куана, машинкада басылган хатка кул куялар һәм хатны шунда ук Ибраһим Салаховка тапшыралар. Үпкә авыруыннан җәфаланган, шуңа күрә инде ун ел дәвамында гел Ялтада гына яшәргә мәҗбүр булган әдипкә карата үзләренең хөрмәт хисләрен яшьләр шул хат аша белдерергә телиләр. Шул хатка кул куйганнарның барысы да кулга алына. Газетаның редакторы Касыйм Шәйхетдинов та иректән мәхрүм ителә.

Сөббухтан ике яшькә генә олы булган Ибраһим Салахов та 1937 елның 25 октябрендә төнге сәгать икедә «козгын тырнагы»на эләгә. СССР Югары судының Мәскәүдән килгән махсус төркеме 1938 елның 12 маенда Казанда утырыш уздыра. Педагогия институтының өченче курс студенты, егерме җиде яшьлек Ибраһим да – гаепләнүчеләр арасында. Аны Язучылар берлеге рәисе Кави Нәҗми биргән юллама белән Ялтада Сеченов исемендәге санаторийда неврастениядән дәваланган вакытта язучы Галимҗан Ибраһимов белән очрашканы өчен гаеплиләр. Ул Кави Нәҗминең үтенече белән әдиптән Казанда бастырылачак альманах өчен кульязма алып кайтырга тиеш була. Әйе, Ибраһим Ялтага килеп төшкән көнне үк урамнан эчтә, кипарислар үскән бакча уртасындагы әдип яшәгән ике катлы агач йортны эзләп таба. Аны Галимҗан ага һәм аның икенче хатыны Хәдичә апа бик җылы каршылыйлар. (Галимҗан Ибраһимов беренче хатыны, язучы һәм тәрҗемәче Гөлсем Мөхәммәдева белән 1933 елга кадәр генә яши, аннары аларның юллары аерыла. Ләкин Гөлсем апа гомеренең соңгы егерме-утыз елын Галимҗан Ибраһимов турында истәлекләр һәм документаль повестьлар язуга багышлый. Ул 1988 елда 85 яшендә Казанда вафат була). Ибраһим аларга баргалап йөри. Казакъстанның Күкчәтау шәһәрендәге җидееллык татар мәктәбен тәмамлаган унҗиде яшьлек Ибраһим Салахов Казандагы педагогия техникумына укырга кергәч, Галимҗан Ибраһимовка үзенең язганнарын күрсәтергә уйлый. Ләкин аңа язучының Ялтага күчеп китүен әйтәләр. Ибраһим Салаховка язучы белән менә хәзер, ничә еллар үткәннән соң, Ялтада очрашырга туры килә. Соңгы тапкыр хушлашканда, әдип аңа альманахта бастыру өчен бер хикәясен тапшыра... Ибраһим Салахов кулга алынган вакытта Кави Нәҗми дә, Галимҗан Ибраһимов та, «халык дошманы» дигән мөһер сугылып, Казандагы Пләтән төрмәсенә ябылган булалар инде.

Тагын бер көннән, 1937 елның 26 октябрендә, хат язуны оештыручы Галимҗан Мөхәммәтшин да кулга алына. Аның гомере фаҗигале тәмамланган. Аны да күмәк котлау хатына куйган имзасы өчен гаеплиләр. Ул 1938 елның 10 маендагы СССР Югары суды карары белән үлем җәзасына хөкем ителә, һәм карар шул ук төнне гамәлгә ашырыла. Ләбиб Гыйльми аңардан бер көн элек нәкъ шундый җәзага дучар

була. Сөббух белән Ибраһим икесе дә, совет хәрби мәхкәмәсенең карары нигезендә, ун елга иректән һәм аннан соң биш елга гражданлык хокукларыннан мәхрүм ителәләр. Хөкемгә тартылган һәр ике кешенең берсе диярлек атып үтерелгән ул елны халык «ләгънәт төшкән ел» дип исемләгән. Репрессияләр иң күп кулланылган вакыт шул елның икенче яртысына туры килгән.

И.В.Сталин 1937 елда киң колач алып, зур тизлек белән дәвам иткән террорның артыкка китүен аңлап ала. Һәм 1938 елның октябрендә СССР НКВДсы буенча «өчлекләр» эшчәнлеген кискен чикли торган боерык чыгара. «Өчлекләр» составына кергән тере шаһитлардан арыну эше башлана, аларны юк итәргә кирәк була. Контрреволюцион эшчәнлектә һәм хезмәт урыныннан явызларча файдалануда гаепләнгән Казандагы «өчлек» җитәкчеләре, ул гамәлләрне өстән килгән әмерләрне үтәү өчен башкаруларын аңлатып, үзләрен якламакчы булалар. Тик Мәскәүдә 1940 елның февралендә узган хөкем карары белән, В.Н.Михайлов белән М.И.Шелудченко икесе дә атып үтерелә. Төньяк Себер тоткыны Сөббух Рәфыйков ул вакытта, әлбәттә, бу хәлләрдән хәбәрдар булмый...

...Чират Хәсән Туфанга да җиткән. Өч елдан соң, ягъни 1940 елның 18 ноябрендә тиздән үзенең кырык яшен тутырачак шагыйрьне дә кулга алалар. Аның «Ант» (1935) поэмасы кискен тәнкыйтькә дучар булып, үзе Сталинга яла ягуда гаепләнә. Сталинга эпиграммасы шагыйрь Сириннең 1935 елның 22 августында кулга алынуына сәбәпче булуын да беләләр...

Бервакыт Пләтән төрмәсендә Хәсән Туфан ята торган кырык кешелек камерага бөкшәеп беткән, туңган, ябыккан, аягына машина покрышкасыннан башмаклар ясап бәйләгән, өстенә җиңсез пинжәк кигән Фатих Кәримне кертеп ташлыйлар. Ул 1938 елның 3 гыйнварында кулга алынып, ун елга ирегеннән, биш елга хокуклардан мәхрүм ителгән икән. Соңыннан билгеле булганча, ул төрмәдән фронтка алгы сызыкка җибәрүләрен сорап, гариза язган була, аның гозерен канәгатьләндерәләр. Шунысы кызганыч: утыз алты яшьлек Фатих Кәрим 1945 елның 19 февралендә дошман пулясыннан һәлак була.

Ике ел үткәч, 1942 елда Хәсән Туфанны үлемгә хөкем итәләр, аннары шул ук елны үлем җәзасы ун ел төрмә һәм тагын биш елга хокукларны чикләү белән алыштырыла. Ибраһим, Колымада интегеп, 1947 елның 25 октябрендә азат ителә. Сөббух белән Хәсән, 1956 елда икесе дә, мәңгелек сөрген тоткыны булудан котылып, шөкер, акланалар. Чөнки контрреволюцион җинаятьләрдә гаепләнеп хөкемгә тартылганнарның «эшләре»н кабат карау өчен комиссияләр төзелә. КПССның 1956 елның февралендә үткәрелгән XX съездында Үзәк Комитетның беренче секретаре Никита Сергеевич Хрущёв 1930 еллар – 1950 еллар башындагы массакүләм репрессияләр турында доклад ясаганнан соң, репрессияләнүчеләрне аклау киң колач ала. Хрущёв «җепшеклеге» чорында – 1950 еллар уртасында илебездә сигез йөз мең кеше шундый бәхеткә ирешә. Алар арасында Сөббух, Ибраһим һәм Хәсән абыйлары Туфан да бар.

Сөббухның тоткынлык газаплары Казанда Кремль астындагы Пләтән төрмәсендә башлана. Шәһәрнең унҗиденче гасыр урталарындагы Пләтән (Читәнле) авылы тирәсендә урнашкан таш бинаны унсигезенче гасыр башында Казан сәүдәгәре Иван Михляев постау җитештерү урыны итеп төзеткән булган. Күп еллар дәвамында бер хуҗадан икенчесенә күчкән әлеге бина шәһәргә кулланылышка тапшырылган. Һәм ул гасыр ахырында төрмә итеп үзгәртелгән дә җинаятьчеләрне җыю урынына әйләнгән. Навигация ачылып, суднолар йөри башлауга, шушы күчерү-озату мәхбүсханәсендәге тоткыннар Себергә җибәрелгән. 1917 елгы Бөек Октябрь социалистик революциясеннән башлап, совет власте өчен яраксыз «элементлар»ны халык телендә «Пләтән төрмәсе» дигән исем алган шушы йортка китереп япканнар.

Илләр тынычлангач, 1960 нчы елларда элекке зиндан онкология үзәге итеп профильләшәчәк, махсус юнәлеш алачак. Аннары 1976 елны РСФСР Министрлар

Советының 7 сентябрьдә чыккан карары нигезендә бина федераль әһәмияте булган мәдәни мирас объекты дип танылачак. Киләчәктә монда, ягъни Батурин урамындагы 7 нче йортта Татарстан Республикасы иҗтимагый палатасы, Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге тарих институты, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе, «Яңарыш» республика фонды урнашачак.

Ә XX гасыр башында «халык дошманнары»н шушында асрыйлар һәм җәзалыйлар. Сорау алу – кыйналу, тагын сорау алу – кыйналу... Аннары камерага кайтып егылу... Көн саен шулай дәвам итә. Аннан кайчандыр дүрт кешегә исәпләнеп, хәзер егерме дүрт мәхбүс дыңгычлап тутырылган тынчу, парлы камерага күчерүләре... Карават урынына эшләнгән ике катлы сәке-сәндерәләрдә ян белән ятмасаң сыя торган түгел. Тынчу һава... Саф һава керсен дип, мәхбүсләр үзләре махсус ваткан тәрәзә өлгесеннән ургылып, суык керә, шуңа туңдыра. Сөббух белән Галимҗан Мөхәммәтшин шул камерада очрашалар. Гомәр Гали күптәннән монда икән инде. Күп тә үтми, Ибраһим Салахов белән Касыйм Шәйхетдиновны да күрше камерадан алар янына күчерәләр. Каршыдагы камера «Үлем камерасы» дип атала. Үлемгә хөкем ителгәннәрне атарга шуннан алып китәләр. Таң алдыннан төрмә артында мылтык аткан тавышлар ишетелә... Шул 1937 елның 7 ноябренә каршы төнне тоткыннар аеруча дулкынланалар, чөнки Октябрь революциясенең егерме еллыгы, олы бәйрәм буларак, аларның барысына да амнистия бүләк итәр, Иосиф Сталин указы белән бөтенләйгә азат ителерләр дип өметләнәләр. Ләкин иртән иртүк көтелмәгән «тамаша»га эләгәләр. Камерага мәхбүсләрне барларга дип килеп кергән төрмә башлыгы ярдәмчесе кинәт карандашын кабинетта онытып калдырган булып кылана. Кесәсеннән алган блокнотына камерадагыларның исәбен язып куярга карандаш кирәк бит. Егерме дүрт тоткынның сигезе әле сорау алуда икән. Шулвакыт үзе дә яңа гына төнге сорау алудан хәлсезләнеп кайткан беркатлы профессор Галимҗан Нигъмәти, яшергән урыныннан алып, ашыга-ашыга, үзендәге карандаш кисәген суза. Чәнти бармак хәтле генә карандашны аңа камераның старостасы Ильяс Алкин (элекке беренче секретарь) сорау алу бүлмәсеннән үткән көнне урлап алып кайтып биргән була. Тикшерүче кабинетыннан урланган шул кечкенә карандаш кисәге аркасында камера иртәнге аш – әче кәбестәле сыек баландадан колак кага һәм карцер режимына куела. Карцерның ни-нәрсә икәнен тиздән үз күзләре белән күрерләр, янәсе. Озынлыгы – биш, киңлеге өч метр чамасындагы, тимер ишекле, дүрт яктан цемент стеналы таш капчык күпләрнең сәламәтлеген суырып алган инде. Тынчу һәм ярым караңгы булуы гына җитмәгән, карцер түшәмендәге люк кинәт ачылып, шлангтан сиптерелгән су тоткыннарның биленнән дә өскә күтәреләчәк. Төнозын су эчендә торып, аякларын көзән җыерудан егылучылар да булыр. Бары тик иртән карцерның ишеге ачылгач кына, су коридорга таба юл алыр.

Төрмә башлыгы ярдәмчесе чыгып китүгә, аскы сәкедә ятучы, беркем белән дә сөйләшмәүче сәер холыклы бер тоткын – элекке район прокуроры – профессорга сугарга кизәнә. Иртәнге аштан коры калганга, аңардан үч алмакчы була. Шунда Сөббух аның кулын тотып кала, аннары үзен читкә этә. Икенче профессор, университетның элекке ректоры Гыйлем Камай теге «сәер»не сәке астына ук кертеп җибәрә...

Өченче каттагы тар камерадан Сөббухның берүзен алып чыгып китәләр. Аны түбәнге катта коридор эченә үк кереп торган ябык машинада суд буласы урынга илтәләр. Андагы бер кешелек камерада сакал-мыегыннан арындырганнан соң, коридор буенча алып барып, аңа душта юынып чыгарга әмер бирәләр. Ул яхшы итеп ашап алгач, тагын теге ике конвоир аны сак астында коридор буйлап суд буласы урынга озатып куялар. Якты бүлмәдә кызыл постау ябылган өстәл янында өч хәрби үзләренчә ялган коллегия оештыралар. Сөббухны коридорга чыгарып торалар да яңадан чакырып кертәләр. Уртада утыручы югары чиндагы суд рәисе үзләре кәгазьгә язган карарны укый башлый. «СССР Югары Суды Хәрби коллегиясенең күчмә сессиясе шулар-шулар

составында Совет Социалистик Республикалар Союзы исеменнән Рәфыйков Сөббух Һади улы илле сигезенче статья буенча гаепләнеп, төрмәгә ябылу һәм, төрмә срогын тутырганнан соң, биш елга барлык гражданлык хокукларыннан мәхрүм калдыруга хөкем ителә».

Судтан соң Сөббухны Черек күл подвалына алып төшеп, зур гына бер камерага кертәләр. Аның исе китә. Обком секретарьлары, наркомнар барысы да шунда. Ләбиб Гыйльми дә шунда. Ләбиб, йөгереп килеп, Сөббухны кочаклап ала да: «Сөббух, җанкисәгем, сине дә атарга хөкем иттеләрме?!» – ди. Алар сөйләшә дә алмыйча калалар, ул арада камераның ишеге ачыла да Сөббухны кире дән тартып алалар. Сөббухны үлемгә хөкем ителгәннәр камерасына ялгыш керткән булалар.

Үлем камерасыннан исән-имин котылган Сөббухны төрмә итеп үзгәртелгән кызыл чиркәүгә күчерәләр. Аңа каршы якта, урам аркылы гына урнашкан Кремль астындагы икенче төрмә күңелгә шом салып тора. Шәһәрдәге төрмәләрнең барысы да тоткыннар белән шыгрым тулган, диләр. Такта киртә белән әйләндереп, койма өстеннән чәнечкеле тимерчыбыклар да сузып җибәргәч, элекке чиркәү чын төрмәгә охшап калган. Җитмәсә, чат-чатта биек манаралар да калкып чыккан.

Авыр тимер ишек аркылы эчкә үтүгә, Сөббух аптырап кала. Монда тоткыннар шулкадәр күп, хәтта якынча исәбен дә чамаларлык түгел. Юк, аларның төгәл саннары билгеле икән. Надзирательләр әмере буенча кичке барлау вакытында тоткыннар йөзәрдән биш сафка тезелергә тиешләр, ди.

Ыгы-зыгылы, шау-шулы халык арасында Сөббух Ибраһим Салаховны күреп ала. Аны аулаграк урынга алып китеп, Черек күл изоляторында Ләбибне күргәнен әйтә.

Кызыл чиркәүнең чаңы да хәзер төрмәгә хезмәт итә. Чаң тавышы ун надзирательнең бозау хәтле өч эт ияртеп, кичке барлауга килүе турында хәбәр бирә. Янәсе, тоткыннар чыгып качмаганнармы? Барлаучылар ишектән килеп керүгә үк, биш йөз мәхбүс берьюлы сәке, сәндерәләрдән сикереп төшеп, тиз генә чуен плитә идәндә биш рәт булып тезелеп торырга тиеш. Ярсыган этләр берничә тоткынның җиңнәрен-балакларын әләктереп ала икән, анысы табигый хәл санала, ярдәм итүче, аралап алучы юк. Кансыз надзирательләр, ашыгып, сәндерәләрдәге капчыкларны актарырга керешәләр. Бер тоткыннан кулдан эшләнгән кырыну пәкесе һәм көзге табыла. Билгеле инде, төрмә тәртибен бозган өчен барысы да ишегалдына чыгудан, димәк, саф һава сулап керүдән мәхрүм ителәчәк. Конвой башлыгы дәһшәтле тавыш белән кисәтеп куя: әгәр дә кәгазь-карандаш табыла-нитә калса, барысын да карцер көтәчәк.

Надзирательләр чыгу юлына борылуга, биш йөз мәхбүс берьюлы кузгалып, һәркайсы алданрак урын әләктереп калырга ашыга.

Чиркәүдә тоткыннарга куелган сәкеләр барысына да җитәрлек түгел. Эзләп-эзләп тә урын таба алмагач, Сөббух үзенең биштәреннән җәймә кисәге тартып чыгара һәм шуны бер сәке астына җәя. Ләкин өстәге сәкедән бертуктаусыз кандала коела, шуңа күрә алар, ишек төбенә күчеп, Ибраһим белән икесе сөйләшеп утыралар, керфек тә какмыйча төн уздыралар.

Һәр көнне чиркәүнең түр ягы каршындагы мәйданда алыш-биреш, сәүдә бара, әйтерсең лә чын базар кайный. Төп үлчәү – паёк. Монда тәүлеккә бирелә торган биш йөз граммлы паёк икмәген дә, суынган арыш чумарын да җаның теләгән әйбергә: шикәр, күлмәк, ботинка һәм башка кирәк-яракка алмаштырырга була.

Тагын чираттагы барлау. Тагын шул этләрне ияртәкән надзирательләрнең чамадан тыш кыланмышлары. Барлаудан соң тоткыннарның тагы сәке алып калырга ыргылулары. Монысында Сөббух белән Ибраһимның урыннары төрле җиргә туры килә. Сайланып тору юк. Кайсы сәке буш, шунда урнашасың.

Барлаудан соң, ниһаять, түрдәге сәкеләрнең берсе астына кереп сыенган Ибраһимны күреп алгач, Сөббух: «Бәй, син монда качкансың ич, эт белән эзләп тә таба алмассың. Чык әле, бер шигырь яздым», – дип, аны үзе янына чакырып чыгара. Коңгырт кара

чәчле, зур соргылт күзле, аксыл йөзле Сөббух тышкы чибәрлеге белән генә түгел, мөлаем карашы, һаман елмаеп торуы белән дә Ибраһимның күңеленә һәрвакыт бертөрле тынычлык иңдереп тора. Кеше йөз-кыяфәте белән генә түгел, эше һәм холкы белән дә матур булсын икән шул.

Мондагы ике йөз илле тоткынны этапка алачаклар, дигән хәбәр йөри. Конвой белән озатачаклар, ди. Киткәннәр урынына Кремль астындагы икенче төрмәдән күчерелгән мәхбүсләр урнашачак икән.

Төрмә итеп үзгәртелгәннән соң, чиркәү ишегалдындагы баганага радио беркетеп куелган. Ул бертуктаусыз тоткыннар сөреләчәк сәфәр юнәлешләрен игълан итеп тора:

– Ак диңгез каналына! Соловкига! Норильскига!

– Тайшет – Абакан юлына! Колымага! Котласка!

...Менә Сөббух, үзе кебек «аеруча куркыныч җинаятьчеләр» белән бергә җәза срогын үтәргә дип, Архангельск өлкәсенә – Ак диңгез тарафларына озатыла. Казан төрмәләрендәге мәхбүсләр эшелоннарга, Столыпин вагоннарына яисә баржаларга мәҗбүри төялеп, күз күрмәгән якларына юл ала. Рәсәйдә Николай II патшаның эчке эшләр министры Пётр Столыпин тәкъдиме белән крестьяннарны Себердәге буш яткан җирләргә күчерү барышында кулланылган шундый товар вагоннары менә хәзер шул ук Себергә «халык дошманнары»н ташый инде.

Сөббухлар өлешенә тигән төрмә ерак Соловкида икән. Соловки – алты эре утраудан торган архипелагның бер утравы. Казандагы кызыл чиркәү бинасы төрмәгә әверелгән кебек, мондагы монастырь да башта – лагерьга, аннары төрмәгә үзгәртелгән. Унбер метр биеклектәге, алты метр калынлыктагы дивары белән ул элек тә төрмәне хәтерләткәндер инде. Һәм төрмә бөтен көченә тоткыннарны газаплап, үкереп эшләп ята. Аның башлангыч рөхсәт ителгән микъдары (лимиты) сигез мең тоткынга исәпләнгән булган, диләр. 1923 елда оешкан әлеге махсус лагерьның вакытлыча тукталып торган чаклары да булган. Ләкин 1932 елдан, яңа сулыш алып, тагын эшләп киткән. Язмыш, диген инде. Нәкъ шул елны татар шагыйре Сәгыйть Сүнчәләй, сәяси тоткын буларак, Соловкига озатылган. Кырык өч яшендә шушы якларга сөрелгән Сәгыйть алты ел буена бөтен авырлыкларны үз башыннан кичергән. Тик аңа ун еллык җәза срогын төгәлләргә насыйп булмаган. Дәүләт террорының иң кызган чорында Ленинград өлкәсе УНКВДсы 1937 елның 9 октябрендә Соловкида узган күчмә утырышында Сүнчәләйне атарга дигән хөкем карары чыгарган. Карар шул елның 27 октябрендә гамәлгә ашырылган. Тоткыннарның беришләре шулай юк ителгән, һәм төрмә конвейер кебек алар урынына яңаларын кабул итеп торган.

Соловки утравындагы төрмәгә яңа аяк баскан Сөббух та үзенең язмышташлары белән бергә искергән торак урынына яңасын төзү, юл салу һәм утын әзерләү кебек авыр хезмәткә тартылган. Җелекне суыра торган авыр эш, ашау-эчү начар, үлүчеләр күп...

Монда кыш салкын түгел, киресенчә, җәй салкынча була икән. Гыйнвар зәмһәририендә температура нибары минус 10°С була, июль чилләсендә бары тик 14°С кына була, ди. Бу якның табигате вак утрауларга, күлләргә бай, диләр. Чыршы-нарат урманнары да байтак икән.

Сөббухның Соловки төрмәсендә кичергән газаплары артта калыр. Чөнки аны Красноярск краеның төньяк өлешендә урнашкан Норильск лагерена күчерерләр. Ә Соловкидагы төрмә 1939 елда ябылыр. 1990 елда монастырь яңадан үз вазифасын башкарырга керешер, туристларны да кабул итәр. Соловки утравының тарихи-мәдәни комплексы ЮНЕСКОның бөтендөнья мирасы объекты дип исәпләнә башлар. Шул елны репрессия корбаннарына Мәскәү шәһәрендәге Лубян мәйданында мемориаль таш куелыр. Ул таш, әлбәттә, Сәгыйть Сүнчәләй, Сөббух Рәфыйков һәм башка бик күп тоткыннар газап чиккән Соловки утравыннан китерелер...

...Казан чиркәү-төрмәсеннән Соловки монастырь-төрмәсенә этап белән озатылган Сөббухның тоткынлык юлы алга таба башка юнәлештә дәвам итә. Аны Красноярск

краеның төньягында урнашкан Норильск лагерена күчерәләр. Норильск бик-бик еракта, Себердә салкын поясның чиге булган поляр түгәрәкнең артында, хәтта аннан да өч йөз чакрым төньяктарак урнашкан. Ул Норильск елгасы буена сыенган. Монда һава температурасы елның сигез аенда түбән була икән. Дөньядагы иң салкын урын мәхбүсләрне үзенең ажгырып торган зәһәр әче җилләре, кеше түзә алмаслык карбураннары белән өстәмә рәвештә җәзалау өчен дә бик уңайлы икән бит.

Сәяси җинаятьчеләрнең бушлай хезмәтеннән тау-металлургия комбинаты төзелешендә рәхәтләнеп файдаланалар. Тоткыннарны хезмәт белән төзәтү лагере аларны башка бервакытта да хөкүмәткә каршы кыек сүз әйтмәслек итеп яңабаштан тәрбияләү эшенә керешкән.

Салкын котыпта да тормыш дәвам итә. Мәхбүсләр калын стена белән әйләндереп алынган «Норильлаг»та җан асрый. Тыныч тормыштагылар өчен 1939 елда комбинат янәшәсендә дип әйтерлек геологлар посёлогы үсеп чыга. Егерме ел элек Норильск җирендә беренче тапкыр бакыр рудасы табылган. Ике елдан соң җитди эзләнү-тикшеренү эшләре башлангач, геологларга кышын яшәргә дип, беренче агач өй салынган.

Шул ук 1939 елны Кече металлургия заводы төзелә, беренче никель алына. Аннары Зур металлургия заводы сафка баса. Оборона предприятиеләрен 1942 елда электролизлы никель белән тәэмин итүнең әһәмияте әйтеп бетергесез зур булган.

1940 елда төзелә башлаган ачык рудникка тоткыннарны колоннага тезеп, тирәякка карап алганнарына мылтык төзәп (янәсе, качарга җыена), көтү кугандай алып барганнар. Ул рудникны, ни сәбәптәндер, «Медвежий ручей» дип атаганнар.

Тау-металлургия комбинатында гына түгел, ә яңа ачылган завод-фабрикаларның барысында да тоткыннарны иң авыр эшләрне башкарырга куйганнар. Әлеге тимербетон корылмалар яңа көчләрне кабул итеп, «тузган»нарын гамәлдән чыгарып торганнар...

Ун ел хөкем срогын тутырганда, нинди хәлдә калуы тоткынның үз бәхетеннән торган. Норильскида металлургия заводын төзешкән, корыч кою цехында тир түккән язучы-галим Гомәр Гали, 1947 елның 10 мартында иреккә чыгарылып, берничә ай заводта хуҗалык мөдире урынында эшләп алганнан соң, туган ягы Татарстанга кайтып китә. Ләкин... Шушы «ләкин»нәр булмасын иде дә бит кеше язмышында! Күкләрдә язылганны җирдә яшәгәндә күрә шул адәм баласы. Тоткынлыктан котылып, туган авылы Иске Тинчәлегә кайткан, шунда ярты елга якын ата-анасы янында торган, 1948 елның башында Казанга гаиләсе янына кайтырга рөхсәт ителгән, шифаханәдә медстатистик, ягъни медицина учёты алып баручы булып эшли башлаган Гомәр Галине янәдән кулга алалар һәм, бүтән әйләнеп кайтмаслык итеп, Красноярск краена сөрәләр. Шунда сөргендә вакытта аның гомерен хезмәттәше өзә. Бик күп еллар үткәч, 2008 елда Казанда Гомәр Гали яшәгән йортка истәлек тактасы куячаклар...

1947 елның 17 октябрендә Сөббух Рәфыйков та, ун елга сузылган тоткынлык срогын тутырып, «Норильлаг»тан азат ителә. Ул калын стеналы будканың авыр ишеген ачып чыгуга, кая барырга белмичә, урамда кала. Аның өчен туган якка әлегә юл ябык, чөнки ул тагын биш ел буена гражданлык хокукларыннан да мәхрүм ителгән. Аңа Норильскида тагын биш елга калырга туры киләчәк. Тик монда кемнең ишеген шакып карарга?!. Бөтен өмете – дусты Галимҗанда инде...

1935 елда «эшли башлаган» Норильск лагере 1956 елга кадәр үз көчендә булачак... Норильск шәһәре Россиядәге иң эре төсле металлургия үзәгенә әйләнәчәк. Ләкин тирә-юньдә җирнең зарарлануы, һава, су һәм туфракның чиста булмавы, урманнарның бетүгә таба баруы экологик тотрыксызлык тудырачак... 1935 елда тоткыннар көче белән төзелә башлаган Норильск тау-металлургия комбинаты «Норильск никеле» исемен алачак. Дәүләт карамагындагы әлеге предприятие 1995 елда аукционга куелачак һәм аның контролендәге акцияләр пакеты шәхси кулларга күчәчәк...

## Гаилә бәхете

Хөкүмәт тарафыннан оештырылган тоткынлык типкесендә ун ел гомере үтеп китә Сөббухның. Хәзер инде гражданлык хокуклары чикләнгән биш еллык хөкем срогы башланачак. Туган җиреннән сөрелгән кеше буларак, ул яшәргә әлегә шушында калачак. НКВДга «явка»га бик еш йөрергә туры килсә дә, анысы инде тоткынлык мәхшәре булмас.

Норильск лагереннан соң шул посёлокта яшәүче Галимҗан исемле дусты, Сөббух тоткынлыктан котылгач та, аны Баянов фамилияле бер танышларына алып бара. Язмыштыр, Сөббух шуларда фатирда торучы хатын, ягъни үзенең булачак тормыш иптәше белән таныша. Дөресрәге, Хәлимәнең биш яшьлек Әлфия исемле кечкенә кызы сәбәпче була аларның якыннан аралашып китүләренә. Бераз сөйләшүгә үк, Сөббух абыйсына ияләнгән кызчык аны «минем әти» дип атый. Әлбәттә, моңсу шомырт кара күзле, уртадан юл ачып, чәче ике якка тарап үрелгән кара толымлы, сөйкемле Хәлимәне Сөббух үзе дә бер күрүдә яратып кала.

Нәкъ биш елдан Сөббух сөекле Казанында булыр. Шундый өметләр белән ул, ниһаять, кулына каләм ала. Авылдагы хәлләрне белешү ниятеннән, утырып, дәфтәр битен тутырып, сагынычлы хат яза. Җавап хаты авыл укытучысы, аның элекке укучысы, Сөббух оештырып җибәргән әдәби түгәрәкнең элекке актив иҗатчысы Таһир Шәрәфетдиновтан килә.

Гомере булса, алдагы биш елда язачак та язачак ул. Язуны тыючы юк, тик матбугатта гына басылма. Языйк әле, алга таба күз күрер. Биш ел тиз узып китәр, Сөббух тулысынча ирекле булыр, Казанына кайтыр һәм бер-бер артлы китапларын бастырып чыгарыр.

Ир-ат туган җиренә тартыр, ди. Күңел һаман Татарстанга тартса да, әлегә монда яшисе булгач, мондагы тормышны көйләргә кирәк шул. Эзли торгач, Сөббух таба үзләренә туры килердәй җайлы урынны. Ләкин яртылаш тау астыннан эчкә кереп торган бу сарайны Хәлимә генә өнәп бетерми. Сөббух үзенең яраткан кешесе белән салам куыште яшәргә дә риза булыр иде. «Ничек җылытырбыз?!» – ди хатыны, бик борчылып. Оста куллы Сөббух, Хәлимәсенең кысыр хәсрәтен таратып, «времянка» дигән мичне чыгарып та куя. Булган бөтен байлыклары сәке, кулдан ясалган өстәл һәм урындыклардан гыйбарәт. Ләкин алар бик бәхетле.

Озак та үтми, Сөббух Норильск комбинаты торак-коммуналь идарәсенә эшкә урнаша. Нибары сигез кешедән генә торган дус, тату коллектив инспектор вазифасын башкарачак Рәфыйковны тугызынчы хезмәткәр итеп үз араларына кабул итә. Әмма хезмәте өчен поляр коэффиценты (нәтиҗәлелек күрсәткече) түләнми, чөнки Сөббух һаман сөргендәге кеше булып исәпләнә. Икәүләп эшләүләренә карамастан, гаиләдә акчага кытлык үзен сиздерә.

Хатыны Хәлимә, бергә яши башлаганнан бирле, көн саен диярлек каяндыр кәгазьләр алып кайта. Бу инде – аның «яз!» дигән сүзе. «И, Хәлимә, Хәлимә, син кирәсең хәлемә!» Менә Сөббух, Себердәге кар бураннарын – пургаларны сурәтләп, шигырь язып утыра:

*Кар томаны каплый һаваны,*
*Ыжгыра җил, куа карларны,*
*Төбенә кадәр сыгып талларны,*
*Диңгез кебек шаулый яланы.*
*Кар сарыла, ябыша битләргә,*
*Һәр яктан җил – булмый күз ачып,*
*Бөтерелеп уйный күкләрдә,*
*Шарлавыктай ага ул ташып.*

(1948)

«Себер җиле, Себер җиле... Искә төшерәсең туган җирне!»

Тормыш арбасының тәгәрмәчләре, вак-төяк дөнья мәшәкатьләрен җиңеп, ышанычлы эздән алга таба тәгәри. Елгадагы су кебек Сөббух та тормышта үз тырышлыгы белән юл ярып бара. Әлфия китаптан хәрефләр таный башлаганда, аңа иптәшкә 1949 елның 10 маенда Сания исемле сеңлесе туа...

Күпне өмет итмичә, эздән дә бәхетле тормыш оештыра белгән Сөббухның танышбелешләре арасында да абруе арта. Ул бер елдан торак-коммуналь хуҗалык идарәсе җитәкчесе итеп билгеләнә. Аңа «управдом», «писатель» дип кенә эндәшәләр.

Ләкин... Ләкин сугыш бетү белән, илдә репрессия машинасы яңа көч-куәт белән котырынып-үкереп эшли башлый. Элекке хәрби әсирләр төрмәгә ябыла, лагерьларга сөргенгә озатыла. Хөкүмәтнең 1948 елның февралендә кабул иткән яшерен карары буенча, утызынчы еллардагы зур террордан соң төрмәдә утырып чыккан кешеләр янә шунда озатыла... Гражданлык хокуклары чикләнгән хөкем срогы тулырга нибары бер елдан артык вакыт калып килгәндә, Сөббухның элекке «җинаятьләре» яңадан карала. Һәм ул 1951 елның 9 июнендә кабат хөкемгә тартылып, монысында гомерлек сөргенгә дучар ителә. Бу – туган җиреңне үз гомереңдә башка беркайчан да күрмисең дигән сүз. Бу – аң белән кабул итә алмаслык, башка сыймаслык, кешене аяктан егарлык тетрәндергеч хәл. Бу – төбең, тамырың белән туган җирдән аерылу фаҗигасе дигән сүз. Моны аңлатырга сүз җитми...

Сөббух 1951 елның 22 сентябрендә фоторәсемгә төшеп, аны альбом битенә урнаштыра да: «Бу чакта минем канатлар бик сынык иде», дип язып куя... Тарих өчен бусы да кирәк.

Авырлыкларга бирешмәгән бәхетле гаилә 1952 елда баракка яшәргә күчә. Озын коридорлы, унлап гаилә бергә торган, шау-шулы барактан тынычрак урынга китәсе иде! Иҗат эше тыныч мохитне ярата.

Сөббухның ихлас теләге фәрештәләрнең «Амин» дигән чагына туры килә: аларга фатир бирәләр. Аннан да олы бәхет буламы?! Әлбәттә, беренче – сәламәтлек һәм тынычлык, ә икенче – эш урыны һәм фатир.

1953 елда яхшы вакыйгалар булып кына тора. 1939 елдан эшчеләр посёлогы дип йөртелгән Норильскига шәһәр хокукы (статусы) бирелә. Себердә беренче шәһәр! Сөббух белән Хәлимә гаиләсендә 19 сентябрь көнне кыз бала туа. Апаларының исемнәре Әлфия – «тәүге», Сания – «икенче бала» дигән мәгънәгә ия. Яңа туган сабыйга «Нәфисә» исемен кушарлар. Ул «нәфис, күркәм, чибәр» булып үссен. Барысының да бәхетләре, тәүфыйклары артсын...

Татарстаннан бик-бик еракта, Ерак Себердә гомерлек сөргендә калу Сөббух өчен килешә алмаслык хәлгә әйләнә. Ул – язучы. Язучылык – аңа Аллаһы Тәгалә тарафыннан йөкләтелгән изге бурыч. Киң катлам укучылар өчен матбугат аркылы чыгыш ясамау, тирән фикер салынган әсәрләрен китап итеп бастыра алмау язучы кеше өчен фаҗигагә тиң. Күңеле төшеп, рухы сына язган вакытта аңа хатыны Хәлимә терәк була. Сөббух үзе дә «ярый әле, гаиләм бар» дип юана. Һәм яңадан кулына каләм ала. Үз башына төшкән авыр хәсрәтне басар өчен байтак кына дәфтәрләрне язып тутыра ул. Шигырьләрендә Себер киңлекләрен сурәтли.

Алар яшәгән Норильск – 200–250 метр калынлыктагы мәңгелек боз өстендә утырган шәһәр. Монда җир 244 көн буена кар астында ята. Үзенең каты салкыннары, кар-бураннары, поляр түгәрәк (ул салкын пояснның чиге булып санала) артында айлар буена кояш чыкмый торган поляр төннәре белән Таймырда кыш бик озак дәвам итә... 20 майдан поляр көннәр башлана: поляр түгәрәк артында кояш, тәүлекләр буе батмыйча, 68 көн һәм төн күкне һәм җирне яктырта. Шул чорда ике метрга якын калынлыктагы туң җебеп ала.

Әкрен генә Сөббухның күңелендә дә яз фасылының гүзәл мизгелләре хасил була. Алар шагыйрь каләме аша шигырь юлларында урын ала:

*Яз кояшы яшьлек алып килә,*
*Ул эретә тирән карларны.*
*Яз кояшы сөя һәрнәрсәне,*
*Яшелләтә тугай, ярларны.*
*Яз кояшы таулар һәм кырларны*
*Җылы нуры белән иркәли,*
*Ал чәчәккә күмә бакчаларны,*
*Сылу кыздай итә җиркәйне.*
(1953)

Ул бу шигырен дәвам итәчәк әле һәм исемен «Яз килә» дип куячак.

Тундра, ягъни җир шарының поляр түгәрәк тирәсендәге урмансыз, үсемлеккә бик ярлы мәңгелек туң – салкыннан туңган җирләр, әлбәттә, җәй көне яшәрә... Шагыйрь Сөббух, өеннән чыгып, тирә-юньгә гаҗәпләнеп карап тора. Менә сиңа мә! Кичә генә җиргә карлы яңгыр яуган булса, ә бүген яшел күлмәк киеп җәй килеп җиткән!

*Бу якларда яшәмәгән кеше*
*Һич ышанмас минем сүзләргә:*
*Кичен менә җир кап-кара иде,*
*Күмелгән ул иртән гөлләргә!*
(1956)

Җәй көне тирә-юнь хуш исле, мәңге яшел саз үсемлеге – сазанаклар, себер лаләләре белән тула.

*Төньяк диңгезенең ярларына*
*Ак аюлар чыга бозлардан.*
*Кыска җәйне бизәп калыр өчен*
*Чәчәк үсә сазлы тундрада.*
(1954)

Июль ахырында монда үгез күзе (арника), балтырган һәм ромашкалар бик күп була.

Август башында Сөббух гаиләсе белән җиләк һәм гөмбәгә йөри. Ак гөмбәнең буе 15 см биеклеккә җитә. Татарстанда ак гөмбәнең чыршылыкта үсүен Сөббух, әлбәттә, белә...

Таймыр турында да шигырь язасы килә әле аның:

*Таймыр төне. Күктә йолдызлар да,*
*Урак кебек ай да күренми.*
*Тәүлек буе кояш янып тора,*
*Монда ак төн нинди күңелле...*
(1954)

Шигырьләре тупланган дәфтәр тышына Сөббух «Ак төннәр» дип язып куя.

Таймыр, ягъни поляр түгәрәктән дә төньякка табарак шактый еракка урнашкан утрау турында ул:

*Таймыр тундрасы – без торган җир,*
*Котып төнен кичерә һәр елны...*

– дигән аңлатма бирә.

Туган як... Аны сагыну хисен берничек тә басып булмый шул. Сөббухның күз

алдына Минзәлә елгасы килә. Шул елга буенда урнашкан газиз авылы – Нөркәй. Революциягә кадәр ул шундый исемдә йөргән. Чынлыкта, ул – Зур Нөркәй авылы. 1970 елларда аңа Кече Нөркәй авылы да кушылачак. Анысы әле киләчәктә... Ә хәзер Сөббух, Енисей елгасына атап, шигырь юллары язып утыра:

*Куе кара урман каплый*
*Енисей яр буйларын.*
*Ага ташып, дулкынланып,*
*Шул Енисей сулары.*
(1956)

Иректән гомерлеккә мәхрүм ителгән мәхбүс-тоткыннарның хәлен дә сурәтләп язып куя Сөббух:

*Дусты, кардәшеннән хәбәр көтеп,*
*Атналарны кемнәр санамый;*
*Хат ташучы нигә күренми? – дип,*
*Тәрәзәгә кемнәр карамый?!.*
*Болыт чәчле шул кыз өйгә керсә,*
*Бераз каушап каршы аласың.*
*Шундый рәхәт була хатлар килсә,*
*Татлы уйга күмелеп каласың...*
(1956)

Салкын Себернең табигатьтәге хайваннар дөньясы шигырьләргә үзләреннән-үзләре килеп керәләр. Татарстанга хас булмаган ак төлке турындагы шигыре:

*Кышкы төндә азык эзләп йөри*
*Калкулыклар буйлап ак төлке.*
*Борын төртеп бара, карны исни,*
*Көлтә кебек койрыгын селкеп.*
(1957)

Буерткыч җәнлекнең куе, озын мехы көмешсыман төстә. Татарстанга ак төлкенең 1941 елда китерелүен туган җиреннән бик еракта яшәүче Сөббух, әлбәттә, әлегә белми...

Себердә көртлекләр (шактый зур кыргый урман тавыклары), карга күмелеп, җирдә төн куналар, кайвакыт кар астында озын юллар ясыйлар. Алар да, соклану галәмәте булып, шигырьгә килеп керәләр:

*Ак яулыкка чиккән бизәк төсле*
*Көртлек эзе энҗе карларда.*
*Кояш нурларының алсуы төшеп*
*Матурлыкны өсти аларга.*
(1957)

Татарстанда көртлекләрнең каен өстенлек иткән катнаш урманнарда яшәвен Сөббух, әлбәттә, белә...

Сөббухның язган шигырьләре үзенә дә ошый. Ул аларны тәэсирләнеп иҗат итә, иң элек Хәлимәгә укып күрсәтә, аңардан һәрвакыт уңай бәя ала.

Сөббухка 34 яшькә җитеп, соңарып кына өйләнергә туры килгәнгә, үз гаиләсенең кадерен бик белә. Ул гаиләгә ир-хатын һәм балалардан торган өй җәмгәте итеп кенә карамый, гаилә аның өчен – ышанычлы тыл да, саклану урыны да. Гаилә – язучының таяныр терәге дә, иҗатының чыганагы да әле ул. Гаиләсе булу белән Сөббух чиксез

бәхетле. Әнә, Хәлимә дә китап язучы ире өчен бөтен мөмкинлекләрне тудырып тора. Булачак романын вак гарәп хәрефләре белән язып утыручы әтиләренә кызлары да комачауламый. Алар бары тик сырлы-бизәкле, урыны-урыны белән төрткеле, өтерле ул хәрефләргә исләре китеп карыйлар.

## Күңелгә тансык очрашулар

Гаделсез хөкем ителгәннәрне яклау башлангач, Сөббухның күңелендә өмет чаткылары кабына. 1953 елның көз ае тоткыннар өчен юмарт булырга охшап тора әле. Хөкем срогы тәмамланып, иреккә чыккан очракта да, «элекке тоткын»ның күңеленә тынычлык урнаша алмый, чөнки ул ватандашлары каршында һаман да «элекке халык дошманы» булып кала бирә. Бу – сиңа кырын караячаклар, син теләгән эшеңә урнаша алмаячаксың, син нәселеңә кара тап төшерүче булып каласың дигән сүз. Сөббухның да тулысынча ирекле кош кебек яшәргә теләве бик табигый. Җитмәсә, ул гомерлек сөргенгә дучар ителгән бит... И.В.Сталинның вафатыннан соң башланган аклау процессы Сөббухка, үзен яклап, кирәкле урынга гариза язу хокукын бирә түгелме соң?!.

Сөббухның СССР прокуроры исеменә 1954 елда юллаган күләмле гаризасы бик вакытлы язылган булып чыга. Ләкин аның «эше»н тикшерү артык озакка сузылган. Ул, нәкъ бер ел да җиде айдан да артып китеп, кайта-кайта тикшерелгән. Ниһаять, Казаннан Баш хәрби прокуратурага аның гаебе исбат ителмәве күрсәтелгән махсус нәтиҗәне теркәп җибәргәннәр. Шуннан соң, илнең Югары Суды хәрби коллегиясенең элекке хөкеме үз көчен югалтып, 1956 елның 9 маенда Сөббух тулысынча азат ителә һәм аңа Норильскидан чыгып йөрергә рөхсәт бирелә. Сәяси репрессия корбаны булган Сөббухның хокуклары торгызыла.

Хатыны Хәлимәнең төпле киңәшен тотып, Сөббух Казанга иң элек берүзе генә кайтып килергә ризалаша. Әйе, башта эш урыны һәм яшәү шартларына кагылышлы мәсьәләләрне карарга кирәк.

Көз патшалык иткән Казан урамыннан ул элекке хатирәләренә уралып атлый. Китап кибетенә кереп, китап диңгезенә чума. Укучы һәм язучы өчен китаптан да кадерлерәк тагын нәрсә бар?!. Ул аларны сатып алып, Норильскига да салачак әле. Андагы дусларына олы бүләге булыр.

Китап кибетеннән чыккач, Сөббух элек үзе торган фатирны эзләп китә. «Хуҗабикә әби исән-сау микән?» дигән уй борчый аны. Егетне йоклап яткан җиреннән кулга алып, бик дорфа кыланган «эшем ияләре»ннән Сөббухны яклап, курыкмыйча сүз әйткән кеше бит ул. Исән икән, исән! Хәтере дә бик яхшы: Сөббухны күрүгә үк танып ала. Чәй табыны янында утырганда, бер сүз икенчесенә ялганып, әңгәмәләре шактый озак дәвам итә аларның.

Хуҗабикә әбидә чәйләп, ял итеп алганнан соң, Сөббух Матбугат йортына юнәлә. Анда ничә еллар күрмәгән каләмдәшләрен очратачагына нык ышанып бара ул. Әлбәттә, юраганы юш килә. Шагыйрь Галимҗан Латыйп «Пионер» (1957 елдан – «Ялкын») татар балалар журналы редакциясендә әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире булып эшли икән. Ул – Сөббухның кордашы дияргә була, аңардан бер яшькә генә олы. Бер ел элек шигырьләрен мөстәкыйль җыентык итеп чыгарган... Язучы Газиз Иделле (чын фамилиясе Усманов) Язучылар берлегенең әдәби консультанты хезмәтендә икән. Ул – Сөббухтан сигез яшькә өлкәнрәк. Алар – әдәбият мәйданына бер вакыттарак килгән каләм ияләре. Газиз бер ел элек «Сайланма әсәрләре»н бастырган...

Үз чиратында Сөббух та иҗат планнары белән уртаклаша. Бу очрашу, ихлас сөйләшү үзенең нәтиҗәсен озак көттермәс. Әнә бит, каләмдәш дуслары, аның иңнәренә канат куеп, китабын бастырырга булышачакларын әйтеп торалар.

Икенче катта урнашкан Язучылар берлеге идарәсендә Сөббухны сөенечле

хәбәр көткән икән. Әңгәмә барышында аңа чакыру билеты тапшыралар. Анда: «Хөрмәтле иптәш, Сезне Татар опера һәм балет театры бинасы ачылу тантанасына чакырабыз», диелгән. Димәк, архитектор Николай Скворцов проекты буенча 1936 елда төзелә башлаган яңа бина, ниһаять, ачылачак! Ирек мәйданында Гавриил Державин һәйкәле һәм аның тирәли утыртылган бакча урынындагы төзелеш озакка сузылган икән. Театр ачылу турында карарның республикада 1933 елның 4 ноябрендә хөкүмәт тарафыннан кабул ителүен Сөббух белә. Бу вакыйга аның Сарманда «Комбайн» газетасында мөхәррир урынбасары булып эшләгән вакытына туры килә.

Сугыштан соң, 1948 елда, рәхмәт яугыры, архитектор Исмәгыйль Гайнетдинов бинаның фасад һәм интерьерларына татар халкының гамәли бизәлеш элементларын да өстәгән. Ян-яктагы ярымтүгәрәк фасадларга шушы 1956 елда А.С.Пушкин (скульпторы Н.К.Вентцель) һәм Г.Тукай (скульпторы Е.И.Шулик) һәйкәлләре урнаштырылган. Сөббух идарә рәисе Гомәр Бәширов бүлмәсеннән шул яңалыкларны ишетеп чыга.

Сөббухның хәтерендә 28 сентябрь көне аеруча истәлекле бәйрәм булып кереп калачак. Ул көнне Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрының яңа бинасы ачылачак. Сөббух дулкынландыргыч әлеге тантанада катнашачак. Сәхнәдә Муса Җәлил либреттосына Нәҗип Җиһанов көй язган һәм, шигырь текстын «татар халык әсәре» дип игълан иткәнгә күрә генә, 1948 елда СССРның Дәүләт бүләгенә лаек булган «Алтынчәч» операсы куелачак. Җик партиясен – Азат Аббасов, ә Алтынчәч партиясен Венера Шәрипова башкарачак. Сөббух беренче тапкыр өр-яңа бинада опера тыңлаячак. Ул анда озак еллар күрмәгән дуслары белән күрешәчәк...

Менә Сөббух мәһабәт бина каршында басып тора. Купшы антик бизәкләр бинага ниндидер серлелек бирә. Тышкы матурлыкны урамдагы бөтен кеше күрә ала. Сөббух, ашыгып, биек ишек аша эчкә уза. Мондагы иркенлек! Мәрмәр басмалар! Паркет идәннәр! Түшәмгә беркетелгән кандилләрдә, бәйрәмгә тантана төсе биреп, шәмнәр яна. Кәефне күтәрә торган музыка уйный... Сөббух фойеда күзләре белән дус-ишләрен эзли. Абау! Ишек янындагы йомшак урындыкларның берсендә утырып торучы кеше Ибраһим Салахов түгелме соң?!. Әйе, нәкъ үзе! Озак еллардан соң беренче очрашу! Алар, кочаклашып, сөйләшә генә башлыйлар. Шулчак яннарына Хәсән Туфан килеп баса. Туганнарча кочаклашып, үзара хәл-әхвәл сорашуга, җиз кыңгырау чыңлаганы ишетелә. Туфан, иелеп, урындык астыннан Ибраһимның култык таякларын алып бирә. Бер шул таякларга, бер Ибраһимга карый да башын чайкый һәм рәнҗүле тавыш белән: «Мөкяфәт...» – дип куя. Ягъни хезмәт бәрабәренә бирелгән «бүләк»...

Халык төркеменә кушылып, алар да тамаша залына керәләр. Мең өч йөз тамашачыны сыйдырышлы зал халык белән шыгрым тулы.

Сәхнәдә гүзәл бинаны ачуга багышланган тантана башлана. Тамашачылар игътибарына күңелле мәгълүмат агыла. ...Татар опера студиясе, Мәскәүдә эшләп, әлеге театр өчен утыз солист әзерләгән. Театр Казанда 1939 елның 17 июнендә Әхмәт Фәйзинең либреттосына Нәҗип Җиһанов әсәре буенча «Качкын» операсының премьерасы белән ачылган. Труппаның беренче составында Зөһрә Бәйрашева, Галия Кайбицкая, Асия Измайлова, Сара Садыйкова, Мөнирә Булатова, Мәрьям Рахманкулова, Фәхри Насретдинов, Усман Әлмиев, Халидә Зәбирова эшләгән. Шагыйрь Муса Җәлил әдәби бүлекне җитәкләгән. «Алтынчәч»нең премьерасы 1941 елның 12 июлендә узган. Баш рольләрне Мәрьям Рахманкулова (Тугзак), Фәхри Насретдинов (Җик) һәм Галия Кайбицкая (Алтынчәч) башкарган. Июль аенда гаскәри хезмәткә алынып, Казан гарнизонында хезмәт итүче шагыйрь, командирының рөхсәте белән, премьераны күреп киткән... Бөек Ватан сугышы башланган 1941 елдан исеме «опера һәм балет театры» дип йөртелә башлаган. Аерым бинасы булмаганга, спектакльләре Казан Зур драма театры һәм Татар академия театры сәхнәләрендә

барган. Ул елларда булып узган вакыйгалардан Себер тоткынлыгындагы Сөббухның бер хәбәрсез булуы аңлашыладыр...

Менә бүгеннән театр үзенең яңа бинасында иҗат итәчәк, аның репертуарында милли классик әсәрләр чәчәк атачак. Театр үзенә бирелгән герой-шагыйрь Муса Җәлил исемен горур йөртәчәк. 1934 елда Мәскәү дәүләт консерваториясе каршында татар опера студиясе оештырылгач, башкалада яшәүче Муса Җәлилне шунда әдәби бүлек мөдире итеп эшкә чакыралар. Ул яңалыкларны Сөббух бик яхшы хәтерли, чөнки аның – Казанда «кайнаган», «Кызыл яшьләр» газетасы редакциясендә бүлек мөдире булып эшләгән еллары. Бүген Сөббух бер горурлык белән, сокланып-сөенеп, биниһая затлы залда иҗатташлары арасында опера тыңлап утыра...

Тәнәфес вакытында Сөббухлар янына радиостудиядә эшләүче өч дус – Зәкия Садыйкова, Гайшә Бикмөхәммәтова һәм Суфия Гыйззәтуллина киләләр. Зәкия кечкенә буйлы һәм хәрәкәтчән булуы белән аерылып тора. Ул шунда барысын да икенче көнне кичкә үзләренә кунакка чакыра.

Яңа бистәдә үз йортлары белән яшәгән Зәкиянең әти-әнисе кунакларны шатланып каршы ала. Муса Җәлил белән Зәкиянең мәхәббәтеннән туган Люция егерме яшьлек чибәр кыз булып үсеп җиткән инде. Опера һәм балет театрының яңа бинасы ачылу һәм театрга Муса Җәлил исеме бирелү бәйрәменә ул да барган икән. Сөббух, бер күрүдә үк, аның йөз чалымнарын Муса Җәлилгә охшата. Люция нәкъ әнисе кебек матур итеп җырлый, шулай ук пианинода уйный икән, өстәвенә үзе дирижёрлык һәм вокал буенча махсус белемгә дә ия булу өчен, музыка училищесында укый башлаган булган. Хыялы кайчандыр әтисе Муса Җәлил эшләгән һәм яшәгән Мәскәү шәһәрендәге кинематография институтында югары белем алу икән.

Муса Җәлилне үзенең фоторәсеме аркылы гашыйк иткән Зәкиянең исә шигырьләр җыентыгы 1940 елда дөнья күргән. Аннан соң ул 1948 елда Шарль Перроның әкиятләрен «Кызыл калфак» исеме белән татар телендә китап итеп бастырырга да өлгергән икән. Зәкия сүз барышында фотоальбомындагы истәлекле бер рәсемне күрсәтә. Хәсән Туфан, үзе 1930–1934 елларда Татарстан радиокомитетында әдәби һәм музыкаль тапшырулар мөхәррире булганга күрә, эш өстәле артында фотоаппарат объективына таба карап елмаеп утырган радиостудия хезмәткәрләренә сокланып карый. Рәсем артына «Сулдан уңга: Зәкия Садыйкова, Ләйлә Латыйпова, Габдулла Фәтхуллин һәм Зәкия Бәдигова-Рәсүлева» дип язылган. Тарихи кадр, әлбәттә...

Милли ризыклы мул табын янында кадерле кунак булып утырганнан соң, рәхмәт әйтеп кузгалуга, Зәкия пианинода уйный башлый. Аңа кушылып, Гайшә белән Суфия «Озату» җырын сузалар:

*Киткән чакта, сау бул, диден,*
*Карадың күзләремә, шул.*
*Өзелде үзәк, янды ла йөрәк*
*Көт дигән сүзләреңә.*
*Кара кашың, дулкын чәчең*
*Онытa алмам, кадерлем.*
*Актык сулышым беткәндә дә,*
*Ташламамын, бәгърем.*
*Китәм, бәгърем, китәм, бәгърем,*
*Китәм, бәгърем, мин китәм, шул.*
*Аерылганнар бер кавыша*
*Дип кенә өмет итәм...*

Баянчы Рокыя Ибраһимованың табышы булып, җырны беренче башкаручы

Зифа Басыйрова репертуарында урын алган әлеге сагышлы көйне шулкадәр җиренә җиткереп башкаралар. Өй эчендәгеләр барысы да, бик бирелеп, «вокаль трио»ның аһәңле җырын гына түгел, күңелне әсир итәрлек моңын да тыңлап утыралар. Җырлаучылар йөрәгендә туган моң башка йөрәкләрне дә кузгатырлык могҗизалы кодрәткә ия. Җыр тәмамланырга да өлгерми, Хәсән абыйлары, үзе дә сизмәстән, тирән итеп көрсенеп куя...

«Озату» җырын тыңлагач, Ибраһим кинәт ерак Тубыл төрмәсендәге камерада булган бер могҗизалы хәлне исенә төшерә. Ул израп йоклап китүгә, Гений Республиканец аны тарткалап: «Тор әле, тор тизрәк! Әнә, ишетәсеңме, ул җырлый!» – ди. Башка өч тоткын да торып утыра. Чыннан да, төрмә ныгытмасы аръягындагы шәһәр мәйданына куелган репродуктордан камерага татарча моңлы җыр агыла:

*Төнгә каршы берәү моңлы итеп, Рамай,*
*Аерылышу көен җырлады...*

Шунда Гений тирән көрсенеп: «Йа Алла, Зифа... Зифа җанкисәгем җырлый бит...» – ди.

*Тынга калды урман буйлары ла, Рамай,*
*Чишмәләр дә акмый тыңлады...*

Чынлыкта ерак Казанда, радиостудиядә бик-бик ягымлы тавыш белән Зифа Басыйрова җырлый:

*Китәм инде, иркәм, мин еракка, Рамай,*
*Сөйгән ярым, синнән аерылып...*

Гений үзенә урын таба алмый: бер тора, бер ята – ул җылый. Зифаның җыры дәвам итә:

*Мине сагынганда, бер карарсың, Рамай,*
*Киткән юлларыма каерылып,*
*Киткән юлларыма каерылып.*

Зифа Басыйрова башкаруында әлеге җыр камера эченә сагышлы нур бөрки. Тоткыннарның күзләренә яшь тула...

Кызганычка каршы, Генийга үзенең Зифасы белән бәхетле күрешүләр насыйп булмаган икән шул. Ул да язучы-галим Гомәр Толымбай һәм комсомолның өлкә комитеты секретаре Мәхмүт Баһаутдинов кебек коточкыч хәлгә юлыга: акылыннан яза. Казанда башта В.И.Ленин музееп оештыручы һәм аның беренче директоры, аннары өлкә культура идарәсенең башлыгы булган Гений Республиканец 1942 елда ерак тоткынлыктан Казанга озатыла. Ләкин ул Арча кырындагы психбольницага урнаштырыла. Авыр язмышлы шәхес бала вакытында ук бәхетсез булган. Табылдык малай балалар йортында тәрбияләнгән. Татар баласы булса да, аңа шунда рус исеме кушканнар. Шулай да татар баласы икәнен белгертү өчен атасы исемен Измайлович дип куйганнар, чөнки Измаил – борынгы яһүд-гарәп исеме. Зифа Басыйрованың да балачактагы язмышы шуңа охшаш. 1921 елның көзендә башланган ачлык аркасында унбер яшьлек кызга туган авылы Мөслимнән китәргә һәм унсигез чакрым ераклыктагы Шуган авылының балалар йортында өч ел яшәргә туры килгән.

Охшаш язмышлы кешеләрнең очрашып, гаилә корып җибәрүләре дә тәкъдирләренә

алдан язылган инде. Атаклы җырчы Зифа Басыйрова 1968 елда улы Рафаэльне шагыйрь Хәсән Туфанның кызы Гөлгенә белән үзе таныштырачак. Бервакыт ул, Гөлгенәне Бауман урамында күреп: «Әйдәгез, каңгырап йөрмәгез әле икегез ике якта. Кечкенәдән бер-берегезне беләсез, кавыштырыйм әле үзегезне», – дип кочып алачак. Гөлгенә йөзгә дә, холкы белән дә әтисенә охшаган. Кояштай балкып елмаюы нәкъ әнисенеке инде. Зифа Басыйрова белән Луиза Салигаскәрова, артисткалар булып, бер театрда эшләгән кешеләр бит. Аңарчы әле тагын унике ел вакыт үтәсе бар... Ә бер елдан Туфанның Тимер (Тимур) исемле оныгы туачак.

Менә бит Сөббух, Ибраһим һәм Хәсән абыйлары Казанда бик еш очрашып торалар. Күрешкән саен үзара әңгәмә вакытында сүз күбесенчә әдәбият һәм бигрәк тә шигърият тирәсендә әйләнә. Алар өчесе дә якын елларда шигырь җыентыгы чыгаруны максат итеп куйганнар. Булачак китапларына исем дә сайлаганнар инде. Ибраһимның туган җир, аның табигате, яшьлек, мәхәббәт турындагы лирик шигырьләр җыентыгы «Дала дулкыннары» дип аталыр, Сөббухның «Ак төннәр» дип исемләнәчәк китабын Себер шигырьләре тәшкил итәчәк, Хәсән абыйлары төрмә һәм сөрген елларында фәлсәфи яктан тирәнәйгән лирик шигырьләр тупланмасын «Җырлар, шигырьләр» дип исемләргә уйлый икән. Шигърият аларны рухи имгәнүдән саклап калган. Шуңа күрә алар өчесе дә, Шигырь галиҗәнабы алдында баш иеп, хөрмәтләрен күрсәтәләр.

Хәсән Туфан:

*...Агыла да болыт агыла*
*Туган-үскән җирләр ягына;*
*Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр*
*Нәрсә әйтер туганнарыма?!*
*Агыла да болыт агыла...*
(1951)

Әйе, Туфанның мәхәббәт лирикасы күздән яшьләр китерерлек. Аның шигырь юллары муенсадагы энҗе-мәрҗән кебек. Ирен үзенең донор каны бәрабәренә саклап калырга тырышкан Луиза (Гайникамал) Салигаскәрова белән хатынына тугрылык саклаган Хәсән Туфанның сокланырлык мәхәббәтенә һәйкәл булырлык шигырьләр болар... Хәсән абыйсы да, Сөббух кебек, сөргендә Себер якларында булган. Казанга ул реабилитацияләнеп шушы 1956 елның җәендә кайткан. Йөрәкләрне тетрәндерерлек хәл: Туфан кулга алынгач, эшеннән чыгарылган театр актрисасы Луиза бер ел элек вафат булган. Шул сәбәпле фатирында ямь таба алмаган Хәсән абыйлары менә ничә көннәр инде җан дуслары хозурында, вакытлыча гына булса да, күңеленә тынычлык таба кебек...

Ибраһим Салахов:

*...Яшьлек, күксел таулар төсле,*
*Киткән саен матур, ягымлы;*
*Томаннарга төренер яшьлегемне*
*Мин онытмам – кайнар чагымны...*
*...Агыйдел алкын икән,*
*Сулары салкын икән;*
*Агыйделкәй кызларының*
*Йөрәге ялкын икән.*

Әйе шул, Ибраһим белән Зәйтүнәнең Кабан күлендә көймәдә йөзгән вакытлары. Егет мандолинада уйный, ә Зәйтүнәкәй, «Агыйдел» көенә туры китереп, аның шигырен җырлый... Ибраһим хыялында шул чакларны яңарта.

Ибраһим да, Сөббух металлургия комбинаты төзелешендә чиләнгән кебек, алтын приискаларындагы «хезмәт белән төзәтү» лагерьларында газап чиккән. Өстәвенә шахта башлыгы гаебе белән авариягә эләгә, сул аягына ампутация ясыйлар, күзләренә дә зарар килә... Тайгада Себер тоткыны Ибраһимга үзләре оештырган әдәби кичләр бер юаныч булып торган. Анда-санда алар – Санҗе Кәләев, Зәен Шашкин, Николай Исидорович һәм Ибраһим – йә Полотай, йә Шашкин кабинасына җыелганнар. Шунда казакъ, калмык, татар, рус әдәбияты классикларын искә алганнар һәм үзләренең шигырьләрен укыганнар. Ул кичләр ничектер күңелләренә ял биргән, кайгыларын оныттырган, яшәү көче өстәгән, сүнеп барган өметләрен кабызган... «Дала дулкыннары» исемле дүртенче китабын нәшриятка тапшыруга, Ибраһим Салахов ГУЛАГ темасын яктыртып, документаль роман-хроника яза башларга һәм тоткынлыкта башыннан кичкән хәлләрне шул әсәрендә сурәтләргә уйлый икән.

Сөббух Рәфыйков:

*...Бик куркыныч монда юлчыга,*
*Усалланып үкерә ак пурга.*
*Боланнарга утырып киләм мин,*
*Мондый көндә чыктым ник юлга?*
(1948)

*...Әле дә шулай сагынып көтәмен мин*
*Йомшак җилле, ямьле яз аен.*
*Күз алдыма килә кичке уеннар,*
*Гүя шаулый әле дә ак каен.*
(1953)

*...Дусты, кардәшеннән хәбәр көтеп,*
*Атналарны кемнәр санамый;*
*– Хат ташучы нигә күренми? – дип,*
*Тәрәзәгә кемнәр карамый?...*
(1956)

Казандагы барлык очрашулар арасыннан Язучылар берлегенең Тукай клубындагы очрашу да гомергә истә калырлык вакыйга булыр, чөнки ул да – иң тансык аулак очрашу. Нахактан «халык дошманы» дигән кара мөһер сугылган Сөббух Рәфыйков, Хәсән Туфан һәм Ибраһим Салаховка, озак еллар үткәннән соң, иркенләп сөйләшергә насыйп булган икән. Урамда көзнең октябрь ае хакимлек иткән вакыт. Сөббух үзе октябрьнең 17 сендә кулга алынганлыктан, әлеге ай аның хәтерендә авыр хатирәләрне генә кузгата. Ярый инде, җан дуслар белән ихластан гәпләшеп, әңгәмә корып утыру шатлыгы Сөббух кичергән күңелсез вакыйгалар тәэсирен кысрыклап чыгара. Ул Казанга кайтканнан бирле, көн саен диярлек яңалык артыннан яңалык булып кына тора. Әнә, татар поэзиясе антологиясе өчен материал туплыйлар икән. Сайланма әсәрләр җыелмасы, мөстәкыйль ике китап булып, татарча һәм рус теленә тәрҗемәдә чыгачак, ди. Анда тарихи җырлар, бәетләр һәм Кол Галидән башлап шигъри үрнәкләр урын алачак икән. Китапка кереш сүз язачак әдәбият галиме Хатип Госман, алар янына килеп: «Үзегезнең күңелегезгә аеруча якын булган шигырьләрегезне һәм аларның юлга-юл русчага тәрҗемәләрен дә эшләп тапшырыгыз», – ди. Ул үзе университетта укыта икән. Сөббух белән Ибраһим, шагыйрь Хәсән абыйлары Туфанга ияреп, бишенче каттагы Тукай клубына күтәреләләр. Башта һәрберсе өч өстәл артына аерым-аерым урнашалар, әмма түзмичә, Хәсән абыйлары янына күчәләр. Алар аны сагынганнар. Тирән сырлар

эз салган киң маңгайлы, чал чәчле, уйчан карашлы Туфан алар өчен бик якын, бик кадерле шул... Аларның шагыйрь абыйлары укуында күңел шигыре тыңлыйсылары килә. Туфан да озак көттерми, аларның уйларын сизгән кебек, үзенә генә хас аһәңле йомшак тавыш белән, йөрәк түреннән ургылган шигъри юлларга күчә. Әле генә бөреләнеп килгән шигырен укый башлый:

*...Тәрәзәңә «җилләр» бәрелгәннәр,*
*«Сагынма!» – дип янап киткәннәр...*
*Күнмәгәнсең... Эштән сөрелгәнсең...*
*Еллар сине донор иткәннәр...*
*Посылкалар белән ярдәм иттең:*
*– Без бит илдә... өйдә бит... – дидең.*
*Ә ул ярдәм*
*Каныңа алыштырган*
*Паёкларың икән бит синең...*
*Алдарсың дип уйлый идеммени? –*
*Ә син мине алдагансың ич:*
*Өзелер хәлгә җиткән гомеремне син*
*Җаның белән ялгагансың ич!*
*Соңгы таңың беленеп килгәндә дә,*
*Күрешү көнен көткәнсеңдер дә,*
*Ләкин ирек,*
*Бераз кичегеп килеп,*
*Эзләп тапты мине Себердә...*

Шагыйрьнең йөрәк авазы булып чыккан шигырь юллары сөекле хатыны Луизага багышланганын Сөббух та, Ибраһим да шунда ук аңлап алалар...

Әйе шул, күкрәкләрендәге яман шеш аркасында, Луиза 1955 елның июнь аенда фани дөньядан китеп бара. Унтугыз яшьлек Гөлгенәсе япа-ялгыз кала. Кешене тынсыз итәрлек фаҗигале хәбәр Новосибирск өлкәсенең Устарка районында урнашкан Покровка авылында мәңгелек сөргендә яшәп яткан Туфанга ярты елдан соң гына барып ирешә. Чөнки иренең киңәше буенча үзен театрга яңадан эшкә алсыннар өчен Луиза Туфаннан күз буяу өчен генә аерылыша. Шуңа күрә ике арада хатлар алышу туктала.

**Рухия АХУНҖАНОВА**

*(Ахыры киләсе санда).*

# ТАТАР ТАМЫРЛАРЫННАН ҮСКӘН ҖЕТЕ ГӨЛЛӘР




Бу чибәр, зыялылыгы кыяфәтенә чыккан ханымны кем буларак тәкъдим итәргә? Әлбәттә, иң беренче чиратта ул – Татарстаннан читтә яшәүче галимә: филология докторы, Америка мәдәниятен һәм әдәбиятын өйрәнүче белгеч. Бер үк вакытта – язучы, җәмәгать эшлеклесе. Әмма аның хакында сүз башландымы, нәсел-нәсәбен, ата-бабаларын әйләнеп узып булмый.

Сүзебез – тугач та Фәхрия исемен алган, бүген исә Гөнүл Пултар буларак билгеле гаҗәеп язмыш иясе хакында булыр. Татар халкын милләт буларак туплаган, оештырган күренекле фикер иясе, Төркия дәүләтчелегенең нигезләрен салышкан сәясәтче Садри Максудиның (1878–1957) һәм шагыйрь Дәрдемәнднең абыйсы Шакир Рәмиев кызы Камиләнең (1892/93–1973) оныгы ул. Төркиянең беренче хатын-кыз дипломаты, сенатор һәм академик Әдилә Айданың (1912–1992) һәм XIX гасыр госманлы дәүләт эшлеклеләреннән булган, Багдад губернаторы шәйхелвәзир Мехмед Намык-паша оныгы Рәшид Мазһар Айданың кызы.

Менә шушы төрек дөньясында мәшһүр гаиләдә, 1943 елның 3 ноябрендә дөньяга килгән Гөнүл, Төркия илчесе булган әнисенең эш урынына бәйле, белемне төрле илләрдә *(Франция, Нидерланд, Югославия)* алган. Башлангыч мәктәп курсын – Парижда, урта мәктәпнекен – Арнавуттагы Америка хатын-кыз көллиятендә һәм Гаагадагы Халыкара Америка мәктәбендә үзләштерү, күрәсең, төрле халыкларның көнкүреше белән шунда яшәп танышу аның киләчәктә нинди һөнәр сайлавына йогынты ясый. Әдәбиятларны, мәдәниятләрне чагыштырып өйрәнү – алардагы охшашлыкларны да, үзенчәлекләрне дә күрергә, аңларга ярдәм итә, шуның белән бергә, халыкларның, милләтләрнең менталь, психологик, фәлсәфи үзлек-үзгәлекләрен дә төшенүгә китерә ала. Бу белгечлекне сайлау өчен телләр белү дә, күп уку һәм төрле мәдәниятләрдән, әдәбиятлардан хәбәрдар булу да сорала.

1967 елда Истанбулдагы Роберт көллиятендә (хәзерге Босфор университеты) бакалавриатны тәгәлләп, кыз укуын Парижда Сорбонна университетында дәвам итә. 1968 елда кияүгә чыга һәм Төркиягә кайтып, «Чагыштырма әдәбият белеме» белгечлеге буенча Анкарадагы Урта көнчыгыш техник университетында докторантура

тәмамлый. Ире – техник фәннәр докторы, төзелеш фәннәре профессоры Мостафа Пултар. Өч балалары туа.

Бу елларда Гөнүл Пултар күп укый, дөнья әдәбиятындагы чәчмә жанрлар, бигрәк тә Америкада һәм Европада роман жанрының үсеш-үзгәреше белән кызыксына, көчен журналистикада һәм әдәбиятта сыный. Бу нисбәттән, 1965 елда «Винтаж» дип аталган сценарие өчен Роберт көллиятенең Югары мәктәбе киноклубы (Төркия) конкурсында беренче урынны һәм 1970 елда француз телендә иҗат ителгән «Дустыма хат» эссесы белән Франциядә Хашетт-Ларусс премиясен алуын да әйтергә кирәк.

1979 елда Гөнүл Пултарның «Дөнья – куласа» исемле беренче романы басылып чыгу, аннан да бигрәк, әсәрнең зур популярлык казануы күпләр өчен көтелмәгән хәл була. Романның төп герое – баласы тууын көткән йөкле хатын; ул бу олы вакыйганы тормышындагы борылыш мизгеле кебек кабул итә. Вакыт иркенлеге биргән көтү айларында героиня үзенең, дусларының, гаиләсенең, илнең үткәнен искә төшереп, хатирәләр аша узганнарга бәя бирә.

Яшүсмер вакыты 1960нчы елларның шаулы вакыйгаларына туры килеп, зур шәһәрдә заманча белем алган кыз ул чакта үзенең урынын җәмгыятькә файдалы шәхес буларак табарга тели. Әлеге теләк аны традицияләрне саклап, хатын-кызга, иң беренче чиратта, гаилә учагын тергезүче итеп караган гаиләсе һәм туганнары белән каршылыкка кертә. Шул ук вакытта героиняның мохите – яшьләрнең зыялы катламы – илдә барган хәлләрдән хәбәрдар булса да, сәяси акцияләрдән читтә торырга омтыла. Алар өчен иң мөһиме – акылы-белеме, зиһене-холкы белән үз иленә, җәмгыятькә кирәк булу, хезмәт итү. Язучы әлеге мохит вәкилләрен илдәге тирән үзгәрешләр вакытында йөзгә-йөз баскан ике зур көчнең – иске традицион җәмгыять кыйммәтләрен сакларга омтылган «өлкәннәр», шул традицияләрне җимерергә теләгән инкыйлабый «яшьләр» лагереның – берсенә дә кермәгән катлам буларак тасвирлый. Шәһәр читендәге аулак урында баласы тууын көткән яшь хатын, узганнарны искә төшереп, «дөрес эшләдемме?» дигән сорауга да җавап эзли.

Язучының икенче романы «Суны минем кулымнан эчсеннәр» дип атала. Ул 1980нче елларда, Лондон шәһәрендә булган канлы вакыйгалардан башлана: террорчылар һөҗүме нәтиҗәсендә төрек илчесе һәлак була, аның хатыны Фатош Атаман кома хәлендә хастаханәгә эләгә. Комадан чыгуга, ул үзенең үткәннәрен хәтеренә төшерә башлый. Әмма аның хәтерендә бер-бер артлы калкуланган вакыйгалар, 1950нче елларда Анадолуда, Истанбулда, аннары Америкада булган хәлләр, әниләре янына килгән улларының белгәннәре белән тәңгәл килми. Болар – моңа кадәр яшереп киленгән хакыйкатьме, төшме, хәтернең ялгышуымы? Әсәр бу сорауларга ачык кына җавап бирми, һәр укучының үзенчә укуын, аңлавын таләп итә.

Гомумән алганда, Гөнүл Пултар әсәрләрендә хатын-кыз язмышын һәм илдәге иҗтимагый-сәяси хәлләрне үреп бирү күзгә ташлана. Соңрак инглиз телендә иҗат ителгән «Леда һәм аккош» хикәясендә дә элеккеге социалистик илләр хәятына бәя бирү омтылышы ясала. Борынгы юнан мифын исемгә чыгарган сюжет, бу хактагы инглиз телле фәлсәфи әдәбияттагы (мәс., Уильям Йейтсның сонеты, 1924) кебек үк, вакыйгаларның очраклымы яки закончалыклымы булуын аңларга омтылып язылган дигән тәэсир туа. Символлар исә язучы куйган сорауларны кешеләр психологиясенә дә, халыклар һәм илләр язмышына да, кешелек яшәешенә дә юнәлтеп аңларга мөмкинлек бирә.

Әдәбиятчылар һәм тәнкыйтьчеләр Гөнүл Пултар иҗатын модернизм юнәлешендә бәялиләр, еш кына язу стилендә Сэмюэл Беккет (1906–1989) белән охшашлык күрсәтелә; әдәбият белеме өлкәсендәге төрле мәдәниятләр тоташуы, синтезы мәсьәләләренә караган эзләнүләре дә француз-ирланд фикер иясенеке белән бер дулкында яңгырый. Дөньякүләм мәшһүр прозаик һәм драматург, «абсурд

театры»н тудыручы, 1969 елны әдәбият буенча Нобель бүләге алган Беккет кебек үк, Пултар да әсәрләрендә адәм баласы өчен иң мөһим кыйммәтләрне эзли, кешеләр яшәү дәвамында кабул итә торган карарларның ни өчен аларны көтелгән нәтиҗәләргә китермәү серләре хакында уйлана. Язу рәвеше ягыннан, аларны төрле (бер-берсеннән ерагайган) мәдәниятләр синтезы чигендә, аларның традицияләрен бер үк вакытта файдаланып, интеллектуаль әзерлекле укучыга атап иҗат ителү берләштерә, күрәсең.

Язучы буларак шактый зур уңышларга ирешсә дә, Гөнүл Пултар төп һөнәре итеп академик фән юлын сайлый. Аның Америка мәдәнияте һәм әдәбияты буенча тикшеренүләре төрле илләрдә (аеруча Төркия, АКШ) дөнья күргән фәнни җыентыкларда басылып тора. Төп эзләнүләр юнәлеше буларак ул әдәбиятта, журналистикада сайлаган теманы тәгаенли: дөньядагы үзгәрешләр һәм хатын-кыз. 1986 елда «Хатын-кызларның азатлыкка омтылуы: Дорис Лессинг эзләнүләре һәм никах проблемасы» дигән темага докторлык диссертациясен яклый. Безнең фикеребезчә, Гөнүл Пултарның язучы булып китүенә һәм әсәрләренең тематикасына да нәкъ менә фәнни тикшеренүләре, Дорис Лессинг әсәрләре зур йогынты ясаган.

Билгеле булганча, инглиз язучысы Дорис Мэй Лессинг (1919–2013), 2007 елда әдәбият өлкәсендә Нобель бүләге лауреаты, коммунизм идеяләреннән – феминизмга, аннары – суфичылыкка килгән фикер иясе буларак билгеле. Аның иҗатын «феминизм әдәбияты», «фәнни фантастика», «футурологик әдәбият» дип тә бәялиләр. Озын иҗат гомерендә ул күп кенә сәяси-социаль, психологик, фантастик романнар яза, әмма аларда һәрвакыт хатын-кыз тормышын үзәккә куя, яшәешнең төп закончалыкларын хатын-кыз күзлегеннән яктырта. Гөнүл Пултарның Дорис Лессинг иҗатын нигез итеп алган фәнни хезмәте дөнья мәдәниятендә хатын-кызларның урынын, ролен билгеләп язылган әсәрләрнең барлыкка килү сәбәпләрен, алардагы карашларны һәм идеяләрне фәлсәфи-культурологик яссылыкта тикшерә.

1992 елдан Гөнүл Пултар Билкәнт университетының инглиз теле һәм әдәбияты факультетында укыта башлый. Озак та үтми, университетта Төрек әдәбияты үзәге оештырып җибәрә. 2005 елны бу Үзәк Мәдәни эзләнүләр ассоциациясенә әверелә.

Фәндә аны аеруча төрек чыгышлы Америка язучылары, аларның үзенчәлекле иҗаты кызыксындыра. Хезмәтләре арасында шәхес һәм мохит, милләт һәм миллият, мәдәният, күптеллелек, миграция мәсьәләләре мөһим урын тота. Әмма төрле мәдәниятләр киселешендәге гаиләдә дөньяга килгән, күп телләр белүче, күп илләрдә яшәгән галимәнең хезмәтләрендә бу мәсьәләләргә төрле яклап, комплекслы якын килү күзәтелә.

Гөнүл Пултарның иҗтимагый-мәдәни эшчәнлеге дә күптармаклы булуы белән аерылып тора. Ул Төркиядә – Америка мәдәниятен, Америкада – Төркия мәдәниятен танытуга зур көч сала. «Төркиядәге Америка тикшеренүләре журналы»н (ингл. *Journal of American Studies of Turkey*) оештырып, аның баш мөхәррире була. Америка Кушма Штатларында нәшер ителүче «Популяр мәдәният» журналының редколлегия әгъзасы буларак, бу юнәлештә дә эшли. Күп кенә халыкара оешмаларда төрле вазифалар башкара.

Аның иҗтимагый эшчәнлегенең бер тармагы татар дөньясы белән бәйле. 1991 елны Гали Акыш оештырган Бөтендөнья татарлары лигасын җитәкләү эше 1997 елдан Гөнүл Пултар җилкәсенә төшә. Шушы вакыттан Садри Максуди оныгы Татарстан, башка төрки республикалар белән тыгыз хезмәттәшлек урнаштыра. 1992 елны Беренче татар корылтаена килгән делегатлар арасында Садри Максудиның икенче кызы Наиләнең улы Али Вахит Турхан һәм кызы Эрэн, уллары Гәрәй, Сәлҗүк белән Гөнүл Пултар да була.

1998 елда Гөнүл Пултарны Гарвард университетының Лонгфелло институтына штаттагы гыйльми хезмәткәр итеп чакыралар. Билкәнт университетында 2003 елга

кадәр, лаеклы ялга чыкканчы эшләвен дәвам итә. Аннары да семинарлар алып бара. 2004 елны Пултарлар гаиләсе Истанбулга күченә.

Соңгы елларда Гөнүл Пултар элеккеге Советлар Союзы җирләрендәге төрки телле халыклар мәдәнияте белән шөгыльләнә. Бер үк вакытта бабасы Садри Максуди Арсалның гыйльми мирасын барлауны үзенең бурычы дип саный. 2018 елны ул аның атаклы «Милләтчелекнең бәгъзе әсаслары» китабын кабат нәшер итә (Ötüken Yazılımları, Истанбул, 272 бит).

Гомумән, Гөнүл Пултарның язмышы, профессиональ эшчәнлеге күпмедер күләмдә әнисенең язмышын кабатлый. 1912 елны Санкт-Петербург шәһәрендә туган Гадилә Садри кызы Максудова (Әдилә Айда; 1912–1992) да башлангыч белемне Берлинда һәм Парижда ала, Истанбулда Нотр Дам де Сион дип исемләнгән француз лицеен тәмамлый. Югары белемгә Анкара университетының юридик факультетында ия була. Чит илләр эшләре министрлыгына имтиханнарны уңышлы тапшырып, 1932 елны 20 яшьлек татар ханымы Төркия Республикасының беренче хатын-кыз дипломаты итеп тәгаенләнә. 1934 елда хатын-кызларны дипломатик эшкә билгеләүне тыю турында карар чыккач, бу өлкәдән китеп торырга мәҗбүр була: Анкарадагы Дәүләт консерваториясендә, Халык мәгарифе көллиятендә, Анкарадагы кызлар лицеенда француз теле укыта. 1941 елны француз теле һәм әдәбияты факультетын төгәлләп, университетта укытуга күчә. Кияүгә чыгып, Истанбулга кайта. Шушы вакытта аның беренче җитди фәнни хезмәте француз телендә басылып чыга: «Виктор Гюгоның Маллармега йогынтысы. Диалоглар» (Истанбул, 1953). Биредә сүз XIX гасыр француз әдәбиятының ике мәшһүр шагыйре иҗаты яки Виктор Гюгоның (1802–1885) Стефан Малларме (1842–1898) иҗатына йогынтысы турында гына бармый. Билгеле булганча, Гюго – француз романтизмын тудыручыларның берсе. Айда ханым милли әдәбиятта романтизмнан – символизм үсеп чыгу проблемасына якыная.

1955 елны аның яңа китабы француз телендә нәшер ителә: «Малларменың эчке драмасы һәм Малларме символларының килеп чыгышы» (Истанбул, 1955). Әдәбият галимәне тарихка тарта. 1956 елны шулай ук француз телендә дөнья күргән китап инде XVII гасыр Франция тарихына, Людовик XIV – Кояш-корольнең Франция белән Госманлы империясе арасында үзара файдалы багланышлар урнаштырырга омтылышларына, «тюрбаннар» һәм «париклар» капма-каршылыгына багышлана («Кояш-корольнең төрек дипломаты»). Алга таба ул Франция корольләре тормышына кагылышлы берничә хезмәт яза.

1957 елны югарыда телгә алынган карар юкка чыгарылуга, Әдилә Айда Чит илләр эшләре министрлыгына әйләнеп кайта. 1958 елны – ООНның Генераль Ассамблеясында вәкил, 1959 елда – Гаага илчелегендә илче киңәшчесе, 1961 елдан – Белград илчелегендә киңәшче, 1963 елдан – мәдәният мәсьәләләре буенча Генераль директор ярдәмчесе, 1966 елдан – Рим илчелегендә Илче-киңәшче. 1976 елда исә Республика Сенатына сенатор итеп билгеләнә. 1980 елга кадәр шушы постта була.

Римда вакытта Әдилә Айда этрусклар тарихы белән мавыгып китә. Билгеле булганча, этрусклар дип б.э.га кадәр 1 меңъеллыкта Аппенин ярымутравының төньяк-көнбатышында яшәгән цивилизациягә әйтәләр. Римлыларга югары мәдәният биргән бу халыкның килеп чыгышы турында бәхәсләр бүгенге көнгә кадәр бара. Башта төп версия буларак, фәндә аларның Италиядән килеп чыгышы тәгълиматы формалаша. Әмма бу караш археологик тикшеренүләр вакытында кире кагыла. Соңрак аларның берничә дулкын булып Анадолудан, Альп буйларыннан һәм Төньяк Каспий далаларыннан (Скифия) килүләре фаразлана. Әдилә Айданың француз телендәге («Этрусклар төркиләр булганмы?», Париж, 1971) һәм төрек телендәге («Этрусклар төркиләр булган. Дәлилләр», Анкара, 1985) хезмәтләрендә этрускларның килеп чыгышы борынгы төркиләр тарихына бәйләп карала.

Бу эзләнүләре галимәне төркиләр мәдәниятенә һәм тарихына якынайта. 1971 елны Төркиягә әйләнеп кайткач, ул төркиләрнең бик борынгы тарихына күз салган хезмәтләр яза («Төркиләрнең беренче бабалары», Анкара, 1987). Бер үк вакытта әдәбият һәм мәдәният мәсьәләләре белән дә шөгыльләнә. Аерым алганда, төрек шагыйре, дипломат Яхья Кемаль тормышы һәм иҗатына багышланган монографияләр нәшер итә. 1991 елны аның әтисе Садри Максуди Арсалга багышланган хезмәте төрек телендә басылып чыга, 1996 елда ул рус теленә дә тәрҗемә ителә (Айда А. Садри Максуди Арсал / науч. ред., примеч., послесл. С. М. Исхакова; перевод В. Б. Феоновой. Москва, 1996. 359 б.).

Гомумән алганда, бу китапны Әдилә Айда фәнни эшчәнлегенең иң югары ноктасы дип атарга буладыр. Бер яктан, ул әтисенең эшчәнлеген, гыйльми карашларын тулы бербөтен тарих итеп, архив документларына һәм истәлекләргә таянып тергезә, бу хезмәтне Садри Максуди Арсалга куелган рухи-мәгънәви һәйкәл дип атарга буладыр. Анда Максудиның Россиядә яшәгән, анда үз милләтенең язмышын үзгәртү өчен сәяси-иҗтимагый һәм фәнни-мәдәни көрәш алып барган чоры да, Ататөрекнең киңәшчесе буларак, Төркиядә реформаларны тормышка ашыру буенча эшчәнлеге дә, Төркиядә илнең рәсми тарихын һәм хокук тарихын булдыру юнәлешендәге гаять зур хезмәтләре дә җентекләп тикшерелә һәм бәяләнә.

Икенче яктан, галимә Идел буе төркиләренең безнең эрага кадәр башланган тарихи юлын реконструкцияли. Китапның «Кереш» дип аталган өлешендә профессиональ тарихчы каләме белән төркиләрнең бик борынгы тамырлары – төньяк һуннардан юл алган чишмә башы, аларның б.э.га кадәр III гасырда Идел-Урал буенда хакимлеге, саклар исеме астында Көнчыгыш Европага һөҗүмнәре, Атилла үлеменнән соң тагын бер дулкын төркиләрнең, огур исеме астында Урта Азиядән Европага хәрәкәте, «болгар» атамасы, Күк төркләр дәүләте, Бөек Болгар дәүләте, болгарларның ислам динен кабул итүе, Алтын Урда барлыкка килү һ.б. вакыйгалар күзәтеп узыла. Казан ханлыгы, аның тарихына тукталып, Әдилә ханым Сөембикә ханбикәне – «Казанның Жанна д’Аркы» дип атый.

Хезмәттә, шулай ук, XX йөз башы татар милли-сәяси хәрәкәте, аның барышы, әйдаманнары турында кызыклы мәгълүматлар бар. Бу китап бүген дә татар яңарышы тарихы белән кызыксынучылар өчен өстәл китабы булып кала.

Күргәнебезчә, Садри Максуди Арсалның кызы Әдилә Айда һәм оныгы Гөнүл Пултар – фән тарихында үз сукмакларын салган галимәләр. Әмма бер кызыклы факт күзгә ташлана: дөнья мәдәниятен фәлсәфи, тарихи, культурологик юнәлешләрдә өйрәнүләр аларның икесен дә татар дөньясына, татар ментальлегенә якынайта.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы.*



*Марс Шабаев (1933–2008)
шагыйрь, язучы, тәрҗемәче.*



*Язучыларыбыз табигать
хозурында. Марс Шабаев һәм
Габделхәй Сабитов. 1967 ел.*



*«Казан утлары» журналы редакциясендә. Сулдан уңга: Равил Фәйзуллин, Самат Шакир,
Шәукәт Галиев, Марс Шабаев, Нәби Дәүли, Зәки Нури. 1964 ел.*



*Татарстан язучыларының IX съезды башланыр алдыннан. Сулдан уңга: Илдар Юзеев, Рафаэль Мостафин, Диас Вәлиев, Туфан Миңнуллин, Марс Шабаев, Аяз Гыйләҗев, Фәнил Мансуров, Нил Юзиев, Әбрар Кәримуллин. 1979 ел.*




*Марс Шабаев, Луиза Батыр-Болгари, Рөстәм Яхин, Марсель Галиев. 1980 ел.*



*«Казан утлары» журналы редакциясе коллективы Марс Шабаевта кунакта. 2003 ел.*

*Фотолар «Казан утлары» архивыннан алынды.*

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ РУХИ МИРАСЫН БАРЛАУ

Фольклористика фәне ике юнәлешне колачлый: аның берсе бүгенге көнгә кадәр тупланган халык авыз иҗаты әсәрләрен өйрәнүгә бәйле булса, икенчесе халыктан фольклор үрнәкләрен җыю-туплау эшен тәшкил итә.

Татар фольклористикасының ике юнәлештә дә үз тарихы бар. Халык иҗатын җыю-туплау һәм өйрәнү белән бәйле тикшеренүләр элек-электән, төгәлрәк әйтсәк, XIX–XX гасырлар чигендә үк аерым татар зыялыларының (К.Насыйри, Р.Ф.Фәхретдинев, Г.Н.Әхмәрев, Х.Б.Бәдигый, Җ.Җ.Вәлиди һ.б.) инициативасы белән уздырыла башлый. Әмма XX гасырның 30 нчы еллары ахырына кадәр татар фольклор әсәрләрен халыктан җыю, аларны туплап бастырып чыгару, ягъни яңадан халыкка кайтару һәм фәнни нигездә өйрәнү системалы рәвеш алмаган була әле.

Татар фольклористикасы тарихының яңа этабы 1939 елда Казанда Татар теле, әдәбияты һәм тарихы фәнни-тикшеренү институты ачылгач башлана. Хәмит Ярми җитәкчелегендә тирән һәм күпкырлы фәнни эзләнүләр юлына чыккан фольклор секторы галимнәре халык иҗаты әсәрләрен җыю-туплау һәм шулар нигезендә махсус саллы җыентыклар әзерләү эшенә керешәләр. 1940–1980 елларда татар фольклорын җыю һәм киң җәмәгатьчелеккә җиткерү максатыннан Татарстанда һәм аннан читтә татарлар яшәгән төбәкләрдә күпсанлы кыр тикшеренүләре уздырыла. Экспедицияләрдә тупланган бай материал «Халык иҗаты» (1940), «Татар халык җырлары» (1948), «Татар халык иҗаты» (2 томда. 1951, 1954), «Татар халык әкиятләре» (2 томда. 1946, 1956), «Татар халык җырлары» (1965), «Татар халык иҗаты» (13 томда. 1972–1988, 1993), «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» (1967) кебек коллектив монографияләрдә, халык иҗаты җыентыкларында, күптомлыкларда чагылыш таба.

XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында татар халык авыз иҗатын академик дәрәҗәдә барлау һәм өйрәнү эше яңа баскычка күтәрелә. Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан уздырыла торган комплекслы фәнни экспедицияләрдә фольклорчы галимнәр эшчәнлеге аерым бер юнәлеш рәвешен ала. Институт тарафыннан әзерләнә торган һәм инде дөнья күрә башлаган «Татар халык иҗаты»ның егерме биш томлык академик тупланмасы аерым бер урын били.

Күптомлык моңа кадәр дөнья күргән унөч томлык басмага кергән материалларны да, аларга керми калган кайбер үрнәкләрне дә һәм академик томнар чыкканнан соң табылган фольклор җәүһәрләренең барысын да игътибар үзәгенә алуны күздә тота. Егерме биш томлык татар халык иҗатының төрле жанрларына караган әсәрләрне үз эченә алган аерым китаплардан («Мифология», «Йола фольклоры», «Әкиятләр» (6 китапта), «Дастаннар», «Китаби дастаннар», «Табышмаклар», «Мәкальләр һәм әйтемнәр» (2 китапта), «Мәзәкләр» (2 китапта), «Бәетләр» (2 китапта), «Мөнәҗәтләр», «Риваятьләр һәм легендалар», «Җырлар» (4 китапта), «Балалар фольклоры» (2 китапта) тора.

Башка халыкларда әзерләнгән академик томнардан аермалы буларак, егерме биш томлык хезмәтнең нигезенә татар фольклорын һәм жанр, һәм тематик яктан якын килеп, халыкның рухи мәдәниятен, күпьеллык тәҗрибәсен чагылдырган тулы бербөтен буларак күз алдына бастыру идеясе салынган. Гасырлар дәвамында туплана килгән фольклор материаллары жанр төрлелеге, йолага бәйлелеге яисә аннан аерылган булуы, кайсы төбәктә һәм кайсы чорда язып алынганлыгы һ.б. яклары белән бер-берсеннән аерылып торсалар да, аларның барысын бергә туплаган сыйфат та бар. Бу – ядкярләрнең татар

телендә булуы, халыкның холык-фигыленә ярашканлыгы, милли менталитетка буйсынуы һәм халыкның тарихи хәтерен бүгенге көнгә китереп җиткерүе.

Бүгенге көндә Татарстан китап нәшриятында егерме биш томлык «Татар халык иҗаты» академик тупланмасының «Мифология» (2021) һәм «Йола фольклоры» (2022) дип аталган томнары басылып чыкты.

Татар халкының мифологик күзаллауларын чагылдырган текстларны тулы бер система буларак тәкъдим иткән «Мифология» томы – татар фольклористикасы тарихында беренче мәртәбә әзерләнгән фәнни хезмәт. Әлеге китапка кертелгән һәм төрле жанрларга (мифологик хикәят, легенда, ырым, ышану, тыю, юрау һ. б.) караган текстлар эзлекле рәвештә «Югары аллалар, дөнья һәм төрки кабиләләр яратылышы», «Әйләнә-тирәдәге төрле объект һәм күренешләрнең килеп чыгышы», «Беренче кешеләр һәм алып пәһлеваннар», «Рух-ияләр», «Түбән рухлар», «Дәвалау һәм саклау магиясе», «Халык ышанулары» дип исемләнгән җиде бүлектә тәкъдим ителде.

«Югары аллалар, дөнья һәм төрки кабиләләр яратылышы» дип исемләнгән бүлек бабаларыбызның һун чоры, төрки каһанлыклар корып яшәгән дәвердәге гомумтөрки кавем күзаллавында формалашкан мифологик карашларын күзәтүгә, аларның соңрак дәвер халык мифологиясендә сакланган эзләрен барлауга багышлана. Фәндә билгеле булган чыганакларда төрле тарихи чорларга караган мифологик мәгълүмат бик аз сакланган, төп пантеонны, генеалогик һәм космогоник легендаларны чагылдырган карашлар шактый чәчелгән. Шуңа да карамастан Азия һуннары һәм Европа гуннарының мифологик карашларын, VI–VII гасырларга караган төрки каһанлыклар дәверендә Алтай, Көнбатыш Себер һәм Төньяк Монголия җирләрен иңләп яшәгән борынгы төркиләрнең дини-мифологик күзаллауларын чагылдырган чыганаклар аз түгел. Борынгы чорларга караган мифологик карашлар системасын күз алдына бастырыр өчен том әнә шул мәгълүматларга киңрәк тукталуга йөз тота. Биредә кытай, грек, әрмән авторларына караган чыганаклар, Орхон-Енисей язмалары, «Ырк битиг» («Юрау китабы»), күренекле галимнәрнең (Гумилёв Л.Н., Потапов Л.П., Кляшторный С.Г., Боротав П.Н. һ.б.) хезмәтләрендә урын алган генеалогик һәм космогоник легендалар, фәндә «борынгы төрки пантеон» дип исемләнгән катлаулы дини-мифологик системаны күз алдына китерергә ярдәм иткән язмалар урын алды.

«Әйләнә-тирәдәге төрле объект һәм күренешләрнең килеп чыгышы» дип исемләнгән бүлек дөньядагы төрле нәрсәләрнең барлыкка килүе белән бәйле текстлардан гыйбарәт. Билгеле булганча, мифологик эчтәлекле легенда текстларының борынгылары күк җисемнәре, кошлар, хайваннар, агачлар, үләннәр һәм башка төрле объект яки күренешләрнең барлыкка килүе һәм аларга хас үзенчәлекләрнең килеп чыгышы хакындагы кадими-архаик күзаллаулар белән танышырга мөмкинлек бирә. Мондый текстларның бер өлеше халыктан язып алынган хәлдә килеп җиткән, икенче бер өлеше исә тел осталары тарафыннан эшкәртелгән, өстәмә мотивлар һәм сәнгать чаралары белән баетылган. Бу бүлектә урын алган легендаларның аерым төр үсемлекләргә яки тереклек ияләренә хас булган сыйфатларны аңлату мотивына корылганнары («Җылан ни өчен адәм ите ашамый?», «Ярканат турында борынгыдан калган сүз», «Сөләйман пәйгамбәр һәм Ярканат», «Мәңге яшел чыршы» һ. б.), Казан шәһәренә урын сайлау белән бәйле булганнары («Жигули казак», «Сихерче кыз», «Яңа Казан», «Елан тавы», «Бараҗ нәселе» һ. б.) аеруча кызыклы.

«Беренче кешеләр һәм алып пәһлеваннар» дип аталган бүлектә татар халкының этногоник легендаларында, топонимик атамалар катламында, фольклор материалларында сакланган, бер-берсе белән көрәшкән борынгы алыпларга һәм зур гәүдәле беренче кешеләргә бәйле легендалар тасвир ителә. «Алып» сүзе үзе борынгы төркиләр, хәзерге татар, казакъ, үзбәк, хакас һ.б. телендә «батыр», «баһадир», «әзмәвер», «пәһлеван» дигәнне аңлата. Алыпларның тышкы кыяфәте турында

болгар-татарларның гарәп сәяхәтчеләре китаплары аша безнең көннәргә килеп җиткән легендалары нигезендә фикер йөртергә мөмкин. Ибн Фадлан китабында, Әбү Хәмид әл-Гарнати хезмәтендә, халык традицияләренә таянып, Идел пәһлеванының сурәте тудырыла. Археограф С.Г. Вахидов тарафыннан язып алынган Нух пәйгамбәргә бәйле легенда сюжеты да югарыда искә алынганнарга якын булып, болгарларны Алыпның уллары итеп билгели һәм Болгар тирәсендәге таучыкларның килеп чыгышын «Алып чабатасының тузаны кагылып ясалган» дип аңлата. Алыплар хакындагы сюжетлар Татарстан Республикасының Тау ягы, Казан арты, Кама аръягы районнарында шактый киң таралган. Барлыкка килүе ягыннан бик борынгы һәм төрле халыклар (башкорт, чуваш, удмурт, мордва һ.б.) иҗатында таралган мифлар белән бәйләнгән әлеге сюжетлар, гасырлар аша үтеп, безнең көннәргә кадәр килеп җиткәннәр, әле һаман да халык телендә калкулыкларны «алып чабатасын каккан җир» дип аңлату яшәп килә.

«Рух-ияләр» дип исемләнгән бүлектә йорт-каралты һәм табигать дөньясы белән бәйле рух-хуҗалар (йорт-каралты (йорт иясе, җорт хуҗасы, җорт бабай, өй анасы, Гамбәр ана, Дәсимә түти, кырсут, ызба иясе һ. б.), мал-туар (абзар иясе, хайван хуҗасы, Зәнки бабай, Мәхүбә түти һ. б.), су (су иясе, су анасы, су үгезе һ. б.), җир (җир анасы, җир атасы һ. б.), юл, ут хуҗалары) хакында текстлар тәкъдим ителсә, бишенче бүлектә («Түбән рухлар») традицион халык мәдәниятендә билгеле бер кагыйдәләрне үтәмәгән кешеләргә зыян китерүче затлар һәм рухлар хакындагы ышанулар системасы ачыклана. Биредә елан белән бәйле ышанулар (утлы елан, аждаһа, юха), ислам мифологиясенә кагылышлы җен, пәри, шайтан, үлгән кешеләргә мөнәсәбәтле барлыкка килгән утлы елан, өрәк, убыр, татар халык ышануларында киң таралыш тапкан бичура, шүрәле, албасты кебек персонажлар хакындагы текстлар урнаштырылды. Әлеге хезмәткә түбән мифология персонажлары белән очрашу мизгелен чагылдырган һәм татар фольклор фәнендә мифологик хикәятләр, сөйләкләр, хорафати хикәяләр дип аталган сюжетлы истәлекләр генә түгел, ә бәлки мифик зат турында төрле яклап мәгълүмат бирә торган, берничә жанрга караган текстлар да кертелү мифологиянең бу катламын тулысы белән күз алдына китерергә ярдәм итә.

«Дәвалау һәм саклау магиясе» дип аталган бүлек татар халкының мәдәниятендә чагылыш тапкан ырым текстларын, алар белән бәйле йола-гадәтләрне тасвир итә. Ырымнар да мифлар кебек үк табигать көчләренә тәэсир итү, көндәлек тормышны җайга салу, төрле рухларны кеше ихтыярына хезмәт иттерү максатыннан туганнар.

Томның «Халык ышанулары» дип аталган соңгы бүлеге табигать күренешләренә, кешенең көндәлек тормышына, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясына кагылышлы ышануларына багышланган. Ышанулар функциональ яктан сынамышларга якын тора, алар да нәрсәдер булачагын хәбәр итү, юрау өчен кулланылганнар. Әмма ышанулар практик тәҗрибәгә, табигать күренешләре белән бәйле күзәтүләргә түгел, ә бәлки мифологик фикерләү калыбына корылган.

Ышануларның эчтәлеге еш кына халыкның борынгы үткәненә, аның йола-ритуалларына барып тоташа. Халыкта «көтү килгәндә, алдан кызыл сыер килсә, көн кояшлы булыр, әгәр дә кара сыер килсә, болытлы булыр» дигән ышану яшәп килә. Бу фикерләү калыбы борынгы заманнарда, яңгыр теләгәндә – корбанга кара сыер, аяз һава теләгәндә кызыл сыер чалу гадәте белән бәйләнгән. Татар халкында «Эт тыны сөяк сындырыр» дигән кызыклы ышану да бар. Н.Исәнбәт аңа түбәндәгечә аңлатма бирә: «Элекке заманнарда тамакка кылчык йә сөяк утырганда, авызга эт тыны җибәргәннәр». Күргәнебезчә, ышанулар һәрвакыт халыкның дини-мифологик күзаллауларына барып тоташа, кешеләрнең магик тәҗрибәләре нигезендә барлыкка килгән фикри сөземтәләр рәвешен ала.

Шулай итеп, егерме биш томлыкның «Мифология» томы борынгы бабаларыбызның бүгенге көнгәчә сакланган мифологик күзаллаулар системасын кабат

тергезү максатыннан эшләнде. Тупланган материаллар күрсәткәнчә, һун дәвереннән алып, борыңгы төрки чорларны үтеп, ислам дине күзаллаулары белән кушылып, бүгенге көнгәчә килеп җиткән мифологик карашлар һәм ышанулар системасы халык авыз иҗатында үсеш алачак сюжетлы жанрларның нигезенә салына, гасырдан-гасырга күчә килгән сюжетларның мотивлар фондын билгели һәм лексик берәмлекләр, ышану кыйпылчыклары рәвешендә афористик иҗат төрләрендә үз урынын таба. Әлеге өлкәгә караган текстлар барысы бергә тупланып, мифологик күзаллаулар һәм ышануларны чагылдыру дәрәҗәсе ягыннан классификацияләнеп, татар халкының мифологик тәгълиматын бер система буларак күз алдына бастыру максатын күз алдында тотып тәкъдим ителделәр.

Шул ук егерме биш томлык «Татар халык иҗаты» басмасының «Йола фольклоры» томы исә – күптомлыкның гомуми принципларын саклап, татар халкының йола фольклорын тулы бер комплекс (хәрәкәт һәм сүз берлеге) итеп күз алдына бастыру юнәлешен алга куйган фәнни хезмәт. Әлеге өлкәгә караган материалларның жанр үзенчәлекләре ягыннан ырым, ышану, тыю (табу), йола җырлары, арбаулар, алкышлар, сыктаулар, келәүләр һ.б. төркемнәргә һәм йолаларны тасвирлаган текстларга бүленүен истә тотып, томда язмалар тематик классификация нигезендә урнаштырылды. Текстлар «Календарь йола иҗаты» һәм «Гаилә-көнкүреш йола иҗаты» дигән төп ике зур төркемгә бүленде, һәр төркем үз эченә берничә тематик бүлекне берләштерә һәм төрле йола жанры үрнәкләрен үз эченә ала.

Әлеге хезмәттә «Яз һәм җәй айларына бәйләнешле йола-бәйрәмнәр», «Көз һәм кыш айларына бәйләнешле йола-бәйрәмнәр» дип аталган тәүге бүлекләр татар халкының традицион мәдәнияте өчен характерлы булган календарь йолаларга багышланган. Календарь йолаларны еш кына аграр йолалар дип тә атыйлар, чөнки алар авыл хуҗалыгы эшчәнлеге – игенчелек һәм терлекчелек белән бәйле рәвештә формалашканнар һәм, ягына карап, ел да теге яки бу тәртиптә һәм якынча билгеле бер вакытта башкарыла торган йола-бәйрәмнәр комплексын тәшкил иткәннәр. Ел фасылларына бәйле рәвештә бу күп катлы комплекс фәндә дүрт чорга: язгы, җәйге, көзге һәм кышкы йола-бәйрәм цикллырына бүлеп карала. Биредә халкыбызның бик борыңгы мәҗүси чорларыннан ук килеп, әле дә югалып бетмәгән Нәүруз, Әмәл, боз озату, карга боткасы, Сабан туе, келәүләр, җыен, өмәләр, Нардуган һ.б. бәйрәм-йолалары белән таныша алабыз.

Томның «Гаилә-көнкүреш йола иҗаты» дип аталган икенче өлеше адәм баласының дөньяга килүе, гаилә корып гомер итүе һәм соңгы юлга әзерләнеп бакыйлыкка күчүе белән бәйле йола-гадәтләрне үз эченә ала.

«Бала туу йоласы» дип аталган бүлек йоланың төп структурасына бәйле рәвештә бала табу белән бәйле йола-гадәтләрне (кендек әбиләр белән бәйле гадәтләр, баланың беренче кырык көненә бәйле ышанулар, бәби мунчасы һ.б.) һәм бала туганнан соң аны кешелек дөньясына кабул итү, саклау һәм аңа багышланган мәҗлесләр үткәрүне (исем кушу, баланы котлап килү, баланы бишеккә салу, сөннәткә утырту һ.б.) тасвир итә. Гомумән, баланың дөньяга яралуы элек-электән зур бер сер буларак күзалланган. Кешелекнең бик борыңгы заманнарында, бу сергә әле аңлатма табылмаганда, баланың дөньяга килүенә мөнәсәбәтле бик күп ырымнар, йола-гадәтләр барлыкка килгән, һәм аларның шактые гаилә көнкүрешендә бүгенгәчә сакланып калган. Әлеге йолаларның нигезендә ана һәм баланың саулыгына, баланың киләчәк тормышына, аның уңышларына, гаилә коруына тәэсир итә дип саналган күзаллаулар ята.

«Туй йоласы» дип исемләнгән бүлек татар халкының традицион мәдәниятендә катлаулы структура барлыкка китергән туй йоласына багышлана, туйга әзерлек, туй мәҗлесе, туйдан соң үткәрелә торган йола-гадәтләрне һәм йола фольклорын үз эченә ала. Бүлек эчендә текстлар фәндә кабул ителгән классификация нигезендә татар халкының барлык этник төркемнәренә дә хас булган гомуми структурага нигезләнеп урнаштырылды: 1) туй алды (яучылау, ярәшү-килешү, кызны кияүгә чыгуга әзер-

ләү һ.б.); 2) туй үзе (никах, кияү егетен каршылау, килен төшерү, туй мәҗлесе һ.б.); 3) туй арты (киленне сынау, килен ягына кунакка бару, тел яшерү, бит ачу һ.б). Шул ук вакытта туй-никахлашу йолаларының эчтәлегендә татар халкының төрле этник төркемнәренең формалашу тарихы һәм яшәү үзенчәлекләренә бәйле рәвештә барлыкка килгән җирле үзенчәлекләр дә бар. Аларның барысын да бер том кысаларында күрсәтеп бетерү мөмкин түгел. Алай да, халкыбызга электән хас булып, хәзерге яшәештән төшеп калу хәлендә тора торган кыз елату, кияү типсәү, яр-яр җырлары, арбаулар кебек борынгы төрки традициягә нигезләнгән үзенчәлекле жанрлар, аларны халыкка кире кайтару максатыннан, хезмәттә урын алды. Шулай ук татар туеның бүгенге яшәешен билгеләгән һәм элекке традицияләрне саклаган кайбер җирле йола-гадәтләр дә томга кертелде. Тегe яки бу төбәктә генә сакланган үзенчәлекләрне күрсәтү татарлар яши торган башка якларда инде югалган яки кулланыштан чыккан гореф-гадәтләрне, текстларны торгызырга һәм күзалларга мөмкинлек бирә.

«Күмү һәм искә алу йолалары» дип исемләнгән бүлектә кеше яшәешендәге өченче этап – ахирәт дөньясына әзерләнү, мәрхүмне соңгы юлга озату һәм искә алу мәҗлесләре тасвир ителә. Күмү йолалары ул – билгеле бер эзлеклелектә үтәлә торган, дини күзаллаулар белән бәйле гамәлләр җыелмасы. Әлеге процессны бер-бер артлы үтәлә торган этапларга бүләргә мөмкин: 1) мәрхүмне күмәргә әзерләү (кешенең биологик үлеменнән алып күмелү вакытына кадәр); 2) күмү урынын һәм каберлекне әзерләү; 3) күмү процессы; 4) мәрхүм истәлегенә үткәрелә торган ритуаллар. Һәр халыкта мәет җирләүне дини йола буенча башкару бар. Ислам дине кабул ителгәннән алып бүгенгәчә татарлар үлгән кешене җирләүне һәм искә алуларны, нигездә, бертөрле итеп – ислам кушканча үткәрә, бу инде калыплашкан гадәт. Монда дини йолалар һәм халык традицияләре, борынгыдан килгән ышанулар бергә үрелеп бара һәм, бүгенге көннәрдә дә алар тотрыклы рәвештә сакланып киләләр.

«Солдатка озату йолалары» дип аталган бүлек традицион халык мәдәниятендә һәм халык ышануларында үз урынын билгәгән солдатка озату йолалары хакында. Биредә «рекрутчина» барлыкка килгән заманнардан ук безнең көннәргә килеп җиткән рекрут елатулары – «наз»лар , солдатка озату йоласының тәртибе (повестка алу, урам әйләнү, кунак булып йөрү, озату кичәсе, улын озатканда, әнисе тарафыннан башкарылган ырымнар, әлеге йола белән бәйле ышанулар, җыр текстлары һ.б.) тасвир ителә.

Югарыда әйтелгәннәрдән күренгәнчә, егерме биш томлыкның «Йола фольклоры» томына тупланган йола иҗаты үрнәкләре — гасырлар буена халыкның тормыш-көнкүрешен, күңел тынычлыгын, камил яшәешен тәэмин итеп килгән бай мирас. Адәм баласы йола белән туган, йола белән көн иткән, йола белән дөнья куйган. Баланың дөньяга килүенә бәйле гамәлләр, туйны җиренә җиткереп, нәсел-ыру каршында йөзгә кызыллык китермәслек итеп башкару, кешене соңгы юлга озату, хуҗалык эшләрен борынгыдан килгән тәҗрибәгә һәм табигатьтәге үзгәрешләргә яраклаштырып алып бару – болар барысы да махсус кануннар һәм йолалар ярдәмендә тәртипкә салынган.

Татар халык иҗатының борынгы чорлардан алып XXI гасыр башына кадәрге сулышын академик яктырта торган егерме биш томлыкның инде дөнья күреп, халкыбыз кулына барып ирешкән томнарында урын алган фольклор ядкярләре, асылда, татарларның борынгы төрки тамырларын, тарихи үткән юлын барлый, аның күпгасырлык борчу-мәшәкатьләрен, шатлык-куанычларын, дөньяны аңлау-аңлатудагы карашларын, тормыш-көнкүрешендәге үзенчәлекләрне чагылдыра, глобальләшү шартларында традицион мәдәниятнең һәм, гомумән, милләтнең үзбилгеләнүен тәэмин итүдә әһәмиятле роль башкара.

**Ләйлә ДӘҮЛӘТШИНА,**
*Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы*

# «САГЫШЛЫ МОҢНАР» ИЯСЕ РӘШИТ АГА, ЯКИ УЛ ГАИЛӘДӘ ҺӘММӘСЕ ШАГЫЙРЬ

*Журналист, шагыйрь Рәшит Гатауллинның тууына 85 ел*

Башкортстанда, Татарстанда үз вакытында танылып, мөселман дөньясын шаулатмаса да, биниһая үрләр яуламаса да, Рәшит Гатауллин үзеннән соң иҗат мәйданында якты эз калдырган үткен каләмле журналист, шагыйрь булып күңелләргә сеңеп калды. Чиксез дәрәҗәдә тыйнак, гадел, сабыр кеше иде ул.

Мин аның биографиясен артык бизәкләргә ашкынмыйм, әмма Гатауллиннарны әүвәл шагыйрьләр династиясе буларак билгеләп үтәсем килә. Әлбәттә, династия дигәндә, мин Татарстанның халык шагыйре, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, фикердәшем Рәдиф Гаташны (Гатауллин) күз уңымда тотам. Танышлыгыбыз аның «Казан утлары» журналында поэзия бүлеге мөдире булып (36 ел!) эшли башлаган елларына ук барып тоташа. Аның хакында әллә ни җәелеп сөйләмәсәм дә, кешелеклелеге, кечелеклелеге турында бер кәлимә сүз әйтми ярамас. Чөнки миңа Татарстанда яшәгән данлыклы якташ шәхесләр хакында ике китаплык материал туплау өчен берничә ел Бишбүләк–Казан юлларын таптау форсаты чыкты. Шул вакытларда кайчакны Рәдиф абый белән Рима апаларның фатирында да куна калырга туры килгән чаклар булгалады. Еллар үтеп, зур кыенлыклар кичереп, ниһаять, 2018 елда, Казанда, ике кисәктән торган китабымның исем туен билгеләп, иҗат кичәмне үткәрү насыйп булды. Шунда китабым каһарманнарының берсе, якташым Рәдиф Кәшфи улының зур игътибарын, ярдәмен тойдым. Ул, Рима ханым урын-җир өстендә ятуга да карамастан, хәстәрен күреп, җаен табып, бәйрәмемне ямьләде. Хәтта матди ярдәменнән дә ташламады. Бүләкләрен тапшырганда, ялкынланып, шигырьләрен дә сөйләде. Әйе, халык шагыйре Әнгам Атнабаев юкка гына «Кешегә бер җылы сүз, наз җитә», – димәгән, күрәсең. Бала чагыннан ятимлек җилләре башыннан сыйпаган, «нужа калачын» шактый кимергән, әмма олы дәрәҗәләргә ирешкән Рәдиф ага – якташлыкның, дуслыкның, рухи кыйммәтләрнең кадерен белүче әдип, якташларына һәрьяклап ярдәм кулы сузарга әзер олуг шәхесебез ул. Без аның белән әле дә элемтәдә. Күптән түгел авылдашларым аша үзенең 80 яшьлек юбилеена багышлап нәшер ителгән затлы китап-альбомын юллап, кабат сөендерде. Минем шәхси китапханәмдә мондый зәвыклы басманың моңарчы булганы юк иде.

Династиягә килгәндә, тагын берсе – оялчан Ләйсән Гатауллина (Якупова). Заманында, без, «Кызыл таң» гәзите редакциясендә аның белән дә бергә эшләдек. Ул да журналист, үзенчәлекле шагыйрә. Әнисе Нәҗибә Әминева (Гатаулллина) – шулай ук, шагыйрә буларак, ике тугандаш республикага да билгеле шәхес. Заманында укытучы, мәктәп директоры булып эшләгән тормыш иптәше Рәфит тә яшь чагында каләм тибрәткән, үзе өчен генә шигырьләр язган.

Гатауллиннар династиясе тумышлары белән Кушнаренко районыннан. Бу бәрәкәтле, изге җирдә шулай ук Мөхәммәт Сабиров, Рәшит Мусин кебек күренекле дәүләт эшлеклеләре, танылган шагыйрь Әзһәр Кәшфуллин һәм башка данлыклы шәхесләр дөньяга килгән. Бу төбәктә Марс исемле авыл бар. Рәшит ага Гатауллин әнә шуннан,



*Өч туган: Рәшит, Рәдиф, Рәфит иске йорт болдырында. Марс авылы, 1966 ел.*

шушы изге туфрактан була инде. Менә шунда игезәкләр Рәшит белән Рәфит «канат чыгарган». Ничек кенә авыр булмасын, еллар үткәч, алар икесе дә, чәмләнеп, университетта укырга, хәтта каләм тибрәтергә – шигырь язарга форсат таба. Рәфитнең, Рәшитнең, шулай ук Рәдифнең дә балалык еллары сугыш чорына туры килә. Авыз тутырып икмәк тә ашый алмыйлар, «әтекәй» дигән кадерле сүзне әйтергә, аның кочагында рәхәтләнеп иркәләнергә дә, түшәмдәге «тәрбия» чыбыгын татырга да туры килми аларга. Чөнки әтиләре Кәшфи ага Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә үк батырларча һәлак була. Әниләре Сәвия апа белән бергә аларга да бик яшьтән «уфалла арбасы»н төбенә җигелеп тартырга туры килә. Сәвия апа өч баланы берүзе үстерә, белем-тәрбия бирә. Куанычлысы шул: арыслландай өч егет үз алларына изге максат куеп, югары уку йортларын тәмамлый, ике тугандаш республикада дан-шөһрәт казана. Газиз балалары өчен җан атып, йөрәк җылысын ихлас өләшкән мәрхәмәтле әни кеше алар белән чиксез горурлангандыр да, үзләренә сокланганды р да.

90 нчы еллар уртасында без Рәшит ага белән «Кызыл таң» республика гәзитенең хатлар бүлегендә бергә эшләдек. Мин – мөдир, ул – әдәби хезмәткәр булды. Тыныч холыклы, җигелеп, оператив эшли торган абзый иде ул. Уртак телне тиз таптык. Дөнья булгач, һәркемнең үтенече дә килеп чыга, бигрәк тә атна азагында: авылга кайтырга, яисә берәр шәхси чарага барырга эштән иртәрәк «шылу» зарурлыгы да килеп туа. Мондый чакта Рәшит ага: «Әнвәр туган, кушылганнарны эшләдем, бүген эштән иртәрәк китәргә иде бит, мөмкин булса», – дияр иде. Әлбәттә, намуслы хезмәткәрнең үтенеченә каршы килеп булмый.

Иҗат кешесе – шагыйрь буларак, Рәшит Гатауллин шактый еллар әдәбият, сәнгать бүлекләрендә дә хезмәт куйды. Шигырьләре исә, күләмле сәхифәләр булып, «Кызыл таң» битләрендә дөнья күрде, газета укучыларыбыз аларны бик яратты, редакциягә җылы эчтәлекле кайтаваз хатлары килеп торды. Аның гади, халыкчан итеп язган шигырьләре йотлыгып укыла иде.

Баксаң, ул студент елларында ук шигырьләр язган, БДУда укыганда, төркем старостасы да булган икән. Бу хакта аның белән бергә укыган, бүген Бишбүләк районының Кыңгыр-Мәнәвез авылында яшәүче педагогик хезмәт ветераны, укытучыбыз Миңнур Рәхмәтулла кызы Ханнанова (Дәүләтшина) да сагынып искә ала. Булачак танылган журналист-галим, «Кызыл таң» гәзитенең баш мөхәррире Муса Мөлеков, шулай ук Равил Карамов, Рәшит Сабитов кебек билгеле иҗат әһелләренең сабакташы булуы хакында горурланып сөйли.

Заманында Кушнаренко, Миякә районнары мәктәпләрендә директор вазифаларында эшләгән Рәшит Гатауллинны әдәбият сөючеләр, гадәттә, шагыйрь буларак белә. Аның шигырьләре матбугатта 60 нчы еллар уртасында күренә башлый. Ә инде 1968 елда алар Казанда нәшер ителгән «Беренче карлыгачлар» исемле коллектив җыентыкта

дөнья күрә. Ике республика матбугатларында да шигырьләре еш басылуы хәлиткеч роль уйнаган булса кирәк, 1993 елда аны Татарстан Язучылар берлегенә кабул итәләр. Берлеккә алынгач та, Рәшит Гатауллин актив иҗат итә, хәтта дәваханәдә ятканда да язуын туктатмый. Рәшит ага каты авырып киткәч, без, журналист Фәрит Фәтхуллин белән икәү, аның фатирына барып, хәлен белеп йөрдек. Ул без килгәнгә сабыйлар сыман сөенә иде. Ни үкенеч, 2000 елның зәмһәрир салкын гыйнварында ул арабыздан мәңгелеккә китеп барды.

Тыйнак талант иясенең үзе исән чагында китабын күрә алмавы гына үкенечле. Хәтер сандыгында тәмам бикләнмичә, бәгырьләрдән җуелмыйча, еллар иләгендә шактый иләнеп, бик соңлап булса да, аның да «Сагышлы моңнар»ы дөнья күрде. 2008 елда авторның бертуганары Рәфит белән Рәдиф Гатауллиннар, Рәшит абыйларының шигырьләрен сайлап, төзеп, ниһаять, Казанда китап итеп бастырып чыгаруга иреште. Ә 2020 елда шагыйрьнең иҗаты бертуганнары тарафыннан тагын да тулыландырылып, «Кил, сөйләшик, дөнья!» атлы яңа шигырь җыентыгы булып, укучылары хозурына иреште. Соңгысында шагыйрьнең иҗаты вә шәхесе хакында этрафлы мәкаләләр дә урын алды. Аларның авторлары – ТР Фәннәр академиясе академигы Дания Заһидуллина, якташ каләмдәшләреннән исә, инде үзе дә бакыйлыкка күчкән Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин, шулай ук Рәшит Сабитов белән Илдус Фазлетдинов. Әлеге җыйнак кына, тыйнак кына, күңелләрне тетрәтерлек, эчкерсез шигырьләр китабы һәммәбезне уйланырга, мәрхүм каләмдәшебез белән бергә сагышланырга мәҗбүр итә. Әлеге җыентыктагы «Сүрелмәс, сүнмәстер инде», «Ничек чыдармын?!», «Ярый әле шунда туганбыз», «Кичер, әнкәй!», «Мин озатам сине», «Шул татар баласымын», «Уфа–Казан», «Ни җитми?», «Үпкәләмим» кебек шигырьләре, мөгаен, берәүне дә битараф калдыра алмый торгандыр.


Әйтергә кирәк, Рәшит ага туган туфрак җылысын тоеп, гомеренең соңгы көннәренә кадәр сагышлы моңнарда бөтерелеп яшәде, йөрәктән йөрәккә җитә алырлык, халыкчан шигырь юллары язды:

*Сагышларым, сагынуларым җыеп,*
*Бер җыр итеп калдыралсам иде.*
*Януларым, ярсуларым җыеп,*
*Йөрәкләрне яндыралсам иде...*

**Әнвәр СӨЛӘЙМАНОВ,**
*Фатих Кәрим, Динис Бүләков исемендәге*
*әдәби премияләр лауреаты,*
*Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре*

*Зәки Зәйнуллинның тууына – 90 ел*

# КАЛӘМЕНДӘ АНЫҢ – АТОМ КӨЧЕ



Язучы, галим һәм җәмәгать эшлеклесе, Һади Атласи һәм Гаяз Исхакый исемендәге премияләр лауреаты Зәки Лотфулла улы Зәйнуллинның тууына – 90 ел. Ул 1933 елның 10 июлендә Башкортстанның Стәрлебаш авылында дөньяга килә. 1952 елда гаскәри хезмәткә алынып, Иркутск шәһәрендә хәрби авиация-техника училищесында укый, аннары Ленинград хәрби округы авиация частьләрендә хезмәт итә. 1958 елда Рига Югары хәрби ракета инженерлары училищесына укырга керә һәм 1963 елда аны уңышлы тәмамлап, гаскәри базаларда атом, водород бомбаларын эксплуатацияләү буенча хәрби инженер була. Бер үк вакытта ул ракета техникасына бәйле фәнни тикшеренүләр алып бара, диссертация яклый һәм хәрби-техник фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала.

1970–1978 елларда З.Зәйнуллин СССР Стратегик ракета гаскәрләренең Рига һәм Серпухов (Мәскәү өлкәсе) шәһәрләрендә урнашкан хәрби лабораторияләрендә өлкән фәнни хезмәткәр булып эшли. 1978–1988 елларда – Рига Югары хәрби ракета-инженерлары училищесында укытучы, өлкән укытучы һәм, 1985 елда докторлык диссертациясен яклаганнан соң, профессор. 1988 елда отставкага чыга һәм Казанга күченеп кайта. Биредә иҗтимагый-сәяси активлык белән беррәттән З.Зәйнуллинның әдәби иҗат өлкәсендәге таланты да ачылып китә.

Туксанынчы еллардан башлап, төрле журналларда һәм газета битләрендә язучының туган ягы кешеләренең самими образларын, гыйбрәтле язмышларын гәүдәләндергән, авторның балачак хатирәләренә киң урын бирелеп, сугыш алды, сугыш чоры, сугыштан соңгы авылдагы кырыс тормыш күренешләрен киң яктырткан һәм фронттагы канлы сугыш эпизодларын да үз эченә алган «Галимулла бабай күгәрченнәре» (1990), «Сугыш алды малайлары» (1991), «Каршы таулар», «Урам» («Үрләр аша» повесте белән башланган трилогиянең икенче, өченче кисәкләре, 1993), «Ата нигезе» (1997), «Эстәрлебаш фетнәсе» (2002), «Арбалы үгез» (2003), «Ат классы» (2004) повестьлары, маҗара жанрында язылган «Ат каракլары» романы (1996) белән «Агыйделнең аръягында» исемле тарихи роман-кыйсса (1998) һәм дистәләгән хикәяләре дөнья күрә.

Татарстан радиосы әдипнең иҗатына һәрвакыт зур игътибар биреп килде. Әсәрләре нигезендә легендар милләттәшебез, атаклы хәрби җитәкче Алексей Антоновка багышланган «Ир егетләр», татар халкының каһарман улы Пётр Гаврилов турындагы «Майор Гаврилов», язучы Кави Нәҗми, аның хатыны Сәрвәр Әдһәмованың фаҗигале язмышын бәян иткән «Каһәрләнгән язмышлар» дигән моноспектакльләр әзерләнде. «Гобәй Пәрау бәрәнгесе», «Яшәдек, яшьнәдек», «Сөннәт белән кендек» кебек хикәяләрен тыңлаучыларыбыз эфирда һәрвакыт көтеп алды.

Журнал укучылар игътибарына «Майор Гаврилов» моноспектакле тәкъдим ителә. Күренекле артистыбыз Әзһәр Шакиров укуындагы бу әсәрдә батыр милләттәшебезнең сикәлтәле тормыш юлы да, эчке кичерешләре дә, тиңсез батырлыгының зурлыгы, әһәмияте дә ачык чагылыш таба.

Әйдәгез, әдәбиятыбызга яңа темалар, яңа каһарманнар алып килгән олпат язучыны хөрмәт белән искә алып тыңлыйк.

# ТОРМЫШТА ДА, СӘХНӘДӘ ДӘ ЗАТЛЫ БУЛДЫ



*Рөстәм Нәбиуллин фотосы.*

Шушы елның март аенда легендар җырчы, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Эмиль Җәләлетдинов арабыздан мәңгелеккә китеп барды. Быел без аның туган көнен инде үзеннән башка гына билгеләп үтәбез – 2 июль көнне тууына 90 ел тулды.

Булачак җырчы 1933 елда Үзбәкстанның Сәмәрканд шәһәрендә туган. 1954 елда шунда ук музыка училищесын тәмамлый. Армия сафларында хезмәт итеп кайткач, 1957 елда Ташкент дәүләт консерваториясенең вокал факультетына укырга керә. Тагын ике елдан балачактан ук күңелендә бөреләнгән хыялын тормышка ашыра. Җаны да, каны да Татарстанга тарта. 1959 елда татар халкының нурлы мәркәзе Казанга кайтып, консерваториядә укуын дәвам иттерә. Аны 1962 елда тәмамлап, Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенә билгеләнә, 1992 елга кадәр шушында, Опера һәм камера музыкасы бүлегендә эшли.

Э.Җәләлетдинов, мөгаен, иң бай репертуарлы җырчыларның берсе булгандыр. Аның иҗатында Рөстәм Яхин, Алмаз Монасыйпов, Фәрит Яруллин, Александр Ключарёв, Нәҗип Җиһанов, Заһид Хәбибуллин, Җәүдәт Фәйзи, Мансур Мозаффаров, Ренат Еникеев, Илдус Якупов кебек инде классик дип бәя бирерлек композиторларыбызның әсәрләре аерым бер урын алып тора.

Татарстан радиосы фондында Эмиль Җәләлетдиновның 145 язмасы саклана. Алар журнал укучыларга таныш, якын җырлар дип уйлыйбыз. Әйтик, «Ак дулкыннар» (Ренат Еникеев музыкасы, Мәхмүт Хөсәен шигыре); «Аккошлар» (Фасил Әхмәтов, Равил Фәйзуллин); «Бер генә сүз» (Рөстәм Яхин, Ренат Харис); «Бер тауда ун чишмә» (Әгъзам Фәттах, Сибгат Хәким); «Казан утлары» (Мирсәет Яруллин, Эльс Гадел) җырлары шулай ук радио концертларында еш яңгырый.

Эмиль Җәләлетдинов зур күләмле жанрларга да мөрәҗәгать итә алырлык әзерлекле җырчы иде. Композитор Бату Мөлеков һәм шагыйрь Ренат Харис иҗат иткән «Казан» ораториясе, Алмаз Монасыйповның «Тукай ритмнары» дип исемләнгән вокаль-симфоник әсәре, Илһам Байтирәкнең Муса Җәлил шигырьләренә язган «Кадерле минутлар» вокаль циклы аның башкаруында ел саен зәвыклы тыңлаучыларыбыз игътибарына тәкъдим ителә.

Гомеренең соңгы елларында Эмиль ага Татарстан радиосы белән аеруча якынаеп китте. Моңа аның Тукайга мәхәббәте сәбәпче иде. Чыннан да ул сөекле шагыйребезнең иҗатын бөтен барлыгы белән бирелеп өйрәнде, баштарак студиягә килеп, аерым шигырьләрен яздырса, моннан берничә ел элек Габдулла Тукайның туган көне алдыннан шагыйрьнең шигырьләреннән һәм аларга җырлана торган җырлардан төзелгән тулы бер әдәби-музыкаль композиция төзеп алып килде. Журнал укучылар игътибарына без аның нәкъ әнә шул язмасын тәкъдим итәбез.

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире*
**Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

## ПУШКИННЫҢ ТУУЫНА – 224 ЕЛ

Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов Рус теле көне һәм Пушкинның тууына 224 ел тулу белән тәбрик итте. Ул көнне М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры янындагы Пушкин һәйкәле каршында тантана булып узды. ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев һәм ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре, әдәбият, сәнгать әһелләре, галимнәр һәйкәлгә чәчәкләр салдылар. Тантанада бөек рус шагыйренең шигырьләре, аның сүзләренә язылган романслар яңгырады.

Пушкинның туган көне уңаеннан Шигырь бәйрәме Чаллы шәһәренең Үзәк китапханәсендә дә булды.

## КАЗАНДА – САБАНТУЙ

Казанда өч мәйданда – Тынычлык, Дәрвишләр бистәләрендәге каенлыкларда, Аккош күле буенда Сабантуйлар булып узды. Төп бәйрәм Тынычлык бистәсе янындагы каенлыкта үткәрелде. Мәйданда халкыбыз тарихына бәйле риваять (сценарий авторы Рүзәл Мөхәммәтшин, режиссёры Айдар Җаббаров) күрсәтелде. Атларга атланган изге ияләр Идел, Чулман буйларын кара көчләрдән коткардылар. Үзәктә – халкыбызның рухи башлыгы булып торган Ак Ана. Аннары яшел чирәмдә үгезләр белән беренче бураznaны сызу, җир куенына беренче орлыкларны салу, яз, җәй, көз кызларының мәйдан тутырып биюләре. Бәйрәмгә килгән халыкны Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Саха (Якутия) хөкүмәте Рәисе Андрей Тарасенко, Казан мэры Илсур Метшин сәламләделәр. Милли көрәштә Сабантуйның баш батыры булып Лениз Абдуллин калды.

## ГАИЛӘ КИТАПХАНӘСЕ

Казанның Галимҗан Баруди урамында төзекләндерүдән соң 27 нче китапханә ачылды. Аны ачу тантанасына Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов килде. Заманча таләпләргә туры китереп яңартылган китап йорты «Гаилә китапханәсе» дип атала. Техник әсбаплар белән махсус җиһазландырылган бүлмәләрдә аудиокитап яздыру, пластинкалардан тарихи язмалар тыңлау, видеога төшерү мөмкинлекләре бар. Китапханәнең төп максаты – гаиләләрне китап укырга җәлеп итү. «Бөтен гаилә белән китапханәгә» программасы кысаларында фондларга иректе керү мөмкинлеге дә бирелә. Фондта 50 меңнән артык китап бар.

Китапханәне ачу тантанасында ТР Рәисе Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, Казан мэры Илсур Метшин, ТР мәдәният министры Ирада Әюпова, ТР яшьләр эшләре министры Ринат Садыйков һ.б. катнашты.

## УФАДА ХАЛЫКАРА КИТАП БӘЙРӘМЕ

Уфа шәһәрендә халыкара «Китап-бәйрәм» ярминкәсе үтте. Әлеге чарада 6 илдән, Россиянең 206 төбәгеннән китап чыгару һәм сату белән бәйле 206 оешма катнашты. Өч көн дәвамында бәйрәмгә 162 549 кеше килгән, 52 мең китап сатылган.

«ТАТМЕДИА» АҖ бу чарага «Казан утлары» китапханәсе» сериясендә нәшер ителгән кесә китапларын, тәбрикләмәләрне, «Салават күпере» журналы редакциясе чыгарган продукцияне тәкъдим итте.

«Китап-бәйрәм» чарасы кысаларында Уфаның «Нур» татар Дәүләт театрында тамашачылар белән очрашу узды. Тамашачылар татар китаплары, тәбрикләмәләр ассортименты белән дә танышты, «Казан утлары» журналы баш мөхәррире, язучы Рөстәм Галиуллин һәм Башкортстан Язучылар берлеге рәисе, язучы Айгиз Баймөхәммәтов белән әңгәмә корды. Ярминкә чатырында Рөстәм Галиуллин китап укучылар белән очрашуда катнашты. Халыкара «Китап-бәйрәм» Уфада ел саен май аеның соңгы атнасында үтәчәк.

## КАЗАН – РОССИЯ КИТАПХАНӘЛӘРЕ БАШКАЛАСЫ

Китапханәчеләрнең Мурманскида үткән Бөтенроссия конкурсында «Казан – 2024 елда Россия китапханәләре башкаласы» дип игълан ителде. Мондый статусны раслаган диплом ТР мәдәният министры Ирада Әюповага тапшырылды.

## «БӘЛЛҮР КАЛӘМ – 2023»

Казандагы «Сәйдәш» мәдәният үзәгендә «Бәллүр каләм – 2023» журналистика һәм масса-медиа өлкәсендәге республика конкурсында җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы булып узды.

Конкурс 13 номинациядә үткәрелде. Җиңүчеләрне ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов, «ТАТМЕДИА» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев, Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Илшат Әминов һ.б. котлады. Котлаучылар арасында Луганскидан килгән кунаклар да бар иде. «Республика Татарстан» газетасының баш мөхәррире Александр Латышев Гран-прига ия булды. Бүләкне – «Лада Гранта» автомобиле ачкычын аңа ТР Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева тапшырды. «Казан утлары» журналының баш мөхәррир урынбасары Вакыйф Нуриев «Журналистикага тугрылык» номинациясендә җиңүче дип табылды. «ТАТМЕДИА» агентлыгының 20 еллык юбилее тантанасына да әверелгән бу бәйрәмдә ТР Рәисе Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров катнашты һәм чыгыш ясады.

### ЗӨЛФӘТ ХӘКИМ – ЕРШОВ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЫ

«Российский писатель» интернет-порталында балалар һәм яшүсмерләр өчен әсәрләргә П.П.Ершов исемендәге XVII халыкара әдәби премия лауреатлары игълан ителде. Алар арасында Казаннан Татарстанның халык язучысы Зөлфәт Хәким дә бар. Ул бу олы бүләккә «Легенды Туган Батыра» әсәре өчен лаек булды. Бүләк бөек әкиятченең туган ягында – Төмән өлкәсенең Ишим шәһәрендә тапшырыла.

### ЯЗУЧЫЛАР – МИҢГӘРДӘ

Татарстан Язучылар берлегенең унике әгъзасы ун көн Саба районы Миңгәр авылында торып кайтты. Алар монда ял итте, иҗат белән шөгыльләнде, укучылар белән очрашты. Каләм ияләренә мондый мөмкинлекне «Татарстанның газлаштыру, энергия саклау технологияләре һәм инженерлык үсеше» дәүләт учреждениесе генераль директоры Җәүдәт Миңнәхмәтов тудырган. Соңгы көнне язучылар Җәүдәт Миңнәхмәтов, Саба районы башлыгы Рәис Миңнеханов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла белән очрашып, монда узган ун көнгә йомгак ясадылар.

### УКМАСЫЙ КАБЕРЕНӘ ТАШ КУЕЛДЫ

Казанның Яңа татар бистәсе зиратында Г.Тукайның дусты, замандашы, шагыйрь, дин әһеле Миргазиз Укмасый каберенә таш куелды, чардуган урнаштырылды. Әлеге игелекле эшнең башында шагыйрьнең авылдашы, тележурналист, Казан кооператив институтының Татар мәдәнияте үзәге җитәкчесе Флюра Абдуллина торды. Чарада Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, ТР Рәисе каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм фондының башкарма директоры Нурия Һашимова, әдәбият галиме Зөфәр Рәмиев, Укмасыйның якташлары – Балык Бистәсе районы башлыгы урынбасары Фирдания Әхмәтҗанова, шагыйрьләр Вазыйх Фатыйхов, Рәсимә Гарифуллина, Татарстанның атказанган укытучысы Рамазан Кәбиров, Бәтке җирле үзидарә башлыгы урынбасары Рәис Нигъмәтуллин, Кече Укмас авылы клубы мөдире Зөлфирә Гәрәева, сәнгать җитәкчесе Резидә Сабирова, Балык Бистәсе имамы Хәмит хәзрәт Идрисов катнашты. Шагыйрь рухына дога багышланды.

### ӘДИПНЕ ИСКӘ АЛДЫЛАР

Әдәбият тәнкыйтьчесе, шагыйрь, нашир, педагог, җәмәгать эшлеклесе, М.Җәлил, Г.Державин исемендәге республика премияләре лауреаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Мөдәррис Вәлиевнең тууына 70 ел тулу уңаеннан каләм әһелләре, җәмәгатьчелек вәкилләре, туганнары Казанның Киндерле зиратында әдипне искә алды. Аның рухына дога багышланды.

### МАМАДЫШКА СӘФӘР

«Казан утлары» журналы редакциясе хезмәткәрләре Мамадыш районына сәфәр кылды. Алар Бөек Ватан сугышы корбаннарын искә алу мәрәсимендә катнашты, промышленность зонасында, Үзәк китапханәнең яңа бинасында, музейда булды, Җөри авылында керәшен халкының милли гореф-гадәтләре белән танышты, Питрау Сабан туе мәйданын, Нократ буендагы ял итү урыннарын, комлыкны карады, Урта Кирмән авылы янындагы изге чишмәләрнең суын авыз итте, соңгы елларда райондагы матур үзгәрешләрне күреп сокланды. Редакция коллективын Мамадыш муниципаль районы башлыгы Анатолий Иванов кабул итте. Безгә шундый кызыклы сәфәр, мәгълүматларга бай экскурсияләр оештырулары, кунак иткәннәре өчен район хакимиятенә, мамадышлыларга рәхмәт!

*Сәхифәне* Вакыйф НУРИЕВ *әзерләде.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман-эссе Р.КУРБАНА «Лишние люди», повесть З.ТИМЕРГАЛИЕВА «Вечное движение», рассказ Т.ГАЛИУЛЛИНА «Плов с комочками»; стихи З.МАНСУРОВА, Д.НАГИМ, Р.ГАРИФУЛЛИНОЙ.*
*«Новые имена»: стихи З.РАМАЗАНОВОЙ с предисловием Ф.Гилязова.*
*«Литературный конкурс «Учитель – прекрасный человек на земле!»: повесть С.АХМЕТЗЯНОВОЙ «Тоска любви».*
*«Литература родственных народов»: стихи А.ГАЗАЕВОЙ. Перевод с балкарского языка Р.Курбана.*
*«Литературная критика»: статья Ф.ГАЛИМУЛЛИНА, посвящённая 85-летию Т.Галиуллина.*
*«Публицистика»: документальная повесть Р.АХУНЗЯНОВОЙ «Память Суббуха Рафикова»*
*«Наука»: статья Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ.*
*Фотоархив, посвящённый 90-летию М.Шабаева.*
*«Обзор книги»: статья Л.ДАВЛЕТШИНОЙ.*
*«Память»: статья А.СУЛЕЙМАНОВА, посвящённая 85-летию Р.ГАТАУЛЛИНА.*
*«Бесценные голоса»: статьи к 90-летию З.ЗАЙНУЛЛИНА и 90-летию Э.ЗАЛЯЛЬДИНОВА. Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: Чёрное озеро. Фото И.АБРАМОВОЙ; радиожурналист Насим АКМАЛ.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and Poetry»: novel-essay by R.KURBAN «Unwanted People», story by Z.TIMERGALIEV «Eternal Motion», story by T.GALIULLIN «Pilaf with lumps»; poems by Z.MANSUROV, D.NAGIM, R.GARIFULLINA.*
*«New Names»: poems by Z.RAMAZANOVA with a preface by F.Gilyazov.*
*Literary contest «Teacher is a Wonderful Person on Earth!»: story by S.AKHMETZYANOVA «Longing of love».*
*«Literature of Kindred Peoples»: poems by A.GAZAEVA. Translation from the Balkar language by R.Kurban.*
*«Literary criticism»: article by F.GALIMULLIN dedicated to the 85th anniversary of T.Galiullin.*
*«Publicism»: documentary story by R.AKHUNZYANOVA «Memory of Subbukh Rafikov»*
*«Science»: article by D.ZAGIDULLINA.*
*Photo archive dedicated to the 90th anniversary of M.Shabaev.*
*«Review of the book»: article by L.DAVLETSCHINA.*
*«Memory»: article by A.SULEYMANOV dedicated to the 85th anniversary of R.GATAULLIN.*
*«Priceless voices»: articles for the 90th anniversary of Z.ZAYNULLIN and the 90th anniversary of E.ZALYALDINOV.*
*The rubric is led by N.AKMAL.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: Black Lake. Photo by I.ABRAMOVA; radio journalist Nasim AKMAL.*

---

*Тышлыкның беренче битендә:* Черек күл.
*И.Абрамова фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* радиожурналист Нәсим Акмал.